ISSN 0206-4189

# Казан утлары

12.2005




*1000нче санны каршылап*

# ҮТКӘН ЕЛЛАР СӘХИФӘСЕ

**Үткән гасырның 30 нчы еллар башындагы әдәби мохит шактый чуар һәм катлаулы. Әдәбиятта төрле сәяси караш, төрле ысул тарафдарлары хөкем сөргән чор. Совет язучыларының бердәм оешмасы—СССР Язучылар союзы төзелер алдындагы (ул 1934 елда төзелә) иҗтимагый халәт, әдәби хәрәкәт... Ул елларда татар язучыларының төп ике басмасы—“Атака” һәм “Яңалиф” журналлары булган.**

## “Атака”




1930 елдан соң “Безнең юл”ның дәвамы булып “Атака” (Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе—ТАПП органы) һәм “Яңалиф” (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының журналы) чыга.

1930 елның июль аенда “Атака” журналының (редакторы Г. Гали) беренче саны дөнья күрә. Ул айга ике мәртәбә чыга торган әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы булып тәкъдим ителә. ТАПП идарәсе һәм “Атака” журналы редколлегиясе укучыларга мөрәҗәгать итеп, болай яза: “...“Атака”ның төп бурычы партиянең матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә торган сәясәтен тормышка үткәрү өчен, пролетариат әдәбиятының гегемониясе өчен көрәшкә кайтып кала”.

## “Яңалиф”




ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Секретариатының 1930 елның 20 июнендә булган киңәшмәсе кабул иткән карарда мондый юллар бар: “...культура-политик һәм гыйльми мәсьәләләрне киңрәк яктыртырга, шулай ук бу журналда татар совет язучыларын тагын да киңрәк төстә катнашырга җәлеп итәргә. Бу журнал өчен тарихи-революцион исем буларак, “Яңалиф” исемен сакларга.”...

Июль аенда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының айлык әдәбият, сәясәт, сәнгать һәм тәнкыйть журналы “Яңалиф”нең (редакторы Фатих Сәйфи-Казанлы) беренче саны дөнья күрә.

Журналның үз йөзе, төзелеше, рубрикалар системасы оеша. “Яңалиф” түбәндәге сәхифәләрдән тора: сәясәт, матур әдәбият, әдәбиятны өйрәнү, сәнгать, культура-көнкүреш, библиография, тәнкыйть һәм хроника.

**Бу журналлар 1930-32 елларда 1500-2200 данә белән дөнья күргән.**

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

12

(998)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Караболак. *Роман.* .......... 5
Айдар ХӘЛИМ. Алтмышынчы еллар – яңа сулыш. *Шигырьләр.* .......... 75
Фәрит ЯХИН. Бакыр бозау артыннан. *Хикәя.* .......... 82
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Озата барам гомер кояшымны... *Шигырьләр.* .......... 98
ИДЕЛБИКӘ. Дөнья авазлары. *Шигырьләр.* .......... 111

**ГУРИЙ ТАВЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Мәгъсум ХУЖИН. Сары яфраклар коелганда. .......... 104
Гурий ТАВЛИН. Үги ана. *Хикәя.* .......... 106

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әгъдәс БОРҺАНОВ. Ясалма дәүләт, ялган кыйммәтләр, тамырсыз халык һ. б. турында. .......... 114

**ДИСКУССИЯ, "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Зәет МИРЗАНУРОВ. Тозсызны күзсез дә күрә. .......... 123

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фатих УРМАНЧЕ. Шигъри осталык серләре. .......... 131

**ФӘН**

Сәвия МИХАЙЛОВА, Рөстәм ЦИУНЧУК. Башкалабыз Казан. .......... 145
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 155
Нияз НӘГЫЙМОВ. Тәрҗемәдә беренче тәҗрибәләр. .......... 173
Өмәр ӨЗҖАН. Исмәгыйль Гаспралы турында Казанда чыккан яңа басма. .......... 176

"Татар энциклопедиясе" битләреннән. .......... 170

**ХӘТЕР**

Хисамеддин ТОГАЧ. "Бер буынның драмасы" әсәреннән өзек. .......... 159

**ЮМОР-САТИРА**

Марат ЗАКИР. Хикәяләр. .......... 180

Мең санның бер чаткысы. .......... 74, 97, 110, 122
Котлыйбыз! .......... 182
Безнең календарь. .......... 183
"Казан утлары" архивыннан. .......... 178
2005 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. .......... 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Ф. БАЙРАМОВОЙ "Карабулак" (продолжение); рассказ Ф. ЯХИНА "За медным теленком"; Стихи А. ХАЛИМА, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, ИДЕЛБИКИ.
"К-80 летию Г. Тавлина": статья М. ХУЗИНА и рассказ автора "Мачеха".
"Публицистика": статья А. БУРГАНОВА "Искуственное государство, ложные ценности и народ без корней".
"Дискуссия": "Герой нашего времени": статья З. МИРЗАНУРОВА.
"Литературная критика": статья Ф. УРМАНЧЕ "Мастерство в поэзии".
"Наука": статья С. МИХАЙЛОВОЙ, Р. ЦИУНЧУК "Казань—наша Столица"; А. ТИМЕРГАЛИН "Словарь нации"; статья Н. НАГИМОВА "Первые опыты перевода"; перевод с турецкого С. КАМАЛОВОЙ "Новое издание о Исмагиле Гаспринском выпущенное в Казани".
"Память": Х. ТОГАЧ. Отрывки из воспоминаний "Драма одного поколения".
Страницы из "Татарской энциклопедии". Страничка из 1000 номеров "Казан утлары".
"Юмор-сатира": рассказы М. Закира.
Наш календарь.
Из фотоархива журнала.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2005 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Казань—снежная зима"—работа художника У. АБДУЛОВА; поэтесса Фирюза Замалетдинова.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel by F. BAYRAMOVA "Karabolak" (continuation); Story by F. YAHIN "For copper calf"; Verses by A. HALIM, F. GIZZATULLINA, IDELBIKA.
"To 80th anniversary of G. TAVLIN": article by M. HUZIN and story of author "Stepmother".
"Publicism": article by A. BURGANOV "Artificial state, false values and people without roots".
"Discussion": "Hero of our time": article by Z. MIRZANUROV.
"Literary criticism": article by F. URMANCHE "Skill in poetry".
"Science": article by S. MIHAILOVA, R. TSIUNCHUK "Kazan is our capital"; A. TIMERGALIN "Dictionary of nation"; article by N. NAGIMOV "First experiences in translation" translatation from turkish S. KAMALOVA "A new edition about Ismail Gasprin issued in Kazan".
"Memory": H. TOGACH. Fragments from memoirs "Drama of one generation".
Pages from "Tatar encyclopedia". Page from 1000 issues of "Kazan utlary".
"Humour-satire": stories by M. ZAKIR.
Our calendar.
From photoarchive of magazine.
Bibliographic list of products published in 2005.
Diary of social-cultural life.
On our covers: "Kazan—snow winter"—work by artist U. ABDULOV; poetess Firuza Zamaletdinova.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.11.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-910. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.

**Фәүзия Бәйрәмова**

# КАРАБОЛАК

РОМАН

## Унберенче бүлек

Иртәштәге атом комбинаты, 1957 елда зур жимерелүләр һәм фаҗигаләр кичерсә дә, эшләвеннән бер минутка да туктамады, киресенчә, жир астына һәм жир өстенә дистәләгән чакырымнарга җәелеп, тирә-юньне басып китте... Шәһәр һәм бу тирәдә яшәүче халыкның зур күләмдә радиация алганлыклары билгеле булса да, аларны урыннарыннан кузгатмаска булдылар. Моның үзенә күрә җитди сәбәпләре дә бар иде. Мәскәүдәгеләрнең фикеренчә, СССР зур көчләр куеп, атом бомбасы ясауга иреште, бу хакта бөтен дөньяга белдерде. Казахстан һәм Ырынбур далаларында, көньякта һәм төньякта бу яңа үлем коралына сынаулар уздырыла башлады, хәзер дә, күпме чыгымнар тотып, ракеталар һәм атом су асты көймәләре эшләнеп ята... Боларның барысына да "Маяк" кирәк, анда җитештерелгән плутоний кирәк, алардан башка боларның барысы да—коры уенчык кына... "Маяк"ны япкан очракта, боларның берсе дә булмаячак, чөнки яңа урында мондый атом комбинаты төзү өчен озак еллар кирәк булачак... Атом шартлавыннан соң халыкны кузгатмауларының икенче сәбәбе—бу серне дөньяга чыгармау. Ягъни, Иртәштә ни ясалганын да, ни булганын да дөньяның бер генә иле, бер генә кешесе дә белергә тиеш түгел, "Маяк" белән бәйле бөтен нәрсә—дәүләт сере... Шуңа күрә, галимнәрнең һәм өлкә җитәкчеләренең кат-кат кисәтүләренә карамастан, "Маяк"тагылар, Мәскәү белән киңәшеп, радиация астында калган кайбер татар авылларын урыннарыннан кузгатмаска, күчермәскә булдылар.

Ул арада "Маяк"та тагы бер радиохимия заводы сафка басты, радиоактив калдыклар эшкәртү цехлары төзелә башлады, яңа атом реакторларына нигез салынды... "Маяк" куәтләнгән саен, тирә-якка атом калдыклары ташлау да арта, чөнки аны башта кая куярга да белмиләр иде әле, шуңа күрә, елга-суларга агызып бардылар... Аннан атом калдыкларын ташлау өчен, комбинат тирәсендәге Карачай күлен файдалана башлыйлар, ул да тулгач, бу агуны Кызылташ, Олыагач күлләренә, Теча, Мәшәләк елгаларына, Метлино буасына, сазлыкларга ташларга керешәләр... Җир астыннан һәм җир

---

*Ахыры. Башы журналыбызның 11 санында.*

өстеннән бу сулар бөтен тирә-якка тарала, Караболактан—Сәнәргә, аннан—Исәткә, алар аша Иртыш-Тубыл-Обь елгаларына чыгып, "Маяк"ның атом калдыклары Төньяк Боз океанына килеп җитә... Мең чакырым арада бу суларны файдаланган тагы меңләгән кеше көчле радиация ала, рак белән чирли башлый... Көньяктан исә атом калдыклары, җир асты суларына кушылып, Чиләбегә таба юнәлә... Көтелмәгән урыннарда җир өстенә бәреп чыгып, алар күлләрне корыталар, мал-туарны кырып салалар, кешеләргә мәңгелек атом тамгасы салып китәләр...

1957 елдан соң да "Маяк"та төрле аварияләр, шартлаулар гел булып тора, әмма аны халыктан бик нык яшерәләр... 1958 елның 2 октябрендә комбинатның 20нче номерлы заводында, уран белән бәйле тәҗрибә уздырганда, көтмәгәндә зур авария була, анда эшләүчеләр көчле радиация алалар... Нәтиҗәдә, күп кеше үлә, сукыраючылар, гарип калучылар була... Ткаченко командасы бу серне халыкка чыгармас өчен барысын да эшли, больницаларга, рак диагнозын куймаска, дигән катгый әмер кылә... "Маяк"та мондый аварияләр елга берничә булып тора, йә реакторларга су килми башлый, йә, торба тишелеп, радиоактив калдыклар агып ята, йә завод торбаларыннан һавага чамадан тыш радиация тарала... Беренче елларны атом комбинатында саклык чаралары булмый, алар аны белми дә... Коры кул белән уранда казынып, плутонийны чиләкләп ташып, Советлар Союзы үзенең атом бомбасын ясауга ирешә... Әмма бу юлда ул меңләгән урынсыз корбаннар бирә, бу ил өчен атом адәмнән кадерлерәк булып чыга...

Ә тирә-юньдә татарларның күпләп үлүен аларның үзләренә кайтарып калдыралар, имеш, татарлар начар туклана, туганнар белән өйләнешеп, кан катнаштыра, шуңа күрә алар күпләп үләләр икән... Бу якларда мона кадәр күпчелек татарларның йөзгә хәтле яшәвен, алыптай гәүдәле, тимердәй бәдәнле булуларын, үзләреннән соң дистәләгән бала, йөзләгән оньк калдыруларын атомчы чиновниклар белми дә, белергә дә теләми...

"Радиацияне бетерә", дигән сылтау белән, "Маяк" тирәсендәге татар авылларына күпләп очсызлы аракы кертеп тутыра башлыйлар... Эчүнең ни икәнен белмәгән мөселман-татар халкы өстенә тагы бер иблис ябырыла... Каты сызлануларга түзә алмыйча, күпләр аракыны наркотик урынына куллана башлый, эчкәч алар чир-авыруларын да, тормыш авырлыкларын да беразга онытып торалар... Шулай итеп, радиациягә ияреп, Урал артындагы авылларга аракы килә, рак килә, үлем килә... Моның җирле халыкка каршы Мәскәү тарафыннан уздырылган махсус мәкерле сәясәт икәнлеген халык бик сонга калып аңлады...

... Быелгы табигать Караболак халкын аптырашта калдырды...

Уралда табигать болай да көйсез, әмма быелгы әкәмәт хәлләрне Караболакта күптән хәтерләмиләр... Башта кыш буе буран котырды, авыл юлларын, урамнарны тирән көрт басты, аякланып йөрерлек хәл калмады... Инде җепшетә башлагач, февраль уртасында, коеп яңгыр ява башлады, Уралтау өстендә яшен яшьнәп, күк күкрәде, күнелләргә шом салып, аҗаган уйнап торды... Аннан тагы катырып җибәрде, өшеткеч салкыннар китереп бәрде, яңгырдан ачыла башлаган тау битләрен боз каплады... Бу дөньяда инде барысын да күргән Караболак халкы, сабыр гына, табигатьнең үз көенә керүен көтте, чөнки, ни генә булса да, кыш артыннан барыбер яз киләчәк иде... Ә яздан соң ямьле җәй башланачак... Караболак халкы әнә шул гап-гади тормыш фәлсәфәсе белән яши иде...

Быел да шулай булды, әмма җәй вакытыннан иртә килде, июнь башында эсселек инде 30 градуска җитте. Бу исә корылык киләсенә шомлы хәбәр

иде... Әмма авыл халкы мона да алып бәрелмәде, үз көе белән яшәвен дәвам итте... Караболак халкы өчен бүген иң мөһиме—туган туфракта калу иде... Чынлап та, Караболакны үз урынында калдырдылар... Начаргамы бу хәл, яхшыгамы—монысын беркем дә белми, әмма тормыш дәвам итте, һәм кешеләр шунысына да шат иделәр... Дөрес, авылда чирләүчеләр күп, кинәт үлемнәр күп, әмма моның чын сәбәбен халык белми һәм һәркем бу хәлдән үзенчә чыгарга тырыша... Быел да менә, җәйгә керү белән, карт-карчыклар төрле үләннәр, тамырлар, бөреләр җыеп киптерә башладылар, яшь гаиләләр бакча тутырып яшелчә-җимеш утыртты, умарта тотты, мал-туар үрчетте... Авыл халкы, инде тынычлана төшеп, тагы үз җаена яши башлады...

Гөлҗиһан да быел ундүртенче җәе белән бара... Теге вакытта үлем тырнагыннан тырмашып исән калгач, ул тиз аякка басты, янадан тернәкләнеп, терелеп китте. Нурҗамал картнәе белән Таһирҗан бабасы аны аякка бастыру өчен нәрсә генә эшләмәделәр! Ул өшкерүләр, ул әллә нинди төнәтмәләр эчерүләр, ул кан агызулар, сөлек салулар, кара мунчага алып кереп, кот койдырулар... Берсе дә калмады... Ашауны да Гөлҗиһан өчен аерым тоттылар, әтисе ана ризыкны хәтта Урал арьягына хәтле барып алып кайта иде...

Ә Таһирҗан бабай өшкереп биргән Биташ чишмәсенең суы... Таһир карт аны тау куышының эченә үк кереп, иң чиста җиреннән ала торган булган... Гөлҗиһан бары тик шуны гына эчте, шуның белән генә юынды, башка суга борылып та карый алмас булды... Ул суны эчкәч, Гөлҗиһанның бөтен күзәнәкләре ачылып, дөньясы яктырып китә иде, кыз бала үзендә мона кадәр булмаган көч, җинеллек, рәхәтлек тоя... Әйтерсең лә, аның иннәренә канатлар үскән һәм алар аны Караболак өстеннән очырып йөртәләр... Дөньяда тере суы була торган булса, ул, мөгаен, шушы Биташ чишмәсе суыдыр... Таһир карттан күреп, аннары Гөлҗиһанның шуны эчеп савыкканын белеп, Караболак халкы да суга шул чишмәгә йөри башлады... Һәм, ни хикмәт, авырулар шактый кимеде, кешеләр янадан аякка бастылар...

Караболак, җан тырмашып, исән калу юлларын эзли иде...

Яшьләр—гашыйк була, өйләнә, балалар үстерә, картлар аларга киңәш биреп, өйрәтеп тора... Җәй артыннан көз җитә, аннан карлы-буранлы кышы башлана... Караболак халкы, элек ничек яшәсә, шулай көн күргән дәвам итә, әйтерсең лә, кайчан гына авыл тулып хәрбиләр йөрмәгән, күчерәләр икән, дигән шомлы хәбәрләр таралмаган... Әйтерсең лә, әле кичә генә алар, үлем көтеп, өйләрендә тәгәрәшеп ятмаганнар, урам-урам зиратка күчмәгәннәр, билгесез авырудан кырылмаганнар... Әмма тормыш дигәнең шундый инде ул, бер кичкенә генә шатлык килдеме, кайгы онытыла, хәл бераз яхшырып китсә, авырлыклар истән чыга... Моның шулай булуы яхшыдыр, мөгаен, югыйсә, адәм баласы гел кара кайгы эчендә генә яши алмый бит, ул барыбер тормышында бер якты нур табарга тырыша... Һәм таба да...

Гөлҗиһан белән дә шулай булды... Ул бик тиз савыкты, тернәкләнде, янадан чаяланып, шаянланып китте... Әйтерсең лә, ул кичә генә кан косып ятмаган, әйтерсең лә, ана инде ак бәздән кәфенлекләр әзерләп куелмаган булган... Хәзер, әнә, аны танырлык та түгел, кинәт кенә үсеп, тулышып китте... Аңа беркем ундүрт яшь бирми, ул инде буй җиткән яшь кызны хәтерләтә... Үзе шул хәтле тере, үткен, үзе, яшь тай кебек, беркемне якын җибәрми, тибенергә генә тора... Өенең түрендә—ут борчасы Гөлҗиһан, урамда хуҗа—атамандай Гөлҗиһан, мәктәп түрендә—бишкә генә укучы Гөлҗиһан, клубта—иң матур кыз Гөлҗиһан... Үзе матур, үзе үткен, үзе башлы, үзе батыр, үзен барысы да ярата тагы... Кыскасы, Караболакта дөнья тагы Гөлҗиһан тирәсендә әйләнә башлады... Һәм бу ана килешеп тә тора иде...

Авылда карап торган бер кыз булса да, Гөлҗиһан иркәләнеп өй түрендә

утырмый, нәрсәгә тотынса, кулыннан шул килә аның. Ул беркайчан да эш кушканнарын көтми, эшне Гөлҗиһан үзе таба, үзе ерып чыга, үз дөньясын үзе әйләндерә... Шуңа күрә Гөлҗиһанны авылда барысы да ярата, "Кем бәхетенә үсә икән Нәбинең бу кызы?",—дип, сокланып аны күзәтәләр... Ә аның насыйбы бөтенләй башка җирдә яши, Гөлҗиһанның күптән инде аны күргәне юк... Ә күрәсе бик килә... Теге вакытта, Иртәштә шартлау булган көзне, ул атасы белән Караболакка кайткан иде... Шаян Гөлҗиһаннан күзен дә алмады, ә Гөлҗиһан, балалыгы белән, бөтен нәрсәне уенга борды... Аннан соң каты авыру барысын да басып китте, күрше егете Фәргать тә аксыл томан артына китеп югалды... Тиздән аны күрәсен дә, тәкъдирдә аларның язмышлары бергә бәйләнгән булуын да белми әле Гөлҗиһан... Аның язмышы, әнә инде, Караболакка якынаеп килә, тик үз хәсрәте, үз кайгысы белән кайта ул туган авылына... Бу хакта да әле Караболакта беркем белми...

Ул көнне кичкә таба көн кисәк кенә суыта башлады...

Башта Урал ягыннан күгелҗем-кара болытлар күренде, аннан боздай салкын җил исә башлады... Көтүдәге мал-туар, хәвеф килгәнен сизгәндәй, авыл ягына карап чабарга тотынды, тизрәк ышык абзар-куралларга кереп качты... Көчәйгәннән-көчәя барган җил-давыл кош-кортны да кетәклекләргә куып кертте, ишек-тәрәзәләрне, ачык капкаларны шапылдатып йөри башлады... Төнгә таба Караболакка көчле давыл килгәнлеген чамаларга була иде...

Шулчак Гөлҗиһаннар капка төбенә бөркәүле йөк машинасы килеп туктады. Гөлҗиһан тәрәзәдән күреп калды—машинадан солдат киеменнән бер яшь егет сикереп төште. Абзарда, мал-туар янында йөргән әти-әнисе каршы алмагач, Гөлҗиһан, уктай атылып, машина янына үзе йөгереп чыкты. Йөгереп чыкты да, каршында пәйда булган чибәр егетне күреп, уңайсызланып, ток суккандай артка чигенде. Аның каршында элеккеге күршеләре Якупның улы Фәргать басып тора иде...

Моннан берничә ел элек, теге шартлау булган көзне, алар әтисе белән Караболакка кайтканнар иде. Якуп төрмә срогын тутырып чыккан, аның авылга күчәсе килә, алар бу хакта Гөлҗиһанның әтисе белән килешеп тә беткәннәр иде инде... Ул арада Караболакның үз язмышы да кыл өстендә калды, күчерәләр икән, дигән сүз таралды... Аннан Якупның кинәт кенә авырып китүе турында хәбәр килде... Шуннан соң ара-хәбәрләр өзелеп торды, чөнки һәркемнең үз хәле хәл иде, һәр йортта авыру, һәр йортта—мәет, кеше кайгысы калмады... Һәм менә шул күрше Якупның улы Фәргать хәзер, солдат киемендә, Гөлҗиһан каршында басып тора... Әмма, никтер, элеккеге кебек, Гөлҗиһан белән шаярмый да, уйнамый да, хәтта аңа карап елмаймый да... Нигә шулай үзгәргән икән ул? Әллә берәр кайгысы бармы икән?

Гөлҗиһан, күңеле нидер сизгәндәй, каплаулы йөк машинасы ягына карады. Аннан елап шешенеп беткән бала-чага һәм Якупның хатыны күренде. "Ә Якуп әзи үзе кайда икән соң, нигә аннан башка гына кайткан алар?",—дип уйлады Гөлҗиһан, тирә-ягына карап. Аннан, җавап көткәндәй, зур яшькелт күзләрен Фәргатькә төбәде, тик, яшен суккандай, карашын тизрәк читкә борды. Ул Фәргатьнең моң, кайгы-хәсрәт, тагы әллә нинди хисләр белән тулы карашын күтәрә алмады. Бу караштан аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Каршында басып торган егетнең аның өчен гади кеше генә булмыйча, язмышына үтеп керәчәк ир-ат буласын күңеле белән сизенә, шуңа күрә каушый иде... Бәхетенә, Гөлҗиһанга ярдәмгә өйдән әтисе килеп чыкты. Ул Фәргатькә һәм машинага күтәрелеп карау белән, нидер сизенеп, егетне үзенең киң күкрәгенә кысты.

—Әтине алып кайттык, Нәби абый,—диде Фәргать.—Бөтенләйгә алып кайттык, күмәргә...

Ул арада башкалар да якынрак килделәр, өйдән Гөлжиһанның әнисе йөгереп чыкты, каршы яктан ашыгып атлаган әби-бабасы күренде. Тирә-як халкы Гөлжиһаннар капка төбенә җыела башлады. Якупның үлеме турындагы хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән иде инде...

Якупның гәүдәсен үзенең ярымҗимерек өенә куйдылар. Соңгы теләге шул булган икән—үз нигезендә соңгы төнне чыгу һәм Караболак зиратына күмелү... Сугыштан да, әсирлектә дә, төрмәдән дә исән кайткан әзмәвердәй Якуп, 1957нең көзендә Караболакка килеп киткәннән соң, аяксыз кала, урын өстенә ята... Миасс—авыл җире түгел, больницадан-больницага тикшерелә торгач, анда нурланыш авыруы табалар... Бүрәнәдәй таза ирнең бөтен тәне радиация белән агуланган булып чыга... Ул күз алдында кибә-корый башлый, бөтенләй аяк-кулсыз кала, тәненнән кан бәреп чыга... Иртәштә солдат хезмәте үткән Фәргатьне ашыгыч чакыртып кайтаралар, ата кеше ана үзенең соңгы васыятен әйтеп калдыра... Васыяте—Караболак була, үлгәч булса да, ул шунда кайтып ятарга тели... Хатынының, әле сабый игезәк кызларының, улы Фәргатьнең күзенә карап, туган авылыннан еракта, Урал таулары арасында җан бирә күрше Якуп... Һәм менә ярымҗимерек өендә ул бүген үзенең соңгы төнен чыга... Сугыш кырларында ятканда, немец әсирлегендә интеккәндә, Себер төрмәләрендә газап чиккәндә, ул шушы нигезе, Караболак авылы белән күп мәртәбәләр хыялланагандыр, саташкандыр... Һәм менә хәзер бөтенләйгә кайтты... Кырык яшендә җир куенына кереп яту өчен, ул инде бөтенләйгә Караболакка кайтты... Ана хәзер сугыш та, сөрелүләр дә, атом үзе дә куркыныч түгел—ул мәңгелек тынычлыгын туган авылында тапты... Үлгәч кайтып егылу өчен дә кешеләргә Караболак кирәк иде, туган авыл кирәк иде...

... Ул төнне Караболак кыямәт көнен хәтерләтте.

Көндез түзә алмаслык эсселек булды, кичкә кинәт кенә суытып җибәрде, ә төнгә каршы авыл өстендә давыл купты... Бу—моңа кадәр адәм заты күрмәгән җил-давыл иде... Ул котырынып, өй түбәләрен алып бәрде, йөзьяшәр агачларны төбе-тамыры белән куптарып ташлады, яшьрәк куакларны шартлатып урталай сындырды... Күктән авыл өстенә кар катыш балчык, агач кисәкләре, таш, тагы әллә нәрсәләр яуды... Төнгә Якупның мәетен сакларга җыенган халык, куркышып, Гөлжиһаннарга кереп тулды, таң атканчы беркем керфек какмады...

Иртә белән аларны тагы да тетрәндергеч хәлләр көтә иде... Кичә генә тузан тузгып торган авыл урамнарын тездән кар күмеп киткән, әмма ул кар ак түгел, кан кебек кып-кызыл, балчык белән катнаш иде... Моны күреп картлар: “Ахырзаман, ахырзаман!”—дип, елаша башладылар, яшьләр дә өркеп калды... Кичә генә ямь-яшел булып утырган Караболак кызыл кар астында ята иде... Ярты авылның йорт түбәсе юк, күп кешеләрнең капка-коймалары ауган, абзарлар җимерелгән, куркынган мал-туар тездән кар эчендә басып тора... Иртәнге якта инде авыл өстендәге кара болыт таралган, Урал таулары ягына китеп бара, бу хәлләрдән оялып кына, күк йөзенә кояш чыгып килгәнлеге күренә иде...

Әмма таш яуса да, йоласына туры китереп, мәетне күмәргә кирәк иде, ул үзенең түбәсез җимерек өендә соңгы юлга озатканнарын көтеп ята ... Авыл ирләре, беренче эш итеп, зиратка юлны чистарттылар, бернечә кеше, ломнар белән чокып, кабер казырга тотынды. Әле яхшы җирнең өсте генә катып киткән, аста барыбер йомшак, көрәк керерлек иде. Таһирҗан карт исә, бөтен тәртибен китереп, мәетне юарга әзерли башлады. Хатын-кыз, бала-чага исә йорт тирәсен тәртипкә китерергә тотынды, чөнки эссе кояш астында кар эреп, бөтен җимерек, чуп-чар өскә чыккан, таралып ята... Гөлжиһан да ишегалдында бөтерелеп йөрде, бу сылу кызның кулында ут

уйнап тора, ул кагылган җирдә гөлләр янадан баш күтәрә, чирәм чәчәк ата, алдында кошлар җыр башлый... Ә бәлки Гөлҗиһанның җаны шулай кош булып сайрыйдыр, аның нурлы карашыннан гөлләр үсәләрдер, дөнья яшәрәдер? Дөнья өстенә таш яуса да, хәтта кызыл кар яуса да, ул бит үсмер кыз бала... Дөньяга гөлләр кебек шатланып үсәр өчен туган кыз бала, ярату-яратылу өчен туган кыз бала... Һәм шушы хисләр аңа бүген канат куйган, шуңа күрә ул ишегалды буйлап очып кына йөри...

Мәетне күмеп кайтканда, кар эреп беткән, табигать янадан үз рәвешен алган, авыл тагы үзенчә яши башлаган иде инде... Чөнки Урал аръягында, Караболак тирәләрендә мондый гарасатлар, җил-давыллар еш була, халык аңа инде ияләнгән... Бу юлы да, соңлап кына булса да, көтү кудылар, җимерек читән-капкаларны утыртып куйдылар, таралып яткан түбә такталарын җыештыра башладылар... Халык мәетләргә дә ияләнеп бара инде, биредә хәзер кеше күммәгән көн юк... Якуп кебек, үлгәч Караболак зиратына еракларда кайтып ятучылар да бар... Аны күмәргә монда алып кайтуларын авыл халкы дөрес дип тапты, чөнки алар өчен Якуп барыбер Караболак кешесе булып калды... Гаиләсен, балаларын да үз итеп каршы алдылар, аларны һәркем үзләренә кунакка алдырырга теләде...

Гөлҗиһаннар өендә дә табын әзерләнә, чөнки ерак юлдан кайткан күршеләрнең аларда туктыйсы килде. Озата кайткан машиналарын бер генә көнгә биргәннәр, шуңа күрә, чәйләр эчеп алгач, кире китәргә ниятләделәр. Чәй янына Таһирҗан картны да дәштеләр, каршы яктан Гөлҗиһанның әби-бабасы да кереп җитте, туганнар җыелышты. Якупның гаиләсен шулай итеп булса да олылыйсылары, кадер-хөрмәт күрсәтәселәре килде аларның... Гөлҗиһан исә мич белән өстәл арасында бөтерелеп йөрде...

—Урыны җәннәттә булсын Якуп күршенең,—дип сүз башлады Нәбиулла, йорт хуҗасы буларак.—Мин аңа гомерем белән бурычлы—ул булмаса, сугыш кырында ятып кала идем мин... Мине коткарам, дип, үзе әсиргә төште... Соңыннан да шуның газабын күрде... Урыны җәннәттә булсын, инде анда булса да, газап күрмәсен...

Ике як та бу тарихны белә иде, әмма бүген ул бигрәк тә тетрәндергеч булып яңгырады... "Күрше хакы—Тәңре хакы",—ди Караболак халкы, Якуп ахыргача шушы изге амәнәткә тугры булып калды... Нәбиулла исә күршесенә тиешенчә ярдәм итә алмавына уфтанды... Караболакка кайтып урнашырга өлгерә алмады бит күршесе, үлем аннан өлгеррәк булып чыкты...

Аның уйларын сизгәндәй, Фәргать әтисенең амәнәтен әйтеп калырга ашыкты:

—Әти гомер буе, Караболакка кайтам, дип яшәде,—диде ул.—Үләр алдыннан безгә дә шуны васыять итеп әйтеп калдырды... Инде ни эшләргә дә белгән юк... Минем әле армия хезмәте бетмәгән, сенелкәшләр кечкенә... Ничек кубарылып чыгып китәргә, кайда кайтып керергә?

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге рәхәт кысылып, сулкылдап куйды. Әгәр Фәргатьләр Караболакка кайтсалар, Гөлҗиһан аны көн дә күрә ала бит, юк, сәгать саен, минут саен күрә ала! Бу уеннан Гөлҗиһан кызарып чыкты, ут булып янган бит алмаларын күрмәсеннәр өчен, тизрәк чаршау артына чумды. Әмма инде чуалып ташланган уйлары аңа монда да ирек бирмәде, төрле яктан килеп, Гөлҗиһанның яшь күңеленә үрмәләделәр... Гөлҗиһанның гомерендә әле мондый хәлнең булганы юк иде, аның дөньяда әле беркем турында да шулай өзелеп уйлаганы, уйланганы юк иде... Чәчәкле чаршауның теге ягында гына утырган солдат киемле күрше егет аның күңеленә кереп урнашкан иде инде... Менә ул, әле ерак балачакта, кечкенә Гөлҗиһанны кулларына күтәреп йөртә... Менә аларны, коры арбага утыртып, авылдан сөрәләр... Менә ул, әтисе белән, Караболакка

нигез урыннарын карарга кайта һәм шаян Гөлжиһаннан күзләрен алмый... Ул Гөлжиһаннын төшләренә керә, гел аның белән янәшә яши, аның өчен яши... Бәлки бу күрше егет Гөлжиһаннын тәкъдиредер, бәлки аның тормышыннан үтеп кенә баручыдыр... Бәлки ул Гөлжиһан турында уйламыйдыр да, чөнки аның өстендә хәзер тормыш йөге, ялгыз әнисе һәм кечкенә сенелләре бит...

Шулчак чаршау артында Таһирҗан картнын тавышы ишетелә:

—Өегезне бергәләп рәткә китербез, кайтасы итсәгез, кайтыгыз, ылан,—ди ул.

Инде Фәргатьнен әнисе сүзгә кушыла:

—Алай гына кубарылып чыгып китеп булмас әле ул,—ди.—Менә Фәргать армиядән кайтсын әле, балалар бераз үсә төшсен... Анда бит әле авыру карт-карчык та бар, аларны кая куясын...

Фәргатьнен әнисе бу авыл кешесе түгел, ул монда Урал артыннан килен булып төшкән, шуна күрә дә Караболакка кайтырга бик үк атлыгып тормый, күрәсен... Игезәк кызлар әле кечкенә, берни анламыйлар, ә әби-бабай урын өстендә ята, ди... Димәк, сонгы сүзне Фәргать әйтәчәк, Караболакка кайту-кайтмау мәсьәләсен ул хәл итәчәк... Гөлжиһан, тын да алмыйча, Фәргатьнен ни әйтүен көтте.

—Армиядән кайткачка кала инде, Нәбиулла абый,—диде ул, ирләрчә нык итеп.—Әтинен васыятен үтәрбез, насыйп булса, нигезне янартырбыз... Тик бераздан инде, солдаттан кайткач...

Гөлжиһаннын күзләренә яшь бәреп чыкты. Солдаттан кайткач! Әле кайчан була ул—солдаттан кайту? Бер елмы, икеме, әллә аннан да күбрәкме? Анда нәрсә булмас? Нигә хәзер үк Караболакта калмыйлар икән сон алар?

—Нигә хәзер үк Караболакта калмыйсыз, Фәргать абый?—дип сораганын Гөлжиһан сизми дә калды.

Өстәл янындагылар барысы да аңа таба борылып карадылар. Кызның ике бите ялкынланып яна, зур күзләрен әллә яшь, әллә моң сарган, керфек очлары дерелдәп, тетрәп тора иде... Кыздагы сәер халәт, яшерен наз һәм моң егеткә дә күчкән, ахры, аның да битләре алланып чыкты, ул күзләрен тизрәк читкә борды... Гөлжиһанга туры карарга оялды, тирә-юньдәгеләр аның күнел хисләрен анларлар, дип унайсызланды...

Өлкәннәр, яшьләрнен хәлен анлагандай, сүзне жай гына башкага борып жибәрделәр. Яна гына мәет күмеп кайтсалар да, барысының да күнелендә якты өмет сызылып үтте—тормыш дәвам итә бит әле, менә, яннарында яшьләр бар... Бер йортта—житеп килгән кыз бала, икенчесендә—буй житкән егет... Димәк, хыял бар, өмет бар, тормыш бар... Әмма Гөлжиһан да, Фәргать тә үзләрендә жимергеч атом тамгаларын йөрткәннәрен белмиләр, чөнки алар әле артык яшь, артык куркусыз һәм артыгы белән бу тормышны яраталар... Ин мөһиме—алар хәзер бу дөньяда бер-берсе барын белә... Бер-берсенә кирәклекләрен күнелләре белән тоя алар... Калган барлык нәрсәләр шушы табигый хисләр алдында, бәхеткә, мәхәббәткә омтылыш алдында вак булып күренәләр... Хәтта атом үзе дә...

Бер-берләренә вәгъдә бирешеп, бер сүз әйтешмәсәләр дә, ике арада хисләрдән күпер салынган иде инде... Һәм Гөлжиһан өч ел буе Фәргатьне армиядән көтте... Бәхетенә, ул Иртәштә генә хезмәт итә иде, берничә тапкыр Караболакка ялга да кайтып китә алды. Шул кайтуларда ул Гөлжиһанга үзенен хисләрен белдерде, әти-әнисеннән өйләнешергә рөхсәт бирүләрен сорады... Ата-ана, әби-баба, бөтен зур нәсел мона сөенеп риза булды, күрше егетен тин күреп, аны үз арасына алырга әзерләнде... Иртәш белән Караболак арасында көн саен мәхәббәт хатлары йөреп торды... Ата-ана, әби-баба, Караболак халкы Фәргать белән Гөлжиһанга ярәшелгән пар итеп карый

башлады... Авыл халкы алар өчен чын күңелдән куанды, чөнки Фәргать белән Гөлҗиһан, чыннан да, бик пар килгәннәр, тиңнәр иде... Икесе дә тәртипле, яхшы гаиләдән, икесе дә күз явын алырлык чибәр, икесе дә унганбулган... Әле Караболакта яшәргә дә исәпләре бар икән... Һәм авыл халкы туй көнен көтеп яши башлады... Фәргатькә хезмәтен тутырырга нибары берничә ай калган иде... Гөлҗиһан мәктәпне тәмамлаган елны туй уздырырга килештеләр, шул көзне Фәргать хезмәтен тәмамлап кайтырга тиеш иде... Әмма ул көзен дә күренмәде, кышын, язын да үзе турында хәбәр бирмәде – Иртәш суына төшкән кебек, кинәт кенә юкка чыкты... Гөлҗиһанга, әкияттәге ятим кыз кебек, җан сөйгәнен күрер өчен, әле бик күп сынаулар, зур юллар үтәргә, авырлыклар кичерергә туры киләчәк иде...

## Уникенче бүлек

Ерак Урал тауларында Фәргатьнең әтисе Якуп "нурланыш"тан кибеп үлгән елны, Мәскәүдә "атом атасы" Курчатов та көтмәгәндә үлеп китә...

Әле алтмыш яше дә тулмаган, үгез кебек ирнең урам уртасында тәгәрәп үлүе күпләрне тетрәндерә, бу көтелмәгән үлемнең сәбәбен йөрәккә кайтарып калдыралар... Тик "атом бомбасы атасы" "нурланыш" авыруыннан үлә... Бөтен гомерен атом серләрен ачуга багышлаган, Иртәштән, "Маяк"тан кайтып кермәгән, үзе ясаган беренче атом бомбаларын сынауда катнашкан Игорь Васильевич Курчатов, атом корбанына әйләнеп, бер уч соры көл рәвешендә Кремль стеналарына кереп ята... Урал тауларында, гүзәл Сим буйларында туып үскән бу галим, нинди куркыныч гыйфритне шешәдән чыгаруларын аңлый, әмма инде соң була... 31 яшендә фән докторы, 32 яшендә күренекле профессор, СССРда уран проблемаларын өйрәнү буенча төп белгеч, өч тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, дүрт тапкыр Сталин премиясе лауреаты, "Маяк" атом комбинатын, Обнинский атом электростанциясен, "Ленин" атомоходын төзүдә катнашкан "атом атасы" Курчатов 1960 елны Мәскәү урамында тәгәрәп, җан бирә... Гомеренең ахырында булса да ул радиация сәбәпле тыныч тормыш белән яшәүче меңләгән кешенең, хезмәттәшләренең гомере өзелүен күрә, алга таба атом коралы җитештерүне чикләргә чакырып карый... Әмма үлем тегермәне әйләнүен дәвам итә, атом аждаһасы инде җир астыннан чыккан була һәм ул янадан-яңа корбаннар сорый... Сугыш өчен, СССРны саклау өчен дип төзелгән атом индустриясе илнең үз халкына каршы эшли башлый... Караболактан Якуп һәм атом атасы Курчатов бер чорда нурланыштан үләләр, радиация милләтләрне, сыйныфларны, дан-дәрәҗәне карап тормый—барысын да рәттән кыра... Бөтен ил өстендә атом аҗаганы уйный башлый, аңа караган кешеләрне газаплы үлем көтә...

Иртәштә радиациядән иң күп кырылучылар уран һәм плутоний белән эш йөртүчеләр арасында була. Соңгысы бигрәк тә яшь хатын-кызларны кырып сала, чөнки плутоний белән эшләүчеләрнең күпчелеген яңа гына институт тәмамлаган кызлар тәшкил итә. Гаять куркыныч радиация белән эш йөрткәндә бөтен саклык чараларын өс-баш алыштыруга һәм юынуга гына кайтарып калдыру аяныч нәтиҗәләргә китерә. Башта "Маяк"ның химия-металлургия заводы хезмәткәрләре, аннан радиохимия заводы эшчеләре һәм турыдан-туры реакторда эшләүчеләр кинәт кенә билгесез авырудан күпләп үлә башлыйлар. Кисәк хәлсезләнү, көчле баш авырту, йокысызлык, ашыйсы килмәү яки ашый алмау, күңел болгану билгеләре артында коточкыч "нурланыш" авыруы торуын һәм аның тиз арада үлемгә китерәсен әле ул вакытта күпләр белми... Плутоний белән эш итүчеләрнең кан составлары кинәт үзгәрә, үпкәләре, бавырлары, сөякләре череп таркала

башлый... Алар бик нык ябыгалар, саргаеп кибәләр һәм тиз арада үлеп тә китәләр... Шулай итеп, 1950-1960 елларда "Маяк"та "нурланыш" авыруыннан 30-32 яшьлек күп кенә инженер-химиклар, лаборантлар үлә... 1957 елда 30 яшьлек техник-химик Таисия Федоровна Громованы соңгы юлга озаталар. Чәчәк атып торган бу гүзәл хатын кинәт кенә йөткерә, ябыга, тыны бетә һәм ул мәңгегә күзләрен йома... Аннан 34 яшьлек З.Г.Моренова, А.Г.Шалыгина кинәт үлеп китәләр, 32 яшьлек Н.В.Симоненко тиз арада җан бирә... Аннан—О.С.Дронова, Ю.А.Исаков, Л.П.Грибкова, Н.Д.Холмогорцева, Ю.В.Клочкова һәм башкалар... Алар барысы да көчле радиациядән һәм үпкәләренә плутоний утырудан үләләр...

Аннан инде ракка чират җитә...

Чөнки "Маяк" ачылганнан бирле 20-25 ел эчендә анда эшләүчеләрнең организмында тупланган радиоактив матдәләр аларны эчтән җимерә, тарката башлый... Шулай итеп, дошман өчен әзерләнгән атом бомбасы, яман шеш рәвешендә, Иртәшнең үзендә "шартлый"... "Маяк"та рак эпедимиясе башлана, әмма аны халыктан яшерәләр, бу диагнозны куймаска тырышалар... 1958 елда үпкә рагыннан техник-химик Н.С.Асауленко үлә, аннан бавыр рагыннан техник-химик В.С.Дронова үлеп китә, аннан инженер-металлург Н.В. Киселева, инженер Л.В.Бурилина, инженер Л.П.Турдазова, эшчеләр В.В.Маслов, техник-инженерлар М.Н.Мельник, Л.И.Королева, инженер Л.П.Зенькович һәм башкалар якты дөнья белән хушлаша... Аларга әле 45 яшь тә булмый... Кайберләрен, аяк-кулларын кисеп ташлап булса да, алып калырга тырышалар... Әмма нурланыш һәм рак "Маяк"та инде тамыр җибәреп өлгергән була... Атом аждаһасын дөньяга чыгарып, биредә эшләүчеләр аны үзләре тудыралар...

Бу яман чир Иртәштә бик зур кешеләрнең дә башына җитә...

Аларны ток җибәргән биек таш коймалар да, адым саен куелган мылтыклы сакчылар да, хәтта Ткаченколар командасы да саклый алмый... "Нурланыш" һәм рак авырулары Иртәштә зур галимнәрне, дәүләт бүләге ияләрен, зур җитәкчеләрне чүпли башлый...

Плутоний буенча зур белгеч, академик, Ленин премиясе лауреаты, Дәүләт бүләге иясе, Социалистик Хезмәт Герое Александр Сергеевич Никифоров "хроник нурланыш"тан үлеп китә... Шәһәр башкарма комитеты рәисе Николай Яковлевич Ермолаев, плутоний цехында эшләп, 26 яшеннән "нурланыш" авыруы ала, икенче группа инвалидка әйләнә һәм илле яшендә, үпкәләрен кистереп, куллары корып, каны бозылып үлә... Ленин ордены кавалеры, плутоний цехы җитәкчесе Евфалия Дембяновна Вандышева 1952 елда ук "хроник нурланыш" белән авырый башлый һәм, гомер буе газапланып, алтмышка җитмичә үлә... Ленин ордены кавалеры, химия цехы начальнигы Зинаида Алексеевна Исаеваны да шундый ук кара язмыш көтә... Ленин һәм Дәүләт премиясе лауреаты, 1957-1974 елларда "Маяк"ның директоры булып эшләгән Георгий Трофимович Залесский да шушы ук авырудан 50 яшендә дөнья белән хушлаша... "Маяк"ка аннан соң килгән директор (1978-1981), Ленин һәм Дәүләт премиясе лауреаты Георгий Михайлович Нагорный да 1988 елда үпкә рагыннан үлә... "Маяк"ның соңгы җитәкчеләре дә кайсы баш мие рагыннан, кайсы үпкә рагыннан берәм-берәм үлә баралар...

Совет атом бомбасы үзен ясаучылар өстендә "шартлый"...

## Унөченче бүлек

Ул көзне Фәргать, армия срогын тутырып, өенә кайтырга тиеш иде...

Юк, Миасстагы ярымҗимерек баракка түгел, Караболакка, атасы нигезенә кайтырга ниятләгән иде Фәргать... Әнисе, әби-бабасы, туганнары

да моның белән килешкәннәр иде. Берничә тапкыр ялга кайтып, Фәргать инде йорт-җирне, абзар-кураны да рәтләп куйган иде... Аның Караболакка кайтырга теләвенең беренче сәбәсе—ата васыяте булса, икенчесе—күрше кызы Гөлҗиһан иде...

Гөлҗиһан...

Ул күзгә күренеп үсә, сылулана, гөл кебек ачыла бара... Караболакта гына түгел, бөтен тирә-якта аңа тиңнәр юк... Ул үткенлек, ул матурлык, ул әдәп-әхлак, ул булганлык—Гөлҗиһанда бар да ташып, нур чәчеп тора... Гадилеге белән бергә, ул үз дәрәҗәсен дә бик яхшы белә, патша кызы, диярсең... Монысына Фәргать сөенә генә, чөнки Гөлҗиһан авылда беркемне үзенә якын җибәрми, егетләр аңа тырнак белән кагылырга да батырчылык итмиләр... Һәм менә шушы патша кызларына тиң гүзәл зат бары тик Фәргатьне генә ярата, аны гына көтә, киләчәген бары тик аның белән генә күрә... Үзенә насыйп булган мондый зур бәхеттән, кызның шул хәтле көчле, саф мәхәббәтеннән Фәргать кайвакытта куркып та куя... Лаекмы соң ул мондый мәхәббәткә, Гөлҗиһан аны кызганып кына яратмыймы? Кыз каршында Фәргать артыгын сөйләргә дә, кыланырга да курка—горур, кыргый авыл баласын өркетеп, биздереп куюың бар... Ә Фәргатьнең Гөлҗиһанны бер дә югалтасы килми, ул үзенең тормышын, киләчәген бары тик аның белән генә күрә... Шуңа күрә солдат хезмәтеннән дә туп-туры Караболакка кайтырга уйлый... Бу көздә аларның никах туйлары булачак, Гөлҗиһан үзе дә, әти-әниләре дә риза... Шуна күрә Фәргать солдат хезмәтенең һәр көнен, һәр сәгатен саный, аның әле моннан да озын җәйне беркайчан да күргәне булмады...

Әмма бу җәйнең әле озак газаплы елларга сузыласын Фәргать белми иде... Үзенең башка беркайчан да Гөлҗиһанның нурлы йөзен күрмәячәген белми иде...

...Караболак, Иртәш тирәләрендә берничә ел рәттән көчле корылык булды, елга-күлләр тәмам саекты, кипте... "Маяк"ның атом калдыклары ташлый торган Карачай күле дә күз алдында кырый-кырыйлап кибеп бетте, төбендә агулы ләм утырып калды... Ул, кибеп, тирә-якка радиация нурлары таратып ята башлады... Бары тик күлнең уртасында гына агулы су тибрәлә... Тирә-яктагы татар авылларына, бигрәк тә Иртәштә яшәүчеләргә чираттагы атом афәте нәкъ менә Карачай күленнән килер, дип беркем дә уйламагандыр, мөгаен... Ә бәла, өермә-давыл булып, эссе җәй уртасында көтмәгәндә башлана...

Башта ап-аяз көндә Уралтау өстендә яшен камчылары ялтырап китә һәм көчле күк күкрәү ишетелә... Әмма бу күк күкрәү үтеп китми, ул тоташ гүләүгә әверелә һәм Иртәш өстенә килә башлый... Кешеләр, котлары чыгып, бу шомлы гүләүнең кайдан килүен белергә теләгәндәй, бер—күккә, бер аяк астына карыйлар... Ул арада күк йөзе кинәт кенә карангыланып китә һәм өермә башлана... Бу якларда аны "Пәри туе" диләр... "Пәри туе" нечкә генә тузан баганасыннан башлана да, көчәйгәннән-көчәя барып, юлындагы карагай-наратларны сындырып, елга-күлләрнең суын үзенә суырып алып, үкереп торган өермәгә әйләнә... Урал аръягында, Иртәш-Караболак буйларында мондый өермәләр еш була һәм күп вакытта ул бәла-каза белән бетә...

Бу юлы да нәкъ шулай булды...

Җәй уртасында күктән тавык йомыркасы зурлыгында боз ява башлады... Давыл көченнән өй түбәләре шатырдап җимерелде, тукталышлардагы такта алачыклар чәлпәрәмә килде, тәрәзә пыялалары коелып төште... Әмма иң куркынычы бу түгел, иң коточкыч хәлләр Карачай күле буенда бара иде... Өермә Карачай күле өстенә төшеп, аның кипкән агулы ләмен, суы-ние белән бергә кубарып алып, шәһәр һәм авыллар өстенә алып китә... Ул

көнне Иртәш өстенә, тирә-яктагы авыллар һәм урман-кырлар өстенә чын мәгънәсендә радиоактив яңгыр ява... Күктән, кисәтү булып, өермә төшкән һәм ул дөньяга 1 миллион кюри атом калдыклары таратып ташлаган иде... Һәм бу тирәдә яшәүче тагы 50 мең кеше нурланыш авыруы алып өлгергән иде...

Фәргатьләрне, бөтен полклары белән, Карачай күлен күмәргә ыргыттылар... Кырык биш гектарга сузылган үле күлнең яртысыннан артыгын бетон блоклар һәм кыя ташлары белән бастырып, күмеп куялар, сулы өлеше исә шул хәлдә кала... Күлне күмүдә эшләгән солдатларга һәр көн яңа өс-баш , резин итекләр бирәләр, файдаланганын шунда ук җиргә күмәләр. Әмма шул хәтле кешенең эшен кем карап өлгерсен дә, бернәрсә белмәгәч, кем тәртип сакласын? Солдатларның бер киемнән берничә көн эшләгән вакытлары да була, кайберәүләр, файдаланган яхшы өс-башны ташларга кызганып, посылка итеп туган якларына җибәреп яталар... Чөнки кешеләр моның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген белмиләр... Әлбәттә, бу посылкаларны алучылар да берничә елда кибеп-корып, саргаеп үлеп китәләр, моның сәбәбен һичкем белми...

Радиацияле Карачай күлен күмгән солдатлар көн аралаш ял итәргә һәм махсус тукланырга тиеш булсалар да, моның белән беркем хисаплашып тормый, аларны һәр көн иртәдән-кичкә кадәр атом зонасында тоталар... Һәм һәр көн мәҗбүри аракы эчерәләр, имеш, аракы радиацияне бетерә... Бу—атомчыларның чираттагы ялганы була, алар кешеләрне шулай исертеп радиация арасында эшләргә мәҗбүр итәләр... Соныннан галимнәр ачыклыйлар: алкоголь радионуклидларның канга таралуын тизләтә генә икән... Һәм аракы эчүчеләр арасында нурланыштан үлүчеләр өч тапкыр күбрәк икәнлеге билгеле була...

Фәргать кебек таза, нык егетләрне эшнең иң авыр һәм иң куркыныч урыннарына, атом тузаны ургылып торган җирләргә билгелиләр... Биредә, нигәдер, күбрәк татарлар һәм казах-кыргызлар эшли... Әмма аларны куркыныч турында кисәтмиләр... Иртәштә инде өч елга якын хезмәт иткән Фәргать биредә нәрсә ясаганнарын яхшы белә. Әмма ул да атом радиациясенең кеше өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуын аңлап бетерми, кая куйсалар, шунда бара... Хәер, солдатның башкача эшләргә нинди хокукы бар соң; бу илдә приказны үтәмәгән өчен трибунал, төрмә көтә бит...

Шулай да Фәргать үзе белгән саклык чаралары күрергә тырышты—һәр көн өс-башын алыштырды, һәр кичне яхшылап юынды, ә менә бирелгән аракыны эчмәде, якын да китермәде... Татар баласы бу агуның үзеннән дә курка иде әле... Атна-ун көн эссе тузан арасында эшләгәч, егетләрнең кайберләре күзгә күренеп хәлсезләнә башлады, каты авырып китеп, эшкә чыга алмаучылар да бар иде. Кемнеңдер күз алдында авыз-борыныннан шаулап кан китә, кемнеңдер эче тотмый, күл буенда укшып, косып ятучылар да күренә башлады... Аларны җыеп алалар да, тиз генә Сөнкүл буендагы ярымутрауга күчерәләр...

"Мендаркин мыс", дип аталган бу урында шундый авыруларны тоталар икән... Заманында биредә Златоуст купецының бай сарайлары булган, диләр, революциядән соң ул йортларны туристик база итеп файдаланганнар, ә сугыш вакытында анда хәрби госпиталь булган. 1946 елда Иртәштә атом комбинаты төзи башлагач, Берия солдатлары килеп, ярымутрауны чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алалар... Бирегә әсирләрне куып китерәләр, һәм алар өстендә радиация тәэсире буенча тәҗрибәләр уздыра башлыйлар... Әсирләр арасында немецлар да, яһүдиләр дә, татарлар да була... Бу яшерен объект НКВДның тугызынчы идарәсенең "Б" лабораториясе дип атала. һәм биредә тере кешеләр өстендә атом тәҗрибәсе уздырыла... Иртәштә

көчле нурланыш алган өметсез авыруларны да бирегә китерәләр һәм алар моннан инде беркайчан да исән-сау чыга алмыйлар... Карачай күлендә эшләгән күп солдатларны, шул исәптән татар баласы Фәргатьне дә шул язмыш көтә иде...

Берничә көн радиоактив тузаннар очып торган күл төбендә алмашсыз эшләгәч, әзмәвердәй Фәргатькә дә әллә нәрсә булды... Ул кинәт кенә үзендә көчле хәлсезлек сизде, аның күңеле болгана башлады, эче кисеп-кисеп авыртырга тотынды... Ул башта моңа игътибар итмәскә тырышты, узар әле, дип уйлады. Шул хәлендә икенче көнне дә эшкә чыкты. Чөнки яңгырлар, җил-давыл башланганчы, күл төбен күмеп бетерергә кирәк иде, аларга шундый әмер бирелгән... Ә эшләрдәй солдатлар саны көннән-көн кими бара... Ул көнне Фәргать берничә егет өчен берүзе эшләде, зур-зур блокларны, ташларны тузан тузгып торган күл төбенә ялгызы урнаштырды, баш күтәрми, көне буе шунда кайнашты...

Кинәт кенә Казахстан чүлләреннән исә башлаган кайнар җил егетне бетон блокларга китереп сылады, ул, башы әйләнеп, җиргә ава язды... Ул арада күмелмәгән күл төбендә тагы "пәри туе" башланды, авыр ташлардан изелеп тузанга әйләнгән ләм, бөтерелеп, баш очында тузгырга тотынды... Бу кызуда битлектән дә сулап булмый, битлексез дә ярамый... Фәргать тыны бетә баруын, буылуын сизде, башы белән очлы ташларга аумас өчен, күлнең капланмаган ләмле өлешенә таба атлады һәм аңын җуеп, кап-кара упкынга очты...

Аның янына кызыл погонлы НКВД сакчылары йөгерешеп килеп җиттеләр. Берсе тиз генә Фәргатьнең битлеген салдырып карады—солдатның йөзе мәеттәй саргайган һәм күзләреннән... Күзләреннән канлы яшь ага иде...

—Беткән бу...

—Списать итәргә...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, сакчылар Фәргатьне күл читенә чыгарып аттылар... Ул кичкә кадәр кызу кояш астында, атом тузаны арасында аңсыз ятты... Кичкә таба бөркәүле санитар машинасы килеп, аны һәм аңсыз яткан тагы берничә солдатны Сөнкүл буендагы махсус лабораториягә алып киттеләр... Бу солдатларның үле икәнлеген дә, тере икәнен дә белүче юк, әмма нинди хәлдә дә аларның һәр әгъзасы фән өчен кирәк иде... Чөнки бу кешеләр атом казанында булып, һәр күзәнәкләре радиация белән агуланган, шул сәбәпле, фәнгә яна ачышлар ясарга ярдәм итәрлек мәхлуклар иде...

Берничә айдан солдат хезмәтен тутырып, Караболакка кайтырга, Гөлҗиһанга өйләнергә җыенган Фәргать өчен, инде үлеп яткан татар егете өчен билгесез тормыш башланды... Бу—аждаһа авызындагы тормыш иде, атом өстәленә тәҗрибә өчен бәйләп салган хайван тормышы иде... Әмма бу хакта Фәргать үзе белми иде әле...

Фәргать берничә көн яшәү белән үлем чигендә булды...

Чиксез каты авыртудан, бөтен эчке әгъзаларының ут булып януыннан, һәм шуны газапланып тоя алуыннан ул үзенең әлегә исән икәнлеген белде... Әмма үзе белән нәрсә булганлыгын аңламады... Ул әле үлмәгән, тере икән, нигә аның белән берәр нәрсә эшләмиләр, хәлен җиңеләйтмиләр, бу газаплардан коткармыйлар соң? Инде үлеп бара икән, нигә тизрәк үлми, нигә адәм түзә алмаслык авыртулардан газаплана? Нигә аның бөтен бите бинт белән чорналган, нигә күзләрен каплаганнар, ачтырмыйлар, нигә ул, телен тибрәтеп, сүз әйтә алмый? Пәһлевандай егет, ыңгырашып, ярдәмгә чакыра, әмма аны ишетмиләр... Ә ул аларның сөйләшкәннәрен ишеткән кебек була, әмма берни дә аңлый алмый... Нәрсә булган соң аңа, нигә һаман аның хәле җиңеләйми, нигә һаман бөтен тәнендә, эчендә үткен пычак белән айкаган кебек көчле авырту? Нигә аңа беркем дә ярдәм итми соң?

Ул үзенең шушы хәлдә күпме ятуын белми...

Авыруы бераз җибәргән кебек тоелгач, битендәге бинтларны сүтеп алганнарын хәтерли... Менә сүтеп тә бетерделәр, менә ул күзләрен ачты, әмма... Әмма ул берни дә күрми иде!!! Тирә-якта тавышлар ишетелә, янында кешеләр басып торганлыгы сизелә, әмма ул аларны күрми иде! Ул күрми, ул сукырайган, сукыр калган иде!!!

Шушы фаҗигане аңлагач, егет яткан урыныннан сикереп торырга итте, әмма көчле авыртуга түзә алмыйча, чалгы белән чапкандай, кире ауды... Ул бер мизгел аның җуеп, тын ала алмыйча ятты, эчендәге көчле авырту бер мәлгә күзләре хакында да оныттырган кебек булды... Ана тизрәк нидидер уколлар ясадылар, көчләп дару эчерделәр, тизрәк тынычландырырга ашыктылар... Чалып ташланган мал кебек, берара ул шулай урынында тынып, таралып ятты... Аннан, күз алдындагы кара бушлыкка карап, сорап куйды:

—Мин күрмим, нәрсәдән бу?

Ана җавап бирергә ашыкмадылар. Бу сорау җавап бирерлек түгел иде...

Егет башка төрле сорау биреп карады:

—Мин шулай сукыр калачакмынмы?

Янындагы хатын-кыз, рус телендә, аны юатырга тырышты:

—Син яшь әле, борчылма,—диде ул, йомшак тавыш белән.—Күрмәвең вакытлы гына булырга да мөмкин, андый хәлләр була... Иң мөһиме—син исән бит, дүрт саның исән...

—Алайса, нәрсә шул хәтле яндыра соң минем эчемне?—дип сорады Фәргать, кара бушлыкка карап.—Утлы пычак белән айкаган кебек...

Бушлыктан килгән тавыш аны һаман юатырга, тынычландырырга тырыша...

—Анысы да үтәр... Туйга хәтле төзәлер, менә күрерсең...

Туй, диюгә, Фәргатьнең йөрәге тибүдән туктагандай булды...

Туй?! Туй... Күрше кызы Гөлҗиһан белән никах туе... Тукта, хәзер нинди көн соң, кайсы ай? Ул бу хәлендә озак ятамы? Гомумән, кайда ята соң ул—Иртәштәме, әллә башка җирдәме?

—Син хәрби частьнең больницасында ятасың,—дип җавап бирделәр аңа, урынны ачыкламыйча гына.—Инде сентябрь керде, көз җитә...

Көз...

Фәргать, үзе дә сизмәстән, ыңгырашып куйды... Юк, тән авыртканнан гына түгел, җан сызлавына түзә алмыйча бәреп чыкты бу аваз... Бу көздә Фәргать, армия хезмәтен тәмамлап, Караболакка кайтырга тиеш иде бит... Аларның Гөлҗиһан белән туйлары булырга тиеш иде... Бүгенге көндә ул—дөм-сукыр инвалид. Кирәк булырмы соң ул Гөлҗиһанга? Әллә бәлки әле яңадан күрә башлар, аякка басар, бәлки шуңа калэр бу хакта беркемгә дә хәбәр бирмичә торыргадыр? Фәргать өчен иң авыр хәл—кеше кулына калу, кеше кулына карап яту иде... Аның өчен иң түбән хәл—сөйгәне алдында мескен, беткән кеше булып күренү... Һәм ул бу хакта берәүгә дә бер хәбәр бирмәскә, бу хәлләрнең азагын көтәргә булды...

Больницада шактый яткач, янәшәсендәгеләр белән аралаша торгач, Фәргать үзе өчен тагы да куркынычрак яңалыклар белде. Ул Карачай күлен күмгәндә бик көчле радиация алган һәм чак кына үлемнән калган икән... Сукыраюы да шуннан икән... Аның тәне генә түгел, эчке органнары да көчле нурланыш алган, атом утында янган булып чыкты... Ул яшәү белән үлем арасында бәргәләнеп ятканда, аңа берничә операция дә ясаганнар, бу көчле авыртулар шуннан икән... Аның белән нәрсә эшләгәннәр, кайсы җирләренә пычак тидергәннәр—Фәргать бернәрсә дә белми... Әмма аның

өчен үлем карары булып яңгыраган хәбәр—Фәргатьнең балалары булмаячак икән... Һәрхәлдә, бу чорда... Алга таба нәрсә булыр—беркем дә бернәрсә әйтә алмый... Ягъни ул егерме бер яшендә дөм-сукыр булып, эче-башы туракланган хәлдә, бала булдырырга сәләтсез бер гарип булып калган...

Фәргать хәзер генә үзенең хәлен аңлады...

Әйе, ул—исән, әмма мондый исәнлектән нинди мәгънә, асылда тере мәет булгач?! Караболакка кайту, Гөлҗиһанга өйләнү турында инде сүз дә була алмый... 16 яшьлек кыз балага нигә мондый гарип ир? Кызганып, бәлки ризалашыр да, чөнки Гөлҗиһан бик кешелекле кыз, әмма Фәргать үзен кызгандырып, кешегә йөк була алмый... Ул бу хәлендә беркемгә дә күренергә теләми, хәтта сөйгәненә дә... Ә алга таба нишләргә кирәген ул үзе дә белми... Әниләренә Миасска ул үзенең исәнлеген хәбәр итәр, ә кайтуын—анда да кайтмас, аларга да йөк булмас... Бераз аякка басканчы, бер-бер төпле фикергә килгәнче, ул шушында калырга булды. Күңелендә, бәлки әле күзем ачылыр, бәлки врачлар нидер эшли алыр, дигән яшерен өмете дә бар иде... Фәргать Сөнкүлдәге бу больницаның радиация алган кешеләр өстендә сынау үткәрүче лаборатория икәнлеген белми иде әле... Белсә дә, аңа барыбер иде, ул врачлар биргән бөтен даруларны эчеп карарга, бөтен операцияләргә түзәргә әзер иде... Тизрәк аякка гына бастырсыннар, янадан кеше итсеннәр...

Фәргать әнисенә өстәмә хәрби хезмәткә каласын хәбәр иттерде, Гөлҗиһанга бер хәбәр дә бирмәде... Авыр булса да, ул хәзергә күңеленнән Гөлҗиһан белән араны өзде. Аңа хәзер шушы хәлендә—дөм-сукыр һәм ялгыз килеш яшәргә өйрәнергә, тормышка җайлаша башларга кирәк иде... Ул әле бу авыру белән, ачы язмышы белән көрәшеп караячак, Гөлҗиһанны бу кара кайгылы тормышына өстерәп кертмәячәк... Язмышын җинә ала икән—ул Гөлҗиһанны үзе эзләп табар, юк икән—мәңгегә онытыр, мәңгегә шушы шәһәрдә, шушы хәлендә калыр... Калган гомере, кабере дә шушында булыр...

Шулай итеп Фәргать Гөлҗиһан өчен кинәт кенә юкка чыга...

Билгеләнгән вакытта армиядән кайтмый...

Билгеләгән вакытта туй булмый кала...

Ата нигезендә яна гаилә корылмый...

Күрше егете Фәргать, суга төшкәндәй, юк була, эзсез югала...

Ә Фәргать Сөнкүлнең лаборатория-больницасында ятып кала... НКВД карамагында булган бу учреждение үзенең аеруча яшеренлеге һәм катылыгы белән аерылып тора... Иртәштә һәм тирә-як авылларда нурланыш, рак белән авыручылар шул хәтле күбәеп китә, аларны дөньядан яшереп дәвалау өчен махсус хастаханәләр кирәк була башлый... Чөнки моңа кадәр күрелмәгән авыруларны башкалар янына салырга, кеше күзенә күрсәтергә ярамый иде... Бигрәк тә бу авыруларның гарип-гораба балалары туа башлагач, галимнәр эшнең ни дәрәҗәдә куркыныч булуын аңлап алалар... Радиациядән алган "нурланыш" авыруының кырык буынга житеп, нәселне җимерүе, кешеләрне гарип итүе, дөньяга мутантлар туугa сәбәп булуы ачыклана... Бу тирәләрдә ике башлы, балык койрыклы балалар туа башлый, буш баш миле, сыңар бөерле, авыш йөрәкле, сукыр, чукрак, телсез балалар туу очраклары да күбәя... Боларның барысын да дөнья күзеннән яшерергә, аерым хастаханәләргә урнаштырырга кирәк була...

Иң башта андый больницаны Иртәшнең үзендә, Сөнкүл буенда ачалар... Бередә радиациядән чирләүчеләр өстендә өр-яңа дарулар сынап карыйлар. Соңрак ФИБ, ягъни Физика-биология институты дип аталган лаборатория-больница Чиләбедә дә ачыла, аларның үзәге исә Мәскәүдә оеша. Әмма

Сөнкүлдәге "Б" лабораториясе үзенең тере кешеләр өстендә уздырган тәҗрибә-сынаулары, рәхимсезлеге белән аеруча аерылып тора... Әллә инде анда дөньякүләм танылган әсир немец галимнәре эшләгәнгә, бу урынны халык телендә "концлагерь" дип атап йөртәләр...

Атом бомбасы ясау сере, нигездә, немецлардан урланган булганлыктан, радиация нәтиҗәләрен өйрәнү тәҗрибәсе дә аларда бар иде... Радиобиология фәне, тере организм өстендә радиация тәэсирен өйрәнү немецларда сугышка кадәр үк шактый югары дәрәҗәгә куелган иде... Шуна күрә сугыштан соң атом өлкәсендә эшләгән бөтен немец галимнәрен, кайсын әсир итеп, кайсын килешү буенча, Иртәш буйларына куып китерделәр һәм Сөнкүл лабораториясенә яптылар... Шулай итеп, атом буенча бөтен дөньяга даннары таралган Штульдреер, Борн, Кач, Риль кебек атаклы немец галимнәре советлар өчен эшли башладылар... Берәүләр Курчатовка ураннан плутоний аерып алу серен өйрәтсә, икенчеләр эшләрен радиобиология өлкәсендә дәвам иттеләр.

Татар егете Фәргать шушы ак халатлы палачларның тәҗрибә өстәленә салынган чираттагы корбан иде...

## Ундүртенче бүлек

Инде билгеләнгән туй вакытлары үтеп китеп, кара күзләргә кергәч, Нәбиулла кызына сиздерми генә Миасска, Фәргатьнең әнисе янына барып кайтырга булды... "Солдат хезмәте бит, ни булмас,—дип уйлады үзе дә сигез еллап армиядә йөреп кайткан ата кеше.—Кыз да кызганыч, авыл халкыннан да яхшы түгел, чөнки туй турында хәбәр инде күптән таралган... Туй дип, Гөлҗиһан җәен укырга керергә дә бармады, эшкә дә урнашмады, хәзер инде ни дә булса хәл итәргә кирәк..." Хәзер инде барысы да Нәбиулланың Миасстан нинди хәбәр белән кайтуыннан тора... Исәнме Фәргать, юкмы, исән икән, ник бер хәбәр бирми, нигә кыз баланы ил алдында мондый хәлгә калдырды? Гөлҗиһан күзгә карап сула бит, үзенең кешегә сиздерәсе килми, эчтән генә өзгәләнә, яна... Ул тәмам олыгайды, житдиләнде, сөйләшмәс, көлмәс булды... Әйтерсең, Караболак күгендә якты бер йолдыз сүнде... Һәм Нәбиулла, бу билгесезлеккә чик кую өчен үзе җыенып юлга чыгып китте... Хәзер инде барысы да аның нәрсә дип кайтып әйтүеннән тора иде...

Әмма ул Миасста Фәргать турында артыгын белә алмады. Дөрес, аның исән-сау икәнлеген белде ул, анысы да бүгенге көн өчен зур нәрсә иде... Фәргать Иртәштә өстәмә хәрби хезмәткә калган булып чыкты, әнисенә ул бу хакта үзе хәбәр иткән... Анысы да була торган хәл, тик нигә бу хакта Караболакка, Гөлҗиһанга да хәбәр бирмәгән ул? Туй булырга торганда араны нигә кинәт кенә шулай өзгән? Әллә араларында берәр аңлашылмаучылык килеп чыкканмы? Яшьләр бит, икесе дә кайнар, икесе дә горур... Ата кеше кызы өчен шулай Уралларга килеп, төпченеп йөрүенә уңайсызланып та куйды... "Ярый, исән икән—исән, насыйп булса, бер күрешерләр, язган булса, өйләнешерләр,—дип уйлады ул.—Кыз әле бик яшь, укырга керер, һөнәр алыр... Тормыш корырга өлгерер әле..."

Нәбиулла Миасста артыгын төпченеп тормады... Төпченгән булса, ул Фәргатьнең өенә бер хат язмавын, Иртәштә калуы турында телеграмма белән генә хәбәр итүен белер иде... Төпченгән булса, монда ниндидер сер барлыгын сизенер иде... Әмма Фәргатьнең әнисе дә, Гөлҗиһанның әтисе дә телеграммага ышандылар һәм аны эзләтеп тормадылар... Хәер, ябык атом шәһәреннән ничек эзләтеп булыр иде аны? Һәм алар барысы да Фәргатьнең үзенең хәбәр бирүен көтеп яши башладылар...

Ә бу вакытта дөм-сукыр Фәргать Сөнкүлдәге Берия лабораториясендә яшәү белән үлем арасында бәргәләнә иде...

Ата кеше Караболакка кайтып кергәч тә бу хакта кызына озак кына әйтә алмый йөрде... Әйтмәс тә иде, Гөлҗиһаннның ничек эчтән януын, билгесезлектән өзгәләнүен күрде.

—Фәргать Иртәштә хәрби хезмәттә калган, кызым,—диде ул, Гөлҗиһанның ялгыз калган чагын туры китереп.

Гөлҗиһанны ток суккандай булды. Аның битләре башта кып-кызыл булып чыкты, аннан кар кебек агарды. Алай да кыз үзен кулга алып өлгерде, газаплануын беркемгә дә, хәтта әтисенә дә күрсәтәсе килмәде.

—Ә син кайдан белдең, әти?—диде ул, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән.

—Миасска барып кайттым мин, кызым,—дип, дөресен әйтергә булды Нәбиулла.—Әнисенә телеграмма белән хәбәр биргән ул, Иртәштә өстәмә хәрби хезмәткә калган...

Гөлҗиһан җавап итеп бер сүз дә әйтмәде. Иелә барган башын югары күтәрде, бугазына килеп төелгән әрнүен эчкә йотты, сер бирмәде... Атылып чыгарга торган хыянәтче күз яшьләрен әтисенә күрсәтмәс өчен ялт итеп тәрәзәгә борылды, ясалма шаян тавыш белән:

—Калган икән—калган инде,—дип әйтеп куйды.—Һәркемнең үз эше, әти...

—Әйе, кызым, һәркем үзе хәл итә,—дип аны җөпләде ата кеше.—Быел укырга керергә соңга калдың инде, киләсе ел өчен әзерләнә башларсың... Кышын эшләп алсаң да була, ничә тапкыр мәктәпкә чакыра килделәр бит...

Аның кызын Фәргать турында уйлавыннан читкә алып китәсе килде, Гөлҗиһанга тизрәк нинди дә булса шөгыль табарга ашыкты. Гөлҗиһан да әтисенең бу сүзенә чат ябышты, барып чыкмаган туй хурлыгын тизрәк онытырга кирәк иде... Ә аны бары тик эш белән генә бастырырга була, авыз салындырып, елап утырмас бит инде Гөлҗиһан башы белән...

—Әйе шул, әти!—диде ул, башын горур тотып.—Иртәгә үк эшкә мәктәпкә барам! Ничә тапкыр килделәр бит инде...

Гөлҗиһан шулай диде дә, ниндидер эш тапкан булып, ишегалдына чыгып йөгерде... Керфек очларына менеп кунаклаган күз яшьләрен әтисенә күрсәтәсе килмәде аның... Кызның хәзер бөтен кешедән дә качасы, дөньядан качасы килә, ул башында ут булып кайнаган бер генә соравына да җавап таба алмый... Ә анда—Фәргать, Фәргать, Фәргать...

Гөлҗиһан атылып урамга чыкты...

Ә урамда... бөтен дөньяны энҗе нурларга күмеп, беренче кар явып ята иде! Менә ак кар бөртекләре Гөлҗиһанның озын керфекләренә куналар, алсу иреннәренә төшеп эриләр, кызның күз яшьләренә кушылып, ут булып янган битләре буйлап агалар... Быел Караболакта беренче кар шулай елый-елый ява, елый-елый ага... Узган ел, Фәргать ялга кайткач, алар ак кар яуган Караболак урамнары буйлап кич буе житәкләшеп йөргәннәр иде... Ярәшелгән парлар булгач, аларны авылда беркем дә гаеп итмәде, барысы да алар өчен сөенеп, туй көнен көттеләр... Чөнки гүзәл Гөлҗиһанга тиң булырлык, горур Гөлҗиһанны буйсындырып торырлык башка кеше юк иде Караболакта... Патша кызы кебек үз дәрәҗәсен яхшы белгән Гөлҗиһанны бары тик мәхәббәт кенә буйсындыра ала иде... Гөлҗиһанның Фәргатьне яратуын бөтен авыл белә... Һәм бөтен авыл туй көнен көтә...

—Безнең туебыз кайчан була, Фәргать?—дип сорый аннан Гөлҗиһан, шук елмаеп...

—Бу юлы кызыл кар яугач түгел инде,—дип көлә Фәргать тә.—

Караболакта беренче кар яуганда булачак безнен туебыз, Гөлҗаным... Нәкъ бер елдан, мин солдаттан кайткач... Көтәрсен бит?..

Гөлҗиһан чытлыкланып көлгән була... Ә эченнән генә ул бу елнын һәр көнен, һәр сәгатен саный башлый... Көтмиме сон?! Көтмиме?! Ул Фәргатьне янәшәсендә торганда да сагына, киткәч, һәр көн анардан хат көтә, бары тик шунын белән яши... Ул аннан ояла да, ана гел тартыла да, сагына да, дөньяда ул булганга сөенә дә... Фәргатькә гашыйк булганнан бирле Гөлҗиһан авырунын да нәрсә икәнлеген онытты, ул бары тик киләчәккә хыял-өметләр белән генә яши... Аларнын Караболакта үз өйләре булачак, Фәргать аны күтәртә башлады инде, анын кулыннан бөтен эш килә... Ул өйнен ишегалды тулы балалар булачак... Уллары Фәргать кебек баһадир гәүдәле, көчле һәм батыр, кызлары, Гөлҗиһан кебек сылу һәм сөйкемле булачак... Гөлҗиһан аларга Караболак тарихын сөйләр, үзләренен Алып Ханнар нәселеннән икәнлекләрен анлатыр, Биташ күленә алып барыр, урман-кырларны, борынгы скиф-һун курганнарын күрсәтер... Ул аларга хан бабалары турында Таһир бабай өйрәткән шигырьләрне укыр, татарча жырлар өйрәтер, догалар ятлатыр... Фәргать исә балаларына тормыш рәтен өйрәтер, акыл бирер, аларны авырлыклардан саклар... Чөнки шундый көчле, акыллы, рәхимле бит ул Фәргать...

...Гөлҗиһан, өй артындагы коймага капланды да, үксеп елап җибәрде... Юк, юк, ул ышанмый, Фәргать аны болай гына оныта, ташлый алмый, ана нидер булган, булган!... Нигә бер хаты, хәбәре юк анын Гөлҗиһанга? Ул бит андый түгел иде, һәр көн озын-озын хатлар яза иде, туй көнен сәгатьләп саный иде... Нигә калган ул Иртәштә, нигә бу хакта Гөлҗиһанга хәбәр бирмәгән? Анын сонгы хатлары шактый кырыс һәм коры була башлаган иде бит... Әллә сон Иртәштә башка хатын-кызны очраттымы икән ул?

Бу көтелмәгән уйдан Гөлҗиһанны яшен суккандай булды. Әйе, дөньяда Гөлҗиһаннан башка да хатын-кызлар күп бит, ә Фәргать алар кызыгырлык кына—матур, гәүдәле... Ничек башта ук шул турыда уйламаган сон Гөлҗиһан? Димәк, тормышта болай да була ала? Хыянәт тә була ала... Бәлки Фәргать Гөлҗиһанны әллә кайчан оныткандыр инде, шәһәрдә башка кызлар тапкандыр...

Бу уеннан Гөлҗиһаннын башлары әйләнеп китте, бу юлы инде күзләренә гарьлек яшьләре бәреп чыкты. Ул, ут булып янган иреннәрен канатканчы тешләп, картнәйләренен өенә таба йөгерде. Анын хәзер әтисе янына керәсе килмәде, ул анын күзенә күренергә ояла иде...

Гөлҗиһаннын бәхетенә, Таһирҗан бабай да биредә булып чыкты, әйтерсен лә, ул аны көтеп кенә торган... Гөлҗиһан да, ярдәм эзләп, шундук Таһир бабасынын күкрәгенә килеп капланды һәм мышкылдап елап җибәрде... Бу мизгелдә аны бары ул гына дөрес сүзләр табып юата алыр кебек иде...

—Ә син борчылма, кызым, барысы да яхшы булыр, иншаллаһ!—диде Таһир бабасы, оныгынын уйларын сизгәндәй.—Табышырсыз да, кый, кавышырсыз да—язганы булыр, Алла теләсә...

Гөлҗиһан, мөлдерәп, Таһир бабасына күтәрелеп карады. Нинди кавышу турында сөйли ул, кем белән? Каян белгән ул Гөлҗиһаннын ни өчен өзгәләнүен?

—Кем белән кавышу турында сөйлисен син, Таһир бабай?

—Кемне уйлыйсын, шунын белән, кызым,—диде бабасы, кызнын чәчләреннән сыйпап.—Тик сабыр итәргә кирәк, кызым, ашыгып нәтиҗә чыгарма... Дөнья бит бу, анда әллә нәрсәләр булырга мөмкин... Бәлки ана синен ярдәм кирәктер...

Бу сүзләрдән Гөлҗиһан сискәнеп башын күтәрде. Әйе шул, бәлки

Фәргатькә аның ярдәме кирәктер? Гөлҗиһанга аның турында әллә нәрсәләр уйлавы өчен оят булып китте. Каян чыгып, аның башка кызлары бар, дип әйтә ала ул? Кеше турында, бигрәк тә яраткан кешен турында ничек шулай уйларга мөмкин? Бәлки Фәргать чыннан да авыр хәлдәдер, бәлки аңа чыннан да Гөлҗиһанның ярдәме кирәктер?

—Миңа нишләргә соң, бабай?—диде ул, бер карарга килә алмыйча интегеп.

—Сабыр итәргә, кызым, сабыр итәргә,—диде бабасы, һаман шул сүзгә басым ясап.—Сабыр төбе—сары алтын...

Аннан бабасы сүзне оста гына башкага борып җибәрде:

—Син быел укырга бармадың инде, кызым?

—Шулай килеп чыкты бит инде,—диде Гөлҗиһан, туй сүзен исенә төшерәсе килмичә.—Киләсе елга барырмын, Алла теләсә...

Гөлҗиһанның бу сүзләреннән Таһир бабасы бик канәгать калды:

—Шулай, гел "Алла теләсә", дип әйт, кызым,—диде ул, оныгының аркасыннан кагып.—Кая барырга уйлап торасың инде, кызым?

—Мин Свердлауга юридическига бармакчы идем,—диде Гөлҗиһан, сүзнең башка якка кереп китүенә куанып.—Әмма анда кызларны бик алмыйлар икән, армиядән кайткан егетләр күп, ди...

—Кыз бала өчен авыррак хезмәт инде,—диде бабасы, җайлап кына.—Кыз бала өчен укытучы, табип эше яхшы инде ул, кызым... Өйдә дә, эштә дә ярый торган хезмәт...

Ул арада сүзгә Нурҗамал әбисе дә килеп кушылды:

—Гомерем буе нәселебездә бер укыган табип булсын иде, дип кызыктым,—диде ул, үз фикерен әйтеп калырга ашыккандай.—Гөлҗиһан кызым яхшы укыганга бик сөенгән идем, врачлыкка китәр, дип... Әллә нәрсә килеп чыкты бит менә... Хәерлесе булсын инде...

Ә Гөлҗиһанның бу турыда уйлаганы да юк иде! Әйе, ул бик яхшы укыды, мәктәпне "биш"кә генә тәмамлады. Аңа уку да, эш тә, кешеләр белән аралашу да бик җиңелдән бирелә иде, ул бер җирдә дә интекмәде, көчәнмәде... Мәктәптә бөтен яктан аңа тиңнәр булмады, укуда да, матурлыкта да, батырлыкта да аны беркем җиңә алмады... Барысы да башта Гөлҗиһан әллә кайларга барыр, әллә кемнәр булыр, дип көттеләр... Чөнки ул кайда барса да укырга керә ала иде... Аннан Фәргать килеп чыкты... Гөлҗиһан аннан башка тормышын күз алдына да китерә алмады, кая анда укырга китү, кемдер булу... Ул кияүгә чыгарга сандык малы әзерли башлады, өй, гаилә, итәк тулы балалар турында хыялланды... Ә әнә, Нурҗамал әбисенә хәтле, аның укып, нәселдә зур кеше булуын көткәннәр икән... Врач булыр дип хыялланганнар... Көтелгән туй булмагач, барысының да беренче сүзләре уку турында иде... Бәлки бу Гөлҗиһанның уй-гамәлләрен башка юнәлешкә алып кереп китү өчен махсус эшләнгәндер, бәлки олылар, чыннан да, Гөлҗиһанның нәселдә бер зур кеше булуын өмет иткәннәрдер...

Ни булса да, бу сөйләшүләрдән соң Гөлҗиһан өйләренә шактый тынычланып, җитдиләнеп кайтып керде... Әтисе белән Фәргать турында сөйләшүләр дә каядыр еракта, пәрдә артында калган кебек тоелды.. Әйе, Таһирҗан бабасы дөрес әйтә—ана бу мәсьәләдә сабыр булырга кирәк. Ашыгып нәтиҗә чыгарырга ярамый, насыйп булса, бар да ачыкланыр, беленер, бераз сабыр итәргә кирәк... Иртәш дөнья читендә түгел, Караболактан да анда күп кеше эшли, Фәргать анда булса, берсе ишетмәсә, берсе ишетер, берсе күрмәсә, берсе күрер... Аның турында дөрес хәбәр авылга барыбер кайтып җитәр, Алла теләсә... Бәлки әле үзе дә хәбәр бирер... Ә хәзергә Гөлҗиһанга үзенең киләчәге турында уйларга кирәк... Аның классташлары күбесе кайсы укырга, кайсы эшкә урнашып бетте инде,

авылда Рәшидә кебек авырулар гына калды... Авылда авырулар һаман бик күп, әмма халык бу хәлгә ияләнеп бара инде... Караболак халкы, гомумән, зарланырга, чирен кешегә күрсәтергә яратмый... Ә югыйсә, һәр йортта диярлек ятып чирләүче бар бит инде...

Боларны искә төшергәч, Гөлжиһан табип булу турында житдирәк уйлый башлады. Әбисе дә, әнә, врач бул, ди... Теге вакытта кан косып, үлемнең күзенә карап ятканда, Гөлжиһанның үзенең дә табип буласы килгән иде... Ул шул хәтле каты сызланды, авырды, ә шул чакта янында хәлен жинеләйтерлек бер табип булмады... Авызына бер дару каптыручы да булмады, әле ярый әби-бабасының үләннәре, сулары булды... Ул вакытта авылда Гөлжиһаннар классыннан гына да жиде бала үлде, яннарында ярдәм итәргә врач булса, бәлки алар исән калырлар иде... Медицина көчле булса, бәлки Хәбибулла абыйсы да исән калыр иде, утыз яшендә үпкәләре череп үлмәс иде... Аннан соң да аларның Сәкәлин урамында гына да иллеләп кеше үлде инде, барысы да яшьләр һәм балалар... Чыннан да, нидән үлә икән алар? Нигә моны беркем дә тикшерми икән? Нигә алар авылында врач юк икән? Медпункт урыс авылы Кояшта, больница алтмыш-житмеш чакрымдагы район үзәгендә... Дөрес, һәр елны мәктәпкә килеп, балаларның беләкләреннән кычкыртып каннарын алып тикшереп йөргәннәр иде урыс врачлары... Әллә Мәскәүдән, әллә Чиләбедән диделәр... Әмма аларның ул тикшерүләреннән авыл халкына ни мәгънә соң, чирләреннән дәваламагач?

Ә ярты мәктәп чирле бит алар авылында, әле бөтенесе дә булмаса... Кемнең чәче коелган, гел пеләш калган, кем начар күрә, ә авылда күзлек юк... Кайбер балалар кинәт кенә артык симереп киттеләр, аякларын чак өстерәп йөри башладылар, ә кайберәүләр артык ябык, карарга куркыныч... Балалар шундый була димени? Гөлжиһанның үзеннән соң туган энеләре дә гел чирли, әти-әнисе нишләргә дә белми... Бәлки бу хәл тимер чыбык белән әйләндереп алган Караболак суын эчкәнгәдер? Бәлки Караболакның туфрагы агулыдыр? Алай дисәң, халык гомер буе шушында яшәгән бит инде, туксанга, йөзгә житкәннәр... Ә хәзер Караболакта кеше туута чирли башлый яки туганда ук чирле туа...Димәк, кияүгә чыкса, Гөлжиһанның балаларын да шул хәл көтәргә мөмкин?

Гөлжиһанның башына башка уйлар керде...

Ул дөньяга башка күзлектән карап, башкача күзәтә башлады...

Кышын ул укытырга Караболак мәктәбенә барды, ана башлангыч классларны бирделәр. Гөлжиһан балаларның бик тиз аруларына, хәлләре бетүенә игътибар итте, хәтта аң жуеп егылу очраклары да бар иде... Авыл баласы, гадәттә, нык, таза була, юк-барга гына селкенми дә.... Ә монда балалар аңсызланып егылалар, гел баш авыртудан, эч авыртудан зарланалар, начар ишетәләр, начар күрәләр... Гөлжиһан үзе укыганда да балалар арасында авырулар бар иде, әмма бу дәрәжәдә түгел иде... Нинди хәл булыр икән соң бу? Нигә болар белән беркем дә кызыксынмый, тикшерми? Шушы сораулар алдында Гөлжиһанның үз хәсрәте, Фәргать кайгысы да онытылыбрак калган кебек булды...

Чиләбе врачлары Караболакка чираттагы тикшерүгә, кан алырга килгәч, Гөлжиһан бу сорауны аларга да бирде. Мондый туры сорауны көтмәгән врачлар югалып калдылар, чөнки бу авылда алардан әле берәүнең дә болай тәрәп сораганы юк иде... Әйе, бу яшь укытучы кызның күзәтүләре дөрес, бу авылда балаларда да, олыларда да бер үк хәл—канның бозылуы, үзгәрүе күренә... Алар барысы да дип әйтерлек каннарында атом тамгасы йөртәләр, бу исә төрле авыруларга, хәтта гарипләккә, баласызлыкка, үлемгә дә китерергә мөмкин... Әмма моны аларның үзләренә ничек әйтәсең? Сәбәбен сорый башласалар ни дип әйтерсең? Моның сәбәбе, әлбәттә, янәшәдәге

"Маяк" комбинаты, бу авыллар өстенә туктаусыз таралып торган радиация... Әмма болар барысы да—дәүләт сере, бу хакта әйтергә дә, язарга да ярамый... Һәм врачларга да төрлечә алдарга, дөреслекне яшерергә туры килә...

—Татарларда ашау гел бер төрле, яшелчә-җимеш, витаминнар организмга аз керә, шуңа укучыларның хәле юк,—дип җавап бирделәр Чиләбе врачлары, Гөлҗиһанны ышандырырга тырышып.

Ә Гөлҗиһан ышанмады...

Нигә аларда яшелчә-җимеш аз булсын ди? Бөтен бакчалар, урман-кырлар шуның белән тулган бит... Гөлҗиһаннар үзләре генә дә кыярын, помидорын, кишер-кәбестәсен, кабагын, суган-сарымсагын бакча-бакча утырталар, кисмәк-кисмәк тозлыйлар... Ә инде җиләк-җимешне, алманы, карлыганкураны, чияне җыеп бетерә алмыйлар, алар бакчада да, урманда да, Караболак буенда да чиләк-чиләк җыярлык... Авыл баласы шуларны ашамый диме? Һәркемнең баз тулы вареньесы, умарта-умарта балы, сөткаймагы—барысы да бар хәзер авылда, беркем ач түгел... Шуна карамастан, барысы да чирли, көн саен кеше үлә, хәтта яшьләр, балалар да...

Гөлҗиһан Чиләбе врачларына менә шуларны аңлатып бирде. Тегеләрнең моңа җавабы юк иде...

—Ашауны әйтә алмыйм,—дип каршы төште аңа Мәскәүдән килгән урыс врач.—Әмма сездә, татарларда, туганнар арасында өйләнешүләр, ягъни кан катнаштыру күп икән... Ә бу, үзегез беләсез, мутациягә, ягъни гариплеккә, нәселнең зәгыйфьләнүенә китерә...

—Юк бездә андый хәл, кем әйтте сезгә моны?—дип чәчрәп каршы төште Гөлҗиһан.—Беркем дә үз туганына өйләнми инде, һәркем үзенең җиде буынын белә... Туганнарга мулла бабай нишләп никах укысын?

Врачлар аптырашып, бер-берләренә карадылар. Ут кебек кайнар, хан кызыдай горур һәм гүзәл бу татар кызына аларның җаваплары юк иде... Аларга ярдәмгә Коншактан килгән үз "татарыбыз" ашыкты:

—И, сенелем, кешенең башын юк белән катырма инде, үзең дә белә торып,—диде ул, бөтен сөйләшүгә йомгак ясап.—Халык эчә бит хәзер, шуңа күрә чирлиләр, үләләр... Сездә дә шул хәл, бездә дә...

—Бездә алай түгел!—дип тагы чәчрәп каршы чыкты Гөлҗиһан.—Бездә алай эчмиләр! Безнең нәселдә беркем эчми, ә энеләрем гел авырый... Теге вакытта мин үзем дә үлә яздым...

—Эчәләр, эчәләр Караболаклар!—дип, Коншак хатыны чәт-чәт килде.—Мин әллә сезнекеләрне белмимме? Менә хәзер керсәң, өй саен әче бал... Аракының да кимен куймыйлар... Эчмәгән кеше юк ул хәзер, шуңа күрә чирлиләр дә...

Алар белән бәхәсләшеп торудан мәгънә юк иде, алар барыбер дөресен әйтмәячәкләр иде... Бәлки әле үзләре дә белмиләрдер... Килгән врачлар Гөлҗиһанны ышандыра алмасалар да, уйга салдылар... Әйе, алар авылында да эчүчеләр күренгәли хәзер, әмма алай ук түгел бит! Ул сабый балаларның, япь-яшь ирләрнең егылып үлүләрендә эчкечелекнең ни катнашы бар? Хәбибулла абыйсы эчүнең нәрсә икәнлеген дә белми иде, утыз яшендә корып үлде... Ә Фәргатьнең әтисе Якуп абый? Аңа да бит нибары кырык яшь иде, теге вакытта, Иртәштә шартлаган елны, Караболактан кайтуга авырый башлаган булган, ул да кибеп үлде... Гомерендә дә эчкән кеше түгел бит...

Фәргать исенә төшкәч, Гөлҗиһанның тагы күнеле кузгалды...

"Әллә ана да берәр нәрсә булдымы икән соң?—дип уйлады ул, хәвефләнеп.—Иртәш шартлаган көнне ул да авылда иде бит, аннан соң Караболакта күпме кеше тәгәрәп үлде... Бәлки авыл егетләрен кырган бу билгесез чир Фәргатькә дә кагылгандыр, бәлки бу мизгелләрдә ул да үлем

күтәп ятадыр?" Бу уеннан Гөлҗиһан чайкалып куйды, тәнендә һәм жанында онытылып торган авырулары кузгалды, башы әйләнеп китте... Аумас өчен ул тизрәк урынга барып утырды. Соңгы вакытта Гөлҗиһан үзендә тагы шул авыру билгеләрен—хәлсезлек, баш әйләнү кебек нәрсәләрне сизә башлаган иде... Авыру шундый бит ул—көчсез, бәхетсез чагыңны гына көтеп тора да, өстеңә ыргыла... Фәргать турында уйлау, билгесезлек Гөлҗиһанны да тәмам көчсезләндергән, бөгеп салган иде... Ә борчулы уйлар аннан рөхсәт сорап тормыйлар, ургылып, һаман өстенә киләләр, җавап таләп итәләр... Ә җавап юк...

Әйе, Фәргать тә, Хәбибулла абыйсы кебек, Иртәштә яши иде бит... Ә андагы хәлләрне күргән халык бик куркыныч итеп сөйли... Элегрәк анда кертмәгәннәр дә, чыгармаганнар да бит... Хәбибулла абыйсы да шуннан чирләп, корып кайтты... Бәлки Фәргатькә дә шунда берәр зәхмәт кагылгандыр? Нигә Гөлҗиһан бу турыда элегрәк уйламаган соң? Кем белән сөйләшеп, киңәшеп карарга икән бу хакта? Таһирҗан бабай карт инде, ул Иртәштәге хәлләрне белерлек түгел... Авылда бу хакта теләсә кемгә ачылып булмый, халык үзе дә анда ниләр булганлыгын белми... Гөлҗиһан бары тик әтисе белән генә киңәшә ала... Ул—армиядә хезмәт иткән, сугышта булган кеше, дөнья күргән, тормышны белә... Һәм Гөлҗиһанның сорауларына бары тик ул гына җавап бирә алачак... Гөлҗиһан аннан Иртәш турында да, Караболактагы бу хәлләр турында да, Фәргать хакында да ачыграк сорар... Әтисе аны аңлар, әтисе аңа ярдәм итәр...

—Әти, минем синең белән бик җитди нәрсәләр турында сөйләшәсем бар,—диде кыз, аның каршына килеп утырып.

Кызының мәктәптәге эше белән мавыгып, үз кайгысын онытып торуына Нәбиулла сөенеп йөри иде. Аның җитди нәрсәләр турында сөйләшергә җыенуын белгәч, бераз аптырап калды. Фәргать турында булса, шуннан артык нәрсә әйтә ала ул аңа? Ул үзе дә Гөлҗиһан белгән хәтле генә белә... Ә бәлки укырга керү турында киңәшәсе килгәндер, көннәр язга авышып бара бит, имтихан вакыты да якынлаша...

—Әти, нигә безнең авылда халык шул хәтле күп үлә икән?—дип, турыдан-туры сорап куйды Гөлҗиһан.

Нәбиулла мондый сорауны бөтенләй көтмәгән иде, бераз аптырап, югалып калды, шактый гына дәшми торды...

—Күп үлә шул, кызым, бик күп,—диде ул, башка җавап таба алмагач.

—Ә нигә?

Нәбиулланың моңа төгәл җавабы юк иде... Ул үзе дә хәйран калып йөри—авылда көн саен мәет, көн саен чирле... Гомер булмаган хәл—бөтен тирә-якка данлыклы Караболакта тумыштан тилеләр, әллә нинди гариплар, телсез-чукрак балалар күренә башлады... Кая анда кешене тикшерергә—үз нәселләрендә әллә нәрсәләр булып ята бит... Туганы Хәбибулла, ямь-яшь килеш, күзгә карап кинәт кенә үлеп китте... Гөлҗиһан үзе чак кына үлемнән калды... Хатыны Хәбирә ике ел рәттән үле бала тапты, Гөлҗиһаннан соң туган малайларда бөтенләй рәт күренми, чирдән башлары чыкмый... Менә күпме вакыт инде Нәбиулланың үзенең дә ниндидер чир-зәхмәт бөтен эчен яндыра, айкый, күкрәген талый, үпкә-бавырын телә... Әмма алар авылында, алар нәселендә чир турында бик сөйләргә яратмыйлар, аны тикшермиләр... Ә Гөлҗиһан, әнә, күзгә карап җавап көтә...

—Үзем дә аптыраган инде, кызым,—диде Нәбиулла, хак дөресен әйтеп.— Элек безнең авыл халкы бик озын гомерле иде, безнең Алып Ханнар нәселендә хәтта йөз илле яшькә кадәр яшәүчеләр булган, диләр... Күпчелек кеше сиксән-туксанга җитеп, үз үлеме белән картаеп үлгән... Ә хәзер әллә нәрсә китте—яшьләр, балалар үлә... Гомер булмаган хәл...

—Ә Таһирҗан бабай нәрсә ди болар хакында?

—Таһирҗан бабаң? Таһирҗан бабаң әйтә ул...

—Нәрсә ди?

Нәбиулла як-ягына карап куйды. Аннан, кызына иелә төшеп, шыпырт кына әйтеп куйды:

—Дөньяны агулыйлар, ди Таһирҗан бабаң... Суда, һавада, туфракта агу бар, ди, шуңа күрә суны Биташтан ташый ул, халыкка да шулай куша, әмма анда чаклы көн дә кем барып йөрсен? Иртәш ягыннан куркыныч килә, ди... Анда ни булганын ул үзе дә белеп бетерми, ул күп нәрсәне сиземләп кенә тоя бит, үзең беләсең... Иртәштән сак булыгыз, ди Таһир бабаң...

—Иртәштән сак булырга?!

Гөлҗиһан утырган урыныннан сикереп торды. Фәргать тә Иртәштә бит, димәк, ул да шул агу эчендә?!

Әтисе дә, урыныннан торып, ишек буйларын әйләнеп килде, тәрәзә пәрдәләрен тартыбрак ябып куйды. Чөнки Караболакта әле озын колак шымчылар да, кирәк урынга җиткереп торучылар да бар... Иртәш белән бәйле мәсьәләдә бигрәк тә сак булырга кирәк, анда бөтен нәрсә дәүләт сере хәзер...

—Теге вакытта Иртәштә нидер булганын күптән сизенә идек инде без,—диде ул, кызы каршына килеп утырып.—Авылдагы бөтен авырулар шул вакыттагы шартлаудан соң башланды бит... Тирә-күрше авылларны юкка гына башка урынга күчермәгәннәрдер... Нindидер зәхмәт, агулану белән бәйләнгән иде бу хәлләр... Ә без калдык... Хәтереңдә булса, коеларны күмделәр, елгага юлны яптылар, болын-кырларга кертми башладылар... Берничә елдан барысына да янадан рөхсәт бирделәр тагы...

—Ул вакытта Иртәштә атом бомбасы шартлаган, дип сөйләделәр бит, әти... Бәлки шуннандыр халыкның бу авырулары?

Нәбиулла үзе дә белә—авылда бу турыда бераз сөйләшеп алдылар да, тындылар... Чөнки авыл халкы өчен атом бомбасы белән гади бомба арасында аерма юк, ул аны белми һәм нинди нәтиҗәләргә китерәсен дә аңламый иде... Хәбибулла да үләр алдыннан: "Атом, үлем",—дип пышылдаган...

—Әгәр ул вакытта Иртәштән нindидер агу таралган булса, һаман шул суда, туфракта бит инде ул, кызым,—дип дәвам итте Нәбиулла, үзенчә фикерләп.—Әллә, чыннан да, шуннан чирлиме икән соң бу Караболак халкы? Әмма моны ничек ачыклыйсың? Сорасаң да, кем җавап бирер? Иртәштә бөтен нәрсә дәүләт сере бит анда... Анда эшкә кергән авыл егетләреннән кул куйдыралар икән, егерме биш ел дәүләт серен ачмаска, дип... Хәбибулла абыең да берни сөйләмәде бит, үлгәндә генә ике сүз әйтеп өлгерде... Бәлки ул безне шулар хакында кисәтергә теләгәндер...

—Әти, әллә Фәргатькә дә берәр нәрсә булдымы икән соң анда?—дип сорады Гөлҗиһан, үз уйларына бирелеп.—Болай кисәк кенә хәбәрсез араны өзәргә тиеш түгел иде бит ул, туй була дип торганда...

Ул хакта Нәбиулланың үзенең дә башына килде. Солдат хезмәте бит, ни булмас, бигрәк тә андый хәрби шәһәрдә, атом коралы белән бәйле җирдә... Әмма әниләренә хәбәр биргән ләса ул, исәнлеген белдергән...

—Ни булса да, көтеп карыйк әле, кызым,—диде ул, Гөлҗиһанның һаман шул турыда уйлавына борчылып.—Мин дә үз юлларым белән белешермен, бәлки әле үзенә дә берәр хәбәр килеп төшәр... Сиңа хәзер укырга барырга әзерләнергә кирәк, кызым, кая барасын хәл иттеңме әле?

—Мин Чиләбегә, медицина училищесына барырга ниятләдем, әти,—диде Гөлҗиһан, уйчан гына.—Нәселгә бер медик кирәк инде... Аннан,

насыйп булса, институтына да керермен, хәзергә училищедан башлыйм әле...

Нәбиулла бу хәбәрне ишетеп, чиксез куанды. Ул Гөлжиһанга бик зур өметләр баглый иде, чөнки анын акылы, тәвәккәллеге, тырышлыгы ирләргә алыштыргысыз... Үзенен авырый башлаганын сизгәч, Нәбиулла, гаиләсе, карт ата-анасы, авыру уллары турында уйлап борчылды, үзе белән бер-бер нәрсә булса, аларны кемгә калдырырмын, дип кайгырды... Анын бөтен карап торганы, өмете—кызы Гөлжиһан иде... Бу бала исән булса, нәсел югалмас, ул берсен дә авыр хәлдә калдырмас, ташламас... Анын медицина буенча китүе бигрәк тә яхшы, нәселләренә бер табип булыр ичмасам... Мондый каты зәхмәтләр заманында үләннәр, сулар белән генә дә булмый шул, гыйлемле белгечләр кирәк... Кызынын шушы юлдан китәргә ниятләвен ата кеше хуплап каршы алды, зур нәсел исеменнән ана үзенен фатихасын бирде...

## Унбишенче бүлек

Чиләбе медицина училищесына укырга кергәндә Гөлжиһан үзендә кан анализларынын бик начар икәнлеген белде...

Бу хәбәр анын түбәсенә китереп суккан кебек булды, ул, берни анламыйча, әле кулындагы кәгазьгә, әле врач хатынга карады. Өлкән яшьтәге врач хатын үзе дә бу анализлардан аптырады, монда язылганнар дөрес булса, бу кыз баланын алдагы язмышы инде хәл ителгән булып чыга ласа... Карап торышка ут чәчеп торган, багалмасы кебек сылу кыз, ә нинди кан... Атом тамгалы... Ягъни, анын инде балалары да булмаячак, булса да, алар гарип туарга мөмкиннәр, үзе дә гомер буе авырудан җәфаланачак... Хәер, хәзер Коншак тирәсеннән күпләр шундый начар кан белән килә...

—Коншактан килденме?—дип сорады ул, уйларын раслау өчен.

—Әйе, апа, Татар Караболагыннан мин... Ә сез кайдан белдегез?

—Канын сөйләп тора, сенлем, канын... Сез аннан барыгыз да тамгалы киләсез бит...

—Нинди тамга?—дип сорады Гөлжиһан, куркып.

Олы яшьтәге татар хатыны артыгын сөйләп тормады, ана артыгын әйтергә дә ярамый иде. Әмма ул бу сөйкемле татар баласын бик кызганды, ана ярдәм итәсе, аз гына булса да хәленен нинди булуын сиздерәсе килде.

—Башын әйләнәме?—дип сорады ул, Гөлжиһаннын авыру билгеләрен үзеннән әйттерәсе килеп.

—Әйе... Гел түгел, вакыты-вакыты белән...

—Борынын еш каныймы?

—Каный... Колакларымнан да кан киткәне бар... Теге вакытта, Иртәштә завод шартлагач, бик озак авырып яттым мин... Чәчләрем дә коелган иде, аннары янадан чыкты... Ул вакытта безнен класстан әллә ничә бала үлде, мин чак кына исән калдым...

Әйе, табип хатын бик яхшы хәтерли ул чакларны... Ул вакытта алар Чиләбегә китергән мәетләрне ярып өлгерә алмыйлар иде, мәрхүмнәрнен туганнары исә күмеп бетерә алмыйлар иде... Ә авыл халкы чебен урынына кырылды, аларга нидән авырганнарын да, нидән үлгәннәрен дә әйтергә ярамый иде... Хәтта врачлар да "Маяк" белән, радиация белән бәйле дәүләт серен ачмаска кул куйганнар иде...

—Ә хәзер хәлен ничек, сенлем?—дип сорады врач хатын, атомнын чираттагы корбанына кызганулы караш ташлап.

—Хәзер яхшы, апа... Кай вакытта тик торганда хәл бетә бетүен, авыз эче кибә, гел эчәсе килә... Аннан үтә... Безнен бөтен авыл шулай авырый, нәрсә икәнен беркем белми... Нәрсә сон миндә, апа?

Врач хатын аның соравын җавапсыз калдырды... Шактый вакыт Гөлҗиһанга текәлеп карап торганнан соң, кинәт кенә сорап куйды:

—Йөргән егетең бармы, сеңлем?

Гөлҗиһан мондый сорауны көтмәгән иде, бит алмалары кып-кызыл булып чыкты... Нигә аның егете турында сорый икән бу апа, әллә Фәргать турында берәр нәрсә беләме?

—Бар иде...—диде ул, ничек җавап бирергә белмичә.—Хәзер юк инде... Хәзергә юк...

—Булмаса, ашыкма, сеңлем,—диде табип хатын.—Бу кан белән сиңа, гомумән, ашыгып кияүгә чыгарга ярамый...

—Нигә, апа? Канның кияүдә ни катнашы бар, кый?!—диде Гөлҗиһан, мишәр үткенлеге белән.

Казан якларыннан килгән татар хатынына аның бу үткенлеге охшады, ахры, елмаеп куйды. Бу чая кыз тормышта югалып калырга охшамаган иде, әмма кайбер нәрсәләрне белеп торырга да тиеш... Соңыннан үкенмәс өчен...

—Кияүгә чыгарга мөмкин, сеңлем,—диде ул, Гөлҗиһанның аркасыннан кагып.—Әмма бала табу белән ашыкмаска кирәк...

—Ә нигә?—диде Гөлҗиһан, берни аңламыйча.

—Чөнки бу кан белән аларның авыру туулары мөмкин,—диде врач хатын, "гарип" дип әйтергә теле әйләнмичә.—Хәер, мондый очракта, гадәттә, бала бөтенләй булмый...

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһан тынсыз-өнсез калды... Ничек инде ул—бала булмый?! Гөлҗиһан ана була алмый, дигән сүз бит инде бу?! Нәселдә булмаганны! Нәрсә сөйли бу Чиләбе врачы?!

—Нишләп минем балам булмасын ди, апа?! Мин сау-сәламәт бит, кайдан чыгып әйтәсез моны? Безнең нәселдә андый кеше юк, барысында да бер оя бала...

Артыграк әйтеп ташлаганын аңлап, врач хатын аны юатырга тырышты. Бу авыл баласын шул хәтле кызу, кайнар булыр дип, кем уйлаган... Ә үзе турында дөреслекне барыбер белергә тиеш бит инде ул, бер өлешен булса да белергә тиеш... Калганын үзе аңлар, бу анализлар белән әле аңа күп газапланырга туры киләчәк...

—Син медицина училищесына килдең, сеңлем,—диде врач хатын, Гөлҗиһанны тынычландырып.—Тиздән үзең дә күп нәрсәләрне аңларсың... Әмма мин сине кисәтеп куюны кирәк таптым—кияүгә чыксаң да, бала табарга ашыкма... Аларның гарип туулары бар...

Гөлҗиһан ничек итеп врач бүлмәсеннән атылып чыкканын сизми дә калды... Бу сөйләшүне башкалар ишетмәдеме икән, дигәндәй, тизрәк якягына каранды, аның бәхетенә, ишек төбендә берәү дә юк иде... Гөлҗиһан йөгереп урамга чыкты, кешеләргә бәрелә-сугыла тулай торакка таба йөгерде... Аның тизрәк бүлмәсенә кереп бикләнәсе, бөтен кешедән, хәтта үз-үзеннән качасы килде... Бүген врач хатын аңа, күзенә карап, үлем карары чыгарган иде...

Озак, бик озак тулай торакның саргайган түшәменә карап ятты Гөлҗиһан...

Аның башында, йөрәгендә, җанында бер генә уй бәргәләнде—аның баласы булмаячак, булса да, гарип туачак... Нигә, нигә алай?! Гөлҗиһанга бит әле нибары унҗиде яшь, аның матурлыгыннан, чаялыгыннан Караболак егетләре телсез кала иде... "Нурыннан күзем камаша",—дип, Фәргать аның йөзенә туры карый алмый иде... Алар бит Фәргать белән өй тулы, итәк тулы балалар үстерү турында хыялланганнар иде! Ничек була соң бу — унҗиде яшендә, "Синең балаң булмый, булса да, гарип туа", диләр? Имеш,

анын канында тамга бар... Нинди тамга ул, кем салган аны Гөлҗиһанга, кайчан салган? Ничек котылырга ана бу куркыныч тамгадан?

Медицина училищесында укый башлагач кына Гөлҗиһан эшнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңлады... Аның канында кызыл кан күзәнәкләре кими башлаган, нәтиҗәдә, генетик код бозылган, хромосома төзәлмәслек булып үзгәргән иде... Бу исә халык телендә "ак кан" дип аталган кан рагына, ягъни, лейкимиягә китерергә мөмкин икән... Боларны белгәч, Гөлҗиһан өнсез калды... Тумаган балалары турында уйлап утыра, ә үзенең хәле һаман яшәү белән үлем арасында икән бит әле... Теге вакытта ул могҗиза белән исән калды, ә аның классташлары шушы авырудан китеп барганнар икән бит... Каннары агуланган... Каннары бозылган... Каннары беткән... Авылда кинәт кенә сукыраючылар, аяк-куллары череп ятучылар да шушы кан авыруыннан икән бит, ә халык аларның нидән чирләгәннәрен, нәрсәдән үлгәннәрен дә белми...

Ә кан нидән шулай кинәт кенә үзгәрә—бу турыда дәреслекләрдә кистереп әйтелмәгән, һаман шул тышкы һәм эчке факторларга кайтарып калдырганнар... Бу бозык каннан ничек котылу юллары да медицина китапларында ачык күрсәтелмәгән—һаман шул режим, дөрес туклану, дөрес яшәү, саф һава, имеш... Иң соңгы очракта, тәнендәге авыру канны даими рәвештә алыштырып торачаклар икән... Әмма ул тиздән тагы шундыйга әйләнәчәк...

Боларны белгәч, Гөлҗиһан кара кайгыга төште...

Аның тәне буенча авыру, агулы кан ага иде...

Гөлҗиһан үзе ныклап авырмый да кебек, әмма каны тамгалы... Һәм ул кайчан да булса үзен бер сиздерергә мөмкин... Кайчан килеп чыгар бу хәл, кайчан бу мәкерле авыру Гөлҗиһанны аяктан егар—беркем белми... Шул исәптән, Гөлҗиһан үзе дә белми... Шушы мизгелдән аның аяк астыннан җир китте, яшәвенең мәгънәсе калмады... Нәрсә дип яшәргә хәзер бу тормышта, нинди шатлыгы бар аның хәзер? Үлем көтеп, яисә гарип балалар табу өчен яшәргәме? Караболакның иң гүзәл, иң чая кызы Гөлҗиһанны шундый язмыш көтеп торыр дип кем уйлаган?

Эчтән шундый утлар яндырса да, тыштан Гөлҗиһан барыбер сер бирмәде, элеккеге Гөлҗиһан булып калырга тырышты. Ул элеккечә сокланырлык матур, сылу, тырыш иде, группаларындагы бөтен эшләрдә башлап ул йөрде... Тик зур яшькелт күзләрендәге тирән сагышны гына Гөлҗиһан беркая яшерә алмады, аның бөтен җан сыкравы шул күзләрендә чагыла иде...

Уку барышында Гөлҗиһан тагы бер тапкыр теге татар табибы белән сөйләшеп карарга булды, чөнки аның кем белән булса да борчуларын уртаклашасы, киңәшләшәсе килә иде... Кызга бүген аның кайгысын аңлаган кешенең ярдәме кирәк иде...

—Апа, мин үз авыруымны беләм хәзер,—дип башлады ул сүзен, табип хатынның күзләренә карап.—Тик нишләргә кирәклеген генә белмим... Нишләргә соң миңа бу авыру белән?

—Яшәргә, сеңлем,—диде врач хатын, берни булмагандай.—Мәгънәле, матур итеп яшәргә... Үлем көтеп утырмаска...

Бу сүзләрдән Гөлҗиһан аптырап китте...

Әллә көлә инде аннан бу врач апа? Үзенең нинди хәлдә икәнлеген белә торып, ничек матур итеп яши алсын инде хәзер Гөлҗиһан?

—Үземнең гомерлек чирле икәнемне белә торып, ничек онытылып яшәп булсын инде ул, апа?!—диде ул, күз яшьләрен көчкә тыеп.

Врач урыныннан торды да Гөлҗиһан янына килеп басты. Ул кызны, кулларыннан тотып, тәрәзә каршына алып килде.

—Әнә, кара әле, сеңлем, урамга,—диде ул, Гөлҗиһанны иңнәреннән

кочып.—Әнә, култык таягына таянып, бер аяксыз кеше килә—яши бит? Әнә, кара күзлектән, дөм-сукыр хатын атлый—ул да яши, әле янында кечкенә баласы... Әнә атлаган саен гарипләр—алар да яшиләр, үз тиннәре белән гаилә коралар, балалар үстерәләр... Тормыштан ямь таба беләләр... Алар белән чагыштырганда, синең бөтен нәрсәң дә бар—яшьлегең, чибәрлегең, акылың, гыйлемең... Иң мөһиме—дүрт саның исән, күзләрең күрә, колакларың ишетә... Нәрсә, бу бәхет түгелмени?

—Ә каным?—дип бүлдерде аны Гөлҗиһан.—Мондый кан белән мин дә шундый хәлгә калырга мөмкин бит... Теләсә кайсы вакытта берәр хәл килеп чыгарга мөмкин... Шуны белә торып, ничек тыныч кына яшәргә була, апа җаным?

—Ә син ул турыда уйлама,—диде врач хатын, Гөлҗиһанны каршысына ук утыртып.—Бу тирәдә хәзер ике кешенең берсендә шундый кан, шундый авыру... Үзләре бу хакта белмиләр дә... Сиңа булачак медик булганга гына әйттем, авылда яшәсәң әле һаман белмәс идең...

—Үлеп киткәнчеме?

—Анысы инде, сеңлем, Алла кулында... Яшәргә теләсәң—яшәрсең, үләргә теләсәң—үләсең инде... Мин үзем егерме ел инде шундый кан белән яшим менә...

Гаҗәпләнүдән Гөлҗиһан сүзен әйтә алмый торды... Һәрвакыт елмаеп йөргән мөлаем, җыйнак бу татар врачы турында авыру дип һичкем әйтмәс... Ә аңа кайдан килде икән бу куркыныч чир, аны бу якларныкы да түгел, диләр бит...

—Безнең авылда Иртәштәге шартлаудан соң халык авырый башлады, ә сез нидән шулай булдыгыз?—дип сорады Гөлҗиһан, үзенә хас үҗәтлек белән...

—Мин бу якларда күптән эшлим инде, сеңлем,—диде врач хатын, бик ачылып китмичә генә.—Әлгәсе миңа да эләккәндер... Бер һаваны сулыйбыз, бер суны эчәбез бит...

Ул монда Сөнкүл больницасы ачылган көннән бирле эшләвен, радиациянең эчендә йөзүен бу яшь кызга әйтеп тормады... Болай да артыграк ычкындырган иде инде... Гөлҗиһанда ул үзенең яшьлеген күргән кебек булды, бу якларга эшкә җибәргәндә ул да шулай ут чәчеп тора иде... Аннан Иртәш, Сөнкүл бу Казан кызыннан бөтенесен тартып алды—яшьлеген дә, сәламәтлеген дә, туасы балаларын да... Бүгенге көндә аның гаиләсе дә, балалары да юк, булмаячак та... Мондый кан белән бу татар кызын да шундый язмыш көткәнгә ул аны бераз булса да кисәтәсе, авыр, катлаулы тормышка әзерлисе килде...

—Син авыруың турында уйлама, сеңлем,—диде ул аңа, чәчләреннән сыйпап.—Әлбәттә, Чиләбе якларыннан башка җиргә күчеп карарга да була, әмма бу тамга кая барсаң да синең белән китәчәк... Син шуның белән яшәргә өйрән... Иң мөһиме—каныңны кыздырма, ягъни, борчылмаска тырыш, нервларыңны сакла... Үлем турында уйлап йөрмә, тәкъдиреңә кайчан язылган—ул болай да шунда киләчәк, әйе бит?

—Әйе, кый...—диде Гөлҗиһан уйчан гына.—Безнең Таһир бабай да шулай ди, "Әҗәлне чакырып китерә алмассың, килсә, куып җибәрә алмассың", ди...

—Бабаң бик дөрес әйтә,—диде врач хатын.—Безнең якларда да шулай диләр... Син кайгырма, сеңлем, хәзер медицина көчле, бәлки әле бу авырулардан да дәва табарлар... Үзең шушы юлдан китеп тә бик дөрес эшләгәнсең, сәламәтлегең үз кулыңда булачак... Башкаларга да ярдәм итәрсең, Алла боерса...

Аның яныннан Гөлҗиһан шактый тынычланып чыкты...

Әйе шул, кан начар булу—ул әле үлем дигән сүз түгел бит... Әнә бу врач апа да "егерме ел шулай яшим," ди бит... "Ике кешенең берсендә хәзер шушы авыру," ди... Ә алар авылында, Караболакта, бөтен кешедә шушы авыру инде болай булгач... Ә алар бу хакта бөтенләй белмиләр дә..."Бәлки белмәүләре яхшыдыр да,—дип уйлады Гөлжиһан, авылдашларын күз алдына китереп.—Белеп нәрсә эшли алырлар иде? "

Врач ана борчылмаска, кызмаска кушты: "Ни булса да кайнарланма, гел салкын канлы булырга тырыш",—диде. Ә ул Фәргать турында уйлауга ялкынланып яна башлый... Бу хәл Гөлжиһанның үзеннән тормый шул, анын йөрәге, күнеле шулай өзгәләнә... Онытa алмый ул Фәргатьне, онытырга теләми дә... Гөлжиһан башка егетләргә күтәрелеп тә карый алмый, үзен гел Фәргатьнең ярәшелгән кызы итеп хис итә... Бу чынлап та шулай бит, алар ярәшкән егет белән кыз иделәр... Бөтен Караболак аларнын туйларын көтә иде... Ә Фәргать Иртәштән бер елдан да кайтмады, икенче елны да күренмәде, өченчесендә дә барлыгын хәбәр итмәде... Әниләренә телеграммалар жибәреп, телефоннан сөйләшеп тора икән, әмма алар янына да бер тапкыр да кайтып карамаган... Исәнлеккә—исән, әмма кайтмый, Миасска да, Караболакка да... Гөлжиһанга ник бер хат-хәбәре булсын?! Әйтерсен лә ул гомерендә дә Гөлжиһан дигән кызны белмәгән, сөймәгән, ана өйләнергә вәгъдә бирмәгән... Димәк, ул Гөлжиһанны оныткан, тормышыннан сызып ташлаган...

Ә Гөлжиһан аны бер генә минутка да исеннән чыгара алмый...

Кич ятса да, иртән торса да—күз алдында, елмаеп, күрше егете Фәргать басып тора... Анын кебек матур елмая торган тагы берәр кеше бармы икән дөньяда? Фәргать елмайганда анын бит урталары балаларныкы кебек уймакланып керә, коңгырт күзләреннән нур түгелә... Анын кара чәчләре дулкын-дулкын булып бөдрәләнеп кин ак мангаена төшеп тора... Пәвлевандай гәүдәсеннән, кин жилкәләреннән көч-гайрәт бөркелә... Андый матур һәм батыр кешене Гөлжиһан гомерендә дә очратканы булмады һәм очратмас та инде... Фәргатькә ни генә булса да ул мәңге Гөлжиһанның хыялында яшәячәк...

Менә алар, анын хыялларында, ак кар баскан Караболак урамнары буйлап йөриләр, балалар кебек кочаклашып чана шуалар... Менә алар бергәләп Караболак болынынннан жиләк жыялар, Биташ чишмәсеннән су эчәләр, мәгарәдә качыш уйныйлар... Менә алар житәкләшеп булачак нигезләренә кайталар... Ишек алды тулы яшел чирәм... Шул чирәмдә Фәргать белән Гөлжиһанның балалары уйнап йөри... Тукта... Тукта, Гөлжиһанның балалары булмаячак бит... Булса да, алар гарип туарга мөмкин... Димәк, Фәргатьнең кайтмавы, аларнын туйлары булмыйча калу—хәерлегә генә булгандыр?... Фәргатьнең күзенә ничек карар иде Гөлжиһан, әгәр ана була алмаса? Бу турыда уйлагач, Гөлжиһанның йөрәге өзелеп төшә язды, чигәсендә кан шаулый башлады... Әгәр гарип балалар тапкан булса? Ул бит Фәргатьне гомергә бәхетсез иткән булыр иде! Димәк, эшнең шушылай бетүе аларнын икесе өчен дә яхшы булган... Таһир бабай әйткәнчә, ни булса да, хәерлегә булган?

Таһир бабасы исенә төшүгә, Гөлжиһан жинел сулап куйды, жаны тынычланды, каны чигәсендә шауламый башлады... Менә кем белән киңәшергә кирәк иде ана... Ул әти-әнисенә, әби-бабасына үзенең авыруы турында берни әйтмәде, үз хәлен алардан яшерде. Ә нигә аларны борчырга, хәвефкә салырга? Врач апа дөрес әйтә, бу турыда, гомумән, уйламаска кирәк... Авыртулары әлегә түзәрлек, хәзер Гөлжиһан даруларда да рәт белә, үз организмын да яхшы өйрәнде... Башы әйләнеп, чигәләре шаулый башласа, монын нинди хәбәр икәнлеген шунда ук анлый, бөтенләй егылмас өчен

дәва хәстәренә керешә... Шуңа күрә өйдәгеләр аның нинди куркыныч авырудан газапланганын сизмиләр дә, белмиләр дә... Алар барысы да Гөлҗиһанга тормыш терәге, киләчәктә ярдәмче буларак, зур өметләр белән карыйлар... Ә менә хәзер Гөлҗиһанның үзенә ярдәм, төпле киңәш кирәк... Юк, авыру мәсьәләсендә түгел, алдагы тормышы буенча Гөлҗиһанга төпле олылар сүзе кирәк...

Ул киләсе елга укуын бетерә...

Алга таба кая барсын, укуын дәвам итсенме, эшкә керсенме? Эшкә керә икән, Чиләбедә калсынмы, әллә бу тирәләрдән еракка качсынмы? Әллә инде шушы авыру-зәхмәт арасына, Караболак якларына эшләргә кайтсынмы? Фәргатьне көтсенме, әллә инде аның белән араны мәңгегә өзсенме, үз тормышы турында уйласынмы? Болар хакында ул ачылып, сәбәпләрен әйтеп, әти-әнисенә сөйли алмый, ә Таһирҗан бабайга сыя... Гөлҗиһанны бары тик ул гына аңлаячак һәм дөрес киңәшен дә бирәчәк...

Һәм ул Таһир бабасына ачылырга булды...

## Уналтынчы бүлек

Бу юлы Гөлҗиһан Караболакка җәйге ялга зур ниятләр белән кайтты... Аңа алга таба язмышын хәл итәргә кирәк иде...

Әмма Гөлҗиһанны авылда берсеннән-берсе авыр, борчулы хәбәрләр көтеп тора иде... Кайтып керүенә, ул әтисен урын өстендә күрде. Өрлектәй таза, нык ир, аяксыз калып, урын өстенә яткан... Аның гәүдәсе дә шешенеп киткән, ул, караватына сыя алмыйча, кисеп аударган имән кебек, авып төшкән...

—Әти, нәрсә булды сиңа?—дип, Гөлҗиһан аның янына ташланды.

Ата кеше иң авыр вакытта кызының кайтып керүенә чын күңеленнән куанды, әйтерсең лә, коткаручысы кайткан иде... Ул хәтта сызлануларын да онытып торган кебек булды, әкрен генә торып утырырга тырышты...

—Менә... аяклар сызлый башлады әле, кызым,—диде ул, үз хәленә үзе уңайсызлангандай.—Бөтенләй йөрми башладылар...

—Нигә башта ук миңа хәбәр итмәдегез соң?—дип өзгәләнде Гөлҗиһан, нишләргә белмичә.—Чиләбедә яхшы врачларга күрсәткән булыр идек...

—Коншакта булдым мин,—диде әтисе сүрән генә.—Ревматизм, шуңа сызлый, диделәр... Кайткач, бөтенләй аяксыз калдым менә...

—Анализларың ничек соң?—дип сорады Гөлҗиһан, сагаеп калып.

—Алары Коншакта калды инде, бирмәделәр... Болай...куркыныч түгел, общий авыру, диделәр... Хәзер авылда мондый авырулар күп бит инде, кызым... Ике йортның берсендә кайсы аяксыз, кайсы кулсыз, дигәндәй... Караболак халкының шулай кырылуына Коншакта ияләнеп беткәннәр инде, "общий авыру", диләр дә, кәгазь тоттырып, кайтарып җибәрәләр... Аннан кеше тиз арада зиратка күчә... Тагын яңа зират башладык бит инде, әйтергә генә җиңел...

Гөлҗиһан икенче көнне үк Коншакка чыгып китте. Әтисенең анализларын аның үз күзләре белән күрәсе, чын дөресен беләсе килде. Әмма Коншакта аңа анализларны күрсәтергә ашыкмадылар, "Анда ревматизм, бу яшьтә була торган хәл инде ул", диюдән узмадылар... Аларның бу битараф җавабы Гөлҗиһанны гаҗәпкә калдырды. Нинди яшь ди ул, әтисенә илле дә юк бит әле! Аларның нәселе—туксанга, йөзгә хәтле авыртуның ни икәнен белмәгән нык нәсел бит! Нигә имән кебек ир кинәт кенә аяксыз калган әле? Аның анализлары ни күрсәтә?

Йөри торгач, әтисенең анализларын тапты, соратып ала алды Гөлҗиһан. Аларга күз ташлау белән, аның аяк астында җир чайкалып куйды—әтисендә,

Гөлжиһандагы кебек, кан авыруы иде... Һәм шунын өстенә, шикәр чире, ягъни, диабет... Ә ул, чыннан да, ашыгыч чара күрмәсәң, аяк-кулларның череп коруын көт тә тор... Бу исә кешене үлемгә китерә... Ә аны, ревматизм дип, "общий авыру", дип, ялганлап, авылга үләргә кайтарып җибәргәннәр...

Гөлжиһан Коншак врачларын елый-елый сүкте, аларны наданлыкта, рәхимсезлектә гаепләде, әтисен, кичекмәстән, юллама белән, Чиләбе больницасына җибәрүләрен таләп итте... Шулай шаулап, бүлмәдән-бүлмәгә йөри торгач, баш врач рөхсәте белән, Гөлжиһанның әтисен Чиләбе ФИБына җибәрергә булдылар, моның өчен хәтта районнан машина да бирделәр... Иртәгә иртүк юлга чыгарга ниятләп, Гөлжиһан янадан Караболакка кайтып китте. Өйдәгеләр бу хәбәрне өметләнеп кабул иттеләр, чөнки авылда, дәваланмыйча ятып, Нәбиулланың үлеп китүе дә бар иде...

Бу кайтуында Гөлжиһан кайгылы хәбәрләрне күп ишетте. Авыл халкы күпләп үлә, чебен урынына кырыла башлаган... Караболакта инде бишенче зиратны ачканнар, көн саен яна мәет, ди... Гөлжиһан белән бер класста укыган Мәйсәрә, Сажидә, Мәрзия үлеп киткәннәр, Әгъзамне читтән алып кайтып күмгәннәр... Алар белән теге вакытта кырда эшләгән укытучы абыйлары да үлгән, тагы берничә укытучы кинәт кенә якты дөнья белән саубуллашкан...

Боларны ишеткәч, Гөлжиһан өйдәгеләрдән яшеренеп кенә, үксеп елады... Ул бу укучыларны, укытучыларны һәрберсен тере итеп күз алдына китерде, күңеленең мондый зур югалту белән килешәсе килмәде... Мәрхүмнәрнең барысы да аның иптәшләре, авылдашлары, остазлары бит... Хәзер алар Караболакның бишенче зиратында яталар... Әле яшь дә башламаган килеш... Гөлжиһан да шулар арасында, бишенче зиратта булырга мөмкин иде бит... Ничек котылырга соң бу афәттән, ничек Караболакны бу бәладән коткарырга? Югыйсә тиздән бөтен авыл зиратка күчеп бетәчәк...

Гөлжиһан әтисенә авыртуны баса торган көчле дарулар бирде, укол ясады, авыруның хәле бераз җиңеләйгәч, Таһир бабаларына барып кайтырга булды... Гөлжиһанның бабасы белән кинәшәсе әйберләр шактый җыелган иде...

Таһиржан бабасы намаз укый иде, Гөлжиһан, ишек янагына сөялеп, аның укып бетергәнен көтеп торды. "Әле ярый бу картлар нык,—дип уйлады ул, сөенеп.—Аның әби-бабасы да, Таһиржан бабай да авыруның ни икәнен белмиләр, Аллага шөкер... Әкрен генә үзләренчә яшәп яталар... Зиратка яшьләр күчә..."

—Үзем дә сезгә барып килергә тора идем әле, кызым,—диде Таһир карт, намазлыгын җыя-җыя.—Атаң авырып китте бит менә... Һәр көн менеп, үземчә өшкереп тә тошәм... Хәле бераз җиңеләйгән кебек була да, тагы сызлана башлый... Авыруның катысы эләккән атаңа, кызым, катысы, ычкындырырга исәбе юк...

—Әтине иртәгә Чиләбе больницасына алып китәбез, Таһир бабай,—диде Гөлжиһан.—Бәлки операция ясатырга да кирәк булыр әле...

—Шулай укмы, кызым? Бәлки шулай яхшырак та булыр... Алла биргән гомерен аягында йөреп уздырсын иде дә...

—Синнән яшереп булмый инде, Таһир бабай, әтинең авыруы начар,—диде Гөлжиһан, керфегендәге яшьләрен сөртеп.—Миндә дә шул авыру—начар кан... Дәвалап та бетми торган ул...

Таһиржан карт шактый вакыт дәшмичә, уйланып утырды. Ул болар хакында Гөлжиһан әйтмәсә дә белә иде ахры...

—Күп кешедә хәзер шундый кан, кызым,—диде ул, уйчан гына.—Тамгалы кан... Моны халык үзе белми генә...

—Элек алай булмаган бит, Таһир бабай! Син үзең сөйли идең бит, безнең авылда Алыплар нәселе яши, дип... Бу Иртәш шартлагач шулай булдымы соң?

—Бу хәлләр тагы да иртәрәк башланды, кызым, Иртәштә шул атом дигәннәрен эшли башлауга, һавага агуы таралды... Шул суга, туфракка сеңде, күккә таралды... Бу тирәдә йөзәр, хәтта меңәр чакрым ераклыкта, халык шул афәттән зыян күреп яши...

—Нидер эшләргә кирәк бит инде, Таһирҗан бабай!—диде Гөлҗиһан, кыза төшеп.—Бөтен авыл үлеп бетә бит инде, әнә, бишенче зиратны ачкансыз! Бәлки безгә моннан күчәргә кирәк булгандыр?

—Кайда күчсәң дә, тамга салынган инде, кызым,—диде Таһир карт, сабыр гына.—Бөтен илендә, дөньясында шушы хәл... Кеше үз башына гыйфритне шешәдән чыгарды... Бүген безнекеләр зиратка күчә, иртәгә чират башкаларга да җитәчәк... Әмма алар бу хакта белмиләр, уйламыйлар әле...

—Юк, бабай, юк!—диде Гөлҗиһан, кыза төшеп.—Болай бөтен авыл белән үлем көтеп утырырга ярамый! Нәрсә булган бу Караболакка? Нидер эшләргә кирәк бит инде!

Таһирҗан карт оныгын тынычландырырга ашыкты, чөнки аңа борчылырга ярамаганын белә иде ул.

—Без, сонгарак калып булса да, эзләнергә тотындык, кызым,—диде ул.—Коншактан, Чиләбедән врачлар чакыртып торабыз, бу чирләрнең нидән икәнен, ничек дәваланырга кирәклеген сорыйбыз... Алар дөресен әйтми, әлбәттә, “гомуми авыру”, диләр дә, берәр төймә каптырып китәләр... Бәлки үзләре дә белмидер, бәлки бу хакта әйтергә ярамыйдыр... Әмма бу зәхмәтнең Иртәш белән бәйләнгәнлеге билгеле безгә... Хәбибулла абыең да, үлгән вакытта: “Атом”,—дип үлде бит... Димәк, аның авыруы да шул атом зәхмәтеннән булган... Ә ул—дәүләт сере, аның хакында сорарга ярамый, сорасаң да әйтмиләр... Халык аптырашта хәзер, кая барып төртелергә белгән юк...

—Әмма авылда авырмаучылар да бар бит!—диде Гөлҗиһан, бу ачышыннан үзе дә аптырап.—Карт як чирләми, менә сез дә бирешмисез карттай-картнәйләр белән... Димәк, бу чир сайлап кына ябыша, сайлап кына алып китә?

—Анысы Аллаһ кулында инде, кызым,—диде Таһирҗан карт, сөйләшүнең шушы якка кереп китүенә куанып.

Чөнки ул белә—бу авыруга бирешмәгән карт-коры барысы да диндәге, намазлы кешеләр. Алар Караболак суына якын килмиләр, ерак булса да, Биташ чишмәсенә йөриләр... Алар яшьләр бик тиз ияләнгән харам ризыкларга, кибет колбасаларына кагылып та карамыйлар, хәләл ит белән генә тукланалар... Кибетләрдә киштә-киштә аракы тора, мәҗлесләрдә хәзер өстәл-өстәл аракы, ә олы як монын нәрсә икәнлеген белмәде бит...

—Караболак халкы диннән чыгып бара, кызым, диннән,—диде ул, зур үкенеч белән.—Менә шуңа күрә зур сынауларга дучар булдык инде, атом ул сәбәпче генә адәм өчен... Динсез, Алласыз яшәгән еллар өчен газабын күрә халык... Ураза вакытында мәктәпләрдә балаларның авызларын көчләп ачтырган укытучылар барысы да китеп бетте инде...

Бабасының бу сүзләреннән Гөлҗиһанга бик куркыныч булып китте. Мәсьәләнең бу ягын ул бөтенләй уйламаган иде, бабасы шундый нәтиҗәгә килер, дип көтмәгән иде... Димәк, бу авырулары Гөлҗиһан өчен дә сынау? Сынау һәм җәза? Ә нәрсә өчен? Гөлҗиһан бу дөньяда беркемгә дә бернинди начарлык эшләмәде бит, ул әле яши генә башлады, ә авырулары инде бугаздан ала... Димәк, эш Гөлҗиһан уйлаганга караганда да катлаулырак икән... Бу хәлләрдән врачлар ярдәме белән генә дә котылып булмаска мөмкин икән... Ә Гөлҗиһанның бу хакта уйлаганы да булмады... Ана Таһир бабасы алдында унайсыз булып китте. Теге вакытта ул аңа күпме догалар өйрәткән иде бит, аны аякка бастыру өчен күпме тырышкан иде, күпме Биташ суы эчергән иде... Чиләбегә китте дә, Гөлҗиһан

шуларның барысын да онытты... Аны үз кайгылары, үз борчу-мәшәкатьләре басты...

—Суны һаман Биташтан эчәсенме әле, бабай?—диде ул, кечкенә вакытларын исенә төшереп.

—Шуннан, кызым, шуннан...Әле бүген дә барып кайтырга тора идем, атана да өшкереп алып менермен, дигән идем...

—Алайса, үзем генә барып кайтыйм?—диде Гөлжиһан, Таһир бабасы белән сүзе бетеп җитмәсә дә.—Үземнең дә күптән күрәсем килә иде Биташны, бераз зәңгәр балчык та алырмын...

Таһирҗан картның оныгын болай гына чыгарып җибәрәсе килми иде, чөнки аның Гөлжиһанга әйтәсе бик җитди сүзе бар иде. Ул оныгын җәйгә озаккарак кайтыр, дип уйлаган иде, әйтер сүзе өчен иркенрәк вакыт көткән иде... Ә вакыт бөтенләй булмаска охшаган, әнә, иртәгә үк атасы белән Чиләбегә чыгып китәргә торалар... Шуна күрә ул Биташка Гөлжиһан белән бергә барып кайтырга уйлады, ана әйтәсе сүзен дә шунда әйтергә булды... Һәм алар, тиз генә җыенып, авыл башындагы Биташка чыгып киттеләр...

Гөлжиһан Караболакны бик-бик сагынган иде...

Чиләбедә күпме яшәсә дә, ул шәһәргә ияләнә алмады, биек, таш йортлар салкыныннан җәй көне дә тунды, өшеде... Суын да яратмады ул Чиләбенең, андагы хлор тәменә ияләнә алмады, шәһәр читләрендә колонка күрсә, авылны искә төшереп, йотылып эчә иде... Туктаусыз ыгы-зыгысына, шау-шуына да күнегә алмады Гөлжиһан Чиләбенең... Шәһәрдә аның бердәнбер юанычы—уку иде, гыйлем гаме аны тулысынча үзенә йотты... Урамда татарлар очраса бик сөенә иде Гөлжиһан, ул хәтта аларның артларыннан ияреп бара... Казаннан килгән концертларны да йотылып тыңлый, ана Уралның арьягы дөнья чите булып тоела иде... Һәм аларның да, Гөлжиһан кебек, татарча сөйләшүләре, җырлаулары ана бер могҗиза булып күренә иде...

Әмма барыбер Караболакка җитми...

Җире-суы агуланган булса да, авыл башын тоташ зиратлар чорнап алса да, дөньядагы бер генә урын да Гөлжиһанга Караболак кебек якын һәм кадерле булмас иде... Юк, булмас иде... Туган авылында бер генә йорт, бер генә кеше калса да, хәтта беркем яшәмәсә дә, җанына җылы эзләп, Гөлжиһан барыбер бирегә кайтып егылыр иде... Менә ни өчен Таһирҗан бабасы күченеп китәргә атлыгып тормаган, әти-әнисе, әби-бабалары шушы фаҗигале Караболакта торып калганнар... Аларның Гөлжиһанны, балаларын туган туфраксыз, туган нигезсез калдырасылары килмәгән...

Ә Караболак, элеккеге тормышы белән, мәж килеп яшәп ята, әйтерсең лә аның өстеннән атом афәте үтмәгән, әйтерсең ярты авыл зиратка күчеп бетмәгән... Исән кеше яшәү турында уйлый шул, Караболак халкы—бигрәк тә... Зарланып, мескенләнеп, елап утырса, Караболак буламыни инде ул? Караболак елгасын яр буйлатып чорнап алган тимер чыбыклар да инде күптән куе үлән арасында калган, халык кайдан теләсә шуннан йөри... Суга төшә, су ала... Елгада бала-чага, малай-шалай чупырдый, каз-үрдәкләр йөзеп йөри, яр буендагы үзәнлектә бозаулар арканланган... Нәкъ Гөлжиһан кечкенә чактагы кебек, барысы да үз урынына кайткан... Гөлжиһан әле Караболакның кораллы сакчылар тарафыннан сакланган чакларын да яхшы хәтерли... Ак халатлы, битлек кигән кешеләрнең коеларны җимереп йөрүе исендә... Аннан яңадан барысын да рөхсәт иттеләр... Халык та, сакчылар китүгә, елга буендагы тимер чыбыкларны алып ташлап, суын файдалана башлады... Гөлжиһан үзе дә, әби-бабалары күрмәгәндә, Караболак суына чумып чыгарга ярата иде... Ә җәй көне эсседә кая барасың?

—Халык һаман Караболак суын файдалана икән...—диде ул, елга ягына борылып карый-карый.

—Караболакның суы начарланды, кызым, аны халык та белә,—диде Таһир бабасы.—Әмма ишле гаиләләр кая барсын, мал-туарга суны Биташтан ташып эчереп булмый бит... Мин үзем чишмәгә йөрим йөрүен, әби-бабаң да Биташтан эчәргә тырышалар... Әмма сездә дә мал-туарга суны Караболактан ташыйлар... Шуларның итен бөтен авыл ашый, сөтен эчә... Бер җирдә яшәгәч, барысы да уртак инде аның, кызым, качам дисәң дә качып котылып булмый...

Шулай сөйләшә-сөйләшә, Караболак елгасы башланган Алабуга сазлыкларын да үттеләр, бер читтә җимерек Урыс Караболагы авылы урыны утырып калды... Анда эшләгән көннәрен Гөлҗиһан әле һаман онытмый, ул анда үлеп беткән иде бит инде... Әле ярый янында әлеге дә баягы һаман шул Таһир бабай булган, аңа барып әйтергә классташы Рәшидә булган...

—Рәшидә ничек, Таһир бабай, күренгәне бармы?—дип сорады ул бабасыннан.

—Ул инде тәмам җинеләеп бетте, кызым,—диде бабасы.—Каты авыруы шулай башына бәрде, ахры, бахырның... Үзе болай әдәпсезләнеп йөрми йөрүен, үзенчә сөйләшеп кенә йөри... "Гөлҗиһан брач булып кайта да мине терелтә",—ди икән...

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге сулкылдап куйды. Ничек ярдәм итәргә соң Рәшидәгә, аңа ярдәм итеп буламы икән инде?

—Теге вакытта аны Чиләбедән килгән врачлар карап йөргәннәр иде бит, булмый, дип киттеләр... Анда—монда алып барганнары юктыр бит тагы, бабай?

—И, кызым, кем йөрсен инде аның артыннан?—диде бабасы.—Әнисе үлде, әтисе үлем көтеп ята, шул исән туганнары карап тора инде, аларга рәхмәт... Тиленәр йортына бирергә кызганалар, безнең авылда андый гадәт юк бит ул... Кешегә бер зыян да юк бит аннан, хәзер авылда Рәшидә кебекләр шактый инде, кызым... Тумыштан шундый булып туалар...

Алар теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, сүз һаман шул авыруларга барып терәлә иде... Шактый вакыт, тын гына, һәркем үзенекен уйлап барды. Әтисен больницага салып, Караболакка кайткач, Гөлҗиһан Рәшидә янына барырга булды. Ярдәм итә алмаса да, хәлен белер, әнә бит ул һаман аны көтеп ята икән... "Гөлҗиһан брач булып кайткач, мине терелтә", дип әйткән бит... Ул элек тә гел Гөлҗиһан тирәсендә була иде шул, кем кыерсытса да, аның янына йөгереп килә иде...

Гөлҗиһан үзенең хәлен Рәшидәнеке белән чагыштырып карады да, тетрәнеп китте. Йа, Раббым, Гөлҗиһанның хәле түзәрлек икән бит әле, ул үз акылында, үз аягында, укып йөри, башкаларга ярдәм итә ала... Ә Рәшидә нинди хәлдә менә хәзер... Югыйсә, алар бер класста укыдылар, бер кырда эшләделәр, бер суны эчтеләр, бер авылда үстеләр бит... Гыйбрәтләнсәң, гыйбрәтләнер нәрсәләр күп монда... Аның уйларын сизгәндәй, Таһир карт та әйтеп куйды:

—Әйе, кызым... Күккә карап фикер йөрт, җиргә карап шөкер ит, дигән борынгылар... Һәр нәрсә чагыштырганда күренә шул... Бу дөньяда гыйбрәт алыр нәрсәләр күп, бик күп...

Кояш кичке якка борылса да, әле көн эссесе сүрелмәгән иде...

Дөньяда берни дә үзгәрмәгән—нәкъ Гөлҗиһан кечкенә чактагы кебек... Баш очында менләгән бөҗәк, кош-корт гөжләп, гүләп тора, һәрберсенең ашыгыч үз эше бар... Әнә бик еракта, җәйге рәшә арасында тибрәнеп, Урал таулары күренеп тора... Бик ярата Гөлҗиһан шул Урал тауларын, әллә Фәргатьнең бала чагы, яшьлеге шунда үткәнгә, бу таулар аңа аерата якын... Өйләнешкәч, алар Фәргать белән Урал тауларына сәяхәт итәргә уйлаганнар иде... Фәргать Миасс тирәсендә әллә нинди борынгы тау

куышлары, серле, төпсез күлләр барлыгын әйткән иде... Имеш, анда да заманында Алып кешеләр яшәгән икән, алар Туфан суыннан шунда качып исән калганнар, ди... Ул якта халык шулай сөйли икән... Аннан ул Алып кешеләр менә шушы Аллакүл, ягъни Биташ буйларына килеп урнашканнар, Гөлҗиһаннар авылын да алар төзеп калдырган... Бу хакта ана Таһир бабасы да күп тапкырлар сөйләгән иде бит...

Гөлҗиһаннар авылын үткәч, Караболак елгасы Зәбир авылы янында Тимеряз елгасына коя, аннан Сәнәргә барып төшә... Урыслар Сәнәрне "Синар" диләр, ул карталарга да шулай язылган... Бабасының әйтүе буенча, элек Караболак белән Сәнәр елгалары кушылган урында, ике арада халык алтын юган... Димәк, бу туфракларда, бу тауларда алтын да бар, дигән сүз... Бәлки ул скиф курганнарыннан су белән юылып чыккан алтын-көмеш булгандыр... Шул алтын-көмешләрен алып, Сәнәр Исәткә, Исәт Тубылга, Иртәшкә барып кушыла, аннан Караболак сулары Обь елгасына ук барып төшә... Аннан—Төньяк Боз океаны... Фәргатьнен, Караболак суы буйлап, шул якларга ук барып кайтасы килә иде... Күпме хыяллары чәлпәрәмә килде, тормышка ашмыйча калды... Караболак суы да хәзер инде алтын-көмештән тормый, аннан хәзер төньяк Боз океанына кадәр агу ага...

Ә Аллакүл-Биташ бу афәттән бераз читтәрәк, тау араларына урнашкан, шуна күрә илгә килгән бәла аңа тәэсир итмәгән кебек... Балачакта Гөлҗиһан авыл балалары белән бирегә еш килә иде, алар караңгы төшкәнче тау куышларында качыш уйныйлар иде... Алып Адәм басып гыйбадәт кылган ташны Гөлҗиһан беркемгә дә бирми иде, ул бары тик аныкы гына иде... Ул малайларның да инде күбесе юк...

—Бу күлне күктән иңгән таш урынында барлыкка килгән дип сөйлиләр иде,—диде Таһир бабасы, Биташның аяк очына килеп утырып.—Элек халык бу тирәгә намаз укырга, теләк теләргә йөргән, хәзер юк инде...

—Бабай, хәтерлисеңме, син миңа монда бер шигырь өйрәткән идең? Мин шуны мәктәптә укыгач, чак кына куып чыгармадылар, хәтерлисеңме?

Таһирҗан карт елмаеп куйды. Булган иде шул андый хәл... Соңыннан Хәбирә килен бераз үпкәләп тә йөрде, балага әллә нәрсәләр өйрәткәнсең, дип... Ә ул Казанда укып йөргәндә ишеткән иде бит бу шигырьне... Аннан мәрткә киткәч, яңадан исенә төште...

—Әйбәт шигырь иде ул, кызым... Шәп сөйли идең син аны кечкенә вакытта... Хәзер оныткансыңдыр инде?

—Син нәрсә, бабай, шундый шигырьне онытам диме инде? Мин аны Чиләбедә редакциягә дә илтеп биргән идем әле, басмадылар, безнең көннәргә туры килми, фикере искергән, дип... Бер дә искермәгән, менә, тыңла әле, бабай!

Әй, милләтнең сылу балалары!
Дөнья тетрәткән Хан бабалары!
Ханыңны—барча гаскәреңне
Дошманнар узып китте...
Куәтле чаклар кайларга китте?
Җыелыгыз, түгелгән күз яшьләр!
Атлагыз алга! Күрсен көндәшләр.
Чәч гайрәт! Баһадир баһалы Жан Син!
Фикереңң бер мәмләкәт, син ана жансың.
Гайрәтле бер милләт житәкчесе бит без,
Ялкынлы милләтнең аркасы бит без!
Яшәде дөньяда баһадир бабаң,
Диде ул, якты тормышта яшәсен балам!

Яшә син дөньяда, ал гыйлем кулга
Тугры юл, карама унга да сулга!
Дөньяны гизеп йөр, бар алга таба,
Гизде бит дөньяны һәм Чыңгыз бабан!
Арма син! Алдан бар, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Таһирҗан карт оныгына сокланып карап торды, ул бер дә үзгәрмәгән иде... Ә аның тәнендә һәм җанында нинди авырулар, газаплы сызланулар барлыгын бик яхшы белә бит Таһир карт... Гөлҗиһан өчен гаять кайгылы хәбәр аның үзендә дә бар, әмма ул аны әйтергә җай таба алмый...

—Бу—безнең татар милләте турында шигырь, кызым, онытма син аны,—диде Таһир карт, аны тыңлап бетергәч.—Менә күрерсең, заманалар үзгәрер... Милләт турында һәр дөрес сүз алтын бәясенә торыр... Халыкны уятыр өчен, шул вакытта менә бу шигырь дә кирәк булыр...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Таһир карт үзе белән алып килгән савытларына чишмәдән су тутыра башлады. Гөлҗиһан да бит-кулларын юды, учлап-учлап боздай салкын су эчте, бөтен тәне-җаны рәхәтләнеп, сафланып киткән кебек булды...Ул, бала вакыттагы кебек, аякларын күл суына тыгып утырды, бер мизгелгә булса да, дөнья кайгылары онытылып торды... Гөлҗиһан, иелеп, яр буеннан бер уч зәңгәр балчык алды, ул, көмеш нурлар чәчеп, бөтен тир-юньдә таралып ята иде...

—Бу балчык өстендә кыш көне дә кар тормый,—диде Таһир бабасы, бер капчыкка зәңгәр балчык тутырып.—Үзе салкын кебек тоелса да, нindiдер эчке җылылыгы бар аның, хәтта карны да эретә ул... Аны белеп, дөрес файдаланырга гына кирәк... Теге вакытта мин сине шуның белән генә аякка бастырдым бит, бөтен тәнеңне, җәрәхәтләреңне шуның белән сыладым... Чиләк-чиләк, арба-арба ташыдык без аны ул вакытта, мунчада шуңа ләгәнгә кереп ята идең...

Гөлҗиһан боларның барысын да хәтерли... Ул вакытта аңа бары тик шушы чишмә суын гына өшкереп эчерделәр, аны шушы зәңгәр балчык белән генә төреп тоттылар... Әйтерсең лә ул чагында болар аның тәнендәге бөтен зәхмәтен суырып алдылар... Башкалар тормаска авып калганда да, Гөлҗиһан аягына басты бит, әмма авыруы Чиләбедә тагы үзен исенә төшерде...

Гөлҗиһан зәңгәр балчыкны учларына кысты, битләренә тидерде... Балчык, тере җан иясе кебек, хәрәкәтләнеп, кыймылдап куйды, рәвешен үзгәртте, ул бер җылынды, бер суынды... Гөлҗиһан аны иснәп карады—зәңгәр балчыктан су исе, җил, күк исе килә иде... Тормышның үз исе...

"Гаҗәп,—дип уйлады Гөлҗиһан.—Училищеда болар турында укытмыйлар да, сөйләмиләр дә бит... Ә аяк астында күпме могҗиза аунап ята...Нигә моны галимнәр өйрәнми икән? Халык медицинасы дигәннәре шушы буладыр инде ул... Тик, Таһир бабасы әйткәнчә, бу балчыкны файдалануның да үз тәртибе бар икән шул... Ул теләсә кемгә файда бирмәскә мөмкин икән... Бу шифалы су да, Аллакүлнең зәңгәр балчыгы да иманы нык кешеләргә генә ярдәм итә, ахры..."

Еллар үткәч, Гөлҗиһан бу шифалы балчыкның фәндә "глауконит" дип аталуын, аның бары тик биредә генә табылуын белер... Чернобыль авариясеннән соң бу балчык дару сыйфатында радиациягә дучар булган кешеләргә эчерә башларлар... Зәңгәр балчыкның кеше организмыннан радионуклидларны чыгаруы билгеле булыр... Чирен биргән кебек, Аллаһ аның дәвасын да бирә икән бит...

Бабасының Гөлҗиһанга әйтер сүзе бар иде...

Ул аны күләгәрәк урынга, тау куышына таба алып китте... Әмма, нигәдер, бу хакта һаман сүз башларга ашыкмады, Гөлҗиһаннын үзенен бу хакта сүз кузгатуын көтте... Картнын хәбәре Фәргать турында иде... Һәм ул хәбәр авыр, кайгылы хәбәр иде...

—Менә шулай яшәгән инде безнен халык, кызым,—диде ул, кытыршы ташны куллары белән сыйпап.—Динне дә белгән, табигатьне дә файдаланган, йөзгә дә житкән... Ә хәзер иллегә дә житмиләр... Син Исмәгыйль бабанны хәтерләмисендер инде, безнең әти ул, шул әйтә торган иде: "Заман ахырында каты чирләр, кисәк үлемнәр күп булыр",—дия иде... Менә шул көннәр житте, ахры, кызым... Һәм безнен нинди куәтле Алып Ханнар нәселенә дә үтеп керде бу зәхмәт...

Карт һаман кирәкле сүзен әйтә алмый интегә иде...

Аны әйткәч, Гөлжиһаннын бөтен тормышы асты-өскә киләсен, үзгәрәсен ул белә иде... Әмма мондый хәбәрне әйтмичә калырга да ярамый... Бәхетенә, бу хакта Гөлжиһан үзе сүз башлады.

—Бабай, мин укып бетергәч, кая китим икән?—диде ул, үз борчуларын исенә төшереп.—Киләсе язга безнен чыгарылыш бит инде... Авыру булгач, мина сайлап алу мөмкинлеге биреләчәк, ягъни, үзем теләгән жиргә китә алам... Бу кан белән Чиләбе өлкәсендә калмаска кушучылар да бар... Сезне ташлап, еракка китәсем дә килми... Фәргать белән дә һаман бер-бер ачыклык юк, суга төшкәндәй юкка чыкты... Биргән вәгъдәсендә тормады...

—Фәргатьнең хәле авыр, кызым,—диде Таһир карт, бу хакта сүз кузгалуга.—Ул Иртәш больницасында ята икән...

Гөлжиһан урыныннан сикереп торды, авып китмәс өчен, кыя ташына тотынды.

—Ә син кайдан белден, бабай?—диде ул, хәле бетеп.

—Иртәштә күреп кайтканнар,—диде бабасы, бик тирән кереп торасы килмичә.—Хәле бик авыр ди баланын...

—Нәрсә булган соң ана, Таһир бабай? Нигә әйтеп бетермисен, нәрсә булган Фәргатькә?!—дип өзгәләнеп кычкырып жибәрде Гөлжиһан, тау куышын яңгыратып.

Анын тавышы, мәгарә эчләрен айкап чыгып, сулкылдап, кире үзенә кайтып егылды... Тирә-юньдә шактый вакыт "Фәргатькә... Фәргатькә... Фәргатькә..." дигән кайтаваз янгырап торды...

—Фәргать сукырайган, кызым,—диде Таһир карт.

—Су -кы -рай -ган?

Гөлжиһан бу сүзне телен чак әйләндереп әйтә алды, анын күз аллары кинәт каранғыланып китте, тирә-ягы тау куышындагы кебек кап-каранғы булып калды... Күл буендагы таш сыннар анын тирәсендә әйләнә башладылар һәм, Гөлжиһан белән бергә, гөрселдәп яр буена аудылар... Аңына килгәндә, ул Биташнын аяк очында ята иде, бабасы анын кардай агарган битенә учлап салкын су сибә... Гөлжиһан әле сөйләшә дә, эндәшә дә алмый, ярыммәет хәлендә, күл буенда ята... Таһир бабасы дога кыла да су сибә, дога кыла да су сибә... Ниһаять, Гөлжиһан телен тибрәтер хәлгә житте, анын беренче сүзе тагы "Фәргать" иде...

—Фәргать... Фәргать кайчан сукырайган?—дип сорды ул, янып кипшеренгән иреннәрен чак кыймылдатып.

—Армиядән кайтасы җәйне шулай булган, кызым,—диде Таһир карт, анын аяк очына ук килеп утырып.—Иртәштә көчле давыл булган, ә боларны агулы күлдә эшләткәннәр... Солдатлар бит, кем алардан сорап торсын... Менә шунда сукырайган ул...

—Алайса, шуңа хәбәр бирмәгән инде ул,—диде Гөлжиһан, әкрен генә торып утырып.—Бу хәлдә кеше күзенә күренәсе килмәгәндер...

—Анда кеше кайгысы булдымы икән, кызым? Күз хәтле күзне тишеп агызгач, башка җирләрен нишләтте икән ул агу? Анысын үзе генә беләдер инде...

Бабасының бу сүзләреннән Гөлҗиһанның йөрәге өшеп, туңып китте, бер мизгелгә, тибеше дә тукталып торды кебек... Тагы егылмас өчен, Гөлҗиһан кесәсеннән тизрәк даруларын алды, аларны учлап эчеп җибәрде, артыннан Биташ суын йотып куйды... Бабасы аңа гаҗәпләнеп карап тора иде...

—Үзем дә хәзер шулар белән генә яшим, бабай,—диде Гөлҗиһан, аннары аның күкрәгенә капланып, сулкылдап елап җибәрде...

Үзенең егерме яшеннән шушындый хәлдә булуыннан да, Фәргатьнең сукыраю хәбәреннән дә, әтисенең операция көтеп ятуыннан да үзәге өзелеп, ул чарасызланып елый башлады... Таһир карт аны туктатмады, кайгысын эченә җыйганчы, күз яше белән чыгарып бетерүен яхшырак дип тапты...

Елап аргач, Гөлҗиһан бит-күзләрен юарга күл өстенә иелде... Су төбеннән аңа, томырылып, Фәргать карап тора иде... Юк, ул сукыр түгел, аның конгырт күзләрендә әйтеп бетергесез сагыш, сагыну күрде Гөлҗиһан... Үзен өзелеп, тилмереп көтү, чиксез ярату күрде... Аңа Гөлҗиһан кирәк, бик кирәк, әмма ул аңа йөк булырга да теләми иде...

Аллакүл суында Гөлҗиһан үзенең бөтен сорауларына да җавап тапкан кебек булды... Юк, үзенең яшәү мәгънәсен тапты—ул Фәргатькә кирәк иде... Бөтен кешегә караганда да, бүген ул Фәргать өчен аеруча кирәк иде... Һәм Гөлҗиһан үзенең гомерен аңа багышларга тиеш иде...

—Мин аны эзләп табарга тиеш, бабай,—диде ул, инде тыныч, ныклы тавыш белән.—Ул минем ярдәмгә мохтаҗ... Һәм мин аны бу хәлдә ялгыз калдыра алмыйм...

—Син аның ярәшелгән яры, балам,—диде Таһир карт, кызның тынычланганына куанып.—Дөньяда әллә нәрсәләр була, үлеп терелгән кешеләр бар... Синеке кебек саф мәхәббәт күп нәрсәләр эшли ала... Иң мөһиме, кешенең күңел күзе сукыр булмасын, барына шөкерана итә белсен... Аллаһ авыруны ничек бирсә, шулай алырга да мөмкин, кызым... Болар барысы да безгә сынау инде, сынау...

Таһир карт аркасын кыя ташына терәп утырды да, күл өстенә карап, әкрен генә мөнәҗәт әйтә башлады... Бу мизгелләрдә ул әллә үз-үзе белән сөйләшә, әллә Гөлҗиһанга нидер аңлатырга тели, әллә күл суларына нидер әйтә иде... Бик борынгыдан килгән бу моң Гөлҗиһанның иң ерак кан күзәнәкләренә хәтле үтеп керде, аны уятырга, яшәртергә теләде, көчле, иманлы булырга өндәде...Бу—кечкенәдән Гөлҗиһан ишетеп үскән Караболак мөнәҗәте, Алып Адәм турында көйле җыру иде... Гөлҗиһанга иң авыр вакытларда, үлем белән тартышып ятканда, Таһир бабасы аның баш очында гел менә шушы мөнәҗәтне әйтә иде... Бу—Караболак ирләренең Коръән ашларында күмәкләп әйтә торган мөнәҗәтләре, аны тыңлаганда Гөлҗиһанның тәннәре чымыр-чымыр килә, күзләре яшьләнә иде... Йөзгә җиткән ак сакаллы картларның, бергәләп, моңлы ирләр тавышы белән шулай мөнәҗәт әйткәннәрен Гөлҗиһанның башка бер җирдә дә очратканы булмады... Бу мөнәҗәт Караболак татарларының мең еллык яшәү тәртибе, әхлак кагыйдәләре иде...

Бу дөньяда иң хөрмәтле—Адәм, диган,
Бу дөньяны зиннәтләде Адәм, диган.
Үз хөрмәтен үзе белсә—Адәм, диган,
Үз хөрмәтен беләлмәсә, хайван, диган.

Ин әүвәле кирәк нәрсә—Иман, дигән,
Китап-Коръән сүзләренә инан, дигән.
Китап-Коръән сүзләренә инанмасаң,
Ул кешене шайтан, дигән, дошман, дигән.

Икенче иң кирәк нәрсә—Намус, дигән,
Намусыңны югалтмаска тырыш, дигән.
Байлык өчен динен саткан адәм заты
Ике дөньясын да бергә сатыр, дигән.

Өченче иң кыйммәт нәрсә—Гакыл, дигән,
Гакылсызның тәүфикъ ягы такыр, дигән.
Гакылсызда оят та юк, әдәп тә юк,
Кеше исемен күтәрүе гаҗәп, дигән.

Дүртенчесе иң кыйммәтле—Әдәп, дигән,
Әдәп кеше мәхәббәткә сәбәп, дигән.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфикъ та юк,
Кеше исемен күтәрүе гаҗәп, дигән.

Бишенче иң кирәк нәрсә—Инсаф, дигән,
Инсафлының күңеле дә бик саф, дигән.
Әдәп-Инсаф динебезнең яртысыдыр,
Расүлуллаһ шулай диеп хәбәр биргән.

Алтынчысы иң кыйммәтле—Күңел, дигән.
Күңле бозык кеше—кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә гел, үлеп җиргә күмел, дигән.

Җиденче иң кыйммәтлесе—Сабыр, дигән,
Сабыр кеше зур бәхетләр табыр, дигән.
Бер дә юктан ачуланып, дөнья бозу,
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.

Янә тагы кирәк нәрсә—Шөкер, дигән,
Ниґъмәткә шөкер сүзе табыр, дигән.
Яткан җирдә Ходай кичер дию хурлык,
Сәбәп эзләп, төз юл белән йөгер, дигән...
Расүлуллаһ юлы белән йөгер, дигән...

Адәмгә ниләр кирәк? Моны Караболакта бик яхшы беләләр иде... Нинди генә шартларда да, хәтта муеннан агу эчендә яшәсәң дә, иң беренче чиратта, Кеше булып калырга кирәк иде... Караболакта исә кеше булып калуны әдәп-әхлакта, яхшы холыкта, миһырбанлыкта күрәләр иде... Таһирҗан бабасы Гөлҗиһанга боларны тагы бер тапкыр исенә төшерде, нинди генә кайгылар килсә дә, сабыр итә белергә, Кеше булып калырга өндәде...

Алар әкрен генә кайтырга кузгалдылар...

Күл буендагы җимерек таш сыннар, тирән уйга батып, аларны озатып калдылар... Үз гомерләрендә күпне күрделәр, күпне кичерделәр инде алар, таш гасырларны, кешелекнең беренче чорын искә төшереп, әле менә һаман басып торалар... Бу тау куышларында беренче кешеләрнең аяк эзләре, учак урыннары саклана... Бөек татар тарихы саклана... Әле генә Аллакүл буенда

булып киткән татарларда Алып Ханнар нәселе саклана... Һәм дәвам итәргә тиеш... Атомнарны җиңеп, бу нәсел, бу милләт җирдә калырга тиеш, чөнки алар адәмгә ниләр кирәген инде беләләр...

Авыл башында аларга каршы йөгергән бер хатын-кызны күреп, Гөлҗиһан курка калды. Әллә соң әтисенә берәр нәрсә булганмы, Ходаем? Чәчен-башын туздырып үзләренә каршы йөгергән бу хатын-кызны башта ул бөтенләй танымады, чөнки алар авылында мондый кеше юк иде... Әмма якынрак килгәч, аның йөзен күргәч, Гөлҗиһан имәнеп китте, бу—классташы Рәшидә иде... Аның киезләнгән чәчләре яулык астыннан бүлтәеп чыгып тора, йөзен газап җыерчыклары баскан, өстендәге күлмәге искереп, таушалып беткән... Ул йөгереп килгән килешкә Гөлҗиһан алдында туктап калды, оялып, бер читкә карап тора башлады. Гөлҗиһан үзе аның кулларыннан тотып алды, яратып һәм кызганып күкрәгенә кысты... Рәшидә, язмыш тарафыннан кыерсытылган бала кебек, борынын аның җилкәсенә төртте... Гөлҗиһан Таһир картка кайта торырга кушты, үзе Рәшидә белән калды. Ул капчыгындагы Биташ суы белән Рәшидәнең тузанлы бит-кулларын юды, башындагы яулыгын селкеп япты.

—Син, Рәшидә, әйдә минем белән безгә кайт, мин сиңа матур күлмәкләр бирермен,—диде ул, нәрсә әйтергә белмичә.

—Ә миңа төймә кирәк,—диде Рәшидә, аңа ихлас күзләре белән карап.

—Төймә? Нинди төймә, мәрҗәнме?

—Юк,—дип көлә башлады Рәшидә, бала чагындагы кебек пырхылдап.—Кесәңдәге төймәләр турында әйтәм мин... Син брач бит хәзер... Мине терелтергә кайттың авылга, мин беләм...

Гөлҗиһан ашыгып кесәләренә тыгылды һәм аннан бер уч дару тартып чыгарды... Әйе, бу аның йөрәктән, каннан, басымнан, бавырдан эчә торган дарулары... Ә Рәшидә каян белде икән бу турыда? Хәер, эш андамыни, әгәр бу дарулар Рәшидәгә дә ярдәм итә икән, һичшиксез, барысын да бирергә кирәк... Аларның барысында да бер авыру бит инде... Халык теләндә әйткәнчә, елга авыруы...

—Мин сиңа бирәм аларны, Рәшидә,—диде ул, даруларны аның учына салып.—Тик син аларны берәмләп кенә эч, яме? Көнгә өчне генә эч... Артык ярамый...

—Беләм инде, беләм,—диде Рәшидә, даруларны тизрәк кесәсенә яшереп.—Өчкә хәтле генә саный беләм инде мин, биш класс укыдым бит... Мин бу төймәләрне башкаларга да бирәм әле, яме? Тик көненә өчне генә! Артыгы ярамый! Брач шулай диде...

Шулай диде дә, Рәшидә авыл буйлап торып йөгерде. Караболакта бүген аннан да бәхетле кеше юк иде... Ул өй саен кереп, авыл халкына берәмләп Гөлҗиһанның даруларын таратып йөрде... "Брач апа бирде, көненә өчәрне генә эчәргә кушты",—дип, һәрберсен өйрәтеп чыгып китте... Ул Гөлҗиһаннарга күлмәккә килергә дә онытккан иде. Гөлҗиһан үзе олы бер төенчек өс-баш җыеп, энеләре артыннан Рәшидәләргә җибәрде... Күңеленнән, алга таба да авылга булдыра алганча дарулар алып кайтырга, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә ниятләп куйды...

Классташы Рәшидәне ташламаска да күңеленнән карар итте Гөлҗиһан... Рәшидә белән очрашу аның бөтен күңелен айкап ташлады, ул тагы үз хәлен аныкы белән чагыштырып карады... Әтисен, сукыраеп яткан Фәргатьне күз алдына китерде... Аларның барысына да Гөлҗиһан кирәк иде... Алар аның ярдәменә мохтаҗ, аннан ярдәм көтеп яталар... Гөлҗиһанның хәзер үз хәлен уйлап, мәлҗерәеп, авырып ятарга хакы юк иде, вакыты да юк... Иртәгә иртүк ул әтисе белән Чиләбе больницасына чыгып китәргә тиеш иде...

## Унҗиденче бүлек

Гөлҗиһаннның этисен Чиләбенен халык телендә ФИБ дип аталган фәнни-тикшеренү институты больницасына салдылар...

Иртәш буйларыннан, Коншак тирәсеннән каты авыру белән килүчеләрнен барысын да шушында яткыралар иде... Халык телендә бу больница турында берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр йөри, имеш, монда авырулар өстендә ниндидер сынаулар үткәрәләр икән, мона калэр кеше эчеп карамаган өр-яна даруларны шуларда сынап карыйлар, ди... Кеше шуны эчеп үлсә—үлә, калса—кала икән... Ә үзе барыбер шунда бара, чөнки Караболакларны да, Мөслимнән килгәннәрне дә башка жиргә алмыйлар, туп-туры ФИБка жибәрәләр... Авыл халкынын үзенә әйтмәсәләр дә, аларнын "нурланыш"тан һәм рактан чирләгәнен белә Чиләбе врачлары, һәм шуна күрә аларны ФИБта гына кабул итәләр... Бередән бик сирәкләр генә исән чыга, алар да, бераз вакыт үтүгә, кабат монда әйләнеп кайталар... Мәетләрнен исә авылга кумәргә коры гәүдәләрен генә кайтаралар, аларнын бөтен эчке әгъзалары, тәжрибә өчен, больницада алып калына... Бавыр-бөерләргә күпме радиоактив матдәләр, плутоний, стронций утырган, кеше шулардан күпме түзгән—барысын да белергә кирәк совет врачларына... Мәетләрнен хәтта сөякләрен, тешләренә хәтле шулай аерып алып өйрәнәләр, шуна күрә татар авылларына кумәргә жип-жинел буш гәүдәләр генә кайта...

Коншактан килгән ашыгыч ярдәм машинасы Гөлҗиһаннның этисен туп-туры шушы ФИБка китереп салды...

Бәхетенә, Гөлҗиһан биредә практика үткән иде, авыруларга укол ясарга, жәрәхәтләрне бәйләргә дә ул шушында өйрәнде. Каннан курыкмагач, житезлеген дә искә алыпмы, аны еш кына операция ясаганда чакыралар иде... Гөлҗиһан беркайчан да ике әйттерми, бер карауда нәрсә кирәген анлап ала, бөтен эшне жиренә житкереп эшли... Шуна күрә аны ФИБта бик яраттылар, укып бетергәч, үзләренә эшкә дә чакырдылар... Гөлҗиһан авырулар арасында бик күп татарларны, шул исәптән, үз авылдашларын да еш күрә иде... Аларнын барысында да диярлек Гөлҗиһандагы кебек авыру иде...

Әтисен ФИБка урнаштырырга да Гөлҗиһан үзе йөгереп йөрде, кирәкле врачларын, палатасын тапты, бар мәшәкатьләрне дә бик тиз һәм ыгы-зыгысыз ерып чыкты... Бәхетенә, анын таныш врач апасы Галия дә биредә эшли иде, Гөлҗиһаннның әтисенен бөтен анализларын, кәгазь белән бәйле эшләрен ул үз өстенә алды. Гомерендә беренче тапкыр Гөлҗиһан үзенен шушы һөнәрне сайлавына сөенеп бетә алмады, язмыш аны менә шушы көннәр, шушы сынаулар өчен әзерләгәнен анлады... Ин мөһиме, Гөлҗиһан башкаларга кирәк, ул кешеләргә ярдәм итә ала... Монын дөньяда бик зур бәхет икәнлеген Гөлҗиһан менә хәзер анлый башлады...

Әмма көн саен кеше кайгысын күреп торунын нинди газап икәнлеген ул әле анлап бетерми иде... Язмыш ана монысын да бик тиз күрсәтте—врачлар, жыелып кинәшкәннән сон, әтисенен аякларын кисәргә кирәк, дигән карарга килделәр... Анализлар күрсәтүе буенча, анын аякларында кузәнәкләр инде үлеп баралар, моны вакытында кисеп ташлап, туктатмасан, черү бөтен гәүдәгә таралырга мөмкин... Бер генә нәрсә бәхәс уятты—тезеннән кисәргәме аякларын, бот төбеннәнме? Тездән киссән, ул әле тормышка яраклы кеше булырга мөмкин, бот төбеннән киссән, тере гарип булып, кеше кулына калачак... Әлбәттә, аны карарлар, Гөлҗиһан үзе дә, әнисе дә, әби-бабасы да аны гомер буе карарга әзерләр... Әмма кеше кулына карап ятырга әтисе үзе риза булмаячак... Әгәр авыру бик таралмаган икән, тездән кисү белән генә чикләнергә кирәк иде...

Бу авыр эштә Гөлҗиһанга арадашчы булырга туры килде... Ул врачлар

белән дә, әтисе белән дә үзе сөйләште... Бу үткен татар кызының еламыйча, каушамыйча шундый житди, куркыныч нәрсәләр турында ачыктан-ачык сөйләшә алуы урыс врачларын да гажәпләндерде... Ә үз хәлен Гөлжиһан үзе генә белә иде, бу көннәрдә аңа йөрәген йомарлап, учына кысарга туры килде. Хисләрен, күз яшьләрен тышка чыгарырга аның хакы юк иде... Әтисе, аяксыз калып, аның күзенә карап ята иде... Эшне сузган очракта, аның үлеп китүе дә бар...

Гөлжиһан әтисенә боларның барысын да әйтмәде, әмма операция кирәклеген әйбәтләп аңлатты... Әтисе бу авыр хәбәрне сабыр гына кабул итте, башка чара юклыгын ул аңлый иде... Нәбиулла кызына бөтен күңеле белән ышанды, язмышын хәл итүне дә аңа тапшырды. “Син ничек дип әйтсәң, шулай булыр, кызым, син шушына укыган бит, беләсең”,—диде ул, сүзне озайтып тормыйча. Шулай итеп, Нәбиулланың ике аягын да тездән кисү хәл ителгән иде...

Врачлар тагы бер тапкыр авыруның анализларын алдылар, тикшерделәр һәм, хәзергә аякларны тездән кисү дә житеп торыр, дигән нәтижәгә килделәр... Башка очрак булса, аны утын тумраны кебек тураклап ташларлар иде, әмма монда кызы Гөлжиһан, таныш врачлар булгач, тәжрибәләр белән мавыкмаска булдылар... Караболак, Мөслимнән аяк-кул кистереп ятучылар бер Нәбиулла гына түгел, мондый операцияләр Чиләбе врачлары өчен гадәти бер нәрсәгә әверелгән иде...

Элеккеге тәжрибәсен искә алып, операция вакытында Гөлжиһанга да катнашырга рөхсәт иттеләр... Врачлар якын туганнарның мондый эштә катнашуларын өнәп бетермәсәләр дә, Гөлжиһан башка мәсьәлә иде... Беренчедән, ул монда барысының да яратканы, аларча әйтсәк, “любимчигы”, икенчедән, Гөлжиһан үзе бик ялынып сорады... Врачлар аңа: “Үз күзләрең белән күрү күңеләңә авыр булыр, кереп торма”,—дисәләр дә, авыр вакытында әтисе янында буласы килде Гөлжиһанның. Бу мизгелләрдә ул аның сакчы фәрештәсенә әверелгән иде...

Янында кызы булгач, Нәбиулла да тыныч иде... Ул Гөлжиһанның күзләренә карап, наркоз йокысына китте... Гөлжиһан исә операция өстәле янында шәфкать туташына әйләнде... Язмыш аңа шундый авыр сынау әзерләгән иде—әтисенең аякларын Гөлжиһан үзе кисеште... Ул врачларга кирәкле әйберләрен биреп торды, бинт, мамык, башка кирәк- яракларын әзер тотты... Битлек астыннан аның зур яшел күзләре генә түгелергә әзер булып, мөлдерәп карап тора иде... Әмма гажәп авыр бу эшне башкарып чыкканда, аның ник бер керфеге селкенсен, ник бер тапкыр куллары калтырасын... Шушы операция вакытында нәкъ маңгай турыннан, бер тотам чәче агарганын соңыннан гына күрер Гөлжиһан... Бу—егерме яшьлек кыз баланың әтисе кайгысыннан агарган тәүге чәчләре булыр... Аннан соң Фәргать өчен агарыр аның чәчләре, балалары өчен чал төскә керер...

Ә хәзергә Гөлжиһан әтисенең аякларын кисүдә катнаша...

Чөнки, катнашмаса, ул үләргә мөмкин...

Тормышның кырыслыгы, рәхимсезлеге аны да катыландыра, кырысландыра... Һәм шушы рәхимсез тормышка каршы ул керпе кебек йомарлана, инәләрен чыгара... Әтисе янында елап утырып мәсьәләне хәл итеп булмаганын ул яхшы аңлый... Таһир бабасы әйтмешли, “бу хәлдән чыгуның сәбәбен эзләп, төз юл буйлап йөгерә...” Әле аңа бөтен гомере буена шулай йөгерергә, тормышның һәр бәхетле мизгеле өчен жан атып көрәшергә, һәр кайгы-хәсрәт өчен дөрли-дөрли янарга туры киләчәк... Тәкъдирендә язылган гомере беткәнче, шулай янып, көрәшеп яшәргә туры киләчәк...

Операциядән соң да Гөлжиһан аның яныннан китмәде, уколын да үзе

ясады, яраларын да үзе юып бәйләде, ашатуын да үзе ашатты... Әллә кызының янында булуына, әллә авылдан бертуктамый якыннары килеп торганга, Нәбиулла күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Ул үзе дә нык, көчле ихтыярлы кеше иде, гел терелү уе белән яшәде. Таһиржан карт исә Аллакүл сулары, өшкергән зәңгәр балчык, төрле үлән-тамырларны Караболактан ташып кына торды, үзе килә алмаса, кеше артыннан биреп җибәрде... Гөлҗиһанның җәйге ялда булуы да ярап торды, уку вакыты булса, ул әтисе янында болай көне-төне була алмас иде...

Гөлҗиһан әтисендәге сабырлыкка, ихтыяр көченә гаҗәпләнеп бетә алмады...

Тиздән ике аяксыз калса да, ник бер ыңгырашсын, зарлансын, өметсезлеккә бирелсен! Әле: "Чуен аяк яхшырак булырмы, агачы да ярап торырмы хәзергә",—дип планнар корып ята... Җәрәхәтләре бераз төзәлүгә, тиздән тимер аяклар ясатырга килештеләр, Таһиржан бабасы кайдандыр белешеп тә кайтты... Гөлҗиһан шуна да игътибар итте—бу больницада алар авылыннан шактый кеше ята иде һәм алар аның әтисен бер минутка да ялгыз калдырмадылар... Әйтерсең лә, бөтен Караболак монда күчкән—рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр, авыл хәлләрен белешәләр, үз кайгыларын онытып торып, шушы шартларда да к е ш е булып яшәргә тырышалар... Бирердә бөтен Коншак районыннан татарлар ята, әмма иң күбе, Мөслимнән, Татар Караболагыннан, Үзбәгәрәктән, Мусакайдан, Сарыкүлмәктән булып чыкты... Алар, ахырзаман әрвахлары кебек, торган урыннарыннан кубарылып, шушы урынга җыелганнар... Кемнедер монда, исән калырмын, дигән өмет китергән, кемнедер—көчле авыру, кемнедер—үлем куркынычы бирегә куып керткән... Бөтен Иртәш, Караболак, Сәнәр, Теча буйлары купкан... Врачларның үзара чыш-пыш сөйләшүләреннән шуны да аңлады Гөлҗиһан—болар барысы да Иртәш белән бәйле авырулар икән... Атом чирләре... Әмма бу хакта кычкырып әйтергә ярамый...

Шушы тирәдә эшләгәндә, Гөлҗиһан күп нәрсәләр ишетте...

Иртәштә "Маяк" дип аталган химкомбинат барлыгын ул инде ишетеп белә иде, анда атом бомбасы ясалуы турында да халык күптән сөйли... Әмма ул комбинаттан тирә-якка туктаусыз радиация таралып ятуын ул әле белми иде... Әмма нәрсә ул—радиация, аның кешегә нинди зарары бар, бу хакта халыкка берни әйтмиләр, хәтта матбугатта бу сүзне кулланмыйлар да иде... Ә монда, больницада, бу турыда аз-маз сөйләшәләр, ычкындыргалыйлар... Әмма артыгын әйтмиләр...

Ул арада, җәйге каникуллар бетеп, училищеда укулар башланды...

Гөлҗиһанның әтисен дә, килгән машинасы белән, яңадан Караболакка алып кайтып киттеләр... Инде хәзер Гөлҗиһан әтисе өчен тыныч иде—ул, тимер аяк белән булса да, яңадан җиргә басты, яши, эшли башлады... Аның янында фәрештә кебек Гөлхәбирәсе, әти-әнисе, әүлиядәй Таһир карт, балалары, Караболак халкы бар... Алар аны бергәләп яңадан аякка бастырдылар, үз җилкәләрен куйдылар, инде аварга ирек бирмәячәкләр... Ул хәзер Гөлҗиһанның ярдәменә мохтаҗ түгел, аның ярдәменә бүген иң мохтаҗ кеше—Фәргать иде... Әтисе кайгысы белән ул аның турында бераз уйламыйча торса да, Фәргать хәсрәте Гөлҗиһанның башыннан беркайчан да чыкмады... Фәргать исенә төшү белән, аның җаны сулкылдый башлый, ул үзен нәрсә өчендер гаепле кебек сизә... Гөлҗиһан белә—ул Фәргатькә ярдәм итәргә тиеш, әмма—ничек итеп? Фәргать үзе аннан ярдәм сорамый, әмма Гөлҗиһан шушындый хәлдә калса, ул аңа ярдәмгә килер иде... Дөнья читенә барыр иде ул Гөлҗиһанны эзләп, аңа ярдәм итәр өчен... Сукырайса, кулларына күтәреп йөртер иде, кашыклап ашатыр иде, әмма беркайчан да ташламас иде... Юк, ташламас иде...

Ә Гөлҗиһан?

Фәргатьнең шушы хәлдә калганын белә торып, ул нигә берни эшләми соң? Нигә ул Фәргатьнең чакырганын көтеп ята, бәлки ул чакырырлык хәлдә түгелдер? Бәлки Гөлҗиһанга үзенә аның янына барырга, эзләп табарга, ана ярдәмгә килергә кирәктер? Гөлҗиһан менә шушы гаять җитди сорауларга җавап табарга һәм бер карарга килергә тиеш иде... Һәм Гөлҗиһан үз язмышында язылган ул карарга килде—училищены тәмамлаганда, ул Иртәшкә китәргә юллама сорады...

Аның бу теләге күпләрне гаҗәпкә калдырды... Гел "биш"кә генә укыган, группада иң тере, иң булган Гөлҗиһанны Чиләбенең теләсә кайсы больницасында биш куллап эшкә алалар иде... Авыруы буенча, аның Чиләбе өлкәсеннән читкә китәргә дә хакы бар, чөнки врачлар мондый начар кан белән башка урында яшәп карарга тәкъдим итәләр. Ә ул, әнә, шул авыруларның үзәге булган Иртәшкә юллама сорый! Балалар кебек ихлас, хан кызларыдай горур һәм гүзәл бу татар кызы белән аның таныш татар врачы үзе сөйләшеп карарга булды. Ул аның мондый карарга килгәнен аңламады да, кабул да итмәде...

—Эшкә Иртәшкә сорагансың икән, сенелем,—диде ул, Гөлҗиһанны каршына утыртып.—Синең сәламәтлегең өчен бик үк кулай урын түгел бит ул...

—Беләм, Галия апа,—диде Гөлҗиһан.—Әмма мин анда барырга тиеш... Бу инде минем өчен хәл ителгән нәрсә...

Врач хатын Гөлҗиһанның шул хәтле катгыйлыгына хәтта аптырап та куйды. Нәрсә тарта аны бу үлем шәһәренә? Ул бит анда үзен нинди хәлләр көткәнен белми, яшьлеге белән шулай башсызлана... Ул Гөлҗиһанны, милләттәше буларак, ярата һәм кызгана иде, шуңа күрә аны һич кенә дә күрә торып, белә торып атом базына җибәрәсе килмәде... Бу балага бар дөреслекне дә әйтеп бетереп булмый, бу тыелган нәрсә... Яшьлеге белән ул аны аңларлык та түгел әле, аңласа, анда ыргылмас иде...Мондый кан, мондый авырулар белән Иртәштән генә түгел, Чиләбенең үзеннән качарга, китәргә кирәк... Әгәр яшисең килсә, әлбәттә...

—Мондый кан белән сиңа анда барырга ярамый, сенелем,—диде ул җитди итеп.—Ул шартларда синдә бик тиз ак канга әйләнү башланырга мөмкин, ягъни лейкимиягә... Син хәзер дипломлы медик, моның нәрсә икәнен яхшы беләсең... Бу уеннан кире кайтырга кирәк, сенелем...

Әйе, моның нәрсә икәнен Гөлҗиһан яхшы белә... Нәрсә белән бетәсен дә чамалый... Әмма аның иң кадерле кешесе, яшьлек мәхәббәте шушындый хәлдә булганда, Гөлҗиһан үз авыруын уйлап, үлемен көтеп утыра алмый... Таһир бабай әйткәнчә, "Әҗәл чакырып килмәс, килсә, кусаң да китмәс..." Язмышында нәрсә язылган булса, шул булыр, әмма Гөлҗиһан Фәргатьне эзләп табарга тиеш... Ә ул аны бары тик Иртәштә генә таба ала...

—Мин хәл иттем инде, апа,—диде ул, эчке бер үҗәтлек белән.—Анда да кешеләр яши, больницалар бар, минем ярдәмемә мохтаҗ авырулар бар... Хәзер медицина көчле, егылып үләргә ирек бирмәсләр әле... Мин анда эшләргә дип барам бит, үләргә түгел, кый!

Гөлҗиһанның бу сүзләреннән врач хатын елмаеп куйды. Шушы хәтле дә үзсүзле үткен мишәр булыр икән! Тәки үз сүзен әйтеп тик тора бит... Әллә ул яшьләрне аңламый башлады, әллә яшьләр аны аңламый... Ә бу бер дә шаяра торган нәрсә түгел бит, анда бу бала белми торган нәрсәләр дә бар...

—Ә син аның яшерен, ябык зона икәнен беләсенме соң?—дип сорады ул, тавышын шактый әкеренәйтә төшеп.—Анда бит болай гына кереп-чыгып йөреп булмый... Бер керсәң, тиз генә чыга алмассың... Аларын да уйлап бетердеңме?

—Беләм, Галия апа,—диде Гөлҗиһан.—Безнең авыллар күп эшли анда... Мин кайда барганымны яхшы беләм...

—Анда радиация барлыгын да беләсенме?

Гөлҗиһан, җавап бирә алмыйча, төртелеп калды. Бу хакта да аз-маз ишетеп белә ул, училищеда да бераз укыдылар, больницада да бу хакта щыпырт кына сөйләшкәннәрен ишетте... Әмма анын бу өлкәдә бар белгәне шуннан артмады, ул әле радиация белән үз авыруларын бергә бәйли алырлык дәрәҗәдә түгел иде... Әле илдә бу турыда ялгышып та сүз кузгатучы юк... Радиациянен нәрсә икәнен белү өчен әле тагы егерме ел вакыт үтүе, Чернобыль атом электр станциясе шартлавы, меңнәрләгән кешенең шул радиациядән кырылуы кирәк иде...

—Нәрсә булса да барам, апа,—диде Гөлҗиһан, үз сүзендә нык торып.

—Авыру әтиеңне, авылдашларыңны да калдырып барасыңмы, Гөлҗиһан?

Врач хатын Гөлҗиһан өчен иң авыр сорауны бирде, аңа җавап та чын дөресе булырга тиеш иде.

—Әйе, апа, барыбер барам... Әти янында әни бар, туганнар бар, авылдашлар да ялгыз түгел... Ә Фәргать ялгыз, берүзе...

Шулай диде дә, Гөлҗиһан үксеп елап җибәрде... Әле генә чакматаш кебек үзенекен чатнатып утырган бу кызның кинәт балалар кебек үксеп елап җибәрүеннән врач хатын куркып калды. Кем соң ул—Фәргать, нәрсә булган аңа? Аннан анын зиһене ачылып, яктырып китте—әлбәттә, йөрәгән егете, мәхәббәте бар бу кызның Иртәштә, шулай булмаса, ут эченә керергә атлыгып тормас иде ул!

—Егетең шундамыни, сеңелем?—дип сорады ул, Гөлҗиһанның чәчләреннән сыйпап.

—Әйе, апа... Без аның белән ярәшелгән идек, инде дүрт ел элек туй буласы иде... Ә Фәргать кайтмады...

—Ул Иртәштә идемени?

—Әйе, ул анда армия хезмәтендә иде... Кайтасы көзне әниләренә телеграмма җибәргән, өстәмә хезмәткә калдым дип... Ә мина бернәрсә хәбәр итмәде... Мин быел гына аның анда сукырайганын беллем, Иртәштән безнең авыллар ишетеп кайтканнар...

Врач хатын барысын да аңлады...

Сөнкүлдә эшләгәндә, ул андый хәлләрне күп күрде... Күчле радиациядән, нурланыштан сукырайган авыруларны Иртәштән аларга китерәләр иде... Бигрәк тә—тоткыннарны, солдатларны, ягъни үз ирекләрендә булмаган кешеләрне... Һәм алар өстендә бөтен сынау-тәҗрибәләрне үткәрәләр иде, тереләй туныйлар иде аларны... Дөрес, ул үзе мондый эшләргә беркайчан да катнашмады, шуңа күрә Сөнкүлдә озак эшли дә алмады... Әмма анда күргәннәре бөтен гомеренә җитәрлек булды...

—Егетең... Иртәштәме, әллә Сөнкүлдәме икән?

—Белмим...—дип сузып кына җавап бирде Гөлҗиһан.—Аның Сөнкүле дә бармыни әле? Мина Иртәштә, диделәр... Шуңа күрә шунда барам мин...

—Алайса, бар, сеңелем,—диде врач хатын, бер карарга килеп.—Сөйгәнең шундый хәлдә икән, бар... Гомер бер генә килә... Саф мәхәббәт тә шулай... Аңа хәзер синең ярдәмең бик кирәк... Коткар син аны, тизрәк коткар аннан... Яшьлегемдә булсам, мин дә нәкъ шулай эшләр идем...

Аның күзләренә яшь бәреп чыкты...

Атом утында көйгән яшьлеген искә төшердеме ул, сөйгән ярсыз, гаиләсез, балаларсыз узган гомерен күз алдына китердеме, авыру картлыгын уйлап еладымы—белеп булмый иде...

Алар Гөлҗиһан белән кочаклашып аерылдылар... Үзендә атом тамгасы йөрткән өлкән яшьтәге татар хатынын ялгыз картлык, шундый ук авыруга дучар булган татар кызын билгесез киләчәк көтә иде...

## Унсигезенче бүлек

Инде алтмышынчы елларның азагы якынлаша да, инде Сталин белән Берия күптән үлгән булсалар да, Сөнкүлдә алар урнаштырган тәртип, алар төзеп калдырган үлем индустриясе бөтен көченә эшләп ята иде... Иртәштә атом реакторлары күбрәк эшләгән саен, дөньяга радиация күбрәк таралган саен, Сөнкүлдәге тәҗрибә лабораторияләре дә ныграк кирәк була башлады...

Ябык шәһәргә Мәскәүдән профессорлар, яшерен белгечләр килеп житте, әсир немец галимнәре белән берлектә, алар радиациянең кеше организмына тәэсирен өйрәнделәр, концлагерьлардагы кебек, тере кешеләр өстендә тәҗрибәләр үткәрделәр... Совет белгечләре алардан өйрәнеп тордылар, шулай итеп, тере кешеләр өстендә атом сынавы уздыру буенча зур тәҗрибә тупладылар... Тиздән бу немец галимнәре үзләре дә нурланыштан һәм рактан Сөнкүл больницасында үлеп беттеләр, әмма алар өйрәтеп калдырган эш, кешеләр өстендә куркыныч тәҗрибәләр дәвам итте...

Галимнәр өчен радиациянең нәсел калдыруга тәэсирен өйрәнү бик мөһим иде, шуңа күрә алар авыруларны махсус "нурланыш" астында калдырып, нәсел өчен җавап бирә торган күзәнәкләрен юк иттеләр... Исән калганнарын Сөнкүл гарипләр йортына урнаштырып, махсус өйләндереп, алар өстеннән күзәтүләрен дәвам иттеләр—мондыйлардан бала туамы, туса, нинди туа, бу балаларда кайсы якка үзгәреш көчлерәк була? Сөнкүл больницасында күпләп яткан дивана һәм тиләләрнең алар баш миләрен өйрәнделәр, арка миләреннән сыеклык алып, аны үз акылында булганнарга җибәреп карадылар... Авыруларны нормадан йөзәр, меңәр тапкыр көчлерәк булган рентген нурлары астында тоттылар, моннан соң аларны ярып карап, организмдагы үзгәрешләрне өйрәнделәр... Этләр өстендә нинди тәҗрибә уздырылса, монда кешеләр өстендә нәкъ шуларны эшләп карадылар... Барысы да фән өчен, совет халкының бәхетле киләчәге өчен дип эшләнде... Берәүләрнең бәхете өчен икенчеләр терелә корбан булырга тиеш иделәр...

Татар егете Фәргать менә шушы үлем тегерменәнә килеп эләккән иде...

Күзләре сукырайган мизгелдән Фәргать өчен тормыш тукталды...

Бөтен эчен утлы пычак белән даими айкап торган көчле авыру да аны уята, хәрәкәтләндерә алмады, әйтерсең лә Фәргатьнең җаны үлгән иде... Ул үзен бөтен яктан чорнап алган караңгылыкны җиңә алмады, киресенчә, кара упкын аны җиңә, әкрен генә йота башлады... Үзенең сукыраюын белгән мизгелдән, Фәргатьтә тормышка карата битарафлык башланды, аңа хәзер бу салкын гәүдә белән нишләсәләр дә барыбер иде... Гәүдәне, арбага салып, әледән-әле операциягә алып чыгып китәләр, әле бер жирен, әле икенчесен кисеп туныйлар... Укол бирәләр дә, туныйлар, укол ясыйлар да, кисәләр... Нәрсәне кисәләр, нәрсәне туныйлар алар—сукыр Фәргать бернәрсә белми... Нәрсә киссәләр дә, аңа хәзер барыбер иде... Әмма иң кирәгенә—аның күзләренә операция ясамадылар, чөнки көчле радиация аның күз алмаларын көйдергән, нурын сүндергән иде инде...

Әзмәвердәй егет, кисеп ташлаган имән кебек, айлар буе больница караватында аунады...

Ниһаять, врачлар ярдәме белән, Миасска, әниләренә телеграмма бирдерде... Ул үзенең сукырайганын, больницада ятканын әйтмәде, Иртәштә өстәмә хезмәткә калам, дип ялганлады... Гөлжиһанга исә бер хәбәр дә бирмәде. Күрше кызы Гөлжиһан, туй, мәхәббәт кара пәрдәнең теге ягында калган иде... Бу якка, бу тормышына ул егерме бер яшьлек сукыр булып, гарипләнеп, бер ялгызы чыкты... Аның янында әнисе дә, туганнары да, сөйгән яры да юк инде... Мондый мескен кыяфәттә ул аларның берсенә дә күренәсе килмәде... Гөлжиһанга—бигрәк тә... Гөлжиһан—яшь, матур кыз,

ул бәхетле гаилә тормышы, итәк тулы балалар турында хыяллана... Ә Фәргать ана боларның берсен дә бирә алмаячак... Аның балалары булмаячак... Димәк, ул хәзер Гөлҗиһан турында да, гаилә тормышы турында да онытырга тиеш... Онытырга тиеш...

Чираттагы операциядән соң Фәргатьне башка бинага күчерделәр...

Әмма ул үзе моны белерлек хәлдә түгел иде, кайда алып барсалар да, нәрсә эшләсәләр дә ул үзен якларлык хәлдә түгел иде... Башы-тәне бинтка чорналып, ул күпме гомер ятканын да хәтерләми, әмма ниндидер моңлы, үзәк өзгеч сагышлы тавышка ул аңына килде... Ул яткан бүлмәдә кемдер татарча җырлый иде...

Әйә агач, яшең күпме,
Коелган яфрагың күпме?
Минем күк хәсрәтең күпме,
Дип сорадым агачлардан...

Башта Фәргать, каты авырудан саташам икән, дип уйлады...

Чөнки элегрәк тә аның, шулай аңын җуйганда, төрле тавышлар ишеткәне бар иде... Ул әле әти-әнисенең, әби-бабаларының тавышын ишетә, әле Гөлҗиһанның чыркылдап көлүләре гел колагында яңгырап тора... Бу юлы да ул шулай, саташып, берәрсенең тавышын ишетәм, дип уйлады, чөнки мондый мөнәҗәтне әбисе гел әйтә иде... Әле Караболакта яшәгәндә үк, Фәргать кечкенә вакытта, әбисе аны кабык арбага салып, шушы көйгә тибрәтә иде... Аннан, теге вакытта авылдан куганда, әнисе Фәргатьне куенына кысып, юл буе шушы сүзләрне иңрәп барган иде... Миасска барып урнашкач та моңлы чакларында әнисе дә, әбисе дә шушы мөнәҗәтне әйтәләр иде...

Үләр идем, үләр хәл юк,
Бу хәлләргә түзәр хәл юк.
Кинәш итәр кешем дә юк,
Сабырлык бир үзең, Алла...

Фәргать бу көйне тетрәнеп тыңлады...

Ул инде наркоздан айныган иде, үзенең саташмавын, бу татарча җырны, чыннан да, өнендә ишетүен аңлаган иде... Ул яткан бүлмәдә кемдер бар, ул, ахры, җыештыра, тирә-якка хлор исе таралган, чиләк тоткасы чылтыраган, йөргән тавышлар ишетелә... Идән юучы татар хатыны эш арасында әкрен генә тавыш белән моңлануын дәвам итә...

Чиксез димә гомереңне,
Якын дип бел үлемеңне.
Сәхәрләрдә зекер әйтеп,
Чыныктыр син күңелеңне...

Бик ерактан, тирән кое төбеннән чыккан тавыш белән, Фәргать ыңгырашып сорап куйды:

—Син кем, апа?

Баштан-аякка хәтле бинтка чорналган бу яңа авыруның кинәт кенә татарча эндәшүенә идән юучы хатын сискәнеп китте. Бу бүлмәгә өметсезләрне, үлемгә дучар ителгәннәрне кертеп салалар... Моннан инде алар туп-туры мәетләр бүлмәсенә—моргка китә... Гадәттә, бирегә салган авырулар инде сөйләшә алмыйлар, операциядән соң аңга килә алмыйча,

шыпырт кына жан бирәләр... Ә бу бәндә сөйләшеп ята, житмәсә, татарча! Кулын юып, ул тиз генә авыру янына килде, аның күзләре урынында буш чокыр күреп, чайкалып китте... Ул дөм-сукыр иде...

—Мин бирдә жыештыручы булам,—диде хатын, аңа кем дип дәшәргә дә белмичә.—Синең исемең ничек, энем?

Тавышыннан ул бу авыруның яшь кеше икәнен чамалаган иде инде, шуна күрә, үзенең олы яшьтәге хатын икәнен сиздерәсе итте.

—Фәргать исемле мин, апа... Ә сезнең исемегез ничек?

—Мин Жәүһәрия апаң булам, энем... Сине бүген генә монда китерделәр, ахры... Бу больницада күптән ятасыңмы?

—Үзем дә белмим инде, апа,—диде Фәргать, чыннан да вакыт хисабын югалтып.—Жәй көне китергәннәр иде, хәзер көз бугай...

—Хәзер кыш инде, энем...—диде Жәүһәрия, аны нык кызганып...

—Моннан чыгу юлы юк икән алайса,—диде Фәргать, бирдә күпме ятуын күз алдына да китерә алмыйча.

—Бөтен жирдән дә чыгу юлы бар, энем, кабердән генә чыгу юлы юк,— диде Жәүһәрия, аны юатасы килеп.—Син исән бит әле, шунысына шөкерана итәргә кирәк...

Ул аннан артыгын сорашмады, чөнки биргә гадәттә карар кешесе булмаган солдатларны яки төрмә әсирләрен китерәләр, алар белән монда эшләүчеләргә артык якынаерга кушмыйлар... Хәер, бу бүлмәгә салганнарның моңа теләге дә булмый, аларның күбесе, аңнарына килә алмыйча, теге дөньяга китеп баралар... Бу татар баласы, әнә, нииндидер могжиза белән терелеп, сөйләшеп ята... Әмма бу вакытлы гына хәл булырга мөмкин, үләр алдыннан бер талпынып алу гына...

Жәүһәриянең үз милләттәшенә ни белән булса да ярдәм итәсе, бераз булса да хәлен жиңеләйтәсе килде.

—Берәр нәрсә кирәкмиме соң, энем?—диде ул, бүлмәдә беркем дә юклыгына инанып.

—Апа, теге жырынны тагы жырла әле...

—Жыр түгел ул, энем, мөнәжәт... Безнең авыл мөнәжәте...

—Безнеке дә... Миңа картнәй гел шуны көйли иде...

—Кайсы авылдан соң син, энем?

—Татар Караболагыннан мин, апа... Тууым шуннан... Аннан Миасста яшәдек... Монда солдатта хезмәт иттем һәм шушы хәлгә калдым...Ә сез кайсы авылдан?

—Безнең авыл күптән юк инде, энем,—диде Жәүһәрия, уфтанып.— Бирдәнештән идем мин... Илле жидедә безне башка урынга күчерделәр... Аннан тагы башка жиргә жибәрделәр, әле урыс арасына, әле буш кыргадалага куып йөрттеләр... Шулай итеп, менә монда килеп эләктек... Безнең авылдан хәзер шушы мөнәжәтләр генә калды инде...

Жәүһәрия яңадан жырларга уңайсызланды, ахры, Фәргатьнең урынжирләрен рәтли башлады, чәй алып кереп эчерде... Фәргать тагы, тагы сорап алып эчте, әйтерсең лә ул айлар буе сусыз торган, әйтерсең лә ул тере суга юлыккан һәм туйганчы эчеп калырга тырыша... Бәлки милләттәше кулыннан алган бу су аңа шифалы булып тоелгандыр, үз телендә әйтелгән сүзләр жанына дәва булып яткандыр... Үз милләттәше белән бу очрашу аңа караңгы упкын төбендә ятканда югарыдан төшкән бер нур булып тоелгандыр, яшәүгә өмет чаткылары уяткандыр... Ни булса да, бу очрашу очраклы гына булмагандыр, чөнки бу дөньяда очраклы нәрсә юк бит...

Фәргать беренче тапкыр онытылып, рәхәтләнеп күзләрен йомды...

Ул әллә йокыга китте, әллә уйланып кына ята—сукыр күзләренә карап белеп булмый иде... Аның колагына яңадан таныш моң—татар моңы

ишетелә башлый... Ул аны әле, әбисе булып, кабык арбага салып тибрәтә, әле әнисе булып, кулларына күтәреп йөртә, Фәргать өчен иң кирәкле, иң газиз сүзләрне әйтә...

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр коллар сабыр итәр.
Сабыр коллар сыйрат күперен
Искән җилләр кебек үтәр...

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шайтан качар.
Сабыр коллар җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар...

Җәүһәрия апасы Фәргать янына һәр көн килеп, кереп йөри башлады. Монда врачлар да сүз әйтмәде, чөнки аларның үзләре өчен дә бу татар егетенең язмышы кызык иде. Гадәттә, мондый күләмдә радиация алган авырулар үлә, алар фикеренчә, Фәргать тә инде күптән үләргә тиеш иде... Ә ул һаман яши! Эчендә ярты әгъзалары киселгән, туракланган, каны агуланган, күзе күрми, ә ул һаман тырмаша... Монда эшләүче галимнәр өчен организмның шулай көрәшә алуы кызыклы факт иде һәм алар Фәргатькә Җәүһәрия белән иркенләп аралашырга мөмкинлек бирделәр... Чөнки аларның икесеннән дә беркемгә дә зыян килерлек түгел, ә бу татар егетенең фән өчен кирәк булуы бар...

Ә Җәүһәрия шуны гына көтә иде...

Ул Фәргатькә өйдән пешереп ризыгын да, башка кирәк- яракларын да ташый башлады, аны кашыклап ашатты... Бик кызганды ул бу татар баласын... Ул аның кулларына, аякларына әйләнде, яңадан яшәргә өйрәтте... Фәргать аңа әкренләп үзенең серләрен сөйли башлады—үз тормышы турында да сөйләде, Гөлҗиһан турында да әйтте... Ул үзенең сукыраюын, авыр хәлдә больницада ятуын беркемгә дә әйтмәгән икән, Җәүһәрия апасыннан да бу серне дөньяга чыгармавын сорады... Әниләре аны Иртәштә өстәмә хезмәткә калган дип беләләр, ә Гөлҗиһан берни белми... Һәм хәзергә барысы да шул килеш калырга тиеш... Шушы хәленә ияләнгәнче, сукыр килеш тә кеше булып яшәргә өйрәнгәнче, ул якыннары күзенә күренмәячәк... Чөнки аның беркем өстенә дә йөк булып төшәсе килми, беркем кулына да каласы килми... Аның кеше күзенә мескен булып күренәсе килми...

Елга якын Сөнкүл больницасында аунаганнан соң, үзе белән киңәшеп, аны махсус гарипләр йортына урнаштырдылар. Чөнки беренче чорларда Фәргатькә яшәргә урын да, медицина хезмәте дә кирәк иде әле... Иртәштә Фәргать кебек дөм сукырлар, телсез-чукраклар, ятим гарип-горабалар күбәйгәч, алар өчен махсус йорт ачарга булдылар. Караучысыз калган бу авырулар Сөнкүлнең "Б" лабораториясе өчен әзер материал, алыштыргысыз, һәрвакыт кул астында булган тәҗрибә чыганагы иде... Фәргать тә ихтыяри-мәҗбүри шунда калды... Аңа өр-яңадан яши башларга өйрәнергә кирәк иде...

Гарипләр йорты чагыштырмача яхшы җиһазландырылган, шундый ук медперсонал белән тәэмин ителгән, үз эчке тәртибе белән яшәп ятучы бер дөнья иде... Фәргатьне үзе кебек сукырлар янына урнаштырдылар, даими күзәтеп, карап торырга врачын, санитарын, тәрбиячесен билгеләделәр. Биредәге сукырларның хәтта аерым оешмалары да бар иде. Әмма Фәргать өчен иң мөһиме—аларны биредә яңадан яшәргә, укырга-язарга өйрәтәләр, белем, һөнәр бирергә тырышалар иде... Һәм Фәргать шушы дөньяга теше-тырнагы белән чытырдатып ябышты, аның яңадан яктыга, зур тормышка

чыгасы килә иде... Һәм ул бер генә мөмкинлекне дә кулыннан ычкындырмаска булды...

Үзе кебек дөм-сукырлар арасында яшәү, алар белән даими аралашу Фәргатьне бөтенләй үзгәртеп җибәрде...

Бу дөньяда аның кебекләр күп икән бит һәм барысы да яшәү өчен тартыша... Берсе дә үлем көтеп утырмый, киресенчә, өйләнешәләр, гаилә коралар, балалар үстереп яталар... Биредә аксаклар янадан йөрергә өйрәнә, телсезләр бармаклары белән аңлатып сөйләшә башлый, сукырлар тишек тишеп булса да укырга-язарга өйрәнәләр... Фәргать гарип кешеләрнең яшәүгә дәртләре көчлерәк икәнлеген аңлады, ул алар арасында тормыштан зарланып, уфтанып утыручыларны очратмады... Монда һәр көн, һәр минут яшәү өчен тинсез көрәш бара иде... Фәргать тә шул көрәш дингезенә ташланды... Шушыннан йөзеп чыкса—ул исән калган, үз дигәненә ирешәчәк, көрәш дәрте сүнсә—төпкә китәчәк иде... Тормыш төбенә тәгәрәячәк иде Фәргать, әгәр үз бәхете өчен көрәшмәсә... Һәм ул көрәшергә булды...

Фәргатьнең күзләре күрмәү бер яктан аңа файдага да булды—ул гарипләр йортындагы тере бәхетсезләрне, үзләренең кем икәнлекләрен дә белмәгән диваналарны, үлгәнче Сөнкүл больницасы өчен тәҗрибә куяны булып торачак бичараларны күрмәде... Күрсә, ул үзенең кайда килеп эләккәнен аңлар һәм коты чыгар иде...

Мәһабәт гәүдәле, ирләрчә кырыс, матур Фәргатьне үзе кебек сукыр кызларга димләп карасалар да, ул баш тартты... Кара пәрдәнең теге ягында калган Гөлҗиһан, чая Гөлҗиһан, сылу күрше кызы һәр төн аның төшләренә керде, бер генә минутка да янынннан китмәде... Ул кайчагында хыялга бирелеп, Гөлҗиһан белән гаилә кору, балалар үстерү турында уйлый башлый, аннан врачларның: "Балаң булмаячак, булса да, гарип тууы мөмкин", дигән сүзләрен исенә төшерә... Юк, Гөлҗиһан турында онытырга кирәк инде, аны бәхетсез итәргә Фәргатьнең хакы юк... Ә Фәргать белән ул бәхетсез булачак, чөнки сукыр, бөтен җире туракланган, ата булырга ярамаган ир-ат чәчәк кебек кызга ничек бәхет китерсен? Фәргать шулай уйлый иде... Шуңа күрә ул Гөлҗиһанга үзенең дөньяда барлыгын белдермәде...

Ә әнисе, туганнары белән арасын өзмәде Фәргать...

Үз кулы белән хат яза алмаганга, ул башта аларга телеграммалар суга иде... Аннан, инде йөри башлагач, шушы гарипләр йортына килеп урнашкач, Миасс белән телефон элемтәсен дә урнаштырды... Чөнки аның өчен әнисенең, якыннарының тавышын ишетү бик мөһим иде, алар да, тавышын ишеткәч, Фәргатьнең исән икәнлегенә тәмам инандылар, тынычландылар... Алар ай саен шулай сөйләшеп тордылар, әмма өйдәгеләргә дә Фәргать дөресен әйтмәде, ә алар үзләре ябык шәһәргә кереп, тикшереп йөри алмадылар... "Өстәмә хезмәткә калдым, бәлки яшәргә дә бөтенләйгә биредә генә калырмын",—диде ул аларга... Фәргать әнисен, туганнарын рәнҗетәсе килмәде, хәтта пенсиясенең бер өлешен дә ай саен аларга җибәреп бара башлады... Җәүһәрия апасы ярдәме белән ул Миасска посылкалар, күчтәнәчләр салуны да гадәткә кертте... Ай саен улының тавышын ишетеп торган, ярдәмен күргән ана кеше аның кайтмавы белән ризалаша төште... Тормыш тагы үз җаена кереп китте...

Шулай итеп бер ел үтеп китте, ике, өч ел үтте...

Бу вакыт эчендә Фәргать сукырлар әлифбасы белән яхшы итеп укырга-язарга өйрәнде, Иртәштәге юридик институтка укырга барып керде... Аның мескен гарип булып, дөньяның төбендә яшәп каласы килмәде, бу хәленнән котылуны бары тик гыйлемдә, гыйлемдә, гыйлемдә күрде ул... Аның үзе

өчен генә түгел, башкалар өчен дә көрәшәсе, бәхетсезләргә ярдәм итәсе килде... Яшьлек, нәселдән килгән ныклык, олы максатлар белән яшәү каты чирне дә жинде—ул инде үлем көтеп яткан гарип түгел, ул көчле рухлы, омтылышлы ир-егет иде...

Фәргатьнең янадан шушы хәлгә килүенә Жәүһәрия апасы да нык булышты. Ул ана әнисен дә, хәтта Гөлжиһанны да алыштырды... Үзенең ире дә шушындый авырулардан газап чиккән ахыр чиктә сукыраеп үлгән татар хатыны Фәргатьне үз баласын караган кебек тәрбияләде, гарипләр йортына киткәч тә арасын өзмәде... Аның үз балалары күптән инде аякка басып, үз гаиләләре белән кайсы—Коншакта, кайсы Чиләбедә яшәп яталар иде, шуна күрә Фәргатькә ул бар жан жылысын бирде... Аның хыялы—Фәргатьне бер яхшы гына татар кызына өйләндерү иде, әмма егет беркем турында да ишетергә теләмәде... Ул бары тик Гөлжиһан турында гына уйлый, аның хыялы белән генә яши иде...

—Әллә Гөлжиһанга сиздереп карыйкмы сон монда икәнлегенне?—беркөнне сак кына сорап куйды Жәүһәрия.

—Юк, юк, апа, бу мөмкин хәл түгел!—дип, кабынып каршы чыкты Фәргать.—Ул яшь, сәламәт кыз бала, нигә үзенең гомерен авыру, сукыр кеше белән бәйләргә тиеш ул?!

—Яратса, бәйләр, энем... Мәхәббәтнең үзенең күзе сукыр була аның... Әгәр монда икәнлегенне белсә, Гөлжиһанның нишләр дип уйлыйсың?

—Килеп житә,—диде Фәргать ике уйлап тормыйча.—Син аны белмисен әле, Жәүһәрия апа, ишетсә, күктән парашют белән тәшәчәк ул Иртәшкә, шундый үткен кыз...

—Сон, шулай булгач?—диде Жәүһәрия, аптырап.—Килсен, күрсен, аннан үзе хәл итәр...

—Ә минем бу хәлдә күренәсем килми ана,—диде Фәргать, башын иеп.—Мескен хәлдә күренәсем килми... Ул зуррак бәхеткә лаек...

Шушы сөйләшүдән соң Жәүһәрия, Фәргатькә әйтмичә генә, Караболакка аның турында хәбәр жибәрде... Бу хәбәр Таһир карт кулына килеп керде... Дөньяда бер генә очраклы нәрсә дә юк иде шул, кешеләр тәкъдирдә язылганга сәбәпче генә...

Укып бетереп, диплом алгач, Фәргать үзе дә Гөлжиһанга хәбәр салып карарга ниятләп тора иде... Әмма ана кадәр ерак иде шул әле, ул укуын әле башлады гына... Фәргатьнең ишетүенчә, Гөлжиһан инде Чиләбедә медицина училищесы тәмамлаган... Ул Гөлжиһанның хәзергә кияүдә түгел икәнлеген дә белә, бөтен күнеле белән аның ашыкмавын, башкага кияүгә чыкмавын тели... Тик бераз гына көтсен, сабыр итсен иде Гөлжиһан... Фәргать бу тормышта үз урынын табачак, һичшиксез табачак! Ул гомер буе гарипләр йортында ятмас, пенсия күзенә карап тормас, үз гаиләсен алып бара алырлык, башкаларга да ярдәм итәрлек шәхес булыр, Алла теләсә... Тик Гөлжиһан гына ашыкмасын, дөньяда Фәргать барын онытмасын, сабыр итсен иде!..

## Унтугызынчы бүлек

Гөлжиһан килергә жыенган Иртәш шәһәре алтмышынчы еллар азагына зур бер промышленность үзәгенә әйләнгән иде инде...

Дөрес, 1954 елның мартында ана, рәсми рәвештә, Озерский исеме бирелде, әмма халык телендә ул барыбер элеккеге исемнәрдә йөрде... Кайчандыр бары тик бараклардан һәм жир куышларыннан гына торган бу яшерен шәһәр "База" дип тә, "Десятая площадка", "Челябинск-40", "Сороковка" дип тә, "Почтовый ящик 21", "Челябинск-65" дип тә

йөртелгән...Хәер, шәһәргә исем бирелсә дә, аның адресы барыбер почта ящигы саны белән атала, шулай языла иде... Озерский исеме ана, адресларга языльп һәм карталарга төшерелеп, янадан нибары 1994 елда гына әйләнеп кайтачак әле...

"Маяк" атом комбинатында нинди генә көчле аварияләр булуга карамастан, шәһәр җир астында һәм җир өстендә җәелеп үсүен дәвам итә... 1957 елгы шартлау да инде онытылып бара, беркем "Маяк"ны ябарга җыенмый, чөнки Советлар Союзы үзенең атом чорына әле аяк кына баскан була... Биредә атом-төш коралы җитештерү буенча илдә, хәтта дөньяда тиңе булмаган яңа төр промышленность үсеп чыга. Кыска вакыт эчендә бер-бер артлы дистәләгән атом реакторы сафка баса... Иртәш ярымутравында җир астын тоташы белән атом реакторлары, радиохимик заводлар, радиоактив калдыкларны саклау һәм эшкәртү өчен йөзләгән каберлекләр һәм объектлар төзелә, уран һәм плутоний белән эшләү дәвам итә... Ә өстә, берни булмагандай, урманнар шаулап утыра, шәһәр яшәп ята... Аста атом казаны кайный, өстә кешеләр яши...

Гөлҗиһан менә шушы шәһәргә эшкә килергә җыена иде...

Бу чорда инде кешеләр Сталин заманындагы агач бараклардан, җир куышларыннан әкренләп ике катлы кирпеч йортларга күчә башлыйлар... Хәер, бараклар әле бик озын гомерле булып чыга, алтмышынчы еллар ахырында да анда тормыш кайнап тора, атомчылар яшәп ята... Эш эзләп авылдан килүче яшьләр, юллама белән бирегә җибәрелгән белгечләр исә күбрәк тулай торакларга урнашалар... Тулай торак бүлмәләре икешәр катлы тимер караватлар белән дыңгычлап тутырылса да, барыбер халыкка урын җитми... Соңрак Иртәштә Финляндиядән кайтарылган әзер такта йортлар да күренә башлый, аулак тыкрыкларда аерым агач йортлар үсеп чыга... Соңгыларында шәһәр һәм завод җитәкчеләре көн күрә... Сталин, Берия үлү белән, Иртәштә алар исемен йөрткән урамнар Ленин, Победа исемнәренә үзгәртелә, һәр җирдәгечә, монда да Совет, Пушкин урамнары барлыкка килә... Һәм алтмышынчы еллар азагында Иртәштә "хрущевка" дип аталган беренче панель йортлар күренә башлый, баракның эшче халкы шунда күчә... Шәһәр күзгә күренеп үсә, аны, нигездә, тоткыннар һәм хокуксызлар төзи... Алар коточкыч авыр шартларда, җимерек баракларда, палаткаларда һәм җир йортларда, башка халыктан аерым яшиләр... Аларны эшкә этле конвой белән йөртәләр...

Иртәш "База" дип йөртелгән такта чорыннан, чын мәгънәсендә, заманча таш шәһәргә әйләнә... Халык үлә тора, туа тора, Иртәштә яңа буын үсеп җитә... Шәһәр үзенең мәдәниятенә, мәгърифәткә, спортка зур игътибар бирә башлый, чөнки яшь буынны таратмыйча тотып тору өчен нәкъ шулар кирәк була... 1952 елның декабрендә биредә Мәскәүнең инженерлык-физика институтының филиалы ачыла, атом белгечләрен шәһәр үзендә әзерли башлый... Кырык яшенә дә җитмичә рактан, "нурланыш"тан үлгән инженер-химиклар урынына сәламәт, яшь буын кирәк була... Шуңа күрә, Иртәштә эшли башлаган Көньяк Урал политехникумына ашыгыч рәвештә бөтен ил буенча яшьләрне җыя башлыйлар... Бирегә Горький, Дзержинский, Кинешма, Кострома, Пенза, Рошаль һәм башка шәһәрләрдән ашыгыч рәвештә дүрт йөз егет һәм кызны китерәләр... Алар нибары уналты яшьтән егерме яшькәчә булалар... Һәм алардан тиз арада үлгән атомчылар урынына белгечләр әзерлиләр, аларны ни көтәсен әйтмиләр... 1950-1952 елларда бу политехникумны 361 кеше тәмамлый һәм аларны туп-туры атом казанына озаталар... Һәм бу яшьләр, 10-15 ел эчендә атом нурланышы алып, сафтан чыгалар... Совет режимы алар урынына яңа кадрлар әзерли башлый... Атом казаны бер дә буш тормый... Соңыннан техникум белән физика институты

бергә кушыла һәм аннан "Маяк" өчен 3000 атомчы белгеч әзерләнеп чыгарыла... 1967 елны, Гөлҗиһан Иртәшкә килгән елны, бу институтны "Маяк"нын булачак директоры Виктор Ильич Фетисов та тәмамлый... Сонынннан ул да баш мие рагыннан үлә...

Иртәштә 1952 елда Маяковский исемендәге кинотеатр эшли башлый, 1953 елнын маенда СССР медицина фәннәре Академиясенен Биофизика институты филиалы ачыла... 1956 елда—Пионерлар сарае, 1958дә—"Маяк" мәдәният сарае эшли башлый, 1959 елда "Строитель" мәдәният йорты ачыла... Яшерен атом шәһәре яхшы азык-төлек белән турыдан-туры Мәскәүдән тәэмин ителә, шуна күрә биредә халык азыкка кытлык кичерми... Ил талоннар белән ризыкка чират торганда, биредә ите-мае һәм башкасы тулып ята... Шуна күрә Иртәш халкын тирә-якта "шоколадники" дип йөртәләр, ягъни, кәнфит ашап ятучылар...

Шушы чорда инде шәһәр читендә зур зират пәйда була һәм ул бик тиз тула башлый... Башта татарларны урыс зиратынын бер читенә, аерым күмәләр, әмма ул бик тиз тәреле каберләр чолганышында кала... Зиратлар һәм каберләр бутала, кушыла, бергә әйләнә... Атом барысын да тигезли... Яшьләр монын белән ризалашалар, олыраклар мәетне татар авылларына алып кайтып күмәргә тырыша... Шәһәрдә татарлар шактый яшәсә дә, анда бер генә татар мәктәбе, балалар бакчасы да булмый... Мәчет, милли мәдәният йортлары турында инде әйтәсе дә юк... Татарлар бирегә эшләргә һәм үләргә генә керәләр...

Һәм шушы таш шәһәргә, урыс шәһәренә, атом каласына татар кызы Гөлҗиһан да килеп ята...

Нәрсә көтә аны биредә, монда анын калерле гомерен дә атом казанына салып кайнатмаслармы, телен, динен оныткан җансыз манкортка әйләндермәсләрме? Бу хакта әле беркем бернәрсә белми...

Атомчы белгечләрне Иртәшнен үзендә әзерләгән кебек, нурланыш алган авыруларны да, читкә чыгармыйча, биредә генә дәвалау юлларын эзлиләр... Шәһәрдә беренче радиация лабораторияләре беренче атом реакторлары белән бергә төзелә... Бу икәүнен һәрвакыт житәкләшеп йөриячәкләрен илдә белүчеләр була, шуна күрә, атом объктлары белән бергә, алардан зарар күрәсе кешеләр өчен больницалар да төзи башлыйлар... Һәм, әлбәттә, радиацияне өйрәнү буенча фәнни-тикшерү институтлары... 1950-1953 елларда гына да 8 мен кешенен нурланыш алуы билгеле була, әмма врачларга алга таба бу диагнозны куймаска кушыла... КГБ генералы Ткаченко үз эшен яхшы белә һәм ул дәүләт серен артык саклый...

Шулай итеп, Гөлҗиһан эшкә килә торган Иртәш шәһәрендә "радиационная медицина" дип аталган өр-яна юнәлеш барлыкка килә, анда ил буенча ин көчле белгечләр тартыла... Алар, еллар үтү белән, бу юнәлештә шактый зур ачышлар ясыйлар, төрле дәрәҗәдәге исемнәргә ирешәләр, дәүләт премияләре алалар, һәм, нәтиҗәдә, шул ук чир белән бу дөньядан китеп баралар... Дөнья медицинасы ракны да, "нурланыш" авыруларын да җинә алмый, киресенчә, авыру аларнын үзләрен җинә...

Иртәштә гарип балалар күпләп туа башлый...

Әмма, ни гаҗәп, бу ябык шәһәрдә илленче елларда бала туу ил буенча күрсәткечкә караганда, ике тапкыр күп була! Моны Иртәшнен яшьләр шәһәре булуы белән дә, тормыш шартлары чагыштырмача яхшы булуы белән дә анлатырга тырышып карыйлар... Бу хәтле күп бала тууны радиациянен кеше организмына сәер тәэсире нәтиҗәсе булуы мөмкин икәнлеген дә әйтәләр... Чөнки бу шәһәрдә үсемлекләр дә кирәгеннән артык котырып үсә, күлдәге балыклар да кеше буе була...

Шәһәр үз тормышы белән яшәп ята, ә "Маяк"ны әледән-әле көчле

шартлаулар, эреле-ваклы аварияләр тетрәтә... 1960 елның 5 декабрендә, СССР Конституциясе бәйрәме көнендә, "Маяк" та зур авария була, эшчеләр көчле нурланыш ала, күпләр үлә... Шәһәр өстенә көчле радиация тарала... Шулай ук 1962 елның 28 февралендә, шул елның 7 сентябрендә, 1965 елның 16 декабрендә "Маяк"та көчле шартлаулар була, бөтен дөньяга радиация тарала... Алтмышынчы еллар уртасында зур давыл чыгып, атом калдыклары күмелгән Карачай күлен күтәрә, миллионлаган кюри радиоактив матдәләр, үлем болыты булып, шәһәр һәм авыллар өстенә оча... Рәсми мәгълүматлар буенча гына да бу афәтләр вакытында 41-42 мең кеше "нурланыш" чире ала... Татар егете Фәргать тә шулар арасында була...

Татар кызы Гөлҗиһан шушы утлы шәһәргә, атом арасына кереп бара... Әкиятләрдәге гүзәл кыз кебек, ул, сөйгәнен эзләп, аны коткару өчен аждаһа авызына кереп бара...

Әмма бу әкият түгел, куркыныч чынбарлык иде...

## Егерменче бүлек

Гөлҗиһан Иртәшнең капка төбенә килеп басты һәм аптырап, туктап калды...

Ул аның ябык шәһәр икәнлеген белсә дә, бу хәтле сак һәм күзәтү астында яшидер дип уйламаган иде... Шәһәрне кош та очып керә алмаслык биек таш коймалар урап алган, аларның өстеннән электр токлы чыбыклар үткәрелгән... Ул коймаларның башы да юк, ахыры да күренми, әйтерсең лә, Гөлҗиһанның каршыда шәһәр түгел, таш төрмә... Койма буйларында да, эчтә дә, тышта да зур-зур этләр йөри, алар һәр нәрсәне килеп исни, һәр кешегә килеп танавын төртә... Этләргә ияреп, сакчы конвойлар йөри, алар да бар нәрсәне капшый, бар нәрсәне тикшерә... Әле шәһәргә кермәгән, әмма инде атлаган саен мылтыклы сакчы очрый, адым саен документлар тикшерәләр...

Медицина училищесыннан Иртәштә эшләргә махсус юлламасы булса да, киләсе алдан хәбәр ителсә дә, Гөлҗиһанны ишек төбендә бик озак тоттылар...

Башта аның әйләндерә-әйләндерә бөтен документларын тикшереп чыктылар, аннан бөтен әйберләрен, сумкасын җентекләп актардылар... Иң соңыннан, бер кечкенә бүлмәгә алып кереп, погонлы хатын-кызлар үзен анадан тума чишендереп, капшый-капшый тентеделәр, чәч толымнарына хәтле сүтеп карадылар... Монысына Гөлҗиһан бигрәк тә гарьләнде, аның әле беркайчан да чит кешеләр алдында болай шәп-шәрә калганы юк иде... Гомерендә дә мондый хәл күрмәгән горур Гөлҗиһанның хурланудан күзләренә яшь бәреп чыкты, ул, берәр усал сүз әйтеп җибәрмәс өчен иреннәрен тешләде... Ана хәзер каршы сүз әйтергә дә, болар белән бәхәскә керергә дә ярамый, бигрәк тә—бу этле сакчылар белән... Ул бит үзенең кая килгәнлеген яхшы белде, ни өчен килгәнен дә белә... Аңа бу шәһәрдә Фәргатьне эзләп табарга кирәк... Шуңа күрә Гөлҗиһан бу хурлыкларга түзә, сүз әйтә алмый...

Ишек төбендә шулай ямьсез кылансалар да, шәһәр үзе Гөлҗиһанны шактый тыныч каршы алды, һәрхәлдә, ул биредә адым саен мылтыклы кешеләрне очратмады... Гөлҗиһан ниндидер куркыныч, утлар очырып торган шәһәрне күрермен, дип уйлаган иде, ә бөтенләй башка күренешкә тап булды... Иртәш бик матур, ямь-яшел, җыйнак, чиста бер шәһәр икән... Ул яшеллеккә төренеп утырган матур-матур тәбәнәк өйләр, шул өйләрнең ишек төпләреннән башланып киткән диңгездәй күлләр, күлләр артындагы кара урманнар... Кара сөремгә батып утырган Чиләбедән соң, аңа бу шәһәр,

әллә инде сөйгәне бирсдә яшәгәнгә, җәннәт почмагы булып күренде... Әмма шәһәр астында җәһәннәм утлары янып торуын, ул ялкынның бөтен дөньяны юк итәргә сәләтле булуын ул әле аңлап бетерми иде...

Гөлҗиһан агачларның бирсдә котырып, тармакланып-тармакланып җәелеп үсүенә игътибар итте... Юл читендәге әрекмәннәренә хәтле колач-колач, чәчәкләр күз явын алырлык җете, яфраклар уч төбедәй зур иде... Гөлҗиһан боларның барысы да көчле радиация нәтиҗәсендәге мутация икәнлеген сонрак белер, әмма хәзергә ул аларга исе китеп, гаҗәпләнеп карап йөри... Аны иң сокландырганы—Иртәш күле булды... Күпме ишетте аның турында Гөлҗиһан, ул, чыннан да, диңгез кебек икән... Аның иге-чиге күренми... Яр буйларында, нәкъ Караболактагы кебек, куе камышлар үсеп утыра, алар арасыннан кыр үрдәкләре пырхылдап очып чыга... Якында гына малайлар кармак белән балык каптырып утыралар, күлгә кереп, чумып-чумып та чыгалар... Нәкъ Караболактагы кебек...

Еракта, Иртәшнең теге ярында, күккә шәмәхә төтен ургытып утырган завод торбалары күренә... "Атом бомбасын шушында ясыйлармы икәнни?",—дип уйлап куйды Гөлҗиһан, бу дәһшәтле күренешне күзәтеп... Күпме куркыныч сүзләр ишетте ул Иртәш заводлары турында, имеш, алар аждаһа кебек, бөтен җир астына таралып ятканнар икән... Анда кергән кеше чыга алмый икән... Анда кешеләр өстендә коточкыч тәҗрибәләр ясыйлар икән... Әмма барысы да шунда эшкә бара, бөтен гомерен шушы шомлы шәһәр белән бәйли... Менә Гөлҗиһан үзе дә шушы атом шәһәренә килеп ята...

Шәһәр урамнарындагы халык Гөлҗиһанга шактый сәер күренде...

Аларның күбесе чамасыз тазалар, аякларын чак өстерәп йөриләр... Шул ук вакытта саргаеп кипкән, үтә ябык кешеләр дә очрый... "Бу—авыру билгесе инде, боларда матдәләр алмашыну бозылган, гормоннар дөрес эшләми...",—дип уйлап алды шунда ук Гөлҗиһан, медицина училищесында укыганнарын исенә төшереп... Хәер, биредә авыру кешеләрнең күплеген дәреслекләрдән тыш та белергә була иде—бала арбаларында гарип сабыйларны күп очратты Гөлҗиһан... Аларның күбесе дауна чирле, ягъни, дивана иде... Бу күренеш ана бик авыр тәэсир ясады... Тагын үзен уйлады... Фәргатьне искә төшерде һәм авыр сулап куйды... Чиләбедә Галия апасы әйткәннәрнен ул дөреслеген аңлады... Әмма ана чигенергә юл юк иде инде һәм ул чигенергә теләмәде дә... "Нәрсә булса да була, инде хәзер барысы да Алла кулында",—дип уйлады Гөлҗиһан һәм үзе эшләячәк больницаны эзләп китте...

Шәһәр больницасы ике катлы яна бинада булып чыкты...

Ул Гөлҗиһанга охшады, чөнки мондагы медицина җиһазлары, тәртип бер дә Чиләбенекеннән ким түгел иде, хәтта артыграктыр да әле... Чөнки биредә радиацион медицина буенча илнең иң зур белгечләре эшли, Мәскәүдән зур профессорлар килеп тора, авырулар өстендә күп тәҗрибәләр үткәрелә иде... Кешеләре дә бик ачык күренә, алар Гөлҗиһанны бик тиз үз итеп, яратып аралаша башладылар... Хәер, Гөлҗиһан үзе дә кешеләргә бик ачык, ягымлы, ярдәмчел иде, ә гадәттән тыш матурлыгы ана күп ишекләрне ачты... Документларын тапшырып, үзе эшләячәк бүлек белән танышкач, Гөлҗиһан тулай торакны эзләп китте. Анысы да больницадан ерак түгел икән, алар бер ишек алдында булып чыктылар... Гөлҗиһанны дүрт кешелек зур гына бүлмәгә урнаштырдылар, аның бүлмәдәшләре барысы да больницаның шәфкать туташлары иде... Биредә гаиләле кешеләр, врачлар да яши икән, алары инде аерым бүлмәләрдә...

Гөлҗиһан дүрт кешелек бүлмәгә урнашуына да сөенеп бетә алмады, чөнки аны, Иртәштә баракларда, палаткаларда торалар, ике катлы караватларда яталар, дип куркытканнар иде... Анысы эшче халкы өчен икән... Ә Гөлҗиһан,

нәрсә дисәң дә, дипломлы белгеч хәзер, фельдшер, шәфкать туташы... Бу белеме белән ул, теләсә, врачларны да алыштыра ала, чөнки аларны, авыл больницалары өчен махсус шулай киң профильле итеп укыттылар... Ул, шәһәрне сайлагач, хәзергә шәфкать туташы эшенә дә ризалашты... Насыйп итсә, алга таба укуын да дәвам итәр әле, Нурҗамал картнәе хыялланганча, нәселдә бер врач булыр... Ә хәзергә аның төп максаты—Фәргатьне эзләп табу... Атом бомбасы ясый торган бу куркыныч шәһәргә ул шуның өчен керде, чөнки эшне ул теләсә кайда таба ала иде... Гөлҗиһанның алга таба язмышы, тормышы Фәргатьтән тора... Әгәр ул һаман Гөлҗиһанны ярата икән, Гөлҗиһан мәңгегә аның белән булачак, аның янында калачак... Фәргать нинди генә хәлдә булса да... Әгәр ул Гөлҗиһаннан бизгән икән, башканы ярата икән, Гөлҗиһан да үз юлын сайлаячак... Бәлки янадан Чиләбегә кайтып китәр, бәлки—Коншакка, ә бәлки Караболакка ук...

Һәм кыз, озак көтмичә, эшкә керешге—Фәргатьне эзләтә башлады...

Әмма—әйтергә генә җиңел—шундый зур шәһәрдә, чит-ят җирдә бер татар кешесен эзләп табарга! Башта Гөлҗиһан үз милләттәшләре арасыннан белештереп карады, Хәбибулла абыйсының биредә яшәүче хатынын—Таифә җиңгәсен эзләп тапты, серне бераз аларга да ачты... Әмма алар берсе дә сукыр татар егетен белмиләр иде, күргәннәре дә булмаган... Әйтерсең лә, Иртәштә андый кеше яшәми... Аннан Гөлҗиһан эш арасында шәһәр больницалары буйлап йөреп карады, әмма алардан да Фәргатьне таба алмады... Андый кеше Иртәш больницаларында ятмый һәм беркайчан да ятмаган булып чыкты... Шуннан соң ул милиция бүлекләренә, паспорт өстәлләренә мөрәҗәгать итте, әмма аларда да Фәргать Зөлкарнәев исемле кеше теркәлмәгән булып чыкты...

Шулчак Гөлҗиһанның башына яшен яктысыдай уй килде—тукта, бәлки ул, чыннан да, Иртәштә түгелдер? Чиләбедә Галия апасы да: "Сөнкүлдә түгелме икән ул?"—дигән иде бит! Ә Сөнкүл ул—бөтенләй башка ябык шәһәр, анда керү-чыгу махсус рөхсәт белән, шунда яшәүчеләр һәм эшләүчеләр өчен генә икән... Дөрес, ул Иртәштән ерак түгел, янәшә генә, әмма читләр өчен анда юл ябык... Гөлҗиһан сорашып белде, Сөнкүлдә, чыннан да, халык телендә "концлагерь" дип аталган больница бар икән. Дөресрәге, ул больница да түгел, ФИБның бер бүлеге, махсус лабораториясе, ди... Гөлҗиһан үзе эшли торган больницада врачлардан сорашып шуны да белде—иң өметсез, иң авыр хәлдәге авыруларны Иртәштән шунда җибәрәләр икән... Аннан инде кире кайту юк, ди... Кеше йә—үлә, йә үлгәнче шундагы гарипләр йортында яшәп кала, чөнки алар гомер буе шул больница каршында махсус хисапта торалар икән...

Гөлҗиһанның йөрәге шашып, ярсып, өзгәләнеп тибә башлады, ул сизенде—Фәргать шунда иде! Аны да, күзләре сукырайгач, шунда озатканнар һәм ул шунда калган... Аның бу хәлдә беркемгә дә күренәсе, йөк буласы килмәгәндер... Бәлки ул аннан китә дә алмагандыр... Бәлки ул хәзер дә шунда газапланып, кеше кулына карап ята торгандыр...

Үзенең Сөнкүлгә болай гына керә алмаячагын аңлагач, Гөлҗиһан телефонга йөгерде... Ул Фәргатьнең, чыннан да, шундагы больницада ятканлыгын белде, әмма ул хәзер аннан киткән иде... Фәргать шәһәрнең гарипләр йортына күчерелгән булып чыкты... Сөнкүлнең милиция бүлегенә шалтыратып, туганы дип алдалап, Гөлҗиһан гарипләр йортының адресын алды, Фәргатьнең бүлмә номерын ачыклады... Хәзер алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген уйларга кала иде...

Иң мөһиме—Гөлҗиһан Фәргатьнең исән икәнлеген белде. Ул исән, аның адресы бар, димәк, аны эзләп табарга була... Анда кертмиләр икән, хат язып җибәрергә мөмкин бит... Фәргатьне эзләп тапканчы, күреп

сөйләшмичә, Гөлжиһан инде туктамаячак иде... Һәм Гөлжиһан Фәргатькә хат язарга булды... Бу мизгелләрдә ул аның дөм-сукыр икәнлеген, бу хатны үзе укый алмаячагын бөтенләй онытып җибәргән иде...

Гөлжиһан хат язарга утырды һәм куркып, каушап калды...

Нәрсә дип язар соң ул ана? "Яратам. Сагынам. Көтәм", дипме? Ә Фәргать күптән инде өйләнгән булса яки башканы яратып йөрсә? Адәм хурлыгына төшәчәк бит Гөлжиһан... Ул хәзер генә үзенең нинди унайсыз хәлгә калганлыгын аңлады... Таһир бабай сүзе белән генә чыгып китәргә кирәк идеме икән ана Иртәшкә, әллә берәр юл табып, тикшертеп карарга кирәк идеме? Юк инде, юк, Гөлжиһан алай бүрәнә аша бүре куып ята торган кеше түгел, ул барыбер монда килгән булыр иде. Фәргатьне эзләп табар иде... Хәзер дә, артык катлауландырып тормыйча, исәнлекне булса да хәбәр итәргә кирәк... Фәргать акылсыз егет түгел, калганын үзе аңлар... Тели икән—ул да хәбәр бирер, җавап язар, юк икән, юк инде, димәк, барысы да беткән... Хакы Гөлжиһан өстендә калмый... Ул—кыз бала, болай да үзенә тиештән арттырып җибәрде кебек... Мәхәббәт, чыннан да, тау күчерә, диләр шул...

"Исәнме, Фәргать абый, сиңа бу хатны күрше кызы Гөлжиһан яза, әгәр онытмаган булсаң",—дип, ярым шаярып, ярым җитди рәвештә башлап китте ул үзенең хатын.

Шулай дип язды да, туктап калды... Кулындагы каләме кинәт кенә авыраеп китте, йөрәге сулкылдап тибә башлады, күзләренә яшь килде... Гөлжиһан үзенең Фәргатьне өзелеп яратуын, беркайчан да онытмавын, оныта да алмаячагын әйтергә теләде—әйтә алмады... Әллә кызлык горурлыгы, әллә артык оялуы ирек бирмәде, әллә билгесезлек куркытты—ул Фәргатькә өзелеп яратуы турында яза алмады...

"Фәргать, син туй көнендә Караболакка кайтмагач, мин бик үпкәләгән идем,—дип дәвам итте ул, турысын әйтергә уйлап.—Хәзер инде хәлеңне ишетеп белдем, барысын да аңладым... Ник бу хакта миңа башта ук хәбәр итмәдең? Без синең белән ярәшкән егет һәм кыз идек бит... Мин сиңа чит кеше түгел идем..."

Гөлжиһанның Фәргатьне өзелеп-өзелеп яратуы, аны еллар буе көтүе турында язасы килде, әмма яхшысынмады... Кызгана яки кылана, дип уйлавы бар, Алла сакласын... Фәргать бик тә горур егет иде шул, ул беркайчан кызгандыруга бармаячак, нинди хәлдә дә мескенлеккә төшмәячәк... Гөлжиһан алдында—бигрәк тә... Шуңа күрә һәр сүзне уйлап язарга кирәк, уйный, дип уйлый күрмәсен...

"Мин, медицина училищесын тәмамлап, Иртәшкә, шәһәр больницасына эшкә килдем,—дип дәвам итте ул, юлламаны бирегә үзе сорап алганын әйтмичә.—Эшемне бик яратам... Тулай торакта бүлмә дә бирделәр, иптәш кызларым бик әйбәт... Монда татарлар да күп яши икән, аралашып, күрешеп торабыз..."

Шулай язды да, туктап калды...

Юк, аның бөтенләй башка нәрсәләр турында язасы килгән иде бит! Фәргать туйга кайтмагач, үзенең тилерә язуы турында, көне-төне аны гына уйлавы турында, тилмереп, аннан бер хәбәр көтүе турында язасы килде Гөлжиһанның, тик яза алмады... Бәлки ул хәзер бөтенләй башка кешедер инде, Гөлжиһан аны биш ел күрмәде бит... Фәргать да хәзер үзгәргәндер, Гөлжиһан үзе дә бу елларда янадан туып терелде бит... Олыгайды, җитдиләнде, кырысланды... Әтисенең көтмәгәндә авырып китүе, аннан аяксыз калуы, үз авыруы турында белүе, авылдашларының күпләп үлүе кайгысы Гөлжиһанны да вакытыннан элек картайтты... Ул да хәзер дөньяга бөтенләй башка төрле карый... Элеккеге бала Гөлжиһан, шаян Гөлжиһан,

ут Гөлҗиһан юк инде... Шуна күрә ул беренче мәхәббәтенә дә хатны бик уйлап, үз-үзен тыеп, зур сабырлык белән язарга тырыша... Ә хисләре барыбер күңелендә кайный, ургый, аларны, сүзгә әйләндереп, кәгазь битләренә төшерә башласаң, дәфтәр битенә ут кабар төсле...

"Син башка шәһәрдә яшисең икән,—дип дәвам итте ул, хисләрен чак тыеп.—Иртәштә булсаң, бәлки күрешер идек... Хәер, мин соңгы вакытта синең тормышыңны белмим, бәлки инде синең гаиләң дә бардыр... Урынсыз борчыган булсам, гафу ит..."

Шулай дип язды да, Гөлҗиһан сулкылдап елап җибәрде...

Дәфтәр битенә күз яшьләре тамды...

Чыннан да, әгәр Фәргатьнең инде гаиләсе булса? Ул бит кеше күзе төшмәслек егет түгел, теләсә нинди хәлдә дә үз тиңен таба ала... Ул чагында Гөлҗиһанга, йөрәген учларына кысып, аларның юлыннан читкә китәргә генә кала... Гөлҗиһан беркайчан да кеше гаиләсенә кермәячәк, хәтта олы мәхәббәте хакына да... Ул моны бик яхшы белә...

Хатның ахырын ничек тәмамларга белмичә, Гөлҗиһан шактый озак уйланып утырды...

Юк, Фәргатькә мондый коры хат җибәрергә ярамый, ул бит хәзер җан җылысына бик мохтаҗ... Бәлки ул үзе дә, тилмереп, Гөлҗиһаннан бер хәбәр көтеп ятадыр, бәлки шул бер җылы сүз аны кабат яшәтер, аякка бастырыр! Ичмасам, җыр белән булса да, күңелендәгесен белдерсен әле, һаман яратуын сиздерсен... Алар авылында егетләр-кызлар мәхәббәтләрен гел шулай җырга салып аңлаталар... Балачактан гашыйк булып, сигез ел яратып йөреп, дөньяда башка беркемгә күтәрелеп карамаган Гөлҗиһанның менә гына хакы бардыр бит инде...

"Фәргать, хәтерлисеңме, син соңгы тапкыр безнең авылга ялга кайтканда, авылга Чиләбедән үзешчән артистлар килгән иде,—дип дәвам итте Гөлҗиһан, уйлары белән үткәннәргә китеп.—Без ул концертны бергә караган идек... Шунда бер яңа җыр башкарганнар иде... Без аны, тын да алмыйча, тетрәнеп тыңлаган идек... Соңыннан син мине озата кайтканда: "Бик моңлы җыр, сүзләре бик мәгънәле, әмма безнең мәхәббәтебез беркайчан да алай бетмәс",—дигән идең... Сиңа шул җырның сүзләрен исеңә төшерәм:

Син ант иттең, вәгъдә бирдең,
Гомерлеккә яр булырмын, дип.
Арган-талган чакларыңда
Йөрәгеңә ял булырмын, дип...

Таң йолдызым, нишләдең син,
Саф иде бит синең күзләрең?
Истән чыкмый, "Өзелеп сөям,
Оныта алмам", дигән сүзләрең...

Ник соң, бәгърем, биргән вәгъдәң
Очып китте искән җил сыман?
Ә мин калдым, ялгыз калдым,
Яфракларын койган гөл сыман..."

Гөлҗиһанның битләренә ут капты, керфек очларында тагы яшьләре тибрәнә башлады... Тагы үксеп елап җибәрмәс өчен, ул хатны тиз генә конвертка салды да, калтыранган куллары белән Фәргатьнең адресын яза башлады... Ахырга үзенең тулай торак адресын да язып куйды... Инде ни булса булды—хат китте, сүз китте, хәбәр китте... Инде алдагысы—Алла

кулында... Язмышында шулай язылган икән—күрешерләр, бәлки кавышырлар да... Юк икән, димәк, шулай язган... Бу билгесезлектә Гөлҗиһан беренче адымын ясады... Җавапны Фәргать бирергә тиеш иде...

## Егерме беренче бүлек

Фәргатькә Миасстан килгән хатларны Җәүһәрия апасы укып бирә иде...

Фәргать даими рәвештә әнисеннән хат алып тора, кайвакытта игезәк сенелләре дә язып җибәрәләр... Ул хәзер аларга җавапны үз куллары белән яза, чөнки сукырлар әлифбасын Фәргать күптән бик яхшы итеп үзләштергән иде инде... Хатны ул әниләреннән, дип уйлады, чөнки ана башка хат язар кеше юк иде... Һәм ул, тәм-томнарын кыстырып, Җәүһәрия апасы янына чыгып китте...

Сөнкүл читендәге агач баракта Фәргатьне инде барысы да беләләр, барысы да бик якын итәләр иде... Аны сукыр, бәхетсез кеше дип һич әйтерлек түгел, бөтен рәвешеннән тормыш дәрте бәреп тора... Аның зур, көчле гәүдәсе, һәрвакыт чиста-пөхтә өс-башы, нур чәчеп торган йөзе, ирләрдә сирәк очрый торган чибәрлеге сукырлыгын да оныттыра, ул килсә, бараktагы бөтен кызлар йөгереп, каршына чыга... Фәргать тәм-томны барысына да җитәрлек итеп алып килә, һәрберсенә нәрсәдән булса да өлеш чыгара... Аннары алар Җәүһәрия апасы белән, озаклап чәй эчә-эчә, хат укый башлыйлар, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыралар...

—Бу юлы әни хатны бер-бер артлы җибәргән әле, ашыгыч әйтер сүзе бар, ахры,—диде Фәргать, Җәүһәрия апасы белән кочаклашып күрешкәннән соң.

—Әниең янына бер кайтып килергә кирәк инде, улым,—диде Җәүһәрия, аның аркасыннан сөеп.—Ана бит, исән чакта күрешеп калырга кирәк, дөньяныкын белеп булмый...

Җәүһәрия апасы бу хакта аңа килгән саен әйтә, тик Фәргать Миасска кайтуын нишләптер һаман суза... Бу юлы исә нигәдер тиз килеште.

—Әйе шул, Җәүһәрия апа, үзем дә шулай уйлап торам,—диде ул.—Хәзер инде укулар башланды, көн саен Иртәшкә йөрисе... Менә кышкы каникулга чыгыйк инде, кайтып та килермен, Алла боерса...

Бу очрашуның тагы да тиз буласын, әмма әнисе белән Миасста түгел, Караболакта очрашасын Фәргать үзе дә белми иде әле...

Ияләнгән гадәт буенча, Җәүһәрия апасы хатны карап та тормыйча ачып җибәрде һәм, күзлеген киеп, кычкырып укый да башлады...

"Исәнме, Фәргать абый",—ул төртелеп туктап калды...

—Бәй, әниеңнән түгел бит бу хат,—диде ул, ни әйтергә белми аптыраганнан.

Аның каушавы Фәргатькә дә күчте, ахры, ул, кинәт карлыгып киткән тавыш белән сорап куйды:

—Кемнән соң?.. Миңа башка язар кеше юк бит...

"Сиңа бу хатны... күрше кызы Гөлҗиһан яза..."—дип укын дәвам итте Җәүһәрия һәм шатланып, кычкырып җибәрде:

—Гөлҗиһаннан бит бу хат, энем! Гөлҗиһаннан, кәләшеңнән! Менә могҗиза, менә Алланың рәхмәте!

Хатның чыннан да Гөлҗиһаннан булуына Фәргать әле ышанып бетми иде. Ничек аннан булсын, алар бит инде биш ел аралашмыйлар, Гөлҗиһан аның адресын белми, ә Миасста әнисенә беркемгә бирергә кушылмаган... Ничек инде—Гөлҗиһаннан булсын?

Фәргать ап-ак булып агарынып, тетрәнеп, телсез-өнсез калды... Ул хатка үрелде, дерелдәгән бармакларын кәгазь буйлап йөртеп, нидер белергә, танырга тырышты... Әйтерсең лә, шушы дәфтәр битеннән ул кемнедер

эзли, табырга газаплана... Менә ул хатны берни күрмәгән күзләренә якын китерде, бит йөзенә куйды, сулышына сеңдерергә тырышты...

—Гөлҗиһан...—пышылдады ул, кинәт кенә кибеп киткән иреннәрен чак кыймылдатып.—Укы, Җәүһәрия апа, танылым мин—чыннан да, Гөлҗиһанның хаты бу... Укы тизрәк...

Фәргать инде нәрсә ишетергә дә әзер иде...

Гөлҗиһан аның хәлен беләме, юкмы, һаман яратамы, әллә инде оныткан мы, ул биш елдан соң Фәргать белән исәнләшәме, әллә бәхилләшәме, саубуллашамы—ул инде барысын ишетергә дә әзер иде... Ул дөньяда менә шушы мизгел өчен генә яшәгәнен аңлады, аның исән калуы да, яшәве дә, үткәне дә, киләчәге дә бары тик Гөлҗиһан белән генә бәйле иде...

Ул Җәүһәрия апасы укыган һәр сүзне йөрәге белән йотып тыңлады... Гөлҗиһанның һәр сүзеннән зур мәгънәләр эзләде, сүз араларына яшерелгән сөю хисләрен көтте... Гөлҗиһанның хаты шактый коры кебек тоелса да, ниндидер әйтеп бетермәгән моң, сагыш сизде Фәргать бу сүзләрдә... Ул Гөлҗиһанның һәр сүзен Җәүһәрия апасы артыннан үзалдына кабатлап барды, мәңге онытмаска йөрәк түренә салып куйды...

Аны бигрәк тә хат ахырындагы җыр тетрәндерде...

Юк, ул аны җыр итеп түгел, Гөлҗиһанның үз сүзләре, әрнүе итеп кабул итте... Аңа еллар аша, Караболакның карлы бураннары аша, Урал таулары аша Гөлҗиһан үзе тилмереп дәшә иде... Бу сүзләр Фәргатьнең күңелен кышкы аҗаган булып яктырта, язгы саф җилләр булып уята, өметләндерә, Гөлҗиһан булып, үпкәли, көтә, чакыра иде...

Син ант иттең, вәгъдә бирдең,  
Гомерлеккә яр булырмын, дип.  
Арган-талган чакларында,  
Йөрәгенә ял булырмын, дип...

Әйе, алар да бер-берләренә нәкъ шулай дип вәгъдә бирешкәннәр иде бит... Язмыш нинди генә булса да, бер-берләреннән аерылмаска сүз биргәннәр иде... Кая китте ул вәгъдәләр? Нигә алар бүген тормыш ярының икесе ике ягында, нигә алар арасында яралы язмыш, мәңгелек караңгылык соң? Нигә аларның яшьлек хыяллары чәлпәрәмә килде, вәгъдәләре утка очты... Атом утында дөрләп янды... Дөрләп янды?!

Ник соң, бәгърем, биргән вәгъдәң  
Очып китте искән җил сыман?  
Ә мин калдым, ялгыз калдым  
Яфракларын койган гөл сыман...

Димәк, Гөлҗиһан да ялгыз...

Гөлҗиһан һаман аны көтә...

Һаман ярата...

—Энем, Гөлҗиһан сине һаман ярата бит!

Җәүһәрия апасының сүзләре аңа әллә кайлардан—Урал таулары артыннан ишетелә кебек тоелды...

—Ярата ул сине,—дип дәвам итте Җәүһәрия апасы, Фәргатьнең үзеннән дә артык сөенеп.—Ярата, әмма бу хакта әйтергә уңайсызлана, кыз бала бит... Шуңа күрә җыр белән язып җибәрергә уйлаган...

—Ул минем сукырайганны беләме икән соң?—дип кинәт кенә сорап куйды Фәргать.

Артык хисләнеп китеп, ул мона бөтенләй игътибар итмәгән иде... Бәлки Гөлҗиһан анын дөм-сукыр калуын, гарипләнүен белмидер? Аны элеккеге таза, көчле Фәргать дип күз алдына китерәдер?

—Шул төшен янадан укы әле, Җәүһәрия апа,—диде ул, бозлы суга чумарга әзерләнгәндәй...

“Фәргать,—дип хатны янадан укуын дәвам итте Җәүһәрия.—Син туй көнендә Караболакка кайтмагач, мин бик үпкәләгән идем... Хәзер хәленне ишетеп белдем. Ник бу хакта мина башта ук хәбәр итмәден? Без синен белән ярәшелгән егет һәм кыз идек бит... Мин сина чит кеше түгел идем...”

Хатта Фәргатьнен авыруы турында башка сүзләр юк иде...

“Хәленне ишетеп белдем”, дигән... Нинди хәл турында әйтә икән ул, анын сукыраюын беләме икән? Кайдан белде икән?

—Белгән, энем, белгән, барысын да белеп язганга охшый Гөлҗиһан,—диде Җәүһәрия, Фәргатькә ярдәмгә килергә теләп.—Йә авылыгыздан берәрсе сине Иртәштә күреп кайтып әйткәндер... Монда Караболаклар күп, дисен бит...

—Гөлҗиһан үзе дә Иртәштә икән бит,—дип, анын фикерен дәвам итте Фәргать.—Укып бетереп, Иртәшкә килгән... Ахрысы, чыннан да язмыш бу...

—Сезгә очрашырга кирәк, энем,—диде Җәүһәрия, егет киресен уйлап куйганчы.—Алла биргән очрак инде бу... Кыз бала сине үзе эзләп тапкан, инде җавапны син бирергә тиеш...

—Тукта, Җәүһәрия апа, адресы бармы сон анын?—дип сорап куйды Фәргать, борчулы тавыш белән.

Җәүһәрия конвертны әйләндергәләп карады, аннан, балалар кебек, шатланып кычкырып җибәрде:

—Бар, энем, бар... Менә... Иртәштә...Больница поселогында тора икән... Совет урамы, 14нче йорт, 15нче бүлмә дигән... Ханова Гөлҗиһан, дигән...

Ханова... Кыз фамилиясе, үз фамилиясе... Димәк, Гөлҗиһан да ялгыз, кияүдә түгел... Бәлки, чыннан да, Җәүһәрия апасы хаклыдыр, бу—Аллаһ биргән мөмкинлектер? Бәлки язмышында шулай язылгандыр... Фәргать үзе дә Гөлҗиһанны эзләп табу, анын белән очрашу уе белән яшәде бит... Тик анын бу кыяфәтендә Гөлҗиһанга күренәсе килмәгән иде... Ул, могҗиза көткәндәй, күзләре ачылуны, янадан күрә башлавын көтте... Әмма караңгылык таралырга ашыкмады... Ә гомер үтә торды... Фәргатькә дә инде егерме жиденче яшь... Нәрсә булса да хәл итәргә, ни булса да эшләргә кирәк иде...

Һәм Фәргать тәвәккәлләргә булды...

Иртәшне ул яхшы белә, Совет урамын, больница бистәсен дә яхшы хәтерли, армия хезмәте вакытында үзләре төзеде алар аны... Ике катлы тулай торакларны да хәтерли... Алар барысы да үзәктә, Фәргать укый торган институттан ерак түгел... Тапмаса, ярдәм итәрләр... Фәргатьне мәсьәләнен ул яклары бөтенләй борчымый иде, чөнки анын өчен күз күрмәү әле ул дөнья бетү түгел... Кайда да кешеләр яши, үзен әйбәт булсан, ярдәмнәреннән ташламыйлар... Фәргать өчен хәзер ин мөһиме—Гөлҗиһан күзенә күренү иде... Анын Гөлҗиһанга мескен булып күрсә килми, ул анда үзенә карата кызгану хисе уянуын теләми иде... Яратуны кабул итә Фәргать, ә кызгануны—юк... Шуна күрә Фәргать бу очрашуны шулай елларга сузды инде, Гөлҗиһанга үзе турында хәбәр бирергә ашыкмады... Бу хәлендә күреп, гайрәте чигер, дип тә курыкты... Ә ул, әнә, барыбер эзләп тапкан... Димәк, тәкъдирләрендә шулай язылган булган... Хәзер инде төп сүзне Фәргать әйтергә тиеш... Аны кабул иту-итмәү исә Гөлҗиһаннан тора... Анын язмышын хәзер Гөлҗиһан хәл итә...

## Егерме икенче бүлек

Гөлжиһан ул төнне төшендә Фәргатьне күреп уянды...

Матур җәй көне икән, алар Фәргать белән Караболак болынында житәкләшеп йөриләр... Болын шул хәтле матур, әйтерсең ул башка дөньядан... Нурлы болын өстендә аллы-гөлле рәшәләр уйнап тора, дөньяда булмаган хуш исләр килә... Фәргать белән Гөлҗиһан болын буйлап атлап түгел, очып баралар икән, аларның аяклары җиргә тими дә... Яннарында—берсеннән-берсе матур балалары, алар да эти-әниләре белән бергә оча... Менә алар шулай оча-йөгерә Аллакүл буена килеп җитәләр... Гөлҗиһан Фәргатьнең бит-күзләрен тау куышыннан агып чыккан чишмә суы белән юа... "Бу—Алып Адәм заманыннан калган тере су, ул безгә ярдәм итәчәк",—ди икән... Гөлҗиһан үзе дә, балалары да шул суда юыналар... Аларның йөзләре, тәннәре тоташ нурга әйләнә бара икән... Менә алар берзаман бөтенләй күзгә күренмәс булалар, болын өстендәге рәшәгә кушылып, җил булып, Караболак өстеннән очып үтәләр... Алда—күз явын алырлык көчле яктылык, ул Фәргать белән Гөлҗиһанны, аның нурга әйләнгән балаларын үзенә тарта, үзенә чакыра икән... Менә алар, шул яктылыкка кереп, эреп юкка чыгалар, Караболак өстендә аларның саубуллашкан авазлары гына эленеп кала... Алар артыннан күктән җиргә салават күпере сузылып төшә...

Гөлҗиһан әсәрләнеп уянып китте...

Болын, Фәргатьнең нурлы йөзе, берсеннән-берсе матур балаларның алар янында очып йөрүләре аны шул хәтле тетрәндергән иде, ул аларны янадан күрергә теләгәндәй, тагы күзләрен йомды... Гөлҗиһанның әле беркайчан да бу кадәр матур төш күргәне юк иде... Ә балалары нинди матур! Йөзләре нинди нурлы аларның... Аннан алар, барысы да тоташ нурга әйләнеп, юкка чыктылар... Күктән ингән яктылыкка кереп югалдылар... Әйтерсең лә, алар алдында күк капусы ачылды...

Төш бик мәгънәле һәм яхшы иде...

Ул Гөлҗиһанга ниндидер хәбәр буласын белдерә иде...

Ә Гөлҗиһан бары тик бер генә хәбәр көтә хәзер—Фәргатьнең җавабын... Ул Гөлҗиһанның хатын алгандыр инде, барыбер, нидер җавап бирмичә калмаячак... Төшеннән күренгәнчә, яхшы хәбәр көтә Гөлҗиһан... Шатлык көтә... Аның моңа хакы бар бит инде... Әгәр Фәргатьнең гаиләсе булса, ул Гөлҗиһанга җавап та биреп тормас... Ул аның өчен кайчандыр авылда җитәкләшеп йөргән күрше кызы гына булып калачак... Әгәр ялгыз булса, ул Гөлҗиһанны эзләп табачак... Фәргатьне белә Гөлҗиһан... Яратуы хак икән, ул ут эченә дә керәчәк... Ут эченнән дә үзенә кирәкне алып чыгачак...

Шулчак Гөлҗиһанның йөрәге жу итеп китте...

Тукта, ул хат язды язуын, ә Фәргать укый алмый бит! Күрми бит ул! Димәк, ул Гөлҗиһанның хатын укымаган... Ә ул тилмереп җавап көтеп ята тагы... "Ә бәлки ул берәрсеннән укыткандыр", дигән зәгыйфь кенә өмет чагылып китте кызның күнелендә.—Анда татарлар булмыйча калмас, Фәргатьнең ана гына башы җитәр..."

Тормыш чынбарлыгы матур төшне каплап китте... Фәргатьнең сукыр икәнлеген Гөлҗиһанның исенә төшерде...

Гөлҗиһан барыбер бу төшенә рәхмәтле иде, ул әле шактый вакыт шунын хатирәләреннән җылынып йөрде...

Бүген—ял көне, кызларның кайсылары авылга кайтып киткән, кайсылары шәһәрдә йөри... Гөлҗиһан авылга теге атнада гына кайтып килде, әниләренә бәрәнге алырга булышты. Таһир бабасына да казып бирде... Караболакта барысы да искечә—яз житсә, бәрәнге утырталар,

күз житсә—казып алалар... Халык авырый тора, үлә тора, туа тора, бу хәлләренә инде ияләнгәннәр... Гөлжиһаннын әтисе чуен аяклары белән дөбердәтеп эшләп йөри, авыл халкы урын өстендә ятарга яратмый шул ул... Иртәш больницаларында, аптекаларда дару күп, бик яхшылары да бар, Гөлжиһан авылдашлары өчен дә ташый башлады аларны... Күп булмаса да, терелтә алмаса да, бераз авыртуларын киметә, сызлануларын баса... Монарчы врачлар тарафыннан бер игътибар да күрмәгән авыл халкы Гөлжиһанга рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый, язып, заказ биреп кенә жибәрәләр... Бу юлы күршеләре тын буылганнан дару сорадылар, ә ул бик сирәк була... Гөлжиһан аны Иртәшнең дежур аптекасында бар икән дип ишеткән иде, шуннан алып куярга булды... Ә классташы Рәшидәгә исә кайткан саен "төймә" кирәк... Баш даруын ул шулай атый... Һәм Гөлжиһан аны авылга кайткан саен алып кайта, Рәшидә исә мона балалар кебек сөенә...

Гөлжиһан жинел генә киенде дә аптекага барып кайтырга булды...

Шәһәрдә алтын көз иде...

Иртәш урамнарына сары яфраклар түшәлгән, алар жилдә салмак кына кыштырдап, хәбәр биреп яталар... Күл буендагы урманнар ут капкандай, кызарып, янып утыралар,—аларны да көз шундый төскә керткән... Баш очыннан, моңлы кычкырып, торналар үтеп бара... Алар Караболак ягыннан Чиләбегә таба очып үтәләр, аннан тагы да көньякка, жылы дингез буйларына китәрләр... Иртәш суында зәнгәр күк, ак болытлар, торналарнын кара шәүләләре чагыла...

Гөлжиһанның йөрәгенә дерт итеп китте...

Бүген—29 сентябрь, Иртәштә шартлау булган көн иде...

Моннан ун ел элек тә нәкъ шушындый матур көзге көн иде бит...

Алар бөтен авыл белән Караболак кырында бәрәнге алалар иде... Кичке якта Иртәш ягындагы көчле шартлаудан жир сикереп куйды, күк ярылгандай булды, дөнья карангыланып китте... Аннан Иртәш өстендә утлы төтен баганасы күтәрелде, Уралтау тирәләрендә ажаган уйный башлады, Караболак өстенә соры томан килгәне күренде... Бу—атом болыты шулай үлем алып килә икән... Гөлжиһан үзенең күзаллары карангылана башлавын, кан косып егылганын хәтерли... Аны авылга атка салып алып кайтканнар иде... Ул вакытта Фәргать тә әтисе белән Караболакка килгән иде...

Аннан соң да инде ун ел вакыт үткән...

Ул вакытта атом утыннан янган агачлар урынында инде яналары үсә... Жимерелгән биналар урынына башкаларын төзегәннәр... Атомнан агуланган шактый авылларны башка урынга күчергәннәр... Караболак шул үле зонада утырып калган... Һәм аларның бөтен авырулары да менә шуннан булырга тиеш... Әмма, бөтенсе бер авыздан киресен сөйләп торганда бу хакта кемгә әйтәсең, кемне ышандырасың?

Гөлжиһан, кирәкле даруларын алып, кайтыр якка борылды...

Борылуга, туп-туры үзенә каршы килгән мәһабәт гәүдәле ир-атны күреп, Гөлжиһан баскан урынында катып калды...

Иртәш урамын тутырып, бер кочак чәчәкләр тотып, аңа таба Фәргать атлый иде...

Аңа житәрәк, кыз нидер сизенеп, туктап калды, Фәргатьнең кара күзлекләрендә үзенең чагылышын күреп, тетрәп китте... Йөрәгеннән, сагыну, сызлану авазы булып, "Фәргать" исеме бәреп чыкты... Бу тавышны Фәргать жиде кат жир астыннан, жиде кат күктән ишетсә дә, таныр иде... Аның каршында Гөлжиһан үзе басып тора иде...

—Гөлжиһан...—диде ул, тавышы калтырап китте.—Менә мин килдем, Гөлжиһан...

Аяк астындагы сары яфракларга җан керде, алар җырлап, Гөлҗиһан белән Фәргать тирәсендә бөтерелә башладылар...

Күктә очып барган торналар Иртәш өстенә төшеп, Гөлҗиһан белән Фәргатькә көмеш каурыйларын калдырып киттеләр...

Урал тауларыннан искән көзге җил аларны зәңгәр күкләргә алып менеп китте, кочагында тибрәтте, җаннарын иркәләде...

Бөтен дөнья шатлыгыннан шашты, чөнки бүген Гөлҗиһан белән Фәргать очрашкан иде...

—Әллә көтмәгән идеңме, Гөлҗиһан?—диде Фәргать, аның кайнар кулларыннан кысып...

—Көттем...—диде Гөлҗиһан, күз яшьләрен җилләр иркенә биреп...

Икесенең дә күңелендә янар таулар кайный, бу мизгелләрдә сүзләр көчсез, фикерләр таркау иде... Алар шулай, җитәкләшеп, Гөлҗиһан яши торган тулай торакка керделәр, бүлмәгә үттеләр... Кочагындагы чәчәкләрне алган булып, терсәгеннән җай гына тотып, Гөлҗиһан Фәргатьне түрдәге урындыкка алып килеп утыртты. Якыннан ул аның йөзенең шактый олыгая башлаганын күрде, әмма андагы нур, кырыс матурлык теләсә кемнең башын әйләндерерлек, телсез калдырырлык иде... Анда Йосыф пәйгамбәр матурлыклары бар иде...

—Хатынны алдым, Гөлҗиһан,—дип башлады Фәргать сүзен, читтән уратып йөртмичә.—Менә... Сорауларыңа җавап бирергә үзем килдем...

—Бәлки башта чәй эчеп алырбыз, Фәргать?—диде Гөлҗиһан, үзен аның белән ничек тотарга белмичә.

Ул аннан тартына да, ул аңа тартыла да, аның Фәргатькә ярдәм дә итәсе килә, әмма бу хакта аңа сиздерәсе дә килми иде... Алар арасында әле ниндидер киеренкелек бар, артык җитдилек бар иде... Шуңа күрә, Гөлҗиһан тизрәк чәй эчәргә тәкъдим итте, Фәргать моңа тизрәк риза булды.

—Куй алайса, Гөлҗиһан,—диде ул, гап-гади итеп.—Караболактагы кебек, бер гөрләшеп чәй эчеп алыйк...

Караболак сүзен ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге тагы кысылып, сулкылдап куйды...

Фәргать, ялга кайтканда, Гөлҗиһанның әбиләрендә туктый иде... Гөлҗиһан шунда кереп, Фәргатьне үзе чәй куеп сыйлый иде... Өстәлне дә үзе әзерли, чәйне дә Фәргатькә үзе ясап эчерә, үзе исә аның каршында утыра... Ярәшелгән егет белән кыз булгач, әби-бабалары бу хәлгә тыныч карыйлар, яшьләр өчен куанып бетә алмыйлар... Аның исеме генә чәй эчү инде, алар сәгатьләр буе шулай бер-берләренә карап, бер җан булып, серләшеп утыралар иде...

—Әти-әниләрең, әби-бабаларың ни хәлдә, Гөлҗиһан?—дип сорады Фәргать, шул татлы мизгелләрне исенә төшереп.—Моннан кайтып йөри аласыңмы?

—Аллага шөкер, барысы да исән-саулар,—диде Гөлҗиһан, сүз башларга сәбәп табылганга сөенеп.—Әле узган атнада гына кайтып килдем авылга... Бәрәнгеләр алдык, өйдә дә, Таһир бабайларда да...

Шулай сөйләшә-сөйләшә чәй эчә башладылар, Караболак хәлләрен искә төшереп чыктылар... Әмма иң мөһим, иң кирәкле сүзләр әле әйтелмәгән иде; алар аңа ничек тотынырга да белмәделәр... Фәргать үзен гади тотарга тырышса да, аның чынаяк тоткан кулы калтырап-калтырап китә, өстәл өстенә үрелгәндә, ул үзенә кирәк әйберне таба алмый интегә иде... Моны күреп, Гөлҗиһанның йөрәге өзгәләнде, әмма ул үзендәге кызгану хисен басарга тырышты... Аңа бу хәлләргә инде ияләнергә, кызганганын Фәргатькә сиздермәскә, сиздермичә генә ярдәм итәргә өйрәнергә кирәк иде...

Гөлҗиһанның бәхетенә, төп сүзне Фәргать үзе башлады...

—Син минем нигә туйга кайтмавымны анлагансыңдыр инде, Гөлҗиһан?—диде ул, чынаягын өстәлгә куеп.

—Анысын аңладым, тик соныннан ник бер хәбәр бирмәвенне аңлый алмадым,—диде Гөлҗиһан, үпкә-әрнүләрен сиздермәскә тырышып.

Фәргать бераз дәшми торды... "Бу кыяфәттә күренәсем килмәде", дип тә әйтәсе килмәде аның... Ин дөресе—ул беркемгә дә йөк булырга теләмәде, хәтта газиз анасына да... Фәргать башта аякка басарга теләде, күзләре ачылуга өмет итте...

—Минем беркемгә дә йөк буласым килмәде, Гөлҗиһан,—диде ул.—Хәтта туган анама да...

—Әниең дә бу хәленне белмиме?—диде Гөлҗиһан, тетрәнеп.

—Берсе дә белми... Синнән кала... Син кайдан белгәнсеңдер, күрше кызы...

Гөлҗиһан аны еллар буе өзелеп көткәнен, исән икәнлеген белгәч, бирегә эшкә килүен әйтеп тормады... Иртәшкә килгәч, Фәргатьне күпме эзләткәнен дә әйтмәде... Алар авылында, алар нәселендә кызлар егетләргә башлап мәхәббәт сүзләрен әйтмиләр, янып үлсәләр дә, ир-атның башлавын көтәләр... Гөлҗиһан бит әле аның ялгызмы-түгелме икәнлеген дә белми... Һәм ул монысын туп-туры сорарга булды, чөнки гаиләсе булса, Гөлҗиһан аның белән алга таба мөнәсәбәтләрен дәвам итә алмый иде...

—Ә син...ялгызмы, Фәргать? Гаилән юкмы?

—Юк, Гөлҗиһан, гаиләм юк, ялгыз мин... Синең кебекне очрата алмадым... Ә син?

—Мин дә ялгыз... Мин сиңа вәгъдә биргән идем бит. Без инде ярәшелгән идек...

"Сине генә көттем, сине генә яраттым, һаман сине генә яратам", дип әйтә алмады Гөлҗиһан... Телләре ул хакта әйтмәсә дә, күңеле, күзләре бу турыда кычкырып тора иде...

Бу сөйләшү шулай өзек-төтек күпме дәвам итәр иде, ул арада шаулашып бүлмәдәш кызлары килеп керделәр... Түрдә Гөлҗиһан белән чәй эчеп утырган чибәр егетне күреп, алар телсез калдылар... Егет пәһлевандай зур гәүдәле, аннан көч-гайрәт ташып тора... Йөзендәге нурдан, матурлыктан күз камаша, затлы кара күзлеге дә үзенә бик килешеп, серле төс биреп тора... Кичләрен дә бер җиргә чыкмаган, бер ир-атка күтәрелеп карамаган Гөлҗиһанның менә нинди ханзадәсе бар икән бит! Менә кем өчен саклаган ул үзен... Гөлҗиһанның уттай янган йөзен күрүгә, алар бөтенесен дә аңлап алдылар, ярым шаярып, ярым чынлап, бу чибәр егетнең кемлеген сорый башладылар.

—Ә бу минем ярәшелгән егетем Фәргать була,—диде Гөлҗиһан, ничек бар, шулай итеп.

Аның бу туры җавабыннан Фәргать тә, бүлмәдәге кызлар да башта югалып калдылар. Аннан кызлар, берсен-берсе уздырып, Гөлҗиһан белән Фәргатьне котларга тотындылар.

—Ә туй, туй кайчан була?—дип сорады үткен украин кызы.—Минем Гөлҗиһанның туенда ут чыгарып биисем килә...

Туй?

Гөлҗиһан белән Фәргать, аптырашып, бер-берләренә караштылар... Алар бит туй турында сүз дә кузгатмадылар... Фәргатьнең уңайсызланып калганын күргәч, Гөлҗиһан сөйләшүне тизрәк шаяруга борып җибәрде...

—Язган булса, туй да булыр, кызлар, биерсез дә,—диде ул, уены-чыны бергә.—Без әле ул турыда сөйләшмәдек, менә сез кайтып кердегез бит... Ә хәзер менә Фәргатьнең кучтәнәчләреннән авыз итегез...

Кызлар, көлешеп, кияү кучтәнәче, дип, өстәл өстенә ябырылдылар...

Ә күчтәнәчләр бик күп иде, кайдан шул хәтле белеп, табып алган боларны Фәргать? Ул ак күбектән генә торган иң яхшы тортлар, дисенме, затлы конфетлар, тәлгәш-тәлгәш йөзем, алма-хөрмә, дисенме, әллә нинди татлы ризыклар, тәмле җимешләр... Бу хәтле нигъмәтне бер юлы бу кызларның бары тик киноларда гына күргәне бар... Алар, көлешә-көлешә, өстәл өстен бушата башладылар, үзләре ара-тирә Фәргатькә дә күз салып алалар... Аның бүлмәдә дә кара күзлектән утыруыннан алар нидер сизенделәр, әмма Фәргать үзен бик гади һәм иркен тоткач, аның сукырлыгын оныттылар... Сөнкүлдән көн дә килеп, институтта юристлыкка укып йөрүен дә белгәч, ул алар каршында бөтенләй үсеп китте... Фәргать, чыннан да, теләсә нинди компаниядә сүзне оста алып барырлык мәдәниятле кеше, җор телле егет иде... Гөлҗиһан аңа читтән генә карап сокланып утырды, аның белән горурланды, Фәргатьнең югалып калмавына, бик тиз үз кешегә әверелеп китүенә куанды...

Чәй тәмамлангач, өстәл өсте шактый бушый төшкәч, кыз Фәргатьне җай гына култыклап алып, озата чыкты... Таныш булмаган урында ул Фәргатьнең читенсенеп йөрүен теләмәде... Шаярып кына башланган сүзгә дә нокта куясы бар иде... Кечке Иртәш аларны җемелдәп торган утлары, Урал ягыннан искән саф җилләре, тормыш шау-шуы белән каршы алды... Бу шәһәр инде Гөлҗиһанга дөньяда иң матур урын булып күренә башлады, чөнки биредә Фәргать бар иде... Ул, үзе дә сизмәстән, култыклаган уңайга, Фәргатькә сыена төште... Фәргать аның кайнар беләген үзенә кысты һәм инде беркайчан да җибәрмәде... Шулай бер-берләренә сыенып, алар кечке шәһәр урамнары буйлап озак йөрделәр... Кая баруларын да ачыкламадылар, ни өчен болай йөрүләренә дә хисап бирмәделәр... Сөйләшмәделәр дә, чөнки бу мизгелләрдә хәтта сүзләр дә артык иде... Алар бер-берләренең җан җылысына, тән җылысына сусаганнар иде, һәм бер-берләренә никадәр газиз, кирәкле икәнлекләрен алар шушы мизгелләрдә аңладылар... Алар бер-берләрен һаман яратуларын, бер-берләреннән башка тора алмауларын аңладылар...

Шулай итеп, языльшуны һәм кечкенә генә туй мәҗлесен Иртәштә уздырырга, ә никах мәҗлесен Караболакта үткәрергә булдылар...

Фәргатькә бик сиздермичә генә, бу мәшәкатьләрнең барысын да Гөлҗиһан үз өстенә алды. Языльшу шәһәр ЗАГСында, ә туй мәҗлесе исә Гөлҗиһан яшәгән тулай торакның ашханәсендә булырга тиеш иде. Ябык шәһәр булганлыктан, авылдан, Миасстан Иртәшкә туган-тумачаны чакырып тормадылар, алар барысы да Караболакка, никах мәҗлесенә чакырылган иде. Иртәштәге туй мәҗлесенә, Гөлҗиһанның хезмәттәшләреннән тыш, биредә яшәүче бөтен Караболак татарларын чакырдылар. Иң кадерле кунаклары исә мәрхүм Хәбибулла абыйсының хатыны Таифә җиңги һәм Сөнкүлдән Җәүһәрия түти иделәр... Шулай ук Фәргатьнең бергә укый торган курсташ егетләре дә җыелды. Шулай итеп, кечкенә генә дип уйланган туй мәҗлесе "ярты шәһәрне" җыйды, ул көнне тулай торак бинасы биеп, җырлап, ду килеп торды...

Гөлҗиһан белән Фәргатькә сокланмыйча карау мөмкин түгел иде...

Алар икесе дә яшьләр, матурлар, горурлар, төз, зифа буйлылар... Икесе дә күз явын алырлык затлы итеп киенгәннәр, әйтерсең лә алар авылда туып үсмәгән, гомер буе хан сарайларында яшәгәннәр... Фәргатьнең дөмсукыр икәнлеген кайберәүләр хәтта анламый да калдылар, чөнки Гөлҗиһан аны кысып култыклап алган, һәм бүгенге көннән алар бер тән, бер җан булып яшәп киткәннәр иде... Шушы көннән Гөлҗиһан—Фәргатьнең күзләре дә, аяк-куллары да иде... Ул—аның гомер юлын бергә үтәргә тиешле тормыш иптәше, законлы хатыны иде... Әмма Аллаһ каршында ул бары тик никахтан соң гына иренең хәләле була ала иде...

## Егерме өченче бүлек

Икенче көнне, больницадан биргән җинел машинага төяләп, Караболакка кайтып киттеләр...

Алга, шофер янына, Таифәттәйне утырттылар, артка исә Гөлҗиһан белән Фәргать һәм Җәүһәрия түти урнаштылар...Дус-иш, таныш-белеш аларны, больница бистәсе буйлап, кул болгап озата барды, бу гади татар кызының түе барысы өчен дә бәйрәмгә әйләнгән иде... Аның шушы кадәр гүзәллеге, булганлыгы белән сукыр егеткә кияүгә чыгуын күпләр вакыйга итеп кабул итте... Бу, чыннан да, әкияттәге могҗизага тиң иде... Моны күреп, каты авыруларда өмет уянды, алар да үз тормышларында шундый изге җаннар очрасына ышанып яши башладылар... Тоташ авырулар арасында, атом казаны өстендә утырган Иртәш халкына менә шундый яхшы үрнәк, җанда өмет тудырырлык хәлләр, соклангыч парлар кирәк иде... Гөлҗиһан белән Фәргать шушы әчкерсез бәхетнең якты үрнәге, мисалы булып тора иде...

Шулай итеп, җиргә беренче кар яуган ап-ак көнне Фәргать белән Гөлҗиһан Караболакка никах мәҗлесенә кайтып киттеләр...

Машина тулы бүләкләр, күчтәнәчләр, һәрберсенә өлеш бар... Аларны Гөлҗиһан, Таифә һәм Җәүһәрия апалары белән берлектә, ай буе җыйды. Башта Гөлҗиһан исеменнән Фәргатьнең әнисенә, әби-бабаларына, туганнарына бүләкләр алдылар, аннан Фәргать исеменнән Гөлҗиһанның әти-әнисенә, әби-бабаларына, Таһир бабайга, башка туганнарына кияү бүләге җыйдылар... Күрше-күләннәр, чыбык очлары да калмады, һәрберсенә бер яулык, бер оектан булса да өлеш чыгарырга тырыштылар... Фәргать пенсиясенең бер өлешен кассага салып барган булган икән, туй чыгымнарына да, бүләк-санакка да ул бик ярап торды. Гөлҗиһанның да җыйгалап барган маясы бар иде, тигезләп бүлә торгач, барысына да җитте... Ә авылда исә аның сандык тулы бирнә малы, әнисе әзерләгән ястык-мендәрләре, үзе чиккән тастымал-сөлгеләре, тәрәзә пәрдәләре, чаршаулары бар... Бу бирнә малы, Караболак гадәте буенча, кыз бала туугa әзерләнә башлаган иде...

Ә классташы Рәшидәгә Гөлҗиһан алдан ук махсус бүләк алырга ниятләп куйган иде... Аның инде җәйге киемнәре күп икәнен белә, Гөлҗиһан аларны шактый алып кайтты, ә менә Рәшидәнең язгы-көзге киеме һаман шул бер иске бишмәт икән... Бер кайтканда аны шул киемнән күреп, Гөлҗиһан елап җибәрә язды, чөнки бу аның мәктәп елларыннан калган иске бишмәте иде... Һәм Гөлҗиһан Рәшидәгә өр-яңа плющ жакет алып кайтырга булды...

Ул вакытта авыл кызлары арасында иң модалы кием—елкылдап торган, кап-кара плющ жакет иде... Аны кигәч, Караболак кызларын танырлык та булмый, шәһәр артистларымыни! Шуның өстеннән кечкенә яшел шәл дә ябып җибәрсәңме? Бетте, син авылның иң гүзәл кызы буласың инде... Әле аягында "прощай" дип аталган каптырмалы итекләр дә булса... Чиләбе, Свердлау кебек зур шәһәрләргә барып урнашкан авыл кызлары Караболакка әнә шулай киенеп кайталар, киез итек һәм мамык шәлгә уранган авыл кызлары алар янында бәп-бәләкәй булып, бөтенләй кечерәеп кала... Һәм Гөлҗиһан, икешәр смена эшли-эшли акча җыеп, классташ дустына да әнә шундый плющ жакет сатып алды... Ә яшел шәл белән "прощай"ны үзенекен бирергә булды, чөнки Гөлҗиһанның да гел яңаны алырга артык мөмкинлеге юк...

Иртәштән Караболакка ерак ара түгел, тиз кайтсаң, бер сәгатьтә дә кайтып җитеп була... Әмма алар бик ашыкмадылар, җайлап кына, шәһәрдән алган тәм-томны, күчтәнәчләрне әйбәтләп саклап кына, дөньяга

хозурланып кына кайтырга булдылар... Никах мәҗлесе әле кичке якта, ахшамнан соң гына билгеләнгән, шуңа күрә, әкрен кайтсаң да өлгерергә була иде... Юллар инде тәмам катырган, өстән ап-ак кар да явып үткән... Юл буендагы каен урманын тоташы белән бәс сарып киткән, алар көндезге кояш нурында күз явын алырлык булып җемелдиләр... Дөнья шундый матур, шундый саф, пакъ, нәкъ Гөлҗиһанның төшләрендәге кебек тоташ нурдан тора... Гөлҗиһан Фәргатьнең куенына кереп бетеп утырган, ул аның йөрәк тибешен ишетә, тән җылысын, җан җылысын тоя... Әйтерсең лә ул, Фәргать белән бергә, Иртәш, Караболак өстеннән оча, бәхете каршына оча...

Кышкы көн тиз карангылана, Караболакка килеп җиткәндә, инде эңгер-меңгер төшкән иде... Шулчак, барысын да таң калдырып, авыл өстенә сәер нур таралды, кышкы күктә аҗаган уйный башлады... Аллакүл тирәләреннән күтәрелгән бу нур Караболак өстен яктыртып бераз торды да, Гөлҗиһаннар кайта торган юлга төште... Аның яктысында ак кар өстендә чәчелеп калган салам бөртекләренә хәтле санарга була иде...

—Күк капусы!—дип кычкырып җибәрде Гөлҗиһан, үзе дә сизмәстән.— Күк капусы ачылды, Фәргать, теләк телик!

—Минем теләкләрем тормышка ашты инде—син янымда,—диде Фәргать, аны күкрәгенә кысып...

—Минем дә,—диде Гөлҗиһан, башын аның күкрәгенә салып...

Әмма икесе дә, эчтән генә, балалар турында уйладылар...

Гөлҗиһан—Фәргатькә, Фәргать Гөлҗиһанга үзеннән бала булмаячагы турында әйтмәде... Алар, могҗиза көткәндәй, әле һаман нәрсәгәдер өмет итәләр иде... Алар, гомумән, бер-берләренә авырулары турында бер нәрсә дә сөйләмәделәр... Мондый бәхетле мизгелләрендә берсенең дә чиргазапларын исенә төшерәсе килмәде... Инде табышкач, инде кавышкач боларның берсе дә булмас, мәхәббәт каршында бу авырлыклар барысы да чигенерләр, юкка чыгарлар кебек тоелды аларга... Дөнья бит бу—сукыр күрә башлый, баласызлар бала бәхетенә ирешә, әҗәл чирләләр аякка баса... Бу тормышта алар белән дә нәкъ шулай булыр кебек тоелды Гөлҗиһан белән Фәргатькә... Әмма мондый бәхеткә ирешү өчен, бик күп сынаулар үтәргә, авырлыклар күрергә туры киләчәк иде әле аларга...

Караболак яшьләрне шаулап-гөрләп, бәйрәмчә каршы алды... Әллә күк капусын карарга, әллә Гөлҗиһаннар кайтканын ишетеп, ярты авыл урамга чыккан. Яшь-җилкенчәк, бала-чага, авыл башына ук чыгып, гармуннар уйнатып, Гөлҗиһан белән Фәргатьне каршы алдылар... Кем җырлый, кем бии, кем Караболак гадәте буенча, юлга кәнфит-прәнек чәчкәнне көтә... Таифәттәй белән Җәүһәрия түти, алдан әзерләнгән капчыклардан алып, юлга тәм-том чәчә, вак акчалар сибеп җибәрә... Бала-чага, ак карны пыр туздырып, аларны җыя, чүпли башлый... Гөлҗиһан кечкенә чакта үзе дә күп җыйды кияү күчтәнәчен, иң күп акча да, кәнфит-прәнек тә аныкы була иде...

Шулчак Гөлҗиһан бер читтә нәүмиз булып басып торган Рәшидәне күрде... Ул да, балалар белән бергә, юлдан акча һәм кәнфит җыймакчы була, әллә ояла, әллә башкалар ирек бирми, башын иеп, бер читтә басып тора... Өстендә һаман шул иске бишмәте... Аны күргәч, Гөлҗиһан атылып классташы янына йөгереп килде, аны мәктәп елларындагы кебек кысып кочаклап алды... Рәшидә, салкын борынын Гөлҗиһанның җилкәсенә төртеп, мышкылдый ук башлады:

—Миңа кияү күчтәнәче калмады, миңа кияү күчтәнәче калмады,—дип такмаклый иде ул, сабый балалар кебек...

—Синамы?—дип сорады Гөлҗиһан, Рәшидәне машинага таба алып

китеп.—Сина бүләкнең ин зуры, Рәшидә! Без сина менә нәрсә алып кайттык...

Һәм ул, бөтен халык алдында, Рәшидәгә елкылдап торган кара жакет чыгарып тоттырды. Моны күреп, бөтенесе аһ итте, Рәшидә хәтта ятсынып, читкә тартылды... Әмма бүләк шул хәтле матур иде, Рәшидә, барысын да онытып, ике кулын сузып, жакетка үрелде, аны, Гөлҗиһаннан алып, күкрәгенә кысты... Гөлҗиһан ана төенчек белән тиз генә үзенең яшел шәлен һәм "прощай" ын да бирде, иске бишмәт кесәләренә кәнфит-прәниген тутырды... Рәшидә, бүләк-күчтәнәчләрне күкрәгенә кысып, авыл буйлап йөгерде, очраган һәрбер кешегә ул Гөлҗиһаннын үзенә матур бишмәт алып кайтуын сөйләде, жакетын әйләндереп-әйләндереп күрсәтте... Аннан, туганнары каршында мактанып өчен, өенә йөгерде...

Гармуннар уйнатып, кышкы юлга вак акчалар сибеп, Гөлҗиһаннар капка төбенә килеп туктадылар... Өйдән, йөгерешеп, ата-аналар, әби-бабайлар, туган-тумачалар чыкты, китте кочаклашулар, китте елашулар... Иң тетрәндергеч очрашу Фәргать белән әнисе арасында булды, биш ел буе күрешмәгән ана белән бала, бер мәлгә никах мәҗлесе турында да онытып, бер-берләренең күкрәкләренә капландылар... Янадан җан индерергә теләгәндәй, ана баласының сукыр күзләреннән сыйпады, бала анасының хәсрәт салган тирән җыерчыкларын капшады... Ул арада игезәк кыз туганнар да абыйларына килеп сарылдылар, бөтен урам, Караболак ярату һәм сагыну сүзләре белән тулды... Фәргатьнең бу бәхетен Гөлҗиһан читтән генә, шатлык яшьләре аралаш күзәтеп торды... Бу бәхетле очрашуда үзенең дә катнашы барлыгын уйлап, ихлас сөенде ул...

Аларга никахны Таһирҗан бабай үзе укыды...

Гөлҗиһанга ап-ак яулык бәйләтеп, Фәргатькә кара бәрхет түбәтәй кидереп, түр башына менгереп утырттылар. Караболак гадәте буенча, ирләр өстәлнең бер ягына, хатын-кызлар икенче якка тезелешеп утырдылар. Өй эче тантаналы, серле тынлык белән тулды... Ап-ак күлмәге өстеннән кара кәзәкиен киеп куйган Таһирҗан бабай үзе дә дулкынлана кебек, Коръән тоткан кулы калтырап-калтырап куя... Чөнки могҗизага тиң бу хәлләргә кеше ышанырлык түгел бит... Гөлҗиһаннын бу бәхетендә ул үзенең дә бераз катнашы барлыгын белә, шуңа күрә аеруча бер җан рәхәтлеге кичерә... Ул Гөлҗиһанны үз баласы кебек яратты, үзендә булган бар гыйлемне, иман нурын ана да биреп калдырасы килде... Ул аны үзенең дәвамчысы итеп күрде... Әмма зур, катлаулы бу юлның Гөлҗиһан әле башында гына басып тора иде...

Таһирҗан карт башта бик моңлы тавыш белән, Караболак көе белән Коръән укыды... Бу шул хәтле тантаналы һәм житди мизгел иде, Гөлҗиһан тирән итеп сулыш алырга да базмады... Фәргать тә Коръән моңын тын да алмыйча тыңлый иде... Бу мизгелләрдә алар, әйтерсең лә, житәкләшеп, күкләр каршында басып торалар иде... Әнә зәңгәр күктән, гаҗәеп моңлы тавыш белән сорау сорый:

—Син, Якуп улы Фәргать, Нәбиулла кызы Гөлҗиһанны үзенә хәләл җефет итеп алырга ризамы?

Янәшәдә генә Фәргатьнең каушаудан бераз карлыккан тавышы ишетелә:

—Риза... Мин риза...

Күктән килгән тавыш инде Гөлҗиһанга мөрәҗәгать итә:

—Син, Нәбиулла кызы Гөлҗиһан, Якуп улы Фәргатькә хәләл җефет булып барырга ризамы?

Башы бик нык әйләнүдән, Гөлҗиһан дәшә алмый, аның күз алдында табын һәм өй эче әйләнә башлый... Барысы да тынып, Гөлҗиһанның җавабын көтә... Күктән килгән тавыш тагы кабатлый:

—Син, Нәбиулла кызы Гөлҗиһан, Якуп улы Фәргатькә хәләл җефет булып барырга ризамы?

Шул чак Гөлҗиһанның колагына Фәргатьнең авыр итеп, ыңгырашып сулыш алганы ишетелә... Гөлҗиһанны чорнап алган ак томан артыннан сулкылдап, ул аннан җавап көтә... Шул тавышка сискәнеп, Гөлҗиһан күзләрен ача, каршында ап-ак булып агарган Фәргатьне һәм аптырап калган Таһир бабайны күрә... Әйе, бу бит аның никах мәҗлесе, аннан Фәргатькә кияүгә чыгарга ризалыгын сорыйлар... Әлбәттә, риза Гөлҗиһан, бу хакта сорап тормаса да була иде Таһир бабасына!

—Риза, Таһир бабай, риза, бу хакта үзең дә беләсең бит инде...

Аның җавабын ишеткәч, өйдәгеләр җиңел сулап, елмаешып куйдылар... Бу ут чаткысы Гөлҗиһаннан барысын да көтәргә була...

—Тәртибе шундый, кызым, сорарга кирәк,—диде Таһир карт, житди булырга тырышып.

Кияү белән кәләштән ризалык алганнан соң, Караболак гадәте буенча, шаһитлар үз сүзләрен әйттеләр, мәһәр турында килешенде... Шушы рәсми өлештән соң, Таһир карт шаулатып дога кылды, яшьләрне Аллаһ каршында ир белән хатын дип игълан итте... Аннан инде котлаулар, бүләк-күчтәнәч өләшүләр, сәдака бирүләр китте... Инде мәҗлеснең бу өлеше дә тәмамлангач, өстәлгә берсе артыннан икенчесе сый-хөрмәт, ризык-нигъмәт чыга башлады... Башта, татар гадәте белән, шулпалы аш килде, өстәлнең төрле урыннарына тау-тау өеп, кайнар ит куелды... Аннан табынга итле бәлеш, аннан дөгеле бәлеш, җимешле бәлеш чыгып утырды... Кунаклар әдәп саклап, тыйнак бер тәртип белән, мактап, рәхмәтләр әйтеп, бар нигъмәттән дә авыз иттеләр... Иң соңыннан өстәлгә чәй килде, чәй янына өем-өем чәкчәк, табак-табак коймак-кабартма, балы-мае, вареньесы, шәһәр татлылары чыгып утырды... Ул арада, ике яктан да сүз алып, яшьләргә матур-матур теләкләр дә әйтеп өлгерделәр... Караболакта, чын мәгънәсендә, никах туе бара иде... Фәргать белән Гөлҗиһанның никах мәҗлесе бара иде...

Гадәттә мондый мәҗлесләр чәйдән соң тәмамлана һәм бирелә дә шулай булды. Ашка дога кылгач, олы як, күчтәнәчләрне кыстырып, өйләренә таралыша башлады, яшьләр исә клубка җыендылар... Никах мәҗлесендә җыр-биюләр каралмаганга күрә, яшьләр монысын клубта дәвам итәргә булдылар һәм, шау-гөр килеп, кышкы урамга сибелделәр... Караболакның карлы урамнары аларны җиңелчә салкынлыгы, аклыгы һәм сафлыгы белән каршы алды... Әллә кайдан гармунчысы килеп чыкты һәм сыздырып уйнап та җибәрде... Караболак өстенә татар моңы агылды, ул кичке тәрәзәләрне һәм хисле күңелләрне чиртеп үтте, картларга яшьлекләрен искә төшерде, яшьләрне үз янына чакырды... Фәргать белән Гөлҗиһан, үзләрен чорнап алган авыл яшьләре уртасында, утлары җемелдәп торган клубка юнәлделәр... Аннан гармун тавышы, җыр-бию авазлары яңгырап тора иде... Караболакның бөтен яшьләре, зурлап, Фәргать белән Гөлҗиһанның никах туйларын котларга чыкканнар... Хәтта олыраклар да түзмәгән, парлашып, бу вакыйганы карарга килгәннәр, Фәргать белән Гөлҗиһанны олы тормыш юлына озатырга җыелганнар иде...

Караболак мондый кичәләрне уздыра белә, аның үзенең язылмаган тәртибе, кануннары бар... Мондый вакытта җырлар яшь парларга багышлана, биюләр алар тирәсендә бара, иң матур сүзләр дә алар өчен әйтелә... Әнә бүген дә яшьләр түгәрәк ясап алаганнар да, уртага Фәргать белән Гөлҗиһанны бастырып куеп, җырлый-җырлый әйләнәләр...

Караболак урамы,
Бу дөньяда сезнең кебек
Матур ярлар булмады...

Аннан Фәргать белән Гөлжиһан уртада кара-каршы басып, биергә тиешләр... Алар биегәндә, тагы махсус жыр жырлана:

Таш ташыйлар, ком ташыйлар
Чиләбе юлларына.
Аерып алулары авыр,
Бирмә ят кулларына...

Жыр-бию туктап торган арада, уртага чыгып котлашулар, матур теләкләр әйтү китә... Бу сүзләрдә, бу хәрәкәтләрдә ник бер тупаслык булсын, ник бер хөсет-начарлык чагылсын... Караболак яшьләре, үзләренен ата-аналары, әби-бабалары кебек, бүген дә чиста, эчкерсез... Авыл өстенә килгән зур афәт тә, һәрберсенә диярлек килеп кагылган каты авырулар, якыннарының үлеме дә бирелдәге яшәү рухын, тормыш дәртен сүндерә алмаган... Шуна күрә алар кешеләргә бары тик яхшылык кына телиләр, яхшыга гына ышаналар... Шуна күрә алар үзләрен басып бара торган кара тормыштан да яктылык табарга тырышалар, бәхетләренә ике куллап чытырдатып ябышалар...

Карурманда кар тирән,
Итәгенә кар тигән.
Һәр китапны укып киләм,
Сөйгәненне ал дигән...
Ай-ли, баланым,
Түгәрәгем, кызыл бит.
Жаның сөйгән, теләгәнең
Белән тигез гомер ит...

Яшьләр жырлап та бетерә алмый калдылар, клубка йөгереп Рәшидә килеп керде. Ул өр-яна кара жакеттан, башында чит-читләре укалы яшел шәл, аякларында каптырмалы "прощай" иде... Аны күргәч, башта танымыйча тордылар, аннан Рәшидә икәнлеген белгәч, аһ иттеләр, кул чабып уртага чакыра башладылар... Бүген Фәргать белән Гөлжиһаннын туе, бүген жаны теләгән һәр кеше түрдә була ала иде... Рәшидә башта оялып торса да, Гөлжиһанның үзен чакыруын күргәч, тизрәк анын янына барып басты. Ул арада гармунчы өздереп бию көен уйнап жибәрде, яшьләр, түгәрәкләнеп, кул чабып тора башладылар. Гөлжиһан Рәшидәне кулларыннан алып, клуб буйлап биеп китте... Рәшидә мона балалар кебек куанды, кайда икәнлеген дә онытып, "прощай"ларын тыпырдатып, Гөлжиһан белән бии башлады... Бүген дөньяда аннан да бәхетле кеше юк иде, бу клубта аннан да матур кыз юк иде... Ул мона чын күнеленнән ышана, чөнки анын матур шәле һәм итеге, бәрхет бишмәте бар! Аңа бәхетле булу өчен хәзер шушылар да житә иде...

Рәшидә арыганчы биеде... Аннан, Караболак гадәте белән, тып итеп кияү егет каршына килеп басты, берни аңламый торган Фәргатьнен кулларыннан алды да, анын белән бии-бии, Гөлжиһан янына килде... Хәзер Гөлжиһан белән Фәргать бергә биергә тиешләр иде, Рәшидә нәкъ шуны тели иде... Моны күреп, башкалар да кул чаба башлады. Бичара Рәшидә хакына, авылдашлары өчен, Фәргать белән Гөлжиһан клуб уртасында салмак кына парлап бии башладылар... Аларга сокланмыйча карау мөмкин түгел иде... Очарга торган аккош кебек горур һәм гүзәл Гөлжиһан... Анын янәшәсендә Урал таулары кебек мәгърур сынлы баһадир Фәргать... Караболакның ин матур, иң затлы балалары... Алар, гүя, биемиләр, ә

Караболак өстеннән очып, йөзеп баралар... Милләтнең бик бәхетле һәм бик бәхетсез ике баласы... Алар хәтер күзәнәкләрендә мең еллык нәсел тамгасын—татар тамгасын йөртәләр... Аларның бәгырьләренә атом тамгасы—үлем тамгасы да сугылган инде... Алар—милләтнең бөек үткәне белән фаҗигале киләчәген тоташтырып торучы соңгы буын... Алар язмышлары буйлап оча, ә аста дөнья белән бәхилләшеп яткан Караболак кала, әҗәл җиле кагылган кырлар кала, аларның язмышына әйләнәчәк Иртәш кала, үлем коралы ясап ята торган заводлар кала...

Канатлары көймәсен иде аларның бу атом утында, рухлары сынмасын иде, чөнки алар да бу дөньяга бәхет өчен туган адәм балалары бит... Татар балалары...

Хәерле юл телик аларга...

**Редакциядән:**
***Бу айда күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәузия Бәйрәмованың юбилее. Каләмдәшебезне ихластан тәбрик итәбез, аңа сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.***

---

*Мең санның бер чаткысы*




2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

## “ЯҢАЛИФ” ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕННӘН

“Яңалиф” журналы Татарстан “Яңалиф” Дәүләт Комитеты органы булып чыгып килде. Аның алдына куйган төп бурычы – татар массасы арасында яңалиф идеясен тарату, яңалифне үзләштерү, яңалиф әлифбасы аркылы социализм төзелеше юлындагы техника үсеше белән таныштыру иде.

Татарстан Җөмһүриятенең УН ЕЛЛЫГЫ унае белән бөтен татар матбугаты Яңалифкә күчеп бетүе сәбәпле һәм яңалиф идеясе татар массасы алдында үзләшкән дип белгәнгә “Яңалиф” журналы үзенең төп бурычларының иң зурысын үтәгән дип әйтә ала. Шунлыктан моннан ары ТДЯК-ы аерым органның кирәге улкадәр сизелмәгәндә (ул типтәге журнал беренче июньнән туктатылган исәпләнә) аның урынына шул ук “Яңалиф” исемендә, икенче тип, ягъни литература, сәнгать, критика, культура мәсьәләләрен эченә алган зур күләмдәге, айга бер рәт бүтән журнал чыгарыла башлый. Элекке “Яңалиф”нең язылучыларына шушы яңа тип журнал “Яңалиф” җибәрелә.

*(Яңалиф. – 1930. – № 1. – Б. 2).*



## Айдар Хәлим

# АЛТМЫШЫНЧЫ ЕЛЛАР— ЯҢА СУЛЫШ

*(Яшьлек дәфтәрләреннән)*

### Яшь каләмдәшләргә ачык хат

*Олы юлдан килгән кәрваннарның*
*Һаваларга оча шул тузаны...*

Халык җырыннан

**Йөгәнен-эшлияләрен асылташ белән чигеп,**
**Табырдан ак толпарларның сөлектәйләрен җигеп,**
**Фаэтонның зиннәтлесенә утыртып һәр зур җанны—**
**Анда Колгали, Мөхәммәдъяр, Имәни вә Мәрҗани,**
**Тукай, Әмирхан, Галимҗан, Тинчурин, Җәлил, Такташ,**
**Кариев, Яруллиннар бар, Габәши, Җиһан, Сәйдәш—**
**Кузлага узыгыз, яшьләр! Яндырып күзләр явын,**
**Биетеп дилбегәләрдә өр-яңа хисле давыл,**
**Әйдәгез, гизик дөньяны, бассын атлар тып та тып,**
**Күкрәп күк, җир убылса да, булмас безне туктатып...**
**Җиләбез! Дәһшәтле гамьне, саф аһәңне җыр итеп**
**Кушабыз, әй, кыйтталарның алтысын да бер итеп!..**
**Чү, җиһан! Аһ, кем сихерли? Салихтыр, Сәйдәштер бу!**
**Гөл биреп, төнне тилерткән таңнарга адаштыр бу!**
**Җиләбез! Җилләр сызгыра! Баса атлар тып та тып.**
**Халыклар чыккан юлларга—сәламлиләр шаккатып.**
**Сәламли Пушкин, Петефи, Гете, Толстой, Мицкевич!**
**Әйтәләр: "Болар азатлык алган үзебезнең татар ич!"**
**...Хыял димә—көн зары бу! Фикер угың алга ат!**
**Тор, кагын, җилкен, и, рух, дер селкет татарны, уйлат!**

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар ("Милли шигырьләр", "Минем түгәрәк имәнем", "Татар вакыты" һ. б.) авторы. Г. Исхакый премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

Ничә гасыр исне җуеп, тыныч актык, сал кебек.
Пегаслар да талчыктылар, ашый торгач талчыбык.
Үзебезне таныек, дуслар, тамырыбыз—нык, көчле без!
Бернинди яшеннәр алмас чикләвектәй төшле без!
Шагыйрьләргә хас эшмени өстән йөзеп саклану?
Юкка мактану, туктаусыз "Тукай бар" дип аклану?
Җырчылар—аз, шигырьче күп, ишегендә тотка юк,
Их, дусларым, тарих катгый, тоткасызга үпкә юк...
Сизәмсез, яшәрә фикер?! Тумый калмас яңа дастан!
Халык даһилыгын дастан данлар әле яңабаштан!
Алга, достойный егетләр! Җыр языек киң карап,
Чын иҗат—тик зур көрәштә, зур матурлык—зур тараф...

*1967*

***

Юк, онытмам төнге казарманы—
Яшькелт нурлар оеган ишектә...
Чолгауларын чалма итеп урап,
Тревога көтә итекләр...

*1961*

## Идел үрендә

Иртәсен дә, кичен дә
Тынгы белми,
Нәрсә, дуслар, чыкмый күңелдән?
Бәлки, рифма,
Зәңгәр җилкән киереп,
Кулын болгар миңа Иделдән,
Төшим әле...

***

Йолдызларны көндез күзләмә,
Бөдрә таллар үсми чагылда—
Эзләмә.
Ширбәтле тел яхшы—табында.
Җырның үз теле бар давылда.

***

Очкын чәчри итек табаныннан.
Дәртле солдат юлда ял итә.
Үз иленә тугры булган егет
Тик бер генә тапкыр ант итә.

***

Котыра давыл, ташкын шаша, шау-шу...
Акчарлаклар поскан кыялар...
Диңгез—миңа бер йотым су икән,
Океаннарда булгач хыяллар...

***

Зәңгәрлектә кинәт эреде йолдыз...
Җиргә кайта яшәр нурлары.
Югалттыммы сине?
Әллә вакытлыча
Оныттыңмы җирдә мин барын?

***

Мөңгерәмәче, егет!
Күзгә керә шундый хакыйкать:
Безнең җырлар кайчак сыеклана
Җырлаганда үзе табигать.

***

Бер ялгызым. Кемдер курай тарта.
Җырлар... кырлар... кырлар...
...Нишләр идем—сикәлтәсез булса
Йөргән юллар?..

***

Ергалаган зур акланны сугыш...
Төпләрендә кыргый гөлләрнең,
Җиргә сеңгән мүкле автоматта
Култамгасы канлы елларның...

***

Күзләр хушлашканда—сүзләр артык.
Күзләр алар... күзләр алдашмас.
Давылларда бер буразна ярып
Тапкан дуслык мәңге адашмас.

*1962*

***

Акылдан шашкан диңгездә
килә ул нинди кораб?
Шигъри ялкыннан да көчле
кайда бар нинди шәраб?

***

Төнге дустым, илһам кошым,
килде-кунды киртәмә.
—Сайрасаң, сайра бүген,—ди,—
очтым-киттем иртәгә!

***

Әнкәй мине алтын басуларда
Каеннарга асып тирбәткән.
Шуңа мәллә каен саргайганда
Моң агыла минем йөрәктән?

## Тирәкләрдән мамык...

Каз өмәсе мәллә Самарада?
Сөзеп торам үткән халыкны:
Сыпыра һәркем тирәкләрдән очып
Борынына кунган мамыкны...

*1964*

## Берәү генә булыр Гомер[1]

Җиз сакаллы оракул[2] Урта диңгез ярларына басып
Кычкыргандыр.
Кычкыргандыр оракул, кычкыргандыр:
“Гасыр комын гасыр комы басса да,
Кай шагыйрьне яза-яза радикулит басса да,
Зевс безгә бүләк иткән тик бер гомер,
Җир йөзендә тик бер генә булыр Гомер”.

***

Җыр кирәк, җыр!
Җиргә җыр кирәк!
Пыскымасын учак—җил кирәк!
Туксан яшьлек картны яшәртерлек
Шигъри энҗе эзләп ян, йөрәк!

Кайнасын җыр тормыш күкрәгендә,
Ялгыз торна җыры булмасын,
Илдә тусын, илгә хезмәт итсен,
Таңнар кебек иркә суласын!

***

Диңгезләрдә—зәңгәр җилкәнем,
Йөрәгемдә—туган илкәем.

***

Җырлыйсым килә, дусларым,
минем күптән язганым юк!
Шигъриятнең кымызында тәннәремне
язганым юк!

***

*И. Шакировка*

Мендең дә син Урал тауларына,
Җыр җырладың басып ташына.
Таулар кайтавазы булыр идем
Җырыңдагы моңлы тавышыңа...

[1] Гомер — борынгы грек шагыйре, “Илиада” һәм “Одиссея” поэмаларының авторы. Кайбер төрки галимнәр аның исемен төрки “гомер”дән алынган дигән фикерне дә белдерәләр.

[2] Оракул — борынгы рим мифологиясендәге күрәзәче.

***

Кырыкмыш күк чапма инде, гомер!
Утларны без яңа кабыздык.
Күп шаярсаң,
Елларыңнан каерып,
Кидерербез чылбыр-авызлык!

***

Билен бөгеп суны үпкән таллар
Үлгән төнгә укый җеназа.
Ә таң абзый,
Зәңгәр каләм белән,
Дим ярына яңа җыр яза...

***

Яшь көмешеңдә чагыла аргы урам.
Яшь сәйләнеңдә бөеклек
Мин күрәм!

Сызлана, ыңгыраша, әй, кеше!
Акыл теше чыга ир балага—
Тормыш теше!

Чын ир булуның ләззәте җиңел килми.
Кайбер кеше картайганчы
Шуны белми.

*1964*

***

Каның синең балык каны кебек салкын.
Бармы синдә яшьлек дәрте, ут һәм ялкын?
Әйт, кызыкмы шулай яшәү дөньяда?
Сындырмагач үз ишкәгең дәрьяда?

***

Яхшы шигырь—канга сеңгән кымыз кебек.
Начар шигырь—теле сынган кубыз кебек.

***

Зәңгәр төннең җиз телендә
Тальянымның бөтен моңын сыгар идем.
Сусаганда, алларыңа, халкым,
Чишмә булып кайнап чыгар идем.

***

Ана корты һәлак булса
Таркала күч.
Дуслык качса, дулый җирдә
Кап-кара үч.

***

Поши булган урманнарда бүре йөрмәс.
Сөю дөрләгән йөрәккә тузан кунмас.
Ил егете изгелеккә юлга чыкса,
Күңел кошы матурлыкны җырлап туймас.

## Җырчы

*"...шагыйрьләргә канат куй!.."*
Константин Библ.

Кешелек тугайларыннан караңгылыкны куып,
Килә чал чәчле яшь-яшь егет:
—Җирне яратыгыз!
—Җирне яратыгыз!
—Янып, илһамланып яратыгыз!

Килә ул—
Мәхәббәттә гомерлек Башкода,
Батырлыкта—үлемсез каһарман.
Җырлап килә—
Ак күбеккә коена яңадан шомырт,
Кайта киткән өмет,
Дәрт-дәрман...

***

Томырылып, яңгыр явып узды,
Сафландырып тынчу һаваны.
Шатланам мин—
Хәзер иманнәрнең
Буйга үсә торган заманы...

*1965*

## Үземә тәнкыйть

Үтәрмен урамнар буйлап,
Үсеп җитсен сакал-мыек!
Җырларым нәкъ каен суы,
Үзе зәңгәр, үзе сыек...

***

Хатын-кызның бөеклеген мактап җырлыйм,
Дөньяда иң гүзәл бизәкне алар чигә.
Мәхәббәттә килбәтсез ирләрне күрсәм,
Җаным читлеккә бикләнеп җәфа чигә.

## Шаяру һәм чын катыш

Кайчан да булса өзелермен,
яшәү белән хушлашырмын дим,
Теге дөньяда тәү эш кылып,
Тукай белән очрашырмын дим.

*1967*

## Сакларбыз!

Сатмадым һәм сатмам, әй туган тел!
Ватмадым һәм ватмам, әй туган тел!

Бар караны таңга бирәм—пакъләрбез.
Үлемсез син, әй туган тел—сакларбыз!

## Халык шагыйренә

Халкың сиңа фатихасын биргән
Бар таушалган хисне яңарт дип.
Әллә шуңа төнен реалист син,
Таң сызылса—янар романтик.

## Бала көткәндә

Син төш күрдең.
Имеш, алар игезәк.
Кыз бала—сөрмәле зәңгәр күзле,
Ир бала—тугач та алдыңа менеп утырган...

Тышка чыктым.
Табырдагы биям,
Күрәм,
Ике колын китергән.
Нинди байлык!..

*1968*

## Казанда

Кемнәр монда чын-чынында "Милләт!"—диеп чиләнә?
Күпләр аны бар дип белми. Мода өчен сөйләнә...

## Моң

Нindидер бер мәңгелек моң килә,
Туасы моң—нинди моң булыр?
Гүләп килгән җир тетрәве сыман
Җырлый бүген—шигъри кылымдыр?!

*1970*



## Фәрит Яхин

# БАКЫР БОЗАУ АРТЫННАН

хикәя

### 1

Авыл аякка басты! Әмма ул иң әүвәле колаклы булды. Сүзнең егәре буш тегермәнне дә онлы итә, диләр, хак икән. Колакка кергән ул сүзләр күпереп китте, йөрәкләргә очкын салды һәм кайнарланып, кабынып, зур утка әверелде. Авыл йокысыз калды. Бу кадәрле галәмәтнең Сасмакта Париж Коммунасы вакыйгасыннан бирле булганы юк иде.

Сабирның катыкчы хатыны Шәмсия Казанга киткән, имеш, көянтәсен сындырган да, кайта алмыйча ята икән дип хәбәре килеп ирешкәч, ире, мескенкәй, алагаем гәүдәсен сөйрәп, калага үзе юл алган. Бер көн буена эзләгән хатынын. "Колхоз базары"нда Арча хатыннары каймак, эремчек, сөт һәм катык сата торган рәтләрне ун әйләнгән. Шәмсиясе менә шушында гына булырга, сынган көянтәсен кочаклап елап утырырга тиеш, имеш. Юк икән шул! Сабирның уңлы-суллы йөрүләренә гаҗәпләнгән Арча хатыннары:

—Каймактан авыз итегез!

—Сөтемне кабып карагыз!

—Эремчектән... Эремчектән!

—Катык... Катык!..—дип кыстыйлар икән моны.

Сабир:

—Куегыз әле каймагыгызны, ташлагыз әле сөтегезне, катык кабар хәлмени! Хатынны менә шушында гына, дигән иделәр. Шәмсиямне эзлим. Көянтәсе сынган. Өченче көн өйгә кайтканы юк,—дигәч, телдән-телгә чыштый-пыштый сүз киткән.

—Көянтәсе Тукай урамында сынды,—ди икән берсе.

—Булыр сиңа, Камал театры янында сынды,—ди икенчесе.

—Юк ла инде... Ул яшьли сөйгән егете Вәлиуллланы очраткан иде.

---

Фәрит ЯХИН (1961) *—шагыйрь һәм прозаик; «Пәйгамбәребез Мөхәммәт», «Ак әбиләр догасы», һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шундадыр. Аны күргәч, кайсы хатынның көянтәсе сынмыйча калганы бар?—дип сөйли икән өченчесе. Әмма болары Сабирның колагына гына ирешми. Ул инде ит рәтенә күчеп, аннан Шәмсиясен эзләштереп маташа.

Итчеләрдән бер юан һәм гайрәтле мишәр:

—Шәмсиянең Фатих әзмәвер кулында "көянтәсе сынган", белмисеңмени?—диярәк әйтүенә, тәмам барысы бергә бер авыздан хахахайлап алгач кына, беркатлы Сабирның күңеле жу итеп, оятка калмас өчен бөтенләй икенче кыяфәткә кереп, Шәмсияне белмәгәндәй:

—Итне каян аласыз, егетләр? Бу кадәр калжалар каян килә?—дип, юри генә, боларны сөйләштерә башлаган.

Юан һәм гайрәтленең авызы ачыла, күзе уйный, теленә сүз килергә өлгерми, бу тагын:

—Нинди ашлык симертә икән боларны?—дип өстәп куя.

Җавап житешми, ул кабат сорауларын тезә.

Ниһаять, юаны түзми:

—Кара әле агай, шушы кадәр чокым булдың инде, башымны катырдың... Әйтсәм-әйтим... чуашлар үстерә боларны!—дип тезеп китә.

—Нинди чуашлар?—ди Сабир, әлегә уенда уен булган хәлендә.

—Аксубай чуашлары!

—Алар анда да бармыни?—ди Сабир тагын да, белмәмешкә сабышып.

Тегесе бер дә уйлап тормаган:

—Урыс белән чуашның булмаган жире юк инде!—дип жавап биргән.

Менә шулчак газиз башына акчалы уй кереп, Сабирны харап итте дә инде. Монда нинди максатта йөрүен онытты. Мал-туар дигәндә ул, көянтәсе сынган Шәмсиясен эзләү хәвәсеннән чыгып, чуашларга кимендә бер-ике бозау, өч-дүрт сарык алырга бару өчен яр буе шофер Хисмәтне котыртырга кереште. Энәсеннән җебенә кадәр планнар да кора башлады. Әмма күңелендә туктаусыз туып торган сорауларга да җавап табарга теләп, аларны Хисмәтнең колагына яудырырга тотынды һәм шунда ук җавабын да ала торды:

—Анда бозау кыйммәт бәяме?

—"Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер!"

—Юлы авырмы?

—"Олы юлдан—пыяла!"—"Иртә чыккан—юлы унган!"

—Кешеләре нинди?

—"Ашлы-туйлы!"

—Чәй-шикәргә ничек?

—"Суның—зәһәре, балның—бәһәре!"

Сабир, канәгатьлек кылып, ишеккә таба юнәлде һәм шул барышы белән авылынача кайтып житте. Әзмәвер Фатихны да, чукынчык Вәлиулланы да белешеп тормады. Агыйделнең аръягы белән чагыштырганда алар беркем дә түгел иде.

Өенә кайтып керде. Кызарып пешкән калач кебек, түгәрәкләнеп, тәмам бәхеткә ирешкәнен яшермичә, канәгать төстә аяк бөкләп өстәл башында май, каймак, җимеш һәм дә мең төрле татлыдан ризык тезеп чәй эчеп утырган хатыны Шәмсияне күргәч кенә Казанга ни өчен барганлыгын исенә төшерде һәм ана кочакларын җәеп якыная башлады. Аның чамасыз күтәрелгән куллары чукмардан да зуррак күренеп, кочагына кергән тегермән ташын он итәр кебек тоелса да, хатыны:

—Иркәм, җанашым, бәгърем!—диярәк өстәл башыннан төшеп, иренең назына чумды.—Кайларда йөрдең, җан кисәккәем, шушы кадәр югалып?

Бу сорауны һәрхәлдә ул бирергә тиеш түгел иде. Инде генә эреп киткән Сабирның күзенә шул чагында мич арасына чиләкләре белән бергә куелган көянтә чалынды.

—Бәракаллаһ, көянтәң сынмаган икән лә!

Хатыны җинелчә калтыранып куйды. Коты чыкмакчы идеме? Әмма кочагындагы Шәмсиясенең бу калтырануы Сабирның нәфсесен генә кузгатканлыктан, тәкатеннән узып, шик-шөбһәгә тарымыйча калды. Бәхетне адәм баласына Аллаһы Тәгалә бер бирсә, чумырып ук тапшыра шул, башаяк чумарлык итеп!

—Яңасын алдым!—дип, Шәмсия көянтә мәсьәләсен чишеп салды.—Өч көн эзләп йөрдем. Таптым, чукынганны, урман ягы марилары алып килгән иде!

Сабирның да бу сүзләргә канәгате килде:

—Яхшы булган, әлхәмдүлиллаһ!

Хатынын кочагыннан чыгарып, Сабир көянтәгә таба үрелде. Алды. Уңлысуллы әйләндерде дә сөйләнде, әйләндерде дә сөйләнде:

—Нәкъ элеккесе кебеген каян таптың? Буявы да тегеседәй яшел, нәкъ шулай ук кыршылган элмәкләренең кадакларын да минемчә итеп какканнар, шул ук рәвешен китереп кәкрәйтеп тә куйганнар әле! Сөбханаллаһ!—дип тезеп-тезеп китте.

—И хәләлем,—диде Шәмсия.—Кулларың бигрәкләр дә уңган икән. Бөтен дөнья синең өлгегә карап эшли!..

Эһ, Шәмсия! Житмәсә иренең беләгеннән дә сыпырып куйды, күзен дә кыскандай итте.

Шул хәрәкәтеннән соң көянтә кайгысы онытылды. Дөньялары тәмам түгәрәкләнеп, Сабир да өстәл башына кунаклады. Казаннан алып кайткан мал-туар һәм чуаш мәсьәләсен исенә төшереп, ишеткән: "Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер!"—өметендә авызын ерып җибәрде. Иренең күзләре уйнап, тамагының кырылуында сәбәп барлыгын сизенеп, Шәмсиясе:

—Ни иде, иркәм-җанашым?—дип, уртага сорау салды.—Май ашадыңмы әллә?

Сабир, үз рәхәтенә чумып дигәндәй, елмайган хәлендә сөенеп утыра бирде. Шәмсиянең көтмәгәндә күңеле кайнарланды, бәгырен шик энәсе тишеп үтте: "Тукта әле, берәр хәлне, аны-моны сөйләмәгәннәрдер бит? Бигрәк елмаеп, әллә кем булып утыра әле бу!"

—Син нәрсә, шул сүзләргә ышандыңмы?—дип, коелып төште Шәмсия.—Әзмәвер Фатихның тоткыны булырга диме инде? Юк сүз ул, ирем-бәгърем, аның, тотса, ташны сыгардай кулларына бүтән бер генә дә килеп кердем юк! Аллаһ сакласын, туйдырып бетерде инде ул. Сиңа Сабирым, житәме соң! Йомшак итеп кенә тотасың, ваклап-ваклап кына үтәсең...

Ә Сабир һаман да елмаеп, үз бәхетенә чумып утыра бирде. Күзләренең зәңгәрлегенә кушылып сер тама. Аның саен сөекле Шәмсиясе җиде йозак астына бикләп куйган кыңгыр эшләрен уртага чыгара бирә:

—Син Вәлиулланы уйлыйсыңдыр инде? Юне юк аның! Көянтәм сыну хакында базар хатыннарына ул гына сүз тараткан. Беркем дә түгел! Күпме итәгемә уралып йөрде. Билләһи, аңа бирелдсем юк!.. Ни... бер-ике тапкыр ялгышуыма хәзер дә үкенеп бетә алмыйм. Каймагыма, сөтемә хуҗа булмакчы иде. Натуралата түләтергә теләде. Нишлим соң? Барысын да белеп кайттыңмы? Билләһи, моннан ары, тәүбә-тәүбә, Аллаһ сакласын, көянтәмне сындырмам!

Шәмсия сөйләде дә сөйләде. Аның саен ире Сабирның исе китмәде, уйларының рәхәтлегенә хәйран калып утыра бирде. Инде ул Агыйделне кичеп чыккан, көтүе белән мал-туарга хуҗа булып алган бай кешедәй хис итте үзен. Хатынының сүзләре бер колагыннан керә торды, хәтер тартмасында тукталыр урын таба алмыйча, арлы-бирле сугылып, икенче колагыннан чыга барды. Әмма уйларыннан вакыт-вакыт айнып та китkәләде, анлый гына алмады: бу нинди бетмәгән көянтә сыну хәсрәте соң әле?

Ул да түгел, Шәмсиясе аның аяк астына егылып елый ук башлады:

—Ирем, бәгърем, ятим итмә?!. Балалар хакына! Авыл халкы алдында оят бит! Кая барыйм сон? Фатихка да минем көянтәм сыну гына кирәк. Вәлиулласы да мәлгунь! Мәңге бакый көянтәмне кабат сындырмам!

Ант суларын мең эчеп кенә калмыйча, инде вәгъдә дәрьясына баштүбән чумып тончыгыр хәлгә житкән Шәмсия, тәмам бушангач, һаман кымшанмый үзалдына серле елмаеп утырган иренә күтәрелеп карарга җөрьәт итте. Шунда гына, башка бер хәл булырга кирәк монда диярәк, аяк өстенә басты да, иренә төртеп:

—Син нәрсә, мине мыскыллап көлеп утырган буласың? Әллә Гайнижамалынны очраттынмы?—дип, тик томалдан жикеренә башлады.—Бетмәде инде шул тәкәрлек чебешенә мәхәббәтен!

Уйларыннан айнып житә алмаган Сабирның күңеле, Агыйделнең аръягында әлегә туарга да маташмаган мал-туар көтүен калдырып, үзенең ничә көннәр яме китеп торган, әмма дә инде Шәмсиясе күренүгә бөтенәеп өлгергән йортына кайтып төште. Теле кабат ачылды:

—Нәрсә этенәсең?

—Этенми сина,—дип тузынды Шәмсиясе.—Йоклап утырганынны белгән булсаммы!

Әмма шунда Сабиры ана аягыннан егылырлык сүз әйтте:

—Сер бар, кинәшәсе иде!

Күпме гомерләрен бергә яшәп тә, иреннән мондыйны ишетмәгән Шәмсиягә бу сүзләр алама акылын яктыртып кояш чыгаргандай итте.

## 2

Сабирның сере шофер Хисмәтнең дә күңеленә май булып ятты. Бу хакта кешегә белдермәскә һәм, эшне озакка сузмыйча, Аксубай-Чистай якларына юлга чыгарга килешенделәр. Юкса, кара көзгә калсалар, ул арада кыш та башланып китсә, сонарырга мөмкин иделәр. Әмма, Шәмсияне искә алмаганда, боларның икесе генә бүлешкән сернең күмәчен авыл халкы күптән инде уртага куеп, телем-телем кисә иде. Һәммәсе дә Агыйделнең аръягына бозау, сыер, сарык ише мөгезле һәм мөгезсез мал-туар артыннан юлга чыгарга жыенды.

Хисмәт белән билгеләнгән вакыт иртәнге сәгать биш иде. Аннан алдагы кичтә генә билгеле булды: аларга югары оч Мөдәррис ияреp гә тиеш икән. Хисмәтнең хатыны ягыннан карендәше, ягъни дә кайнеш тиешле кешесе булганлыктан, аны калдырмаячагы анлашылды. Сабир, ризасызлык белдереп, буза куптаргандай кыландырып маташты әле:

—Ни хәл бу? Каян килгән? Кешегә тишмәскә сүз куешкан идек бит!—дип кабарынды-бүртенде.

Әмма Хисмәт өстәл уртасына бер шешә ак аракы китереп утырткач, артыгын сөйләшеп тормастан баш кына боргалады.

Хисмәтнең белем колакта түгел иде, әмма дә Сабирның һәр сүзен ана элеп утырды. Шул утырудан тагын да шактый җәелеп, икенче ярты чыкты һәм бусы инде икесен дә тәмам харап итте.

Иртәдә алар юлга чыга алмадылар. Таң белән ашкынып килеп житкән Мөдәррис боларны, хатыннарын да ярдәмгә чакыртып, өйләгә кадәр урыннарыннан кузгата алмады.

Мескеннәрнен кичкә генә күзләре ачылды. Бер башланган дип, яна йорт бурасын күтәрергә әзерләп куйган Хисмәтнең әржәсе белән аракысына хужа булып өлгергәннәр дә яртысына ук житеп, бушатып та ташлаган булып чыктылар.

Юлга кузгалу тагын бер көнгә сонарды.

Урамга чыксалар, Хисмәтнең капка төбендә торган машинасының әржәсенә дә, янына да халык тулган. Кайсы утырырга, кайсы инде тәмам

зарыгып, төшәргә дип этешә һәм тартешә иделәр. Сабир белән Хисмәтне күреп алуга, һәммәсе дә тынып калдылар. Арадан беркатлыраклары:

—Китәбез, кузгалабыз, иншаллаһ!—дип куйды.

Бу сәгатьнең житәчәгеn иртәнге дүрттән бирле көткән халыкның бәхете куш киләсе иде, Хисмәт:

—Коелыгыз! Эшкә барып кайтасым бар!—дип һәммәсен өркетте.

Әмма кузгалырга теләүчеләр табылмады. Халыктан жинел генә котылу мөмкин түгел иде.

Сабир:

—Калсыннар!—дип, Хисмәтне читкәрәк алып китте.—Болар таңгача сакларга әзер.

—Син болай ит,—диде Сабир, кинәшен тотуны әмер итеп.—Машинанны колхоз гаражына илтеп биклә, төнге каравылчыга, рәис үзе кушты диган булып, кеше-кара күрмәгәндә аннан аны алып чык, Дүрт куак артына китереп куй. Шуннан гына шылырбыз. Ә халыкка, иртәгә кибет буенда, сәгать алтыдан да сонармый кузгалабыз дип әйт. Бетте-китте!

Хисмәтнең сүзләренә һичкем ышанырга теләмәде. Әмма өенә таба кайтып киткән Сабирны күргәч кенә:

—Бүген бармаулары хак икән!—дип, халык коелыша башлады.

Шулай да тәмам ышанып бетмәүчеләр, монда хәйлә барлыгын сизенүчеләр Хисмәтнең әрҗәсендә колхоз гаражларына кадәр утырып барып, йозак салуына кадәр карап тордылар. Арада әллә каян ишетеп килгән Камай авылы урыслары да бар иде.

—Гомер булмаганны!—дип зарланышты халык.—Мәңге бакый Хисмәт машинасын үз капкалары төбендә кундырды, бүген генә закон үзгәргән икән!..

## 3

Авыл төне буе йокламады. Йөз дә иллеле лампалар Ленин бабай ягып калдырган электр утын туйганчы яндырды. Машина тавышы ерак юлдан үтеп киткәндә дә тиз генә аркаларына бишмәт эләргә өлгереп йөгереп чыккалаган халыкның ни күзе, ни зиһене ял күрмәде. Ә төн уртасында, чәй дә эчеп тормастан, Сабир бакча артлап кына Хисмәтләргә килеп керде. Буылып өргән этләр авылны кабат аякта йөртергә өлгергән иделәр.

—Ул китте инде!—дип, ишек артыннан гына җавап бирде Хисмәтнең хатыны.

Сабирның борыны сасы тәмәке сөременә күнегеп беткән, башка төрле исләрне танырга теләмәсә дә, җылы астыннан чыккан Хисмәт җанашының бәгырьгә үтәрлек йомшак тән хушбуен сизенеп, күнеле кытыкланды.

—Әллә ачып тормаска итә инде?—дип мыгырданды ул.

Әмма шунда ук җавабын да алды:

—Ачмыйм шул! Суык керә!.. Сабир иртәрәк килсә, Өч тирәк төбенә барсын дип әйтергә кушты. Сонармаска әйтте. Энем Мөдәррис тә килеп китте инде,—дип Сабирның күнеленә коткы салды.

—Мин бит аңа Дүрт куак төбенә килергә куштым, нинди Өч тирәк инде ул тагын?!

Әмма Хисмәтнең хатыны сүзендә нык торды:

—Куакмы, тирәкме, агачмы, талмы, юкәме, каенмы, имәнме, тупылмы...—дия-дия, урман һәм су буйларында очраган һәртөрле үсентеләрне гүяки санап чыгарга итте. Ул шулай әйтә калды, Сабир, өенә кайтып, алдан әзерләнгән биштәрен эләктерде дә, йокы аралаш сөйләнеп яткан хатынына колак салды:

—Нәрсә дисең?

Юньле җавап һәм адәм күнеленә яраррлык сүз ишетмәгәч:

—Бусы да ычкынган бугай,—диде дә, Дүрт куак төбе дип йөртелгән урман башы юлына юнәлде. Хатыны:

—Гайфулла, Вәлиулла, Фатих, Ибрай...—диярәк әллә дога укый, әллә кеше исемнәрен саный-саный саташып сөйләнгән хәлендә йоклап калды.

## 4

Агыйделнең аръягына житеп килгәндә таң аткан, кибетләр ачылган, Сабир белән Мөдәррис исә "юл аягы"ннан соң черем итеп алырга өлгергән иделәр. Сасмак халкы исә, мәжнүн булып калулары белән ризалашмыйча, ул көнне таң атканчыдан алып кичкә кадәр колхоз гаражларыннан Хисмәтнең машина белән кайтып килүен һәм, барчасын төяп, Агыйделнең аръягына алып китәсен көттеләр. Әмма Аллаһыдан бу эш насыйп ителә калса, үзләре үк бер әржә халык булачакларын, сатып алган мал-туарга урын да калмаячак икәнлеген башларына кертеп караучылар да бар иде. Шулай да алар кемнең дә бәлки төшеп калачагына яки Агыйделнең аръягына ирешкәч адашачагына, һич югы бер сарык та алмыйча буш кайтачагына өмет тоттылар. Тиздән һәркайсы бер-берсенә шул күзлек аша карап, үзләрен һичшиксез байлык иясе сыйфатында тоя башлады. Бары тик кичке дүртләр якынлашып килгәндә генә, Хисмәтнең машинасында Сабир белән Мөдәрриснең инде карангы төндә үк олы юл чатына чыгып утырып китүләре тәгаенләнеп, хакыйкать мәгълүм булды. Кибет янында да өченче көн жыелышып көткән халык, берара буза куптарып, ахырда алдануларына тәмам төшенеп, сатлыкка дип тезелгән шешә тулы киштәләрне кайгыдан бушатып бетерә язгач кына таралыштылар. Кайсы берләре:

—Аларның авылга әйләнеп кайтасылары, күрше булып яшиселәре дә бар әле!—дип, янарга теләп әйтсәләр, бүтәннәре, арттырып жибәреп:

—Кирәкләрен бирербез!—диярәк зәһәрләнеп тә алдылар.

Болары ук артык иде. Хәер, кем белә, сабантуйлары бар, башкасы. Әгәр дә кибет суына тамакны чылатсаң, ике дөньяна бер моржаны чыгарып була да була инде ул.

## 5

Акчаны Хисмәт тә, Мөдәррис тә ике бозау һәм өч сарыклык кына алып килгән булып чыктылар. Әмма дә Сабирның Шәмсиясе иренең колагына мең тукыды:

—Кара аны, дуңгыз булып йөрмә анда! Акчабыз күп түгел. Бирүче очсызланырга яратмый ул, кемнең алдатасы килсен! Безгә дүрт тана, үгездән дә ярый, алсаң, шул житкән. Сарык дип дуңгыз тыкмасыннар!—диде.

Һе, әллә Сабирын юләр дип белде инде, дуңгыз белән сарыкны аермаска!

Бу кадәр малга хужа булу өчен йөрәк тә кирәк, куәт тә сорала иде. Үзе бер көтү шул болар.

Көзгә кергәч үк итнең килосы йөз утыз сумнан үтеп бара иде. Шул хисап белән санаганда да, тояклы мал юньле хужаның кулыннан алты мең тәнкә чамасыннан китәргә тиеш иде. Ун меңгә менмәгәе!

Сабир бу исәп-хисапны бик тиз ясап өлгерде. Әмма: "Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер!"—дигән сүз белән гамәл итеп карарга булды. Һәм иптәш агайларына:

—Кышлау таналарны да биштән арыга менмибез!—диде. Халык монда күндәм тоела. Бик кичкә калмыйча китеп тә барырбыз!..

—Аллаһ боерса, диген!—Мөдәррис суфийана һаваланып алды.

—Алла кушса!—дип куйды Сабир да.

Хисмәт Сабир кебек мулдан кылана алмаячагына уфтана иде. Кешегә акча каян киләдер? Әмма гомере буена тәгәрмәчтән төшми эшләгән Хисмәттә ул юк иде. Ә менә көннәр буена корсак киереп өендә яткан Сабирда, әнә, буа буарлык! Юк, дөрес түгел бу дөнья, баштанаяк дөрес төзелмәгән, кирәкле юлдан китмәгән. Бүген генә аны борып җибәреп булмый шул, хәерсез!

Сабир бу вакытта акчаларын кисәкләп-кисәкләп ун-сул һәм ас-өс кесәләренә тутырып куйды.

—Санаганда җинел була ул!—диде.—Буталмыйсың!

Аңа карап Мөдәррис тә барлы-юклы акчаларын шулай кыландырды. Тик Хисмәтнең генә, ачуы килү аркасындадыр, акчаларын бүлгәләп маташасы килмәде.

"Бисмилла" әйтелеп, авылны базар ясарга кузгалдылар. Халык сату итәргә башмак тана, кышлау үгез һәм вак терлекләрен арканлап иярткән, кайсылары куып кына китергән, ә калганнары бөтенләй дә буш булып, тамаша кылу максатында көлешеп сөйләшкән абзыйлар тирәсендә тәмәке төтененә батып тора иделәр. Хатын-кызның күбесе бары тик сатулашу максатында гына йөргәнлектән, юк эшләрен бар итеп, сүзнең озынына күнелнең ихласын биреп колак куймакта һәм тел тегермәнендә татар ясмыгын тарттырмакта иделәр.

Бу юлысы ишектән Хисмәт беренче булып чыкты. Әмма аңа һичбер кеше:

—Барин, безнең барин!—дип сүз катмады, бүреген салмады, билен бөкмәде. Аның бу юлы өстенә кигән үз бишмәте, яна булса да, май тамып инде төсе бозыла башлаган һәм җәбәхәер кыяфәттә иде. Бары тик Сабирның бурсык йөзе мал ияртеп килүчеләрне үзенә тартты. Һәммәсе дә диярлек аны уратып алдылар һәм, кулына таба бауларын сузып:

—Минекен ал, менә минеке бик яхшы!.. Нәселе яхшы, симезлеге дә ару гына! Җәй буе иген өстендә булды, инде хәзер уҗымнан кайтып кергәне юк!—дип, терлекләрен мактарга һәм шуның белән үзләрен дә күкләргә чөяргә тотындылар.

Аларның ихлас булулары Сабирның күңеленә хуш килде. Үзенең егет чагыннан бирле шушы кадәр дә соклангыч вакыты булмаганлыгын исенә алып өлгерде. Халык арасыннан эчкәрәк узды. Үз терлек-туарын мактаучылар Мөдәррискә яна бер дәрт белән ташландылар. Шул ук сүзләрен кабатлый тордылар. Тик Хисмәт кенә һичкемне кызыксындырмый иде. Ул моңсу бала кебек читтәрәк басып торды-торды да:

—Бозау алам, сарык алам!—дип халык өстенә оран салды. Бары тик аның янында басып торган, тамашага хәйран бер әби генә:

—Улым, әллә халык санын алалармы? Мине татар дип яздырыгыз әле шуларга!—дип, якын килеп үтенечен белдерде. Әллә саңгырау, әллә ансызлык иде, Хисмәтнең:

—Бозау алалар!—дигәненә каршы:

—Нәрсә аулыйлар? Боз аулыйлар? Бозаулыйлар?—диде дә, колагына кулын турылап, җавапның кайтарылуын да көтеп тормыйча, халык арасына кереп китте. Бу вакытта Сабир инде ике бозауны эләктерергә өлгергән, бәясенә хакны билгеләп сатулаша иде:

—Кыйммәт... Бик кыйммәт! Бер бозауга бишне кем сорый инде? Өчтән алам, өчтән!

Сатулашып җинә алмаганнарны башкалары алыштыра торды. Әмма кулына кергән аркан очларын Сабир җибәрергә теләмәде. Мөдәррис инде сайларга-сайланырга өлгергән, сатучыларны куандырып акча саный иде. Сабирның да, аны чамалап алуына, сабыры сынды. Сораган хакларын үз нәфсесенә тигезләп, ахыры күнәргә булды.

Ул арада акчасын кесәсеннән чыгарырга өлгергән Хисмәт аның янына

килеп житкән иде һәм бөтен эшен бозып ташлады. Һәммә кеше ана ябырылды. Кулындагы акча төргәге аларга бик мулдан күренде. Әмма:

—Дүрт меннән узмыйм!—дип күкрәк сугуы бөтенесен дә өркетте. Сатучы халык кабат Сабирга әйләнеп килеп, аннан мөмкин кадәр күбрәк акча каерырга тырышты.

Ходай рәхмәте һәркемгә дә бертигез түгел шул ул. Хисмәтнен куйган бәясенә дә күнүчеләр табылды. Ин күп бозау байлыкка кинәнгән Сабир көтүенә керергә тиеш булса да, анын артык сатулашуы сәбәбеннәнме, атаган бәяләре күпләрнен гайрәтен чигерде. Хисмәт белән Мөдәррис өчәр бозау, дүртәр сарык сатып алып, терлеккә дип тутырып килгән акчаларын тотып бетерергә өлгергән иделәр. Хәер, Сабирнын да кулына дүрт бозау кергән, әмма акчасынын яртысы кесәсендә калган иде.

Базарнын дәрте китте. Халык таралыша башлады. Алар артыннан Сабир, акчасын кушлап, берсеннән икенчесенә йөгерә торды:

—Биштән алам, жәмагать, биштән алам!

## 6

Шул көнне үк кичкә алар кайтыр юлга чыктылар. Әгәр дә унга-сулга борылмый, туры гына барсалар, яки сонгы паромга житешәчәк, яисә иртәнге беренчесен көтеп алып, Саескан тавына тан атканчы чыгачак иделәр. Ә анда—Агыйделнен аръягы түгел, үз ягы!

—Паромга сонарсак, мал-туарны су буендагы болынга таратырбыз да ашатып алырбыз!—диде Сабир, сатып алынган бозау, тана һәм сарыклары хакында кайгыртып.

Хисмәт машина фараларын кабызды. Инде энгер ирешеп өлгергән, юлдан еректарак очраган агачлык, мижа һәм урманлыклар, өсләренә төн юрганын ябынып, тыныч йокыга талган, бары тик янгырдан сон юешләнеп калган асфальт кына ялтыраган көзге кебек күренә иде. Хәзер, ал яктагы фаралар кабызылгач, асфальтнын да төсе үзгәрде, ерактан сузылып күренгән ялтыравыгы сүнде, үз йөзе ачылды. Мөдәррис тагын да әйтеп куйды:

—Агыйделне әйтәм, шагыйрьләр-язучылар гына Чулман диеп бозып бетерде!

—Агыйдел Башкортстанда түгелме сон ул?—дияргә мәжбүр булды Хисмәт.—Без бит әле Чистай тирәсендә генә!..

—Жизни, без Кама дип йөри торган, язучыларнын Чулман дигәне асылда Агыйдел икән ул!

Хисмәт бу кадәр шаулы һәм башына сыйдыра алмас хакыйкатьне ишеткәч, кинәт хәтере кузгалыпмы, шартлатып тормозга басты. Машина ана карап кына туктый алмыйча, юл кырыена килеп чыкты. Ярый әле башаяк түбән очмадылар. Хисмәтнен күнеле сизенеп алды һәм, жәһәт кенә машинасын турылап, асфальт юлга борырга өлгерде. Әржәсендәге мөгезле һәм мөгезсез терлекләр, кабинадагы юлдашлары бу көтелмәгән хәлдән болганып куярга өлгергән иделәр.

—Жизни-и-и,—дип сузды Мөдәррис, кабат үз жаена кайтып утыргач,—нәрсә булды?

Хисмәтнен сүзе кыска чыкты:

—Әллә ниләр сөйләп барасын шунда!

—Нишләп алай булсын?—диде Мөдәррис, үзен тыя алмыйча.—Бик белеп сөйлим, аны минем бабай да әйтә торган иде!

—Бабанны әллә тулы акылда иде дип беләсенме?—Хисмәткә Мөдәрриснен ул дәлиле генә житми иде булса кирәк. Әмма каен энесе дә бик жинел генә бирешергә теләмәде:

—Гәжиттән укыдым! Үзем укыдым. Бер академик язган!

Гәжит сүзендә дөреслекнең аз иканлеген яхшы белә иде Хисмәт:

—Анда ниләр язмаслар! Дөньяны бутап яталар шунда!—диде.—Безнең колхоз рәисен дә алар күкләргә чөеп мактадылар. Унбиш хатында бала үстерүен, һәр сөяркәсенә йорт салдыруын, үзенә амбар кадәрле келәтләр эшләтүен, халыкка биш ел буе хезмәт хакын юньләп түләмәвен телгә дә алмаганнар!

—Академик язган, академик!—дип, Мөдәррис укыган гәжитеннән исендә калганнарны тезеп китте.—Кама дигәннәре урыстан гына калган атама икән ул. Казанны алганда, шул су белән төшеп, безне камап алганнар. Иделдән түгел, бик беләсегез килсә!... Чулман дигәннәре—хәзерге Агыйдел дип аталган суга кадәр генә төшә. Чын Агыйдел—монда Иделгә килеп кушылганчы сузыла!

Хисмәт тагын килешмәде, әмма бу юлы кайнешенә ышана башлаганлыгы тавышына чыгарга өлгергән иде:

—Ә башкорттагы Агыйдел нәрсә?

—Анысы да Агыйдел!—диде Мөдәррис, сүзен өскә чыгара алуына куанып.—Шуннан ук агып килә инде Агыйдел. Чулман елгасы аңа кушылып кына кала!

—Җәгъръфия китапларында нигә соң аны Кама diләр?

—Гадәт буенча.

—Әйтәм аны безнең әтиләр җырда да: "Агыйдел"—дип кенә җиппәрә торган иделәр!—Хисмәтнең чын күңелдән әйтелгән бу сүзләре Мөдәррис тарафыннан тантаналы төстә кабул ителде.

Еракта Чистайның урам һәм йорт утлары күренә башлаган иде. Тамак ялгап алуны кирәк табып, берәр ашханәгә туктарга булдылар.

## 7

Ашханә олы юл өстендә, сый-хөрмәткә бай иде.

Сабирның инде үзенең туеннан бирле болай юмартланганы юк иде. Бу юлы да артыгын кыланып ташлады: һәммәсен, үз хисабына ашатудан тыш, эчертте дә әле, җитмәсә, юлга дип һәркайсы кыздырылган берәр тавык һәм савыт китерттеләр. Исәп-хисаптан төшеп калган утыз алты тәңкәсен табу шатлыгыннан Сабир бер үзе дүрт ярты алды. Имеш, авылга кайткач, җитми калып, кибеткә йөгерәсе булмасын!

Мурзихага килеп туктаганда паром инде суга кереп киткән һәм иртәнге бишкәчә бүтән әйләнеп килмәячәге билгеле булды. Төн уртасы үтеп бара, ач терлекләр машина әрҗәсендә күренмәгән салам-печән ише коры-сары эзләштереп сөзешәләр, бераздан мөгердәшә башларга тиеш иделәр. Яр кырыена килеп баскан Мөдәррис, иркен сулыш алып:

—Эһ, Агыйдел!—дип куйды.

Гомерләренә мондый халәтне кичермәүләре аркасындамы, мал-туар белән бәйләнешле вакытта сак һәм үз-үзенә үтә таләпчән булу тиешлекне төшенмәгән һәм белә дә алмаган бу юлаучыларның саташулары менә шушыннан башланып китте дә инде. Алар кинәт бушанып алдылар. Нугай даласында инен-буен әйләнеп йөргән, көзгә вакытка хас булмаган җылы-йомшак җил иш өстенә куш булды. Учак тергезелеп, аш-су җылытылып, беренче йөз грамм аракы тамакларыннан узуга, өч татарыбыз да бер авыздан, көйләрдә буталып маташмыйча гына җыр суздылар. Милли моңнар остасы Илһам Шакировның колакка ятышлы, күңелгә үтемле тавышы бер якта торсын,—татарыбызга бу сәгатьтә, бу урында һичкем житкерә алмый иде...

Бер кичне генә Агыйдел ярында уздыру һичнәрсә түгел ул. Кешеләр әле барлык эшләрен ташлап, борчулардан аерылыр өчен әллә кайлардан килеп, су буенда учак ягып ял итәләр. Гомер бакый авыр эштән артыгын белмәгән, барлык сөенечләре бер-ике татар гәжит-журналын укып чыгу, телевизордан

берән-сәрән күрсәтелә торган татарча тапшыруга мөкиббән китеп утырудан гыйбарәт исә дә, боларга канәгать итүдән артык аларга нәрсәнең тәтегәне бар? Театр тамашалары, рәтле концерт карап, спорт сарайларында онытылып калганнары бармы соң аларның? Хәер, болары ук табигать балаларына кирәк тә түгелдер бәлки? Нигә дип гомерләрен юк белән уздырсыннар ди алар?

Сүз иярә сүз чыгып, шактый гомерләре узгач кына, инде батыраеп алгач, иртәнгәчә бозау һәм сарыкларын көтүләп ашатасы иттеләр. Алмаш-тилмәш караштырып торырга булдылар. Хисмәтнең рульдә кайтасы исәпкә алынып, ана йокларга кинәш ителде.

Һәрьяктан уйланылган эш булганлыктан, барысы да Ходай кушканча борчусыз гына тәмамланырга тиеш иде. Үзе беренче ике сәгатькә мал-туарны караштырып торырга әйткән Мөдәррис, уйга чумып, күз йомып алганын да сизми калды, таңда гына уянып китте. Караса, ни сарыклары, ни бозаулары-таналары юк иде. Йөрәге селкенеп куюга, махмыры да онытылып, уңлы-суллы йөгерендә. Анда-монда сыер-сарык тоякларының тирән чокырлары болынлыкны чуарлаган, ә мал-туарның үзләре генә күренмәде. Ул шулай әвәрә килеп, нәрсә эшләргә белми чапкынлап йөргәндә, әйләнеп-әйләнеп, тәмам адаштым инде дигәнендә, әле йокыларыннан уянырга да уйламаган Хисмәт белән Сабир янына килеп чыкты. Бердән, малларны югалту кайгысы, икенчедән иптәшләрен табу шатлыгы аның күңелен тәмам йомшартып, кабат кичәге салмышлыктан калган махмырын кузгатты. Машина кабинасында Хисмәт белән Сабир тәмам эреп, парланып беткән тәрәзәләрен дә сөртмичә изелеп йоклый бирделәр. Ишекне киң итеп Мөдәррис ачып җибәргәч кенә башларын калкыттылар. Ни булганлыгын әлегә белми иделәр. Сабир:

—Кара, яктырырга өлгергән,—дип, сәгатен караштыра башлады.—Әллә туктаган инде?

Әмма ул ялгышты. Инде паром күптән йөри башлаган, сәгать тә сигезгә таба бара, кузгалырга күптән вакыт иде.

## 8

Аллаһының рәхмәте, югалган малларын тиз таптылар. Хисмәт, катлап-катлап сүгенгәннән соң, машинасын кабызды да:

—Утырыгыз, көзлектә-кышлыкта хайваннар авылларда капка төпләренә җыелып сыенучан була, көтүләре кузгалганчы, җәһәтрәк кыланыйк,—дип, дөбер-шатыр айкатып-чайкатып, асфальт юлга алып чыкты да, шул хут белән беренче күренгән авылга килеп тә керде. Әле кичә генә сатып алынган бозауны-сарыкны танып буламы соң? Ярый әле Сабир, башкаларныкы белән буталмасыннар өчен мөгезләренә кызыл чүпрәкләр бәйләгән иде. Мөдәррис белән Хисмәт анысын да эшләмәделәр. Сабирның да тамгалары төшеп калырга мөмкин!

Авыл урамының аркылысына баскан тана гүяки аларның килеп житкәнен көтеп алды. Мөгезендәге кызыл тасманы күреп өлгергән Сабир:

—Рәхмәт төшкере, минә бит, үзе көтеп, каршы чыгып тора!—диде дә, туктап та җитмәгән машинаның ишеген ачык калдырып, юлга сикереп төште һәм, малкаен барып кочардай булып, аңа таба йөгерде. Әмма иясе инде нәкъ менә шушы татар икәнлеген әлегә хәтерләп калырга өлгермәгән тана бозау, койрыгын күтәреп, аннан кача башлады. Кем уйлаган юл кырые буйлап сузылган пычрак, ләм һәм саз эчендә җан иясе бардыр дип? Кая барырга белми чапкан тана бозау шуларның берсен таптап үтеме, и кузгалды, и котырды, и чинап җибәрде бер нәмәрсә—ана башкалары кушылды. Сазлыктагы ләм өемнәре җанлана башлап, гүяки җен, убыр һәм шайтаннар купты. Барысы да чинаша иделәр. Кайсы-кая йөгерешеп, дөньяны кузгаттылар. Арадан телевизор экраннарында гына күреп калынган

фил кадәрле берсе күренде. Кып-кызыл күзләре белән усал-усал карап алды да, “мырк-мырк, мырык-мырык” килә-килә, Сабирның өстенә ташланды. Кая качып котылырга белмәгән мескен татар ни бозавы артыннан чаба, ни машинага кабат килеп утыра алмый калды. Ул арада аны дуңгыз, борынына элде дә, сазлык эченә ыргытты. Сабир йөзтүбән ләмгә чумды. Сасы һәм шакты ис белән бергә борын, авыз һәм колак тишекләренә саз тулды. Коты очу шул кадәргә җиткән иде ки, ул тиз генә башын күтәрде һәм күзе күргән якка таба йөгереп, койма башына сикереп менгәнен сизми дә калды. Әле дә ярый ике сыер кадәрле теге чучка аны ул арада күз уныннан җуеп өлгергән, юл уртасында туктап калган Хисмәтнең машинасына карап тора иде. Бераздан кузгалды. Машинаны әйләнеп узып, арткы көпчәкләренә ышкына башлады. Аның саен мескен “Газик” машинасы сазлыкка таба төшә барды. Ярый чучканың башына акыл кереп, ниндидер сәбәп белән арырак, берникадәр юлны чабып үтте дә, мыркылдап тукталды. Нәрсәнедер эзләнергә тотынды.

Бәла аяк астында икән ул, Сабирның, коймадан кучеп, җайланып менеп утырган капка баганасы көтмәгәндә чайкала башлап, шатырлап сынды да, дөбердәп җиргә ауды. Үгез кадәр ир аның астында калды.

Тамаша күрергә халык җыела башлады. Кайсылар нәрсә булганын күреп калырга өлгергән, кайсылары халык шаулашканга гына килгән иделәр. Көлешә үк башладылар. Ул кешеләрнең моңа кадәр бу рәвешле ахмак кәмитне күрмәгәнлекләре әлегә Сабирның үзенә мәгълүм түгел, һәрхәлдә шушы кадәр оятка төшү аның үзенә насыйп булмаганлыктан, бәладән котылу юлы барлыгын күрми һәм белми иде. Машина кабинасыннан көлә-көлә, тәгәрәп диярлек чыгучы Мөдәррис күренде. Хисмәтнең инде күзләреннән яшь ага, ерган авызы елаган баланыкы кебек салынып төшкән иде. Ул да, машинасыннан чыгуга, тәгәрәп китә язды. Бу хәл кабат көлке тудырды.

Бераздан сакаллы абзыйлар да үзләренең сабыйлар хәлендә калганлыкларын тоеп өлгерде, халык тынычлана башлады. Бу өч татарның шушы карангы, элеккеге чуаштан урыска әверелгән авылда нишләп йөргәнлекләре беленгәч, тагын да көлешү җәелеп, һәммәсенең авызлары бердәй колакларына менде. Инде вакыт уникегә таба атлый, дуңгыз һәм чучкалар кабат тынычланып, сазлык һәм ләмлекләренә кереп яткан, өч татарыбыз гына тәмам аптыраашта иделәр.

Бәхеткә, авылның көтүе хөкүмәт алышынганнан бирле чыкканы булмыйча, мул-туар үзенә кирәкчә, үз ирегендә һәм теләгендә таралып-сибелеп йөри дә, шулай иркендә ишләнеп, тернәкләнеп, хуҗаларын бәрәкәткә күмә булып чыкты.

Ике шешә аракы бәясенә берничә мужик безнең өч татарга ярдәм итәргә алындылар. Сәгать дигәндә сарык һәм тана, бозауларны җыйнап та алдылар, әрҗәгә дә төяделәр. Кибет бикле булса да, көмешкәче Зина карчыкның җиңел кулыннан алынганны күтәреп ята иделәр, яннарына милиция машинасы килеп туктады. Аннан башта берәү төште. Салмыш кыяфәтле, озын әрдәнә буе бу каланчаның, ягъни участок милиционеры капитан Зарипов икәнлеген, халыкка бәла, иленә имгәк булуын урыслыкка төшкән чуашлар яхшы белсәләр дә, йөзеннән татарлыгы аңкыган шушы җәфаны бакыр бозау артыннан Агыйделнең аръягыннан килгән өч юлаучыбыз авыз ерып каршы алдылар. Ни булачагын чамалаган, Каланча Зариповта бармак башлык та иман әсәре юклыгына шикләнмәгән мужиклар тизрәк моннан таю ягын карадылар.

—Һо!.. Үзебезнең егетләр икән!—диде, татарчалап иркенәеп һәм зурлап каршы алырга барган Сабир. Әмма Каланча Зарипов аны үтеп китте дә, төркемнең уртасына килеп, кобурасыннан пистолетын чыгарды, һәм һавага төбәде:

—Атам, кулларыгызны күтәрегез!

—Ягез әле, егетләр, шаяртмагыз!—дип, Сабир авызын ерган иде дә, Каланчаның үз туксаны тукылды:

—Атам, ике әйттем юк!—Ул, чыннан да күккә төбәп атып җибәрде.

Армия хезмәтен үтеп, бер генә дә мылтык атып карамаган һәм аның тавышын гомергә дә ишетмәгән өч татар, алар яныннан китәргә өлгерми калган биш урыс мужигы пычрак җиргә ятарга мәҗбүр булды.

Зарипов арадан иң кечкенә гәүдәле Мөдәрриснең сыртына шакшы итекләре белән китереп басты да:

—Селкенәсе булма! Барыгыз да кулга алынды!—дип әмер бирде.

Бу вакытта аның күзләре әле яңа гына бушатылган шешәгә төште. Хисмәтнең машина кабинасы ишеге ачык, шофер утыргычына гәҗит кенә җәелсә дә, тезелгән ризыкның шактый мулдан булганлыгы пешкән помидор, сөяк-санак, консерва савытларыннан беленеп тора иде. Бу шешәләргә күзе төшкәндә Зариповның ачуы көтелгәннән дә артыграк кабара иде.

—Закон минем кулда! Аттым-үтердем, бетте-китте! Качарга маташканы өчен дип кенә рапорт язам да...

Аның болай сөйләнүе хәерсезлек билгесе. Хисмәт, моны аңлаган хәлендә, аваз чыгармый ята бирде. Ярый әле авызына теге "шайтан суы"н капмаган иде. Исерек хәлдә руль артына утырган дип аңа бәйләнә алмаячаклар! Әмма кем белә? Әнә ничек кыланган була бит! Таптый-сыта. Мондый адәмдә иман буламы соң?

## 9

Чистай зинданында төн уздыручы тоткыннар исненең авырлыгына, милиция кавеменең миһербансызлыгына зарлана алмадылар. Боларын нәкъ шулай булырга тиеш дип кабул иттеләр. Хисмәтнең фикеренчә, бәлки аларны тыныч кына җибәрерләр дә иде әле. Әмма бөтен эшне Сабир бозып ташлады. Бер танасы башы-аягы белән җәлке идеме инде? Өстенә хәерсез милиция китереп баскач, аның белән генә котылсаң да ярар иде, юк шул. Адәм баласының күрәчәге маңгаена язылып куелган, диләр. Шулайдыр шул, шулайдыр!

Милиция бүлегенә, тикшерү шарты дигән булып, юлаучыларны китереп, кәгазь тутыра башлаганда, арада олы погонлысының машина әрҗәсенә тәрәзә аша гына күзе төшкәнлегә, андагы тананы калдырсалар, эшнең еракка китмәслегә билгеле булды. Әмма дә Сабир күтәрелеп бәрелде, белер-белмәс урысчалы кеше үзгәрде дә китте:

—Не имеешь право, не имеешь право!—диде кат-кат.

Ә теге олы погонлы адәм башлыклары булып чыкты, майор.

—Что тычешь?—ди бит.

Ә Сабир:

—Кем тәртә әле? Кто тебе тыкнул?—ди.

И киттеләр, и киттеләр. Ике ягына ике милиционер килеп ябышып, тынычландырмакчы булган иделәр, бар шул гайрәтле кешеләр, Сабир аларны җилкәсе аша гына чөеп җибәрмәсенме! Олырак гәүдәлесе кишталек өстенә барып төште, икенчесе—милиция майорының өстәленә. Кишталек тә, өстәл дә—чәлпәрәмә, коймак урынына изелеп, чыра кебек чәрдәкләнделәр.

Китте тунаш, китте дөмбәсләш. Каяндыр унбишләп милиция әһеле пәйда булды. Сабирны да, һичбер сулышсыз утырган Хисмәтне дә, авызы ачылып, хәйран хәлендә почмакка сеңгән Мөдәррисне дә сөлләделәр һәм, анадан тума калдырып, салкын, бозлы зинданга кертеп ташладылар.

—Ерткычлар!—дип үкеренде мыскылланган Сабир.

—Кабахәтләр!—дип сүгенде күгәреп каткан Хисмәт.

—Үтерделәр!—дип елады зәңгәрләнеп беткән Мөдәррис.

Зиндан эче ярым караңгы иде. Озакламый арып-талып йокыга киттеләр. Әмма зиндан боз кебек. Йокылары тирән булуга карамастан, ярты сәгатьтән соң өчесе дә туңып уяндылар. Ни хикмәт, һичбер җирләре авыртмый, җаннарын гына туңып үлү куркынычы биләп алган, булган хәлләрдән соң башлары тәмам айнырга өлгергән иде. Ә бу вакытта милиция әһеле исерешеп беткән булып чыкты.

Мөдәррис түзмәде, ишеккә барып ябышты:

—Үтерәсез, чыгарыгыз моннан! Үтерәсез!

Аның сүзләрен һәм дөбердәтүен ишеткән кеше булмады. Әмма Мөдәррис аның саен катырак сүгенә һәм шашына барды. Ул чыгырыннан чыкканга карап, иптәшләренең дә түзәр әмәле калмыйча, сөякләренә кадәр шалтыр-шолтыр калтырана башладылар. Сабир түзмәде, ишеккә китереп типте. Аллаһының биргән куәте белән зиндан ачылырга тиеш иде. Әмма ишегә селкенеп тә карамады. Тәмам шашынудан соң табигатьтә дә шулай, нәкъ адәм холкындагыча, аңа тынычлану иңә. Тоткыннар да тынып, бер-берсенә таба елыштылар. Шушында гына алар үзләренең зур бәлагә дучар булуларын төшенделәр.

## 10

Юл үзенең авырлыгы белән түгел, уй-хәсрәте белән изде. Сабир машина әрҗәсендә, көзге салкын һәм өстән явып торган юеш кар астында, аягы сынык сыңар бозавын кочаклап, елый-елый кайтты. Аңа илнең хәерсезлеге, дөньялыкны гаделлек иясе Аллаһы Тәгаләнең ташлавы аермачык булып ачылды. Ул хәзер һичнәрсәгә һәм һичкемгә ышаначак түгел иде. Күз алдында базарда ит сатучы теге Фатихлар вакыт-вакыт пәйда булып, Шәмсиянең көянтәсен сындыра-сындыра мыскыллап көләдер сыман тоелды.

Аларны зинданнан иртәнге якты белән чыгардылар.

—Болай җинел котылуыгызга сөенегез!—дип Зарипов куркытып әйткәч, суд юлында йөрерлекләре дә калмаган юлаучылар моннан тизрәк чыгып таярга кирәклеген төшенделәр. Аларны мыскыллап әрҗәгә ташланган әнчек эт балалары сыңар бозауның сынган аягыннан аккан һәм инде укмашып өлгергән канын ялыйлар иде. Инде яшәү өметеннән ваз кичкән бозауның күзләре зур ачылган, салкыннан һәм сынык аягы авыртудан ул да калтырана, борынынача юешләнеп яше ага иде.

Юлда аларга терлек төягән машиналар очрады. Аның саен өчесенең дә бәгырьләре ертылып, җан сүрүләре бүселеп алды. Алар да шулай хәерле юлга чыккан иделәр бит, аларның да бәхете камил иде. Әмма ни мәгънә? Минут эчендә адәм баласының аягы таеп китәргә, ул баштүбән килеп төшәргә, харап булырга мөмкин. Бәла—аяк астында, анда салам җәелмәгән. Чамалап кына атлаганда да бик таманга туры килә бу тормышта! Ә чама белән йөрмәгән иделәрме соң? Бик чама белән генә, җаен-җайга туры китереп, әмма таралды да китте бәхетләре.

Сабир нәрсә генә дип уйларга да белми иде. Бәхетен сыер сөзгән авыл агае салкын көзнең ул мәгънәсез минутында бу дөньялык йөзендә бер дә гаделлек юклыгын күнеле белән тойган, акылында аңлаган, үз күзе белән күргән һәм аңа каршы бер генә дә, мыскыл кадәрле генә булса да эш майтара алмаячагыннан хәйран иде. Элек хет ичмасам партия бар иде, ул гүяки дәвернең намусы һәм вөҗданы буларак аңлашыла һәм үзенең "дөреслек" кылычы белән һәртөрле хәшәрәтнең муенына чабарга мөмкин иде. Һәрхәлдә Сабир үзе коммунистлар партиясе әгъзасы булмаса да, аны шулай дип тоя һәм белә иде. Ул вакытларда начальник-чиновник ишеләр дә ул партиядән котлары очып, әллә кем булып китә алмыйлар иде шул. Партиянең күзләре күпне күрә, колаклары ерактан ук ишетә иде. Ә хәзер, менә аны алып ташладылар да, кем гадел хөкем йөртә, кемгә таянырга?

—Аллаһы Тәгалә!..—Сабир гомере буе Аллаһының барлыгына ышана һәм хәтта дуңгыз булып исергәнендә дә гамәлендә аңа таяна иде. Ә ул—еракта, теге дөньядан хөкем йөртә! Ә бу дөньяда, бүген, хәзер кирәк иде ул!

Юлда хәерле кешеләр очрамый калмый. Машина эче жылынып житкәч Хисмәт бензины бетеп килгәнгә борчыла башлады. Якын-тирәдә генә ягулык алырлык урыннар күренмәде. Очрый калганда да кесәләрендә бер тиен акчалары юк. Милиция кавеменең шушы кадәр дә явыз һәм ерткычларча талаячакларын электән ишетеп белгәч, Хисмәт эшнең шушы килеш жинел генә тәмалануына сөенергә тиеш булса да, татарлыгы йөзенә бәреп чыгып, ачуыннан:

—Кабахәтләр!—дип куйгалады.

Инде бензины тәмам бетеп, Чистай-Казан юлы өстендә, Ырынбург трактының шәрә кырында "Газик" тукталып калды. Бәхетләренә артларыннан килеп чыккан машинада килүче шофер аларны узып китмәде, кабинасыннан елмая-елмая төште.

—Нәрсә, абзыйлар, ватылдыгызмы әллә?

—Бензин бетте шул, энем!—диде Хисмәт, аңа исәнләшеп кул суза-суза.—Монда заправка да күренми!

—Ә-ә, юк ул монда. Чистайга кергәндә бар иде, эшли торганы хәзер Казангача очрамаячак инде! Нишләрсез икән?—дип, "Газик"ның бензобагына иелеп, төрткәләп алды. Шыр буш булганлыгы колакка ишетелеп тора иде.

—Син, энем, мөмкинлегең булса, булыш инде?—дип үтенде аннан Хисмәт.

—Ярар, абый!—диде егет, һичбер ялындырып тормыйча.—Миндә бер канистр бензин бар иде. Кара көнгә калсам дип алынган. Юлда ни булмый, үзегез дә беләсен!

—Әйе,—диде Хисмәт, игелекле кешегә очравына сөенеп.—Тик минем акчам юк иде. Чистай милициясендә төн кунып чыгарга туры килде. Тузаныма кадәр какканнар.

—Алар кайда да шундый!—диде егет, кабинасыннан канистр чыгарып.—Юлда шоферлар үзара хәерхаклы булмасалар, ерак йөрү юк инде!

Ул китеп баргач кына, Хисмәт:

—Кем иде икән бу изге бала? Исемен дә сорап калмадым,—дип әйтеп, Мөдәррискә карап куйды. Зур бәладән соң насыйп булган шушы яхшылык аларның күңеленә яшәү көче өстәде. Машинага да икенче жан кергәндәй булды. Бу тизлек белән кайтканда алар караңгыга кадәр Сасмакка килеп керергә тиеш иделәр.

Ни өчендер паромда да теге хәерхаклы шофер күренмәде, юлда да ватылып калмаган иде инде ул. Мөгаен алданрак житешеп, паромның башкасы белән Каманы кичкәндер!

Паромнан чыккач, Мөдәррискә дә теле кайтты:

—Агыйделнең аръягында бер энәгә сыер!—дип әйтеп куйды.

Хисмәт, машинасын читкәрәк чыгарып туктатты да, әржәдәге Сабирга таба күтәрелеп:

—Әйдә, төш инде! Катып үләсең бит!—дип әйтеп карады.

Әмма Сабир тыңларга да теләмәде. Аның кочагында сынык аяклы сыңар бозау иде. Гүя менә шуны да аннан тартып алырлар, бәгырен кисәрләр сыман тоелды.

Сабирның теләгенә Хисмәт каршы килә алмады. Бары тик:

—Ярый алай булгач, мә, бөркән!—дип, өстеннән бушлатын салып, аңа ыргытты.—Ничек телисең—шулай! Хужаның акылы—үзендә!

Алар бүтән бер генә дә тукталып тормадылар. Хәер, туктатучылар да булмады. Кайтып житкәнчегә кадәр "Газик" жинел генә элдерде дә элдерде. Сасмак якынайган саен моңа кадәр буш кебек тоелган күңелләрендә хис-

тойгылары тыгызлана барды. "Менә, качып киткән идегезме, Алла суктымы?"—дип бөтен авыл белән көләчәкләр, бу бер дә сер түгел! Тик менә хатыннарына нәрсә әйтерләр? "Агыйделнең аръягыннан бер энәгә бер сыер алырга киткән идегез!.."—диярләрме? Әллә бакыр бозау хәсрәтен уртаклашырлармы? Сынык аяклы сыңар бозау өчен Агыйделнең аръягына чыгарга, акчаларын суга салып кайтырга язган булган шул, һични эшләр хәл юк!

—Тукта! Тукта!—дип Сабир машина кабинасының түбәсен төйгәч, Хисмәт тормозга басты һәм тизрәк ишеген ачарга ашыкты:

—Ни булды?

—Ашыкма әле?—диде Сабир, күзгә Казан суы ярыннан тауга таба үрмәләп менеп баргандай күренгән туган авылы Сасмак ягына күрсәтеп.—Күз әленсен әле, болай кайтып керсәк, адәм көлкесенә калырбыз! Сабыр итик!

Аның тәкъдименә һичкем каршы түгел иде. Сабир әрҗәдән төште һәм яшел кыяк хәлендә салкын кышка керергә уйлаган арыш уҗымына таба атлады һәм аны комсызланып җыя башлады. Бераздан кочагы белән күтәреп, сынык аяклы сыңар бозавына китереп салды. Мескен җан иясе, арыш уҗымы исен сизеп, аяк сыныгына карамастан, аңа таба килде. Онытылып ашый башлады. Агыйдел аръягыннан кайтып килүче мыскылланган өч юлчы аңа алтын бозауны күргәндәй карап тора иделәр. Бичара Мөдәрриснең күзләренә яшьләр килде һәм ул, аны-моны әйтмәстән, авылга таба туп-туры арыш уҗымы буйлап кайтып китте. Бу да түгел, бозау машина әрҗәсеннән төшмәкче булып талпынды. Сабир аны күтәреп алды. Җиргә бастырды. Өч аягында гына ныклы тора алмыйча, бозау авышып-авышып китте. Әмма уҗым буйлап аксап эчкәрәк керде, ашый бирде. Сабир аның артыннан килде.

Шунда Хисмәт машинасын кабызды һәм авылына таба үкертеп кайтып китте. Сабир арыш уҗымы өстендә сынык аяклы сыңар бозау белән ялгызы басып калды. Аның әле өенә шушы алтын бәясенә төшкән бозауны ияртеп кайтып керәсе, анда кайнар хатыны кочагына авасы бар иде...

Уеннарыннан кайтып килүче балаларының шаулашуыннан Шәмсия айнып киткәндәй булды. Өйгә алар әле кереп җитмәгән иделәр. Ул, рәхәттән изелгән тәнен сөйрәп, Сабиры янына үрмәләде, һәм, иренең кочагын ачып, песи баласы кебек шунда йомарланып ятты. Балалары, аларга игътибар итеп тормастан, түр якка таба уздылар.

—Әти кайткан икән, йоклый, арыган!—дип сөйләнеп алдылар. Шәмсия изелгән хәлендә иренең кочагында йокыга китте. Ул инде хәзер элеккеге көянтә сындырып Казанда калгалаучы Шәмсия сыйфатында иртәгә дә, берсекөнгә дә уянмаячак иде. Юк, ул торыр, әмма катык-сөт белән йокләнеп Казанга йөгермәс. Ничек тә җан асрар әле. Кибән кадәре ире бар, жигелсен! Әнә, Агыйделнең аръягыннан көтүе белән сыер, сарык, тана, бозау алып кайткан. Анда бер энәгә бер сыер, ди, бозаулары да бакыр бәясе генә икән...

Шәмсия саташа иде.

Абзар ягында сынык аяклы сыңар бозау, башмак тана белән карт сыерның көрпә чөмерүләреннән көнләшепме, канәгатьсез мөгрәп куйды. Әмма ишетер кеше юк иде. Карлар ява, көннәр тундыра башлауга, үзен барлап, Мөдәррис белән Хисмәтнең килеп керәсен ул түгел, Сабир да әлегә белми һәм күз алдына китерә алмый йоклый. Хәер, аларга гына сүзе табылачак ул чүмәләнең. Чын ирләр кулында сына икән ул көянтә, "Агыйделнең аръягында!.."

*Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

## Зур күләмдәге, айлык, сәяси, әдәби, художество, экономика һәм тәнкыйть журналы "ЯҢАЛИФ"

Татарстан Халык Агарту комиссариаты һәм татар совет язучылары оешмасы органы.

РЕДКОЛЛЕГИЯ: Ф.Сәйфи-Казанлы (җаваплы редактор), Г.Нигъмәти, Исхак Рәхмәтуллин, З.Гали, И.Рәми.

**"Яңалиф"**—культура революциясе проблемаларын марксизм-ленинизм нигезендә теоретик яктан эшләүгә хезмәт итәчәк.

**"Яңалиф"**—әдәбият, тәнкыйть, гомумән, матур сәнгать буенча күтәрелгән мәсьәләләрдә сыйнфый сизгер юл билгеләүне күзәтәчәк.

**"Яңалиф"**—татар совет матур әдәбиятын идеология, стилистика, тел ягыннан тиешле дәрәҗәсенә күтәрүгә, ягъни пролетариат әдәбияты сафына якынлаштыруга, шулай ук матур әдәбиятта солтангалиевчелек буржуа милләтчелеге агымнарының сыйнфый йөзен кызганычсыз рәвештә ачуга ярдәм итәчәк.

**"Яңалиф"**—культура революциясе барышында алга куелган мәсьәләләр тирәсенә совет җәмәгатьчелеге фикерен туплауга, шул юлда активлык күрсәтүгә ярдәм итәчәк.

**"Яңалиф"**—үзенең тирәсенә пролетариат һәм совет язучыларын, гыйльми эшчеләр, культура эшчеләрен тупларга тырышачак.

**"Яңалиф"**—социализм төзелеше юлында актив катнашкан эшче, колхозчы, партиец, комсомол, вузчы, гыйльми эшчеләр, культура эшчеләре һәм башкаларга каратылып чыга.

**"Яңалиф"** түбәндәге бүлекләрне эченә ала:

матур әдәбият—сәнгать—тәнкыйть—экономика—культура—әдәбият тарихы—библиография—хроника һәм башкалар.

"Яңалиф" журналының вакытында чыгып баруы һәм яхшы кәгазьдә басылуы тулысынча тәэмин ителде.

**Подписка алына:** баш экспедициядә, "Татиздат"ның кантон, район һәм Казандагы китап магазиннарында, Советлар Союзындагы барлык почта бүлекләрендә, шәһәр һәм авыллардагы хат-гәзит йөртүчеләрдә, тимер юл станцияләрендәге китап киоскаларында.

**Турыдан-туры подпискалар җибәрү өчен адрес:** Казань, Чернышевская 9, экспедиции Татиздата.

**Редакция адресы:** Казан, Чернышев урамы, 21. Телефон № 22-84.

**Корреспонденцияләр өчен:** Казан, почта ящиге № 54.

**Телеграмнар өчен:** Казан, "Яналиф".

**Язылу бәясе:** 1 елга—5 сум, 6 айга—3 сум, 3 айга—1 с. 75 т., аерым саны—60 т.

*(Яңалиф. – 1930. – № 1. – 4 тышлык бит).*

Şigriət
Шигърият



## Флера Гыйззәтуллина

# ОЗАТА БАРАМ ГОМЕР КОЯШЫМНЫ...

### Баганалы заманалар

**Басу юлы—шигърияткә ашу юлы.
Ләкин бүген бу басулар янып ята.
Басу басып, нефть фонтаннары ачып,
Кылдыкмы без мәңге төзәлмәстәй хата?**

**Җырлап аккан кара алтын елгаларын
Хаталанып бордыкмы без кире якка?
Басуларга адым саен яра ясап,
Күпме байлык озатылды җиде ятка!**

**Арыш, бодай шаулап үскән басуларның
Киләчәге—янулардан булды корбан...
Чор тудырган корбаннары күп булса да,
Җыр-шигырьдә нефтьченең даны зурдан.**

**Зурдан монда—скважина "торналары",
Зур һәм биек көянтәле баганалар!..
...Бу торналар: "Тор-рыйк!!!"—диеп кычкыра алмый,
Баганадан ычкына алмый заманалар.**

**Ни кызганыч, даны, аты зур булса да
Хезмәт халкы—ирегеннән ерак тора.
Хәерчедәй елап-елап, үз өлешен
Чит мәмләкәт агаеннан сорап тора...**

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә; "Йөрәгемдә шаулый карурман", "Күз нурларым" һ. б. китаплар (шигырьләр, күпсанлы поэмалар) авторы. Казанда яши.*

Мена мин дә, көянтәле баганадай,
Утлы басу уртасында басып торам,
Чор тудырган хаталарның хәтәрлеген
Иңнәремдә җилфердәтеп асып торам.

Һәм кычкырам:
—Тор-рыйк!!! Тор-рыйк шушы төштә!!!—
Ихтимал, без танылырбыз шушы эштә...
Ихтимал, без яна-яна яктырырбыз...
Җирне утка салучыны таптырырбыз.

## Сокландым гына...

Идел ул—милләт кәүсәре!—
Җырлап Иделгә үрләгез!
“Саекты, болганды”,—диеп,
Сез аны хурлый күрмәгез...

...Иделгә тоташ булса да
Хәзерге иҗат сукмагым—
Мин бары шигырь уртладым,
Бер тамчы су да йотмадым.

Мин бары сокландым гына
Иделем камышларына,
Ярдан кул изәп калганда
Гомерем агышларына.

## Узып тора гомер...

Үзен гөнаһсызга санаучылар—
Гөнаһ шомлыгына—табыналар,
Бер түмгәккә мең кат абыналар:
Җирнең ярасына кагылалар.

Җир бәдәне гел ярадан тора,
Каны саркып тора һәр тарафтан.
Йә, әйтегез!—мондый тарафларны
Бер гөнаһсыз җиргә кем тараткан?

Юк шул... Дәшми безнең беребез дә
Исән чакта, күңел чиста чакта.
Дәшми-тынмый гына канда йөзү
Кемнәргәдер ошый кебек хәтта.

Гөнаһлы җан сансыз-дансызларны
Откан даны белән кызыктыра—
Әҗәл сазлыгына батучыга:
—Тотын!—диеп, сәлам сузып тора.

Узып тора гомер...—әрәмнәргә
Узганлыгы өчен үкендереп,
...Шул сәламга бер үрелгән өчен
Синнән мең кат гафу үтендереп.

## Аклык

Тирә-юнем ап-ак моң урманы.
Ап-ак безнең язмыш чыршылары.
Синең сәламеңне юллап, миңа
Бу чыршылар көмеш җыр сузармы?

Бу ак тылсым—синең моң байлыгың...
Чор шөһрәте синең кочагыңда.
Чорга саулык телим, чыршыларга
Исемеңне синең кушамын да.

Синең үзәк өзгеч җыр-моңнарың
Отып алам язгы ярсулардан.
Хисләремдә күпме ярсысам да,
Ачуланмам сиңа, ачуланмам.

Исемнәргә кер, тап кундырмабыз,
Без бит инде аккошлары кышның.
Сак-Сок нәселеннән булсам да мин,
Гомерем буе сиңа таба очтым.

Сак-Сок сагышы белән сагышландым
Бер ялгызым таңнар аттырганда.
Төннәр озын хәзер, күзләремә
Йокы алалмасам, аптырама.

Аптырама, көн яктыру белән
Алмашынса төсем, тавышларым.
...Мин китәрмен... Син калырсың җирдә,
Акка манып аккош язмышларын.

## Сөрелсә дә үзе сөргеннәргә...

Татарымның ачы аһ-зарларын
Җуялмаган чорлар агышы.
Казан ярындагы ак дулкында
Ханбикәнең үкси сагышы.

Дулкын сөзеп йөзә көмеш көймә
Сөембикә аһы тирәли.
—Сагышларга, гүзәл, бирешмә!—дип,
Ак болытлар ләйсән сибәли.

Бу ләйсәннәр өмет яңгырыдыр,
Никадәрле якты наз анда!
...Сөрелсә дә үзе сөргеннәргә,
Рухы яши аның Казанда.

Рухы яши аның һәр татарда,
Азатлыкка, алга чакырып,
Иман иркендәге ярымайлы
Манаралар булып калкынып.

Иртәләрен ул да уйлангандыр,
Чумып ак дулкыннар шавына...
...Ничә гасыр инде Идел яры
Гүзәл Ханбикәсен сагына.

## Җавабым шул!..

...Бу җан миңа, белмим, кемнән күчкән?
Кем җирләгән тәүге җәсәдем?
Кайсы чорның рәхмәт фәрештәсе
Чәчкән җиргә илһам чәчәген?

"Дус" дигәнем—явыз дошманыммы,—
Кемнәр белән соң мин көн күрәм?..
Төшләремдә аю... бүре күрәм...—
Аю, бүре булып үкерәм.

Алтын таҗлы болан булып йөгерәм
Ак каенлы уйсу болыннан...
Каенкаем җирне нурга мана:
Кояш тама яшел толымнан...

Мин дә, ахры, калган гомеремне
Болын яме белән ишләрмен.
...Аю, бүреләрне үкертерлек
Кайгылардан ләкин нишләрмен?!

Ничек ирешермен ак бәхеткә—
Кубарылып килер гасырдан?
Бәхет көтеп үткән һәр минутым
Сорау булып ташка басылган.

Бу дөньямнан китеп, кабат тугач,
Мин булырмын мәгърур таш кыя...
—Язганнарың өчен җавап бир!—дип,
Баш очымда күкләр яшь кояр.

...Җавабым шул:
Шигырь кылычында
Күпме кыелсам да чыдармын...
Газиз милләтемнең бар кайгысын
Чыдамлыгым белән сынармын.

## Ятимлек

Ятимлек ул—тынгы тапмас вулкан:
Җирләр тетри анда, күрәмсез?
Ятимлек ул чал таулардай уйчан,
Атом бомбасыдай иләмсез...

Ятимлек ул—кылыч!—милләтемнең
Борынгыдан җанын айкаган.
Күз-яшь катыш кан дәрьясы сыман
Кайгы чоңгылында чайкалам.

Ятимлектән җиргә сагыш саркый,
Чор шәүләсе уйный чәчемдә...
...Авыр тойгым—янар вулканнарда,
Уем—чал гасырлар яшендә!

Палачлары чорның адым саен,
Битлекләре ефәк оектан...
Йөзтүбәнләй дөнья авып килә,
Ятим бусагага коеп кан.

Ятимлек ул—кадап куйган хәнҗәр
Йөрәктәге тере ярага...
Шул яралар аша үтә гомер—
Иңнәремә башын сала да...

## Сугыш тынды...

...Сугыш иде... Тәрәзәләремне
Кара җәймә белән капладым.
Төннәр озын җанга шакыды җил
Көйләп канлы сугыш такмагын.

...Сугыш иде... Күзләремне йомдым:
Күзләремә йокы кермәде.
Хыялымда калган бала чагым
Күк күгәрчен булып гөрләде.

...Сугыш иде... Сугыш очкычлары
Безнең өстә канат кайрады.
Кайгы кайрагына әверелгән җан
Көн яктысын төннән аерамы?

...Сугыш тынды... Менә алтмыш ел мин
Көнне төнгә ялгап уй сарам—
Шатлыклардан балкып торсын өчен
Балачактан көткән бусагам.

***

Тарих айкап, татарымны барлыйм:
Даны аның кайда балкыган?
"Азатлык!.."—дип, көрәшкән дә татар,
Җанын фида кылып, кан койган...

Каны аның далаларга сеңгән,
Иделләргә аккан ургылып...
Илгә иелеп әчкән кайгылары
Маңгаена баткан сыр булып.

Әнә Идел кабат дулкын чайкый,
Ирек гаме белән яр тула...
Казанымның мең еллыгы аша
Ирегенә Ватан тартыла.

## Сал агызма, Казан!

Сал агыза Казан, сал агыза—
Агым уртасыннан юл ачып.
Сөйгән ярлар салчы булып китә,
Без калабыз ярда елашып.

Сал агыза Казан, сал агыза—
Сал башына уеп тамгасын.
Шушы саллар безнең сагыну җырын
Киләчәккә илтеп ялгасын.

Сал агыза Казан, сал агыза
Сал сәфәрен бәйләп салчыга.
Үз дөньясын Идел тарсынмый ла...—
Саллар санап йөрәк ярсына!

Сал агызма, Казан! Сал агызма!
Агышлары салның сагышлы...
Сагышларга бирешмәс тә идем—
Гомерләрем ярдан авышты.

***

Чәчрәп тамган каннан ал тап кала,
Кара күмер кала янудан.
Кем белми соң әчтә үч-нәфрәтнең
Яралганын яралanудан?

Санап бетергесез тамгаларның
Карасы да миндә, алы да...
Ярый әле сызланулар уза,
Ярый әле вакыт агыла!

## Яратуым өчен...

Озата барам гомер кояшымны,
Күп калмаган Кояш баерга.
Гашыйкларны таңнар кавыштыра,
Кояш баешлары аера.

Озата барам гомер кояшымны,
Таң нурына манып канатым...
Бу тормышны шундый яраттым мин,
Яратуым өчен җан аттым.

Озата барам гомер кояшымны,
Ераклаша барам үземнән...
Атылырга җитеп йөрәк кага—
Яшьләр тама Кояш күзеннән...

*Гурий Тавлинның тууына 80 ел*

# САРЫ ЯФРАКЛАР КОЕЛГАНДА

Аның Халыкара урамнан, Педагогия институты ягыннан (Кави Нәҗми урамы) горурлыгын балкытып килүе Матбугат йорты тәрәзәсеннән аермачык күренә. Тавлин бу. Аны кем белән дә булса бутау мөмкин түгел. Ул башкаларга да йөрергә урын калдырган, ул берәүнең дә юлына аркылы төшми — кемнеңдер юлын чикләү аңа хас сыйфат түгеллеге аның йөрешендә-кыяфәтендә үк чагыла. Кирәкми башкалар сукмагы-юлы, олы юлын ул үзе сала. Ә горурлыгын яшермәве — аның сөенече чагылышы, шатлыгын һәркем белән уртаклашырга, аларны да сөендерергә теләве. Шатлыгы исә зур — ул роман язган! Кырыгынчы еллар азагында татар әдәбиятында күләмле әсәр язарга алынучылар бер кул бармаклары санына да җитми иде. Педагогия институтының дүртенче, соңгы курс студенты, әнә, романын инде тәмамлаган. Матбугат йортына Гурий шушы әсәрен өлкән әдипләрдән укыту нияте белән ашыгып килә — их-х, романын кулында китап итеп тоту бәхетен тату көнен тизрәк якынайтасы иде...



Башын уңга янтайтып, югартынга карый Гурий. Озын чәчләре адымнары җаена күтәрелә дә җилкәләренә кабат кагыла. Егетнең адымнары кыю. Шулай булырга да тиеш — Гурий инде сугышның яман юлларын узган, афәтнең күзенә туры текәлерлек итеп үзен чыныктырган. Ә кыюлыгы-горурлыгы һич тә масаю түгел, борын чөеп яки баш салындырып халкыңа игелекле хезмәт итү мөмкин булмавын күңеленә юылмаслык сеңдергән ул.

Матбугат йортының өченче катында — ул чакта Язучылар берлеге шундагы ике бүлмәдә иде — Гурийның килүен ерактан күреп торган әдипләр роман язган егетне үз итеп, үзләренә тиң итеп каршыладылар. Әңгәмә куерды, бәхәсле фикерләр әйтелде, романчы егет каләм көчләрен ныгыткан язучылар белән үзен бериш тотты, сүз алышуда сыгылмады. Соңгы арада басылган хикәяләре турында сыртына сыланырдай тәнкыйть ишетсә дә, билен бирмәде. Андый ишарәләрнең кайберсен ул:

— Бүтән кабатланмас, — дип карусыз кабул итте — кимчелегенне тану егетлек лабаса! — яки: — Сез, хикәянең ахырын укыганда, уңга-сулга һәм артка-алга карамыйча, ашыккансыз, — дип көлемсерәде, аның киңәеп елмаюында хыялны чынга тиңли алуы көче һәм чынны хыялга төреп тасвирлый белүе кодрәте ялтырап чагылды — сер пәрдәсен ябарга хәйлә дә кирәк ич! Монысы да иҗат кануны.

Сер пәрдәсен төшерү-тарту исә Гурийга тормышның вакыты-вакыты кирле-морлы агышына, кешеләрнең уйлану сәләтен җуя баруларына игътибарны җәлеп итү өчен кирәк. Фикерләү куәсең булса, син пәрдәне үзең ач — яшәешебез галәмәтләренәкәмәтләрен күреп, артыңа аума ләкин. Иҗатның башлангыч чорында Гурийның хикәяләвендә карашын-теләген пәрдә артына яшерүе кәмит өчен хәйлә коруы түгел. Хәер, хәйләне оста оештыру начардан саналмый лабаса, хәйлә-хыял иҗатта җитеш сурәтләүнең, колачлы тасвирлауның беренчел таләпләре ич. Әдәбиятның шушы кануннарын яшьли үк өйрәнергә керешкән иде Гурий.

Яшь язучының сүрәтләүдә-тасвирлауда ара-тирә, хәтта еш кына астыртын фикерләве, әйе, яманлыкка-явызлыкка өндәве, чуалышка-фетнәгә котыртуы итеп бәяләнә алмый. Ул иҗатының башлангыч чорыннан ук кешеләрне игелек-изгелек кылып яшәргә үзенчә, әмма ялварып мескенләнмичә чакырды (журнал укучыларга тәкъдим ителгән "Үги ана" хикәясе моңа ышандыргыч мисал, мәсәлән), һәм бу мәсләгенә гел тугры булды.

Ләкин Гурийның әсәрләреннән әшәкелек эзләүчеләр дә табылган икән. Илленче ел

башында Педагогия институтын әйбәт тәмамларга әзер студентны сталинчыл җәмгыятькә пычрак сылауда гаеплиләр, зинданга ук ябып куялар. Сугыш афәтен кичергән егет Сталин төрмәсе афәте уртасына басарга мәҗбүр ителә. Монда кушкыларның сыртны яруын гына түгел, ә күп очлы мондый камчыларның күңелне телгәләргә тырышып чыжлавын да татый егет. Һәм бу хәерсез еллар Гурий Ивановичның соңыннан язылган "Афәт" исемендәге күләмле әсәрендә чагыла. Бактың исә аның һәм шул заманда рәнҗетелгән иҗатташ иптәшләренең "гаепләре", татарның фәлән-фәлән язучылары әсәрләрен дә өйрәник, наданлыкка йөз тотмыйк, дигән чакыруга кайтып кала икән. Шулай, Гурий үзе язганча, аны чүлгә "язмышы якалап китерде".

Гурийның әсәрләрен укыганда, үзгә-үзенчә тасвирлау яки истә-оста югында әйтелгән фикер укучыны туктальш уйланырга мәҗбүр итә. Мине Гурий дәдәйнең "Яшьлек галәмәте" исемле новелласында мондый юллар уйга төшергән иде.

"Ялгыз йортның озынча тәрәзәләре батып баручы кояшның җете нурларын кире чагылдыралар. Галим аларны юл читендә үзенә корбан көтеп утыручы хәлсез җанвар күзләренә охшата".

Нигә озынча соң әле тәрәзәләр? Нигә алар кояш нурларын кирегә бәрәләр? Нигә тәрәзәләр җанвар күзләренә охшаган да нигә ерткыч җанвар корбанын мескенләнеп көтәр хәлдә калган?

Әсәр героеның халәтен табигать күренеше белән бергә кушып чагылдыру, аны яшәеше уртасына бастыру өчен әдәби осталык дигәнең кирәк шул...

Югарыдагы өзек Гурий дәдәйнең 1968 елда чыккан "Сары яфраклар коела" исемле җыентыгыннан алынды. Новеллалар китабы бу. Сүз җаеннан шунысын да искәртик, татар әдәбиятында гел новеллалар гына тупланган китапны укучыларга Гурий Тавлин беренче булып бүләк итте дип беләм.

...Матбугат йортындагы әңгәмәгә килә-китә тордылар. Гурий да озак юанмады. Әнә, ул институтына кайтып бара. Озын чәчләре адымнары җаена күтәрелә дә җилкәсенә кабат кагыла. Чәчләре, җилкәләрен сыйпап:

– Сине тормыш-язмыш күп үк газаплар чиктерер, хәзергә без сине үзебез иркәләп рәхәтләндерик әле, – диләр кебек.

Язучылар әңгәмәсен без, каләмне җигә генә башлаучылар, читтәрәк торып тыңладык. Мондый әңгәмәләр ул чакларда еш оеша һәм алар үзләренә күрә әдәби дәресләр иде.

Әлеге әңгәмәне тыңлаганда, минем башка кыю гына, хәтта бераз дорфарак уй килде: телгә алынырлык хикәяләр язсам, Гурий дәдәй, мин синнән, Язучылар берлегендә әгъза булу өчен, рекомендация сораячакмын, әзер булып тор, дип әйтәм, яныңмасе. Мин, Гурий Тавлинның язучылыгы шул чакта ук рәсмиләштерелгән, дип уйлый идем. Алай булмаган икән. Язмыш шуклыгы, димме, шактый еллар узгач, Гурий Иванович Тавлинга андый рекомендацияләрнең берсен... мин бирдем. Менә бит – дөнья – язмыш дигәнең ничек әйләнә... Гурий дәдәй белән яшь арабыз биш ел булса да, бу очракта мин аңа "абый"га әйләндем кебек. Әмма Гурий Ивановичка хөрмәтем дәрәҗәсеннән торып уйлаганда, мин аңа бурычымны үтәдем. Яшьләр арасының бер куанычы шул.

Ара дигәннән...

Бик тә ерак-ерак җирләрне, афәтле дә һәм кайбер төштә рәхәтле дә чомбыраклы-араны таймыйча-чүкмичә үтәргә Гурий дәдәйгә яшьлегендәгечә көч-куәте булышты, иҗатын туктаусыз бөтәйтерлек электәгечә кодрәте-гайрәте аны ташламады.

...Гурий Иванович Тавлин 1925 елның 25 декабрендә Татарстанның Зәй районындагы Урта Баграж авылында туа – аңа хәзер, әйе, сиксән яшь тулган булыр иде. 1998 елда вафат.

Ул 1943 елда армия сафларына алына, Курск дугасында дәһшәтле бәрелешләрне кичерә, Украинаны, Белоруссияне, Польшаны азат итүдә катнаша, сугышчан батырлыклары өч орден һәм медальләр белән билгеләнә. Педагогия институтын "ерак-ерак җирләрдә йөреп" кайтканнан соң тәмамлый.

Гурий Иванович 1954 елның сентябрендә тоткынлыктан тулысынча акланып азат ителә. Ә студент чагында язылган "Дунай дулкыннары" исемле беренче күләмле әсәре тикшерү органнарында кульязма килеш үк юкка чыга. Шушы хәлне истә тотыптыр, Гурий дәдәй "Афәт" исемле трилогиясенең беренче һәм икенче кисәкләрен китап итеп чыгару өчен бик тә тырышты. Мин аңа:

– Трилогияне тулысынча чыгарсаң, әйбәтрәк булмасмы? – дигән идем. – Өченче

кисәген дә язгансың һәм, тиздән аны тулаем әзер итәм, дисең ич.

— Юк, болары ташка басыла торсын! — диде, җавабы катгый иде.

Трилогиянең беренче һәм икенче кисәкләре 1996 елда аерым калын китап булып чыкты, өченче кисәге 1995 елда "Казан утлары" журналында басылып калды...

Газап чиктергән җирләрдән әйләнеп кайткач, бервакыт, Гурийны телефонга чакыралар.

— Сез Гурий Иванович Тавлин буласызмы?

Гурий сискәнеп куя — нигә эзләп тапканнар аны, "тегеннән" түгелме бу кызыксыну? Әмма шөбһәсен бетерерлек көчен җыя, шулай да рәсмирәк итеп җавап кайтара:

— Әйе, мин — Тавлин Гурий Иванович. Ләкин мин сезне белмим. Тавышыгыз аз гына таныш та кебек...

— Мин... — Шалтыратучы кем булуын әйтә.

— Сез... сез исәнме?!

Беренче карашка мәгънәсез тоелган бу сорау шалтыратучыны гаҗәпләндерми.

— Исән мин, Гурий. — Һәм йомшак тавыш белән болай дип өсти: — Ләкин мин сез белгән җирдә түгел, җибәрелдем мин аннан. Үз белгечлегем буенча эшлим, шуңа сөенәм. Төзелештә мин.

— Адресыгызны әйтегез! Мин сезгә хәзер үк барам!

— Мин сезне чакырып шалтыратам лабаса. Эзләп табуым — очрашу теләгеннән.

Шалтыратучы кеше Гурий Тавлин һәм башкалар "эше"н алып барган тикшерүче Газыйм Салихов икән. Теге гасыр ахырындарак бу кеше турында Татарстан радиосы аша тапшырулар булды. Боларны радиокомитетта озак еллар эшләгән Эльза Гобәйдуллинаның оештыруы хәтеремдә. Тапшыруларның берсендә яшь егетләр "эше"н группачылыкка-төркемчелеккә әйләндермәү өчен тикшерүченең тырышлыгы да әйтелде кебек. Әгәр гаепләү төркемчелек мәгънәсен алса, егетләргә җәза катырак буласы икән...

Җылы каршылый Гурийны тикшерүче. Егет тә үзен иркен тота. Чәй янында күп нәрсәләр искә төшерелә. Һәм Гурий кинәт, холкында — үзен тотышында булмаганча, "җебеп төшә", хәтсез вакыттан соң көче кайткач кына:

— Мин сезнең ике тапкыр чәегезне эчтем, — ди. — Беренчесе — сез, җавап алырга чакыргач, миңа чәй ясап бирдегез. Бик тә тәмле чәй эчәсем килгән чак иде. Икенчесе — менә бүген. Хәзер дә чәйне үзегез ясадыгыз. Бик тә тәмле булды.

Ә күзләреннән тагын борчак-борчак яшьләр агыла Гурий дәдәйнең...

**Мәгъсум ХУҖИН**

# Гурий Тавлин

## ҮГИ АНА

ХИКӘЯ

Кичке энгер, куерганнан-куера барып, караңгы төнгә әйләнде. Күкне эрелеваклы якты йолдызлар чуарлады. Өйләрдә утлар алынды.

Сәлим, эштән кайткач, ванна бүлмәсендә пөхтәләп кырынып, юынып чыгып, өстен алыштырды. Стена сәгатенең идәнгә кадәр асылынып төшкән герен күтәрде, урамга караган тәрәзәләре төбендә чәчелеп яткан вак-төяк әйберләрне ашыкмыйча гына тәртипкә китерде. Аннары өстәл артына зәңгәр абажурлы лампа астына дәрес әзерләргә утырган ак чырайлы, юка бәдәнле кызчыгының арык иненә иплэп кенә кагылып, карлыккан тавыш белән:

—Энҗе, ишекне бикләп кал, кызым. Мин сезгә яңа әни алып кайтырга барам,— диде.

Кызчык, алдындагы дәреслегенә капланып, үкси башлады.

—Менә сина мә!—диде бу хәлгә югалып калган ата. —Нигә балавыз сыгасың? Кирәкми. Без синең белән яна әниең турында сөйләштек бит инде. Әнисез, беләсең, авыр, бик авыр бит сезгә. Сөрт күзләреңне, кызым, елама юкка...

Әтисенең үтенечле таләбе кызчыкның сулкылдавын төкәндермәде, киресенчә, көчәйтте генә. Сәлим, аның калтыранган иңнәренә кашларын җыерып бераз карап торгач, гардероб янына барып плащын киде дә, кепкасын кулына алгач, кискен һәм боерылу тавыш белән:

—Елаудан хәзер үк тукта! Сиңа ана инде кирәк булмаса, ул әле энең Шәүкәткә кирәк, шуны уйла, акыллы баш. Ишекне биклә, без тиздән кайтырбыз,—диде һәм, чыгарга ишекне ачкач, тавышын йомшарта төшеп: —Ана бүгеннән үк, әни, диярсең, ишетсен колагың...—дип, бусаганы атлады.

Кызчык, тирән көрсенеп, әтисенең коридорда ераклаша барган аяк тавышларын тыңлап торды. Аяк тавышлары тынды, бүлмәдә стена сәгатенең тигез текелдәве белән бәләкәй караватта йоклаган кечкенә Шәүкәтнең тын гына мышнавыннан бүтән нәрсә ишетелми башлады.

Энже, ишекне бикләгәч, тәрәзәгә барды. Тышта төн карасы күңелне өшетерлек шомлы, куркыныч. Кызчык, артка чигенеп, як-ягына каранды. Бүлмәдә алар Шәүкәт белән икәве генә. Бала караучы Нәҗия апа монда көндезләрен генә була. Шәүкәтне төнлә Энже белән әтисе карый. Сабый ярты төнгә чаклы тыныч кына йоклый, аннары өч-дүрт тапкыр уяна һәм, уянган саен, әче тавыш белән акырып елый. Йокының ул, үч иткән кебек, иң тәмле чагында уяна. Ләкин берни эшләп булмый, торырга, "кушбугазны" тынычландырырга туры килә.

Кызчык тынгысыз энесе янына килде, аның өстенә ябылган юка юрганны рәтләде. Кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, яшьләрен сөртте. Ләкин сөрткәнгә карап кибәме күз яше! Әнисе исән булса үксер идеме? Юк, әлбәттә. Менә аның карашы әнисенең кечкенә өстәлдә кара рамга куелган зурайтылган рәсеменә төбәлде.

Рәсемдә әнисе тирән кәнәфидә. Яңагына уң кулын куеп, нәрсә турындадыр уйланып утыра. Ул нәкъ тере кебек... Кызчык мәрхүмә әнисенең тик ана гына хас назлы, йомшак тавышын, кайнар иркәләүләрен исенә төшерде. Кинәт рәсем ана:

—Кызым,—дип дәшкән кебек булды.

Энже сискәнеп китте, йөрәге еш-еш тибә башлады. Ул, әсәрләнеп, як-ягына каранды, инде онытыла барган тансык тавышны тагын ишетергә теләп сагаеп тыңланды. Әмма, колакларын ничек кенә торгызса да, сәгать текелдәве белән кечкенә энесенең ваемсыз мышнавыннан башка тавыш ишетмәде.

—Әни!.. Ник дәшмисен, әнием?—диде ул ахырда, өтәләнеп. —Нигә син безне ташлап киттең, әнием?.. Мин әти алып кайтасы яна әнидән куркам. Нигә син юк, әнием?..

Рәсем кызчыкның ялварулы сорауларына җавап бирмәде. Кызчык бераздан янадан элекке урынына барып утырды һәм, арык йодрыгын рәсемдәге әнисе шикелле яңагына куеп, уйга чумды. Нигә безгә яңа әни? Әти үги әниләрнең явызлыкларын, миһербансызлыкларын белмимени соң? Белмидер... "Золушка" киносын карамады ул...

Энженең иреннәре тагын калтырана башлады. Күзләренә янә яшь тыгылды. Яңадан үзен, энесен, вакытсыз дөньядан киткән сөекле әнисен кызганып пышык-пышык елады. Тик ни файда? Хәсрәтнең чирегенең чиреге генә яшь койганга, үрсәләнеп сыктаганга карап юкка чыкса икән. Алай булса, кеше бәхеткә елап кына ирешер иде.

Ишек шакыдылар. Энже барып келәне күтәрде. Аннары, исенә килеп, куркудан бөрешеп, артка чигенә-чигенә, күзләрен зур ачып көтә башлады. Бу

көтү секундлары ана бик озак тоелды. Менә ишектә мөлаем йөзле ят хатын белән әтисе күренде. Яна әниебез шушы апа микәнни инде? Әнигә ул бөтенләй охшамаган бит, дип уйлады кызчык, хатынны баштанаяк күздән кичереп. Усалдыр ул...

Сәлим хатынга, житди итеп:

—Безнең гүрнәчәбез менә шушы инде, Әминә. Конкрет сөйләшик, калам, дисән, балаларыма ана, миңа хатын булырсың, калмыйм, китәм, дисән, тотмам, китәрсен. Минем бар байлыгым—ике балам, бүтән чуртым да юк. Әнә, сиңа өнәмичә кызым Энже текәлеп тора, бәләкәй караватта улым Шәүкәт мышный. Соңгы сүзеңне әйт,—диде.

Калмасын, китсен ул, әти, китсен, дип инәлде кызчык үзалдына. Ул ят хатынны ошатмады.

Ләкин хатын аны үртәгәндәй:

—Китмим, калам, Сәлим, пәлтәмне салырга булыш миңа,—диде. Өстен салгач, ул югалып калган Энжегә борылды. Булачак үги әнисен тәүге кат күреп өреккән кызчыкның көенечле карашы белән бу өйдә инде гомере буена төпләнергә дип калган ят хатынның игелек, рәхим-шәфкать бөркелеп торган ягымлы карашы очрашты. Аннары ул күптән таныш кеше кебек аналарга гына хас ягымлылык белән:

—Исәнме, кызым,—диде.

Аңа кызчыкның суырылган йөзе, елаудан шешенгән күз кабаклары, әсәрүле кыяфәте үтә аяныч тоелды.

—Исәнмесез, апа.

Җавабын Энже чак ишетелерлек әйтте. Аның авыруныкы шикелле кипшеп яргаланган төссез иреннәре кызганыч тартышып куйдылар.

—Син без кайтканны көтеп зарыккан идең инде, шулаймы?—диде хатын, кызчыкның күнелендә үзенә карата нәфрәт дөрләгәнен бөтенләй сизмәгән кебек.

Җавап бирергә Энженең теле әйләнмәде, ул, шулай дигәнне аңлатып, башын гына какты.

—Бүген тоткарлануыбыз өчен үпкәләмә, кичер безне. Мин сиңа сүз бирәм, моннан соң сезне беркайчан да төнгә ялгызыгызны калдырмам, без гел бергә булырбыз.

Энже елап җибәрүдән көчкә тыелды. Тыныч, эчкерсез тавыш аны иркәләп йомшартканнан-йомшарта барды. Аннары аның аңын, бу сүзләр барысы да ялган, бу апа миңа ярарга тырыша, үзен яхшатлы итеп күрсәтеп, күнелемне яуларга юхалана, дигән шомлы уй көйдереп үтте. Ул уеның хаклыгына инанырга ниятләп, әтисенә карады һәм әтисенең йөзе якты, елмаюлы икәнен күрде.

—Син тәртипле, эш сөючән, сүз тыңлаучан бугай,—дип дәвам итте хатын сүзен. —Бүлмәгез ямьле, әйбәтләп җыештырылган, җылы. Ач түгелме син? Ашыйсың килмиме?

—Юк.

—Әйдә, мине кухнягыз, савыт-сабаларыгыз белән таныштыр...

—Таныштыр, кызым, күрсәт әниенә савыт-сабаларны,—дип, әтисе ят хатынның үтенечен хуплады.

Кызчык булачак үги әнисен ияртеп кухняга үтте.

—Менә безнең савыт-сабалар,—диде ул, стенага беркетелгән шкафны ачып. —Плитә өстендәге кәстрүлдә—аш, өстәлдәге чүлмәктә—сөт.

—Шәүкәткә нәрсә ашатасың?

—Ул манный боткасы ярата. Сөт эчә. Төнлә ашамый, уянып көйсезләнә генә...

Хатын, кухнядан чыккач, мәрхүмә ананың кара рамдагы рәсеме торган өстәл янына барып, рәсемгә кызыксынып карап торды һәм аның янына иплэп кенә вазадагы чәчәкләрне этәреп куйды. Аннары Энжегә борылып:

—Син, кызым, дәресләреңне хәзерләденме әле?—диде.

—Юк,—диде кызчык, җинел сулап.

Ул ят хатын аларның әниләренең рәсеме янына килгәч, аны өстәлдән алып ташлар, дип курыккан иде.

—Өстәл артына утыр әле,—диде хатын ана—Кая, мин сина, бәлки, дәресләреңне әзерләшергә булыша алырмын?..

Энҗе өченче класста укый. Аларга бүген өйдә грамматикадан боерык фигыльле өч җөмлә язып килергә куштылар. Энҗе инде мәктәптә үк бер җөмлә уйлаган, тик аны ничек язарга гына кыенсынган иде. Ят хатын аны ничек язарга икәнен әйтте. Ул, Энҗе янәшәсенә утырып, аның язганын күзәтте. Әни дә минем язганымны шулай карап утыра иде бит, дип сагышланды кызчык. Ул, эше шапшак чыкмасын дип бик тырышып язды. Әтисе, ул ят хатын белән дәресләрен караганда, идән буйлап арлы-бирле йөрде. Әти шатланамы, борчыламы—белмәссең, дип уйлады Энҗе. Ул дәресләренә әзерләнеп беткәч, хатын ана урын җәйде. Аннары юынырга кушты һәм ятар алдыннан бер җамаяк сөт китереп:

—Бу сөтне эчсәң, мин чиксез шатланырмын, кызым,—дип елмайды.

Кызчык сөтне эчеп урынына яткач, хатын аның маңгаеннан үбеп:

—Йокла, кызым. Шәүкәт уянып елый башласа, торма. Иртән ашарга әзерләргә дә тормассың. Матур төшләр керсен сина. Йокла...—диде.

Энҗе, йокы аралаш, энесенең елый башлавын ишетте. Аның берничә секундка гына ачылган күзләре әтисенең Шәүкәт караватына ашыгып баруын күреп калдылар. Аннары ул, төнлә тагын бер уянуында, кечә ана берничә тапкыр, кызым, дип дәшкән хатынның Шәүкәтне кулларында тирбәтеп торуын күрде. Энесе шомырт кара күзләрен ят хатынга төбәгән һәм нәни куллары белән аның тулы күкрәгенә тотынган иде. Энҗе, үзе дә сизмәстән, елмаеп, күзләрен йомды һәм иртәнгә чаклы бүтән уянмады. Ул уянганда инде тәрәзәдән кояш елмая, аларга Шәүкәтне көндезләрен караучы Нажия апа килгән иде. Энҗе, урыныннан торгач, кухняда табада май чыжлаганын ишетте, борыны бүлмәгә тәмле ризык исе таралуын тойды. Аның күңелен кинәт шатлык, тик бәйрәм көннәрендә генә була торган сөенеч биләде. Юынгач, ул мәктәпкә киеп бара торган күлмәген кулына алды. Күлмәге көндәгечә түгел, чистартылган, җентекләп үтүкләнгән булып чыкты. Дулкынланудан аның тыны кысылды. Күзләре белән күлмәгендә таплар, җыерчыклар эзләп күпме генә капшанса да, аларны таба алмады һәм ана шунда әнисе үлгәч эзсез юкка чыккан куаныч тойгысы кире кайтты. Ул мәктәпкә китәргә әзерләнеп беткәч, үги әнисе, аның алдына чүгәләп, кулларыннан тотты:

—Кызым, мәктәбеңә кадәр озатып куйыйммы сине?

Кызчык, кирәкми, дигәнне аңлатып, башын селекте.

—Ярый алайса, сау бул, кызым.

Энҗе, чиксез дулкынланып, үги әнисенең күзләренә мөлдерәп карады. Аның үзе өчен әле ят, әмма инде ничектер якынайганнан-якыная барган бу ягымлы хатынның муенына сарыласы, аны онытылып кочасы, шашып үбәсе килде. Хатынның чәчләреннән борынына бәрелгән тәмле хуш ис аны шаккатырды. Үз әниемнеке кебек үк ис, дигән уй узды аның башыннан, һәм, елап җибәрүдән чак тыелып:

—Хуш...—диде.

Кызчык бу җинел сүзгә тагын үтә ягымлы, җылы, иркә сүз өстәргә теләде, әмма соңгы мизгелдә тыелып калды. Аның күз алдында үги әнисе белән бергә үз әнисе гәүдәләнде. Үз әнисе... Ул, карашын идәнгә текәп, кулындагы портфелен як-якка селти-селти, ишеккә юнәлде. Ишек аның артыннан, ни гаҗәптер, гадәттәгечә шапылдап ябылмады. Шуңа ул ихтыярсыздан артка борылып карады һәм бусага төбендә үги әнисен күрде. Чү, аның күзләрен яшь пәрдәсе томалаган, ирен читләре көйсезләнергә җыенган Шәүкәтнеке кебек

аска тартылып турсайганнар түгелме?.. Юк, түгел, түгел... Әнә ул кыенлык белән елмайды. Алар өендә әле бары бер генә тон кунган ят хатынның авызына бик ачы әйбер капкандагы шикелле йөзен чытып елмаюы, аның үзен каушаган, аптырашка калган кебек сәер тотуы Энҗене әсәрләндерде.

—Син миңа үпкәләмә,—диде ул, портфеле тоткасын ике кулы белән дә чытырдатып кысып. —Үпкәләмә. Бер ни дә уйлама да. Мәктәпкә мин үзем генә барырга өйрәндем инде. Синә кадәр дә анда мине берәү дә озатмый иде. Син дә озатма...

Ниһаять, үги ананың елмаюы табигый төс алды. Кызчык бу тапкырында да теле очыннан менә-менә ычкынырга торган кадерле сүзне әйтә алмады. Дөньяда кемгә дә газиз һәм үтә ягымлы бердәнбер кешегә генә әйтелә торган бу мөкатдәс сүзне сиңа игелек күрсәтә башлаган икенче берәүгә шундый ук садәлек, самими эчкерсезлек белән әйтү, чыннан да, авыр да, уңайсыз дадыр ул.

*1958*

---

## *Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

*ХРОНИКА*

### "Татиздат"та

1931 нче елны "Татполиграф" һәм "Красная Татария" нәшрияты "Татиздат"ка кушылалар. Бу чакта бу берләштерелгән нәшрият матбагаларында барысы 1000 гә якын эшче эшләячәк.

"Татиздат"ның 1931 нче елгы нәшрият планы буенча барлыгы 9 гәзит һәм 10 журнал чыгарылачак. Гәзитләрнең бер елгы тиражлары 158.000, журналларныкы 74.000 булып, еллык тиражлары: гәзитләрнеке – 12.280.000, журналларныкы – 1.500.000 булачак. Бу гәзит-журналларның еллык расходлары 1.300.000 сумнар булып, аларга барлыгы 1000 тонна кәгазь тотылачак.

ДАИМИ МАТБУГАТ 1017 исемдә чыгарылып, күләме 4018,5 табак, тиражы 12.249.000 булып, анар 43.825.000 табак кәгазь тотылачак.

МАТУР ӘДӘБИЯТТАН (шул 1017 исемнән) 100 исем беллетристика әсәрләре (күләме 500 табак, тиражы 600.000), БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ 100 исем (1000 табак, тиражы 150.000), ТЕАТР ӘДӘБИЯТЫ 15 исем (45 табак, тиражы 75.000), ТӘНКЫЙТЬ, ПОЭТИКА ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ ӘСӘРЛӘРЕ 10 исем (30 табак, тиражы 50.000) китап чыгарылачак.

*(Яңалиф. – 1930. – № 3. – 2 нче тышлык бит).*



## Иделбикә

# ДӨНЬЯ АВАЗЛАРЫ

### Ах, каләм

**Ах, каләм, агыз җанымның
Ташыган моңын, назын.
Кузгат, чирт ай-еллар тыныч-
Тын яткан тойгы сазын.**

**Шигырь-җырга салып, агыз
Мәхәббәт януларын:
Сөйлә—дөнья иңләр көчле
Хисләр бәхете барын.**

**Мине сүрелдергән еллар
Сине, каләм, басалмас:
Сафлык эзеннән гиз һаман—
Омтылышың картаймас.**

**Юкса, куркыталар безне;
"Тик яшьлек—шигырь", диләр.
Әйт, каләм: "Җыр—мәңге яшь ул...
Тик булмый мәңге—юләр...
Чал җырны—Гомер, диләр..."**

### Шопен васыяте

**Чит Парижда сагынып яшәп туган илне,
Язган вальс, мазурка йә "полонез"ны.
...Васыять иткән: "Тәнем калсын ят җирләрдә,
Тик ... күмегез илгә илтеп—йөрәгемне"...**

---

ИДЕЛБИКӘ (Лена Садыйкова) *—шагыйрә; "Мәхәббәтнең мең фасылы" , "Бәхеткә үс, Кеше" , "Дөнья авазлары" исемле китаплар авторы. Ульяновск шәһәрендә яши.*

***

Син—аяз күк, тере йолдыз
        күл төбендә,
Иң якын дус, тугры сердәш
        кыен көндә.
Кайгы-хәсрәт бүлешәсең:
        "чыда, чыда..."
Яшерен уйлар, урын даулап,
        синдә чыга...
Канат җәеп синдә очам,
        йөзәм, буйлыйм...
Моңнарымны сиңа салам—
        җырлыйм, елыйм.
Язмышыма каршы барам
        йәки күнәм.
Синдә янам, синдә көям,
        синдә сүнәм.
Бата-калка бөтереләм
        дулкыныңда,
Ай-йолдызга кадәр ашам
        кай көнемдә.
Туктый сәгать—онытылам,
        галәм тына,—
Башым белән чумам сиңа,
        шигъри дөнья!

## Теләгем

Үз вакытында үлән җыям, ак чәчкә,
Шифага дип, сары, зәңгәр мәтрүшкә...
Фани дөньям мәшәкатьле булса да,
Озайтасы килә аны—йөз яшькә...

Һич зарланмыйм, әйтмим: "тормышым авыр",
Җирне бит җанландыра ләйсән яңгыр.
Табигать баласы бит мин: гөл, матдә,
Мәхәббәтеннән җирнең җан савыгыр.

Телим: еллар имин булсын, ырыслы—
Очып кунсын күренми Һома кошы:
Бәхет миңа йөзе белән борылсын—
Гомеремне бизәр шигырь нәкыше!

## Кызым рәсемнәре

Тетрәндерер меңнәр хисен—
Кызым вакыт хатирәсен
Яза: уза чорлар, яна—
Күз алдымда булып рәсем...

Рәсемнәрдән багам үзем:
Анда минем язым, көзем...—
Инде кызым дәвам итә
Яшәү көем, моңым, төсем—
Таныйм әче дөньям йөзен!..

## Кол Галигә

Кол Гали, иҗатың үлмәс, югалмас,
Йосыфыңны бер күргән—һич тыныч калмас
Рухы, Хакка тугрылыгы—чын бер алмаз.
Җәл, Зөләйхаң андый ук яшь түгел имди...

***

Әйтерсеңме: Мәхәббәтнең чиге кайда?
Салса да ул күңеленә әрнү-яра,
Аерылсаң да, югалтсаң да, Яр исемле
Яраң—Сөю хисең җанда мәңге яна!

***

Кышның сөям энҗе бәсле урманын,
Чәчәк аткан, яшәргән җирне—язын...
Җәй-көз—юмарт, җанны да ул баета,
Бары көч-дәрт бирсә миңа сүз-назың!

***

*Рәссам, шагыйрә кызым Лилия Юсуповага*

Татыганбыз дөньялыкның шактый тозын,
Юкса син—яшь, минем гомер—ахры, озын...
Игезәктәй яшибез тик: дус, фикердәш...
Шигърияттә дә без шулай калыйк, кызым!

***

Кайгы-сагышларга очрап, Хыял
Каңгырганда, тапмый үз юлын,—
Өзгәләнгән минутларда Хакка
Ялварамын кайчак: "Ал колың..."

Вакыт үтеп, җанны баскан ул йөк-
Әрнү узып, Илһам килгәндә,
Ходама мин инде: "...алма!" димен,
Шөкер, димен, Яшәү биргәнгә!"

***

Сиңа кадәрге бай җанны наян тәкъдир
Үзгәртте: мин хәзер ярсулы бер фәкыйрь.

Тормышыма давыл булып ябырылдың,
Җанны утта үртәп, көлен тик калдырдың.

Көлендә дә шытып үсәр, бәлки, чәчәк:
Башкага юл ачсам—кайгым да бетәчәк.

Әмма янган күпер яшәр хәтеремдә:
Ишандыра алмас мине хәзер кем дә...



**Әгъдәс Борһанов**
тарих фәннәре докторы,
профессор

# ЯСАЛМА ДӘҮЛӘТ, ЯЛГАН КЫЙММӘТЛӘР, ТАМЫРСЫЗ ХАЛЫК Һ. Б. ТУРЫНДА

Фәнни эшчәнлегем нәтиҗәсе итеп, мин "Кайлардан килүең дә кайларга баруың, Рәсәй?" дигән китап бастырып чыгарган идем *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1998)*.

Бу мәкаләгә кереш сүз рәвешендә тикшеренү ысулларымның үзенчәлекләре, дөньяга карашларым турында искәртеп үтәргә кирәктер.

Беренчедән, философ та, социолог та булмаганлыктан, мин кандидатлык диссертациямнән башлап ук тикшеренүләремне тарихи яссылыкта алып бардым, тарихи вакыйгаларны фәлсәфи, социаль-иктисади һәм социаль-сәяси күзлектән чыгып өйрәнә килдем: мине диалектик кануннар, җәмгыять үсешенең икътисади нигезе һәм өскормасы, этик мәсьәләләр, кешеләрнең үзүзләренә һәм башкаларга, шул исәптән хакимияткә һәм Ватанына мөнәсәбәтләре кызыксындыра иде. Телгә алынган китабымда болар һәм милек мәсьәләсе теоретик тирәнлектә өйрәнелде.

Икенчедән, тикшеренү-өйрәнүләремне чагылдырган барлык мәкаләләрем дә антикоммунистик, ягъни коммунистик карашларга каршы юнәлтелгән иде. Бу һич тә реакцион-хыялый коммунистик идеологияне кабул итә алмавымнан гына түгел, коммунистик идеологиянең кешеләрдәге хосусый милекчелек һәм милли-азатлык мәсьәләләрен кире кагуы яки аны дөрес аңлата алмавы аркасында да булды. Җәмәгатьчелек аңында хосусый милекчелек мөнәсәбәтләрен уяту аларны коммунистик карашлардан арындырып кына хәл ителә ала. Милли мәсьәлә белән дә шундый ук хәл—совет хакимияте аны марксизм-ленинизм нигезендә чишәргә азапланды, шуның белән үтә дә федераль дәүләт булган Советлар Союзын һәлакәткә китерде.

Коммунистик фәлсәфәгә һәм социологиягә каршы демократик хосусый милекчелек фәлсәфәсен һәм социологиясен куярга кирәктер. "Фәнни комму-

---

Әгъдәс БОРҺАНОВ (1920) – *Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры. Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы. Тарих фәннәре докторы. "Казан утлары" журналының даими авторы. Мәскәүдә яши.*

низм" тәгълиматенең төп төшенчәләре түбәндәгеләр: җәмгыять (дәүләт) милке, базарча булмаган планлаштырылган икътисад, пролетариат диктатурасы—ул әкренләп чын демократиягә әверелачәк, имеш. Монысы, әлбәттә, хыял гына, чөнки планлаштырылган икътисадка демократия һич тә хас түгел. "Октябрь революциясе" дигән түнтәрелеш бары тик 1918 елның җәенә кадәр генә, сугыш һәм солых мәсьәләләрен хәл итәргә тырышканда гына революция иде. Ә инде "социалистик" хыялга йөз тоткач, ул, демократик казанышларны сызып ташлап, контрреволюциягә әверелде. Ул Россияне упкынга—коммунистчылфашистчыл билгесезлеккә төшерде, бары тик хакимиятне кулларына алган, большевик түрәләрнең чикләнмәгән башбаштаклыгын, чикләнмәгән диктатурасын гына китереп чыгарды. Бу "революция", беренчедән, милекчелек мөнәсәбәтләренең, икенчедән, хаким сыйныфның да алмашынуына юл ачты. "Октябрь революциясе"нең икенче этабында крестьяннарны коллективлаштыру аркасында милекчелек һәрнәрсәне дәүләтнеке итүгә кайтып калды. Буржуаз аристократик бюрократиянең хакимлеге вак буржуаз-пролетар түрәләр тарафыннан бетерелде, алар бюрократиянең иң түбән дәрәҗәсендәге катламы гына иде.

Буржуаз идеологиянең төп асыл төшенчәләре: хосусый милекчелек, базар икътисады, демократия: соңгысыннан башка базар мөнәсәбәтләре бөтенләй була алмый. Демократиянең чыганагы—базар, базар мөнәсәбәтләре, ул тигез хокуклы субъектлар үзара көндәшлектә чакта гына була. Икътисадка капиталистик монополия булганда ул өлешчә, ә коммунистик монополия (дәүләтләштерү) булганда тулысынча юкка чыга. Милекне үзәкләштерүнең төп максаты да көндәшлекне-конкуренцияне булдырмау бит.

Хәзер җәмәгатьчелек бер сорауга җавап эзли: коммунизм буш хыял гынамы, әллә юкмы? Хәер, бүген безне ул мәсьәлә борчымаска тиеш. Беренчедән, коммунизм буш хыял булганда да, аны көч куллану юлы белән, бер гаепсез миллионнарча кешеләрне юк итүдән тартынмыйча, урнаштырырга мөмкин. Советлар илендә һәм аңа тартылган башка социалистик илләрдә бу шулай эшләнде дә. Икенчедән, коммунизмның төп асыл максаты—бар яктан да житкелекле-камил дәүләтләрдәге халыкны бәхетле, мул тормышта яшәтү. Иң алга киткән илләрдә бу максат, коммунизмны телгә дә алмыйча, аңа каршы килеп тормышка ашырылган. Марксизм-ленинизмның төп хатасы изелүчеләрсез, тигез хокуклы җәмгыять төзү фикерен алга сөрүендә түгел, аның алгарышүсеш субъектларын коммунистик партия бар иткән пролетарийлар белән алмаштырырга тырышуында. Һәр заманда да мәсьәләләрнең мәсьәләсе булып алгарыш-үсеш субъектлары кемнәр һәм алар нинди социаль-икътисади мөнәсәбәтләрдә оеша һәм яши, дигән мәсьәлә тора. Россия тарихы куып керткән, марксизм-ленинизм тирәнәйткән сазлык-упкыннан кайсы сыйныф безне тартып чыгарыр икән соң?

Коммунистик идеологиянең фәнни түгеллеге марксизмның пролетариатка чиксез ышанып, аңа изгеләрчә табынуында. Пролетар хәрәкәте дип халыкара коммунистик хәрәкәт китереп чыгаруы Маркcның иң зур хатасы булгандыр. Бу каян килә соң? Марксизм классиклары тарихи мантыйк әсирлегенә пролетариатка алгарыш өчен яңа сыйныф итеп караулары аркасында килеп капканнар. Ә ул бервакытта да андый сыйныф булмаган, сыйфаты белән үк була алмаган.

Капитализм чорына кадәр нәрсә булган соң? Феодаль җәмгыять "өченче катлау"ны тудырган, шуннан җәмгыятьне үзенә яраклаштырып, өстен буржуазия сыйныфы барлыкка килгән. Хакимияткә ия булгач, пролетариат та шундый үсеш-үзгәреш кичерер дип уйлаганнар. Марксизм булмастайны тәңгәлләштерергә тырышкан: пролетариат үзенә кадәр булган буржуазия сыйныфыннан чыгышы белән дә, җәмгыятьтәге дәрәҗәсе белән дә бик нык аерылып тора. Буржуазия җитештерүче милекчеләр, икътисади тормышны оештыручылар булган, алар икътисадны да, мәдәниятне дә яхшы белгәннәр, рухият өлкәсендә дә өстенлек иткәннәр. Хакимият урләренә һәм финансларга ия булып алгач, революция аларны шулай раслаган да. Пролетариат исә го-

мер бакый бөлгенлеккә төшкән, үз сыйныфыннан аерылган шәхесләрдән торган, таркалып барган җәмгыять җимешләре генә булган, тормыш төбендә калган. Марксизм коточкыч бөлгенлектәге пролетарийлар "сәяси җитлегүгә сәләтле, үзләрен расдый алачаклар", шул рәвешле калганнарны да ияртәчәкләр дип санаган. Пролетариатның мәдәнилеге булмаган, була да алмаган, ә шунсыз "сәяси җитлегү" турында сүз дә алып барырга мөмкин түгел. Мәдәнилек—гомумкешелек күренеше, ул җәмгыятьтәге барлык сыйныфларның талантлы-зыялы вәкилләре тарафыннан бар ителә һәм үстерелә, аңа байлар сыйныфы матди ярдәм күрсәтә. Аны фәкыйрьлек-ярлылык түгел, ә иркенлек-муллык тудыра. Кайберәүләр алгарыш-үсешне акыл хезмәте белән шөгыльләнүче урта сыйныф тәэмин итә, фәнне киләчәкнең җитештерүче көче итеп караган марксизм да шул фикердә булган, диләр. Әмма шунысы бар: бу "җитештерүче көч"нең үз милке булырга, шул нигездә җәмгыятькә кирәкле нәрсәләр җитештерелергә тиеш. Ә бу хәзер дә, киләчәктә дә булмаячак. Милек бюрократлар һәм олигархлардан торган өстен сыйныфлы дәүләт кулында, дәүләт исә үз мәнфәгатенә хезмәт итүче фәнне бары тик шуның өчен генә санлап тора. "Урта сыйныф" дип әйтергә мөмкин булса, ул да шул ук пролетариат, бу социаль төркемнәр арасында бары тик мәдәнилек дәрәҗәсе белән генә аерыла, аның сыйныф саналырлык милке юк. Хезмәт хакыннан башка бер матди мөмкинлеге дә булмагач, ул үзе белән бергә эшләүчеләрне дә сата ала, бары тик аның үзен генә эштән куа күрмәсеннәр! Пролетариатның Ватаны юк, пролетариат һәрбер илдә дә бар, чөнки ул—тамырсыз, ул—милексез. Бары тик милек кенә кешеләрне берләштерә ала.

Пролетарийлар исә икътисадны оештырырга-булдырырга кирәклек турында уйлап та карамыйлар, алар белемсез, наданнар. Хакимияткә килгән очракта алар үзләре генә бер эш тә кыра алмыйлар. Җитәкче булып алсалар, акырып-бакырып кына җитәкчелек итәләр. Халык хуҗалыгы һәм дәүләт белән идарә итүне буржуаз белгечләр кулына тапшыру да бу очракта коткара алмый. Чөнки пролетарийларның аларга мөнәсәбәте дошмани, шикләнүчән була. Көнбатыш илләрдә исә хакимияткә килгән буржуазия, хәрби диңгез, дипломатия өлкәләрендә үз кадрлары булмаганлыктан, бәреп төшерелгән аристократиянең зыялы-белемле вәкилләрен эшкә тартырга, аларга яхшы хезмәт хакы түләргә мәҗбүрләр. Азмы-күпме үзе дә мәдәни һәм мәгълүматлы буржуазия аларның белемен бәяли белә, үз байлыгының бары тик фәнни һәм мәдәни яссылыкта гына үсә-арта барачагын аңлый. Аз белемле, надан пролетариатка мәдәнилекнең кирәге юк, ул зыялыларны күрәлми, аларга төрле мәсхәрәле кушаматлар тага, "без университетларда укымадык" дип кенә җиффәрә! Белем һәм мәдәнилекнең барлык тармакларында да без дөньяда артта сөйрәлеп килдек, бары тик хәрби мәсьәләләрдә генә алда булдык, аңа чыгымнарны кызганмадык, чөнки анысы коммунизмның бөтен дөньяда җиңүе өчен кирәк иде. Ләкин соңгы вакытларда, коммунистик хакимиятнең ахырында ул да сыната башлады, фәнгә нигезләнеп булдырылган хәрби техника да үсеше өчен иҗади ireклек таләп итә, ә андый ирек коммунистик системада була алмый. Һәр тереклек, һәр җан иясе үзенең үсешен тәэмин итәр өчен ирекле булырга тиеш, бу—яшәешнең беренче шарты бит.

Иң кызганычы шунда ки, пролетариат үз диктатурасын урнаштыргач та ялланып эшләү коллыгыннан котыла алмады. Алай гына да түгел, үзләре "азат итәргә" җыенган башка хезмәт ияләре сыйныфы белән берлектә, "пролетариат хакимияте шушы инде" дип аларны ышандырган коммунистик бюрократиянең тагын да каты коллыгына дучар булды ул. Коммунизмның хәтәрлеге дә шунда, ул кешелек тарихындагы иң зур ялган иде. Төрле диннәр бу дөньяда итагатьле, динле булган кешеләргә генә теге дөньяда оҗмах вәгъдә итсә, коммунизм исә барлык ач-ялангачларга, гарип-горабаларга бу дөньяда ук оҗмах вәгъдә итә. Шунысын да әйтергә кирәк, пролетарийлар, төгәлрәге, алар исеменнән коммунистлар җәмгыятьне "үзләренчә" үзгәрттеләр—милекчелекне бай катламнан гына себереп түкмәделәр, ә үзләренең теләктәшләре булган крестьяннарны да мал-мөлкәттән ваз кичтерделәр, зыялыларның исә асыл

затларын юк итеп яки чит илләргә сөреп, акыл хезмәте белән горурланудан да мәхрүм иттеләр. Шул рәвешле, барысын да пролетарийларга тиң коллар ясадылар. Коммунистларча бу: "фабрика-заводлар—эшчеләргә, жир—крестьяннарга!"—дигән шигарь белән эшләнде. Халык өчен шунысын да әйтик: "черек" зыялыларга бер нәрсә дә вәгъдә итмәделәр. "Үз кешеләр, килешербез", диделәр. Һәм... килештеләр дә! Хәзер зыялылардан да хокуксыз, мескен, хәерче катлам илдә юк...

Фәнни тикшеренүләремнең иң зур казанышы итеп мин, әлбәттә, Россияне бюрократик дәүләт буларак нигезләп, аның гражданнарының милли байлыкларга хуҗа—милек хуҗасы булырга тиешлекләре турындагы фикерләремне әйтер идем. Әгәр чынлыкта шулай булса, кешелек җәмгыяте социаль сыйныфларның таркалуыннан, ярлыларны коллыкка дучар ителүеннән арынып иде, бәлки. Халык ялланып эшләүче коллар булмаска, эшче хуҗалар булырга тиеш.

Дүрт төп фикер:

1. Россия халкының үзенчәлеге шунда ки, ул бөтен ил буенча этник аралашып таралган, милли төбәкләр дә шунда кирә. Шуңа күрә кавем-милләтләрнең табигый байлыкларга хуҗа булу мәсьәләсен гадел итеп ике төрле юл белән чишәргә була. Беренчесе—теге яки бу кавем-халык кайсыдыр төбәктә тупланып яши икән, аның табигый байлыкларга хуҗа булу хокукы да бәхәссез. Икенчесе—төрле кавем-милләтләр буталып-аралашып яши торган төбәк булса, табигый байлыкларга барысы да хуҗа булырга тиеш. Аларның табигый байлыклары—милке үзләре арасында хосусый милек буларак өлешләп бүленер иде. Юк, ул һич тә, колхозлар яки дәүләт милке саналып, хакимият башындагы бюрократ түрәләр тарафыннан үз мәнфәгатьләре өчен генә файдаланмаска тиеш.

Бу мәсьәләне хәл итүнең тагын бер юлы—Россиядә Октябрь түнтәрелешеннән соң милләтләргә Ленинчыл принциптагы җирле мөстәкыйльлек—суверенитет бирү. Ул исә хакимлек итүче түрәләрнең аерылып чыгуга—сепаратизмга юл тотуларына, милли икътисади бар милекне каракларча үзләре генә үзләштерүгә мөмкинлек калдыра. Россия Федерациясенең дәүләт төзелеше теге яки бу төбәктә тупланып яшәүче төрле кавемнәрнең милли-мәдәни мохтариятләренә нигезләнергә тиеш. Ул төбәкләрдә яшәүче халыклар, алар исәбенә русларны да кертеп (!), мөстәкыйль идарә итү хокукыннан файдалансыннар. Ул автономия-мохтариятләрнең үз җирле хакимиятләре—башкаручы, кануннар чыгаручы органнары, суд-мәхкәмәләре булып, үз бюджетлары белән яшәр иделәр. Әгәр дә СССР шундый дәүләт булган булса, ул таркалмас та иде. Инде Россия Федерациясе дә шулай оешса, ничек яхшы булыр иде дә бит... Моның өчен хакимият башындагыларның тоталитарлыктан, башка халыкларны йотып бетерүдән баш тартулары гына кирәк. Әмма акыл җитмәүдәнме, әллә ач күзле комсызлыктанмы, бу гамәл эшләнмәде. Нәтиҗәләре күз алдыбызда...

2. Төп милек—ул җир һәм аның байлыклары. Җиргә милек хуҗасы булу белән калган барлык нәрсәләргә дә хуҗа булу—икесе ике нәрсә. Беренчесенең чикләре бар: җир, тулысынча хосусый милек буларак, беркемнеке дә түгел, ул һәрберебезнеке.

Җир—безгә кирәкле барлык нәрсәләрне җитештерүче, бар итүче бирдәнбер байлык. Аны арттырып булмый, әмма аның уңдырышлы өлешләре табигый бәла-казалар яки аңа ерткычларча комсыз мөнәсәбәтләр аркасында бик нык кимергә дә мөмкин. Кайчандыр оҗмахтай җирләрнең ком чүлләренә әверелүләре шул хакта сөйли. Кешелек Җир шарында һаман ишәя-арта бара. Җирнең кыйммәте дә шуңа күрә арта тора. Әле бит вакыт-вакыт яңа җир асты байлыклары да табыла (алтыны-алмазы, нефте-башкасы). Икътисади кризислар кебек башка сәбәпләр дә юк түгел.

3. Игенчелекнең иң мөһим үзенчәлеге шунда ки, җирне эшкәртү, аннан файдалану аны бары тик яхшырта, уңдырышлы гына итә. Әлбәттә, аңа тиешенчә сак, игътибарлы мөнәсәбәт булганда гына. Җир теге яки бу кавем-халыкның милке, бары тик алар гына аңа катышырга, үз мәнфәгатьләрендә

аннан файдаланырга мөмкиннәр. Әгәр нинди дә булса низаг-тарткалаш килеп чыкса, моны суд-мәхкәмә генә хәл итә ала.

4. Җир базар мөнәсәбәтләрендә дә хосусый милек булып калырга тиеш. Базар мөнәсәбәтләренә корылганда демократик җәмгыятьтә бәясез-түләүсез, бушлайга бер нәрсә дә булмый. Җир дә үзгәреп торучан бәяле милек. Совет хакимияте заманында рәсми рәвештә хосусый милек булып саналмаса да, ул сатыла-сатып алына иде. (Дача-бакча җирләре һ. б.) Җир теге яки бу кешенең мирас милке, аның өстендәге төрле корылмалар-биналар да җире белән бергә сатыла. Әгәр дә җирнең хуҗасы аңардан тиешенчә файдалана алмаса яки баш тартса, ул аны җир банкына базар бәясе белән сатып бирергә тиеш.

***

Югарыдагы фикерләр демократик хокукый дәүләтләрдә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүрешенә карый. Рәсәйдәге чынбарлык һәрвакытта да аның белән ярашып бетми шул.

Шул рәвешле, халык аңына, дәүләтчелек ул иң төп кыйммәтләрнең берсе, дигән төшенчә сеңдерелә. Халык исән калу, тереклек итү өчен бу шартка күнәргә мәҗбүр. Ә башкача нишләсен соң ул?

Бүгенге көндә хәлләр ничек? Мин үткән гасырның туксанынчы елларында, туган якларыма кайтып, шундый манзара күргән идем. Бер-берсеннән берәр чакрым арада ике авыл бар: Кузьминовка белән Федотовка. Беренчесе—урыс авылы, икенчесендә керәшен татарлары яши. Кузьминовкадагы урамнар пычрак, аларны чүп баскан, каралты-куралары киртәләп тә алынмаган, кайбер капкалар бер генә кадакта дигәндәй эленеп тора, ишек алларында юри генә дә берәр җиләк-җимеш агачы күрмәссең. Ә Федотовкада—җанга рәхәт: авыл бай, чиста-төзек урамнар, йортлар каршында чәчәккә күмелгән ян бакчалар, алмагачлар-чияләр, умарта оялары... Шундый ук күренеш Иске Иштирәк, Мөэмин Каратай, Сарабиккол авылларында да. Урыс авылларында искереп беткән йортлар, яңалары күренми дә, чиркәүләр дә бик аз. Ә татар авыллары төзекматур йортлары, арада яңа салынганнары да бар,—таза такта коймалы каралты-куралары, мунчалары, капка төпләрендә утыручы ак яулыклы-альяпкычлы чиста-пөхтә әбиләре белән аерылып тора. Авылларның болай булулары Татарстанга хас күренеш. Хәер, Россиянең башка төбәкләрендәге урыс авылларында да хәерчелек-фәкыйрьлек күзгә ташлана, халык ач-ялангач диярлек, исерекбашлар да күп.

Ярлы-фәкыйрь урыс авылларының юкка чыга баруын, халыкның читкә китәргә омтылышын мин урысларның кайчандыр чит җирләргә яулар чабып күчкән яки күчерелеп китерелгән килмешәкләр булуына, шунлыктан тамырланып китә алмавына да бәйләп карарга тырышам. Ныклап тамыр җибәрергә дүрт-биш гасыр вакыт бик җиткән кебек югыйсә. Әмма юк шул... Урыс ул төп үз җирендә дә, әйтик, "нечерноземьесендә" дә, шундый ук хәлдә яши бирә.

Димәк, башка сәбәпләре дә бардыр. Төп сәбәбе дип мин гади урыс кешесенең бервакытта да хосусый милке булмавын әйтер идем. Шуңа күрә алар тузганак кебек "җиңелләр", аларга "оҗмах кебек җирләрне" эзләп күченеп йөрү берни тормый. "Бу җир әйбәт булмаса, яңасын эзләрбез. Башкалар җире булса, кысыла төшәрләр, теләмәсәләр—куарбыз!" Урысларның буыннан-буынга алга сөргән сәясәте шул бит.

Әмма татарлар да үз туган җирләрендә күптән инде тулы хокуклы хуҗа түгел, шулай да аларда хосусый милекчелек хисе тирәнрәк, тотрыклырак. Ни өчен шулай соң? "Чөнки—дип язган күренекле милләттәшебез Садри Максуди,—төрки халыклар үз тарихларында һәрвакыт күчемле һәм күчемсез милеккә (җир кишәрлекләре, биналар-йортларга) хаклы булганнар". Ата-бабаларыбыздан мирас булып калган төп үз җиребез, үз ватаныбыз бу дигән уй-тойгы, күрәсең, бик тирәндә, күңел төбендә үк ятадыр. Шуңа күрә дә татарлардагы милекчелек хисе, җир хуҗасы булу тойгысы—мәңге онытылмаслык, гомер бакыйлык хис ул.

Урыслар—тамырсыз халык, дидек. Тамырлары үз ватаннарында да юк аларның. Булыр иде дә, гомер-гомердән яулап алу белән шөгыльләнгән дәүләтләре аларны бер яудан икенчесенә куып кына торган. Милке булганнарны алай тиз генә кузгатып булмас иде, ә болар хосусый милексез, бар белгәннәре талау да көчләү генә. Шуңа күрә дә урыслар чирүе һәр җиргә таралган. Шуның өчен дә алар, 1991 елда СССР таркалгач, 25-30 миллионлаган үз милләттәшләрен, күз дә йоммыйча, чит дәүләтләрдә "онытып" калдырдылар, мыскылҗәберләнүләргә дучар иттеләр. Хәзер исә, үз тарихи ватаннарына кайтарырга теләмичә, аларга төрле киртәләр коралар. Ә элегрәк "туган дәүләтләре" кыерсытудан, мохтаҗлыктан интегүчеләр меңләп-йөз меңләп чит илләргә мөһаҗирлеккә китеп бардылар. Әйе, милексез халык—шул ук бомж шикелле ул, аның йорт-җире, нигезе юк, шуңа күрә бөтен дөньяга таралып яшәргә мәҗбүр дә.

Философ С. Франк урыс кешесен "шәрә кеше" дип атый, "аның шәхси хокукы үз тәнен капларга гына җитә", ди. Андый кешенең тормышын тиешенчә көйләп җибәрерлек милке-мөлкәте юк. Ә бит милек кешенең үз-үзенә, башкаларга, даими үсештәге хакимияткә һәм Ватанга булган мөнәсәбәтләрен билгели. Милек, шул рәвешле, аны эшчән итә, үз Ватанының тулы хокуклы хуҗасы, иркен-мул тормышлы шәхес итә.

Урыс кешесенең "шәрәлегенә" сәбәп урысларның меңь еллык тарихына һәрвакыт юлдаш булган, шәхесне котылгысыз изеп торган хәл-вакыйгалардыр. Бу хакта Ю. Н. Афанасьевның "Хәтәр Россия. Бүгенге чикләнмәгән хакимият" дигән китабыннан *(Мәскәү, РГГУ. 2001 ел)* тулырак мәгълүматлар алырга була.

Урыс кешесенең "шәрәлеге" тумыштан киләме, әллә ул социаль-тарихи шартларга бәйлеме? Философ Н. Бердяев та бу сорауларга җавап эзләгән. Ул "урыс күңеле-калбе чиксез киңлек белән имгәтелгән" дигән нәтиҗәгә килә. Дәүләтнең колач җитмәслек җирләргә хуҗа булуы аркасында урыс кешесе аларны буйсындырып-үзләштереп бетерә алмаудан интегә, ул ярдәмгә мохтаҗ. Ул бу эш-гамәлләрне үзәк хакимияткә тапшырырга күнеккән. Әйе, урыс кешесенең күңеле урыс җире, урыс кырлары шикелле үк киң-иркен. Аңарда славяннарча буталчык тәртипсезлек хөкем сөрә. Яулап алынган урыс җирләренең галәмәт зур-чиксез булуы урыс кешесен тәртипсезлеккә, эшсезлеккә дучар иткән, шуңа күрә халыкның тормыш-көнкүреше коточкыч үзәкләштерелгән, шәхси һәм иҗтимагый көчләрнең ирке кысылып, бөтенесе дәүләт мәнфәгатьләренә буйсындырылган. Нәкъ менә шулар урыс кешесенең яшәешен күңелсез-караңгы иткән дә инде. Урыслар шатлана да белми диярлек. Урысның ялкаулыгы, ваемсызлыгы, җавапсызлыгы шулардан килеп чыга. Николай Бердяев "Россиянең язмышы" дигән китабында шул мәсьәләләрне бик тулы шәрехли.

Гомерлек уңышсызлыклар, начар тормыш шартлары урыс аңында бик аздан да канәгать булу тойгысы тудырган. Крестьянның хезмәт белән байлыкка мөнәсәбәте гаять каршылыклы. Ул алар арасында бернинди бәйлелек тә күрми. Байлыкның хакимлек, көч һәм матди муллык китергәнен аңлый ул. Әмма аны намуссыз, гадел булмаган, башкалар хисабына тупланган байлык дип саный. Күренекле рус философы В. Розанов, Россиядә милек, мал-мөлкәт хезмәт куеп алынмый, ул йә бүләк, йә талап җыелган була, дип саный. "Кем аздан да канәгать, аны Ходай онытмас",—ди урыс. Димәк, артык тырышып эшләүдән мәгънә юк, әкияттәге Емеляга тиңләш...

Иманым камил: бу халыкны арка сөяксез, умырткасыз булырга дәүләт өйрәткән. Беренчедән, чит җирләрне яулап-басып алып, үзенекен "бер диңгездән икенче диңгезгәчә" киңәйтүе-зурайтуы аша, икенчедән, күпчелек халыкка хосусый милекче булырга мөмкинлек бирмәве белән дәүләт аны шуңа этәргән. Ә хосусый милек чикләнгәнлекне, киртәләп куюны, кемнекедер булуны сорый, шунсыз ул беркемнеке дә түгел, ул юк дигән сүз. Урысның милеккә, мал-мөлкәткә төкереп каравы аркасында дәүләт үзенә кирәкле әйберләрне үзе җитештерергә мәҗбүр булган. Бу хәл бигрәк тә хәрби сәнәгатьне үстерүдә

ачык күренә. Хәрби сәнәгать комплексы һәрвакыт ил икътисадының "төпсез чуманы" булган. Шуның өстенә тоташ урлашу (казна малын да, бер-берләренекен дә), кеше кайгысына ис китмичә карау, битарафлык, соңгы тиененә кадәр эчеп бетерү, тормыш үзе дә бер тиенлек кенә дип санау... Урыс кешесе боларга бер аек күз белән карап алса, үзенең никадәр мескен, никадәр бәхетсез икәнлеген аңлар да иде, бәлки.

Юк шул... Ул гаепләләрне һәрвакыт читтән эзли, барысы да "гаепле", тик ул үзе генә түгел. Империячел бөеклек чире аның аңына да, канына да сеңдерелгән, аны түрәләр, дәүләт шулай тәрбияләгән. Милексез, мал-мөлкәтсез халык ничек "бөек" була алсын икән?

Ә лозунг-шигарьләр искиткеч мавыктыргыч: "Бетсен хосусый милекчелек! Яшәсен гомуми милек!" Күпчелек халыкның үз милке булмагач, ярлы-ябагайга нәкъ шул кирәк тә. "Бетсен байлар! Яшәсен тигезлек!"—бу "тигезек" дигәне ни-нәрсәне аңлата, ул кайда алып барып чыгар—анысын беркем дә белми, белергә дә теләми. Имеш, ярлы-фәкыйрь булсак та, барыбыз да бертигез, берберебезгә һич көнләшеп карарлык түгел. Без әнә шул хыялдан һич аерыла алмыйбыз шикелле.

Шул рәвешле, Россиянең мәңге төзәлмәслек җәрәхәте, яман шеше булып хәерчелек һәм хокуксызлык кала. Хәерчелек, изге хосусый милек булмау аркасында—котылгысыз, ә хокуксызлык—җәмгыять тормышында дәүләтнең үзен "бөек" итеп санавыннандыр. Соң, милкең, мал-мөлкәтең булмагач, нинди хокук турында сөйләргә мөмкин тагын?

Россиядә чынлап торып алгарыш-үсеш чыганакларын булдырырга кирәк. Шул мәсьәләне чишә алмаса, ил-дәүләт һәлакәткә атлаячак. Үз тарихында инде өченче әйләнеш ясап шунда таба атлый бит ул.

Аның һәр әйләнеше өч адымнан тора. Беренче әйләнештәге беренче адымы—XIX гасырның икенче яртысындагы Кырым сугышы; аннары—урыс-япон сугышы; аннары—империалистик беренче бөтендөнья сугышында катнашу... Боларның өчесендә дә Россия җиңелә.

Икенче әйләнеш—самодержавие коллыгыннан котылырга тырышу: 1905—07 еллардагы һәм 1917 елгы Февраль түнтәрелешләре; "мең еллык урыс коллыгын" 1917 елгы Октябрь революциясе-контрреволюциясе нәтиҗәсендә коммунистик "югарылыкка" күтәрергә тырышу; икенче бөтендөнья сугышына дучар ителгәч, җиңелүгә тиң "җиңү" яулау, чөнки ул дөнья илләренең өчтән бер өлешен диярлек ясалма алгарыш-үсеш юлына—социалистик юлга этәрде.

Өченче әйләнеш—коммунистик тупыйктан чыгарга омтылу: Хрущев "җепшеге", КПССның XX съезды; Горбачевча "үзгәртеп кору"; Ельцинча "реформа" һәм Путин дәвам итә торган торгынлык заманы.

Шулай итеп, соңгы әйләнешне дә түгәрәкләп киләбез. Дәүләтне һәм җәмгыятьне бюрократларча "камилләштерергә" тырышу һаман да бер төрле эшләнә: "китмичә китү" бу шул ук "мең еллык коллыкны" саклап калу омтылышы. Димәк, өченче әйләнештә дә ил-дәүләт һәлакәткә атлавыннан туктамый әле. Кайчандыр Николай Гоголь: "Кая чабасың син, Рәсәй!"—дигән сорау куйган. Рәсәй һаман да һәлакәтенә таба чаба, дип кабатларга мәҗбүрбез: СССР таркалып, ул инде яртылаш кына калды бит. Ә таркалу һаман дәвам итә. "Бозык дәүләт, бозык халык"... Нинди кызганыч хәл...

Россия бөтен кешелек дөньясы алдында һәм үз-үзе алдында гафу үтенеп, тәүбәгә килергә тиеш. Читләр килеп, гөнаһларыңнан арындыруны көтеп утырмаска кирәк, үзең арынып, илнең демократик тарихын яза башлар вакыт җитте.

Төньяк Осетия-Аланиядәге Беслан фаҗигаләре уңаеннан халыкка мөрәҗәгатендә Россия Президенты В. В. Путин: "Көчсезләрне кыйныйлар",—дигән сүзләр әйтте. Бюрократия һәр җиңелүеннән соң яңа терәүләр эзли башлый. Юк, күптән инде "көчсезләрне" түгел, акылсызларны кыйныйлар. Бу бигрәк тә үзен "бөек" дәүләткә санаган илләргә кагыла. Гитлер фашизмының, япон милитаризмының һәм совет коммунофашизмының һәлакәтләре безнең акыллыбашларга сабак була алмады. Хәзер теләсә кайсы дәүләтнең көче—

башкада. Һич тә хәрби һәм җәза көчләрең яхшы булуда түгел ул. Аннары, Россия әле алай ук көчсез илләр исәбенә дә керми. Һәрхәлдә, җитәкче түрәләр башкачарак фикердә. Ә менә түрәләр һәм җәзалау органнарын арттырып, аларга зуррак хокуклар биреп кенә дәүләтне нығытып булмаганлыгын аңларга акыл җитми. Хәзер Россиядәге бюрократ түрәләр саны элекке СССРдагыдан да өч мәртәбә диярлек артык. Аларны терәтеп кенә череп беткән бинаны саклый алмыйсың. Аның арка умырткасын яңартырга кирәк. Һәр дәүләтнең арка умырткасы—үсеш-алгарыш субъектлары булган милекчеләр сыйныфы җәмгыяте ул. Моны аңлау өчен илнең өч гасыр буе түбән тәгәрәү тарихы җитми микәнни соң?

Ил җитәкчелегенең халык белән мәче-тычкан уены уйнавы гаҗәпләндерә. Президент В. В. Путин 2005 елның 25 апрелендә Федераль җыенга юллаган мөрәҗәгатендә чынлап торып болай ди: "Без илне эшлексез һәм сатлык түрәләр кулына тапшыру ниятендә түгелбез". Инде Ленинның "безнең иң начар эчке дошманыбыз—бюрократ" дип раславын гына кабатлыйсы кала. Аның "Совет власте һәлак була-нитә калса, сәбәпчесе бюрократизм булыр" дигән сүзләре тормышка ашты бит. Баш түрәнең үзенә буйсынган башка түрәләргә шундый ямьсез бәя бирүе әйбәт, әлбәттә. Аның бу сүзләренең азмы-күпме файдасы да булыр бәлки. Бер генә нәрсә борчый: Президентның әлеге сүзләрендә яшерелгән фикер дә бар—халкыбыз акыл ягыннан бик үк камил түгел. Билгеле, без юләр халык, чөнки безне төпсез чанага утырткannar. Әмма илгә кемнәр хуҗа, ә кемнәр үзен дә яклый алмаган томана икәнлеген генә аңларлыгыбыз бар әле. Хөрмәтле Президент әфәнде, кадерле Владимир Владимирович, без сезнең белән илне һич тә ул түрәләр кулына бирмәс идек, әгәр дә ул сүздә генә түгел, чынлап та безнең кулда булса. Хикмәт шунда ки, Россия халкы күптән инде теге мәзәктәге мужик хәлендә. Хәтерлисезме, ул иптәшенә кычкыра: "Аю тоттым!"—ди. Ә иптәше: "Бире китер!"—ди. "Бик китерер идем дә, җибәрми бит!" Россия дә әнә шул "эшлексез һәм сатлык түрәләр", ягъни "аюлар" кулында ич.

Хакимлек итүче түрәләр халыкка аның җирен-суын, калган барлык байлыкларын—кыскасы, күчемсез һәм күчемле милкен һич кайтарып бирмәячәк. Халык чит-ят хакимият тарафыннан яулап алынган халәттә хәзер, ул—ялланган кол, ул үсеш-алгарыш көче була алмый, димәк, аның киләчәге дә юк. Россия хакимиятенең гомер-гомердән килгән бәласе дә, гаебе дә шунда ки—түрәләр үзләре идарә итә торган җәмгыятьнең асылын белмәгән, белми, белергә дә теләми. Россия халкы дигән томананың томаналыгына исәп тотып кына әлләни ерак китә алмаслар шул.

Россия—табигый булмаган корылма: җәмгыяте дә, аны йоткан дәүләте дә ясалма. Аның өстен сыйныфы очраклы рәвештә властька вакытлыча үрмәләгән социаль катламнан тора. Бюрократия өстен сыйныф буларак идарә итә икән, андый дәүләт табигый түгел, ул ямьсез, ялган дәүләт. Һәрхәлдә, ул Гареп һәм Шәрыктагы дәүләтләрдән күп еллар-гасырларга артта калган. Ул, үзенә хас булмаган социаль һәм икътисади максатларны хәл итәргә алынып, "койрыгын алса—борыны ябыша, борынын алса—койрыгы ябыша" торган кош хәлендә калган.

Бик аяныч хәл...

**Редакциядән:**

***Мәскәүдә яшәп иҗат итүче милләттәшебез Әгъдәс ага Борһановка шушы айда 85 яшь тулды. Аны олуг юбилее белән тәбрик итәбез, сәламәтлек, уңышлар телибез.***

*Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

**Хәйретдин ВӘЛИ**

### “ЯҢАЛИФ” һәм әдәби мирас

Без “әдәби мирас” дип бу урында гарәп хәрефе белән басылган әдәбиятыбызны әйтәбез. “Яңалиф”кә күчкәндә гарәп хәрефе белән басылган әдәбиятыбызга мөнәсәбәт ничек булыр? Бу мәкаләдә мин шуңар тукталам. Гарәпчеләрнең һәр чыгышларында яңалифчеләргә каршы куйган бер пункты, үзләренчә иң көчле бер пункты—“гарәп хәрефе белән басылган әдәбиятыбызны югалтабыз” мәсьәләсеедер.

Гүя латинчылар элекке әдәбиятны бөтенләй ташлыйлар, имеш. Ибраһим Биккулов шикелле ялкынлы гәрәпчеләрчә әйтсәк, “безне бабаларыбызның мөкаддәс мирасларыннан мәхрүм итәргә телиләр”, имеш. Бу үткәндәге бер чыгышны хәтерләтә хәтерләтүен. Консерваторлар да бит пролетариат властьне алган вакытта: “пролетариат властьне алгач үзенең тупас куллары белән культураны җимерер, тупас аяклары белән әдәбиятны таптар...” дигәннәр иде. Бу чыгышлар да әзерәк шуңар ошый ошавын... Чынлап та, яңалифчеләр гарәп хәрефе белән язылган әдәбиятны ни эшләтү уеңдалар. Яңалифчеләр бу мәсьәләгә ничек карыйлар? Алар чынлап та гарәп хәрефе белән язылган әдәбиятыбызны искә алмыйлармы?

Билгеле, яңалифчеләр гарәп хәрефе белән басылган әдәбиятыбызны архивларга төяп куярга җыенмыйлар. Шулай ук аны шул көе гарәп хәрефе белән язылган хәлендә калыр, аңар һич игътибар булмас, аның кирәге юк дип тә уйламыйлар.

Үткән мәдәниятнең һәрбер җимешен кадерләп саклау һәр аңлы кешенең бурычы булырга тиеш. Татар массасы латин хәрефенә күчү белән элекке әдәбияттан аерылачак түгел. “Яңалиф” гарәп хәрефе белән басылган әдәбиятыбызны яңадан латин хәрефе белән басып чыгуны алдына куя. Безнең капитализм чорында басылган әдәбиятыбызны китап мәйданында бөтенләй юк та инде*. Без аларны барыбер латин беләнме, гарәп беләнме басу мәҗбүрияте алдында торабыз. Болар әнә шул яңадан басылганда безненчә—яңалифчеләрчә, латин хәрефе белән басылырга тиешлеләр. Әлбәттә, бу эш бер плансыз эшләнмәс, житди бер план белән эшләнер. Кайсыларын күчерергә, кайсыларын икенче планга калдырырга—башта менә бу мәсьәлә чишелеп куелыр. Беренче моментларда бөтен әдәбиятны берьюлы латин хәрефенә күчереп чыгу алга куела алмас.

Әлбәттә, гарәптән латинга күчерү мәсьәләсендә икътисади як та зур роль уйнар. Икътисади як, производство күтәрелгән саен без дә бу юлдагы хезмәтне, латин белән басып чыгару хезмәтен күтәрә барырбыз. Кирәк аң-белем әдәбиятын, кирәк матур әдәбиятны латин хәрефенә күчереп басып таратуда хронология методын куллану ярап бетмәс, феодализм чорыннан башлап күчерә алмабыз. Бездә бу эштә шушындый метод тотарга кирәк булыр: иң элек хәзерге социальный тормыш өчен кайсы әсәрләр иң кирәк, иң зарур—шулар беренче урында торыр. Әдәбиятны латин хәрефенә күчерүдә хәзергедән үткәнгә таба бару методы кулланырга тиеш булыр. Дәреслекләрне латинга күчерүдә аеруча әһәмият биреллдеге *(бирелгән)* хәлдә, әдәбиятның бер тармагын башта күчереп, аннан икенче тармагына керешү методы куелмыйча, бәлки әкеренлек белән һәр бүлемнән күчерелү планы тормышка ашырылырга кирәк булыр.

Безгә матур әдәбиятны латинга күчерүдә классикларга зур урын бирергә кирәк булыр. Латинчылар тарихның үткәндәге файдалы эшләрен тәкъдир итәрләр, дошманлык тоту сукырлыгыннан азат булырлар.

Инде бу үткәнне латинга күчерү хезмәте күпмегә тартылыр соң дигән сорау килергә мөмкин. Башта шуны әйтергә кирәк, латинга күчкәч бездә полиграф эшләре техника, индустриянең иң югары күтәрелгән урыннары Яурупа, Америка мәмләкәтләрендәге кебек иттереп куярга киң юл ачыла. Шунлыктан без гарәп хәрефе белән чыккан әдәбиятыбызның иң кирәклеләрен сайлап алып латин хәрефе белән басып чыгару эше тиз барачак дип хисаплыйбыз.

*(Яңалиф.–1927.–№ 1).*

---

* Бу җөмлә журналда шулай буталчыграк басылган. – *Р.Мәрданов.*

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

**Зәет Мирзануров**

# ТОЗСЫЗНЫ КҮЗСЕЗ ДӘ КҮРӘ...

*Ышанмагыз, бабай Сәйдәш надан ул,*
*Түгел надан гына, анларга хан ул!*
Габдулла Тукай

Безнең авылның Мөбарәкша бабай улларына әйтә торган булган:

—Өйләнегез, мөселманнарны арттырыгыз! Әмма хатын-кызга артык таләпләр куймагыз, онны камыр итсә—шул хатын. Бик ышанып та бетмәгез: күрше түбән авылга төшәсегез булса, югарысына менәм диегез, каршыгызга кеше чыгарып үтертергә мөмкин.

Бәлкем журналистларга һәм язучыларга да артык олы таләпләр кую, һәртөрле дискуссияләр кору зарурлыгы юктыр? Чабата үргән сыман әзер калыпка куып, татарча җөмләләрне хатасыз төзеп нәрсәдер яза икән—димәк язучы! Амебаны амебача хәрәкәтләнүе, черкине черки булып безелдәве, карганы исә былбыл булып сайрамавы өчен гаепләү, житмәсә шундый сайрауга өмет баглау—бу жинел акыллылык түгелме?.. Ә бәлкем каләм тибрәтүче намусына тукыну да кирәкмәс матавыктыр, чөнки анын да май яккан, уылдык сыланган ипи ашыйсы килә, ә хакыйкатькә юл яручыга, вөждан белән хисаплашучыга тәм-томны бик тәтетмиләр... Язучылык—талантлылар юлы, имеш. Ә бит талантны гыйбадлар мәхәббәтен яулауга гына хезмәт иттерү күпкә отышлы. Гыйбад дигәндә гадиләр белән беррәттән зур кәнәфи биләүчеләр дә күздә тотыла, әлбәттә...

Каләм ияләренең олуг гыйбадлардан алган интервьюларын укыганда мондыйрак картина күз алдына баса. Имеш ки бәгъзе каләмзат дустыбыз түше белән шуышып яисә мүкәләп арт яклап түрәнең башмаклары арасына килеп керә дә, муенын өскә таба бора һәм елмая төшеп, психиатрия хастаханәсе пациенты да дөрес җавап бирерлек катлаулылыктагы, "ике икен дүрт була, шулай бит Фәлән Фәләнеч, сез бу хакта ничек уйлыйсыз?", тибындагы "сорауларын" бирә... Хезмәткә багышланган мәкаләләре исә нигездә һаман былтыргы "А", охшаш эчтәлектә, геройлар һәм алар яшәгән төбәк исемнәре генә үзгәрә...

...Журналда, игълан ителгән дискуссия кысаларында исә, ни гаҗәп, әңгәмәбез шактый кызыклы, мәгънәле һәм эчкерсез бара. Әмма, гаделлек хакына искәртергә телим, Миргазиян Юнысның 2003 елны Татарстан китап нәшрияты чыгарган "Альбатрос язмышы" дигән китабы дөнья күргәч үк мондый анлашунын башланырга хакы бар иде. Анда әлеге автор безнең дискуссиядә янгыраган фикерләрнең байтагын күтәрде бит. Менә берсе: "...Социалистик реализм илле елдан артык әдәбиятка юл

күрсәтеп килде. Татар әдәбияты дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган Матросовлар, Ардуан батырлар, дөнья күләмендә беренче урынга чыккан сыер савучылар белән тулды..."

Зур язучыбызның фикерләрен каләмзатларыбыз колакка эләргә ашыкмады микән, һәрхәлдә алар, шахта, ә бәлкем цирк атларына ошапмы, иске юлдан, әллә түгәрәктән микән, тайпылмадылар, һәм шуна, әлеге фикерне тагын да үтемлерәк итеп, Айдар Хәлим, дискуссия кысаларында кабатларга мәҗбүр булды. Әмма әлеге шәхесләрнең фикерләре гелән унисон яңгырый дип булмый. Мисалга, Миргазиян ага маскульт укучылар тәрбияләүче жанр—детективларны әдәби журналга якын җибәрмәү ягында. Ә Айдар Хәлим, киресенчә, андый авторларыбызны Рауль Мирхәйдәровтан түбән куюга ризасызлык белдереп яклый, хәтта ки мактап чыга, бик күп шундый, һәм башка авторларның әллә ни резонанс тудырмаган әсәрләренә дә журнал битләрендә тәнкыйди анализ ясалмауга ризасызлык белдерә... Ачлык мәйданнары кичкән, утлы күмердәй кулны пешерә торган китаплар язган язучыбыз өчен шаянлык та ят нәрсә түгел, әлбәттә, бәлкем ул, үзе әйтмешли әйбәт "провокация"не күздә тотып, яки тәнкыйтьчеләр өчен даими мәйданга ирешү максатында кызыл армияче тапкырлыгы күрсәтепме, шундый бәхәсле фикерен тәгәрәткәндер? Әгәр мөхәррият шул җимгә чиртсә, кеткелдәп көләргә исәпләгән булуы да ихтимал... Сүз дә юк, Миргазиян агай мең кат хаклы: урысның әдәби журналлары детектив ише укымлыкларга юл бирми, әмма аудиторияләрен катастрофик тизлектә югалта бару шартларында татарча гәҗит-журналларыбыз, үз-үзләрен саклау инстинктына буйсынып булса кирәк, маскульт (китч) әсәрләргә мәйдан бирә, һәм моны бәлкем ничарадан бичара дип аңлап, гафу итәргә ярыйдыр. Шулай ук русча язучы милләттәш язучыларның мөхтәрәм журналыбыз ярдәмендә татар әдәбиятына интеграцияләнүен хуплыйм. Моңа карышучы "үз" язучыларыбыз аршыннарыннан, калыпларыннан ардык бит инде, җитмәсә һәммәсе бертөрлерәк уйлый, тик әйтүләрендә генә аерма бар, кайсы ярсып бәян итә, ә кайсы басынкы... Күбесенең нәрсә хакында ни әйтәсен укымый да белеп була башлады. Ә тегеләр үзгә чишмәдән, бүтәнчәрәк ноктага басып уйлыйлар һәм тасвирлыйлар... Һәм әлбәттә, Мансур Вәлиев хаклы: Рауль Мирхәйдәров белән ярышырлык детектив язучылар бездә юк һәм моның объектив сәбәпләре дә бар.

Төбенә чүп-чар, ләм утырып, суы саега, агымы әкренәя, өслегенә чирәм чәчәк ага башлаган татар әдәбияты атлы дәрьябызның алкынлыгын кайтару өчен тәнкыйтьчеләргә күп хезмәт түгү фарыз. Айдар ага Хәлим үз язмасында, әлеге дәрьяның үзен генә түгел, шуның бассейнына туры килгән һәр ермакны да җыртып чыгарга тырышкан. Барча куяннарның койрыгын берьюлы тоту нияте ничек барып чыккандыр, әмма аның максималистлыгы барыбер хуплауга лаек. Журналның ике санында дөнья күргән хезмәтен, әдәбиятыбызны коткару буенча үзенә күрә бер манифест дип тә карап була, минемчә... Әмма аңа тарафдарлар табылырмы? Хәтта шушы дискуссия кысаларында да сүз чүбе белән дәрьябызны тагын да саектырырга тырышулар тукталып тормады бит.

Моннан күп еллар элек тамак шешеп хастаханәдә ятарга туры килгән иде. Стенадагы репродуктордан бер союздаш республика җитәкчесенен чыгышын тыңлавыбыз истә калган. Шулкадәр итеп мактый бу генераль секретарьны, ничек сүзен, эпитетын табып бе.ерә, исләр китмәле. Палатадашым, зур гына оешманың баш бухгалтеры, эре гәүдәле агай түзмәде, урыныннан торып, зур кызыл телен чыгарып, ялманган хәрәкәтләр ясап:

—И, тәмле, и, тәмле!—ди-ди палата буйлап йөренергә керешге. Коньяктагы республика җитәкчесенең ялагайлануын ул шулай гәүдәләндерде.

Ә әдәби тәнкыйть жанрыбыздагы шуна охшаш хәл белән нишләргә??

Мактау мәкаләсе—тәнкыйть, мактаучы—тәнкыйтьче дип атала башлавына, ягъни фальсификациянең шушы төре яралуына инде байтактан бит. Мактауга корылган шундый язмаларны туплап, анализлап, әйткәндәй, уртак ваклаучыга китерсәк, нәтиҗә сыйфатында, теләсә кемгә багышлап шундый мәкаләсе язу өчен хезмәт итәрлек үрнәккә ирешербез... Башламы—татар әдәбиятының үткәне турында гомуми сүзләр, казанышларыбыз хакында күптән калыпланган җөмләләр, оя-оя

язучыларның һәм аларның әсәрләре исемлеген язып, кайберенә тез йөгенеп, кайберенә сәлам биреп узу. Исән түгелләренә тибеп тә үтү гаеп саналмый. Урталыкта мәкалә героеның исеме һәм әсәре өчен буш урын калдырасың һәм аны да мактыйсың, җөмләләренне "ассоциатив фикер ията", "кызыл җеп булып сузыла" кебек әзер очламнар белән чачаклыйсың, иҗаты якты, нурлы, фәләнне төгән белән синтезлаган дип җиффәрәсең. (Мондый эчтәлекле мәкаләләргә, әйтик, филология фәннәре кандидатлары һәм докторлары рәхәтләнеп имза сала дип беләм.) Һәм шушындый макет-мәкалә (мокыт-мәкалә дип укылуга да каршы түгелмен), әдәбиятыбызның киләчәгенә өмет баглауны аңлатучы гомуми сүзләр белән тәгәлләнә. Закончалыклы уртаклыкларга таянып, әлеге тип язмаларны әзерләүдә житештерүчәнлекне тагын да арттыру максатында, компьютерга программа төзеп кертергә дә була... Бәлкем алар инде бардыр һәм язучылар, журналистлар әзерли торган уку йортларында уку әсбаплары рәвешен дә алганнардыр.

Мәкалә башында телгә алынган Мөбарәкша агайның бер оныгы, минем яшьтәш болай ди:

—Теләсә кайсы инженерны ике ай укытып экономист ясап була, ә экономистан, ике ел укытып та инженер чыгарып булмый,—ди. Бәлкем әдәбиятыбызга язу күәсе булган бүтән өлкә белгечләрен рекрутлап, әдәби курсларда укытыргадыр? Бу ысулга эчке эшләр министрлыгы мөрәҗәгать иткәләде һәм халык хуҗалыгыннан килүчеләр үзләрен эш белән җинаятьчелеккә каршы көрәшү өлкәсендә расладылар, зур уңышларга ирештеләр дип ишеткән бар. Кайсыдыр рус гәҗитендә: журфактан рәтле журналист чыкмый, ин шәпләре КАИдан чыга дип тә яздылар...

Мәгълүм ки, инженерлар проект төзи, проект белән эш итә. Ә проектта, салынасы объектның кирәклеге техник һәм экономик яктан нигезләнә, нинди вариантның отышлылыгы дәлилләнә, аны тулаем күз алдына китерерлек күләмдә сызымнар, эшне башкарып чыгарыр өчен кирәкле сумма каралган смета, кайтартылырга тиешле материаллар һәм җиһазларның күләме, маркалары, ташу ераклыгы һәм башкалар бәйнә-бәйнә тәгаенләнә. Инженер белеменә ия укучы язучылар яки журналистлар язган язмаларны укыгач та, үз күзаллау тәҗрибәсеннән чыгып, бәй монда бит өстән яки яннан (арттан) караш кына, ә кайда перспектива, кайда аркылы, буй киселеш, әһәмиятле төеннәрне аерып, олайтып күрсәтү, бу вакыйганы хәрәкәткә китерүче чыганак нидән гыйбарәт кебек сорауларга җавап тапмый. Табиблар да, бүтән профессия вәкилләре дә табалмый тилмерә үз сорауларына җавапны милли басмалардан. Нәтиҗәдә татар әдәбияты һәм журналистикасы үз укучыларын һаман югалта тора. Нигездә татар язучылары һәм журналистлары язганнарны укый торган бердәнбер тугъры интеллигенция вәкилләре булып авыл укытучылары торып кала. Чөнки алар әлеге каләм ияләре белән рухташрак, бигрәк тә бер өлеше, татар теле укытучылары; үзләре дә кайчандыр язучы яки журналист сукмагын сайлап азапланганнар, белемне бер альма матердан эстәгәннәр, мөгаллимнәр уртак...

Һәм татарның каләм ияләре, үзләренең язмаларында, әйтик болай да рәнҗетелгән шул укытучылар, ягъни үзләренең затлыраклардан булган соңгы могикан укучылары адресына, тупас сүзләр ычкындырырга, "надан" дип гаепләргә (мондый хәлләр булды), телетапшыруларга килеп, "без халык тәрбиялибез" дигән дәгъва белдерергә җөрьәт итәләр. Кемнәр соң бу, үзләрен алланың кашка тәкәләре дип санаучылар, каян чыкканнар? Әдәбиятыбыздагы уңышларны барлаганда бик тә зурлап КДУның татар бүлеген телгә алабыз. Уңышсызлыкларны ачыклаганда да онытмыйк аны. Урта мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең олимпиадаларда җиңү яулаган каймагы киләме бу бүлеккә? Бәлкем бу бүлектә уртача сәләткә ия абитуриентларны Әбугалисинага әйләндерерлек куәткә ия белемнәр биреләдер? Ә бәлкем язу сәләте булган яшьләр биредә нидер табу белән бергә, нәрсәдер югалталардыр?

Дискуссиябез кысасында басылган КДУ галиме Әлфәт Закирҗанов мәкаләсен күздән кичерик. Автор, репертуар белән таныштыру йөкләнгән театр агенты кебек күп драматургларны телгә ала, әсәрләренең кыскача эчтәлекләрен сөйли һәм барысын да "бишлелек" дип бәяли. Татар әдәбияты дәресләрендә укучы балалардан әсәр һәм язучы турында да шушылайрак сөйләтәләр. Автор белән йөз процент килешмәскә рөхсәт итегез.

Алыйк Мансур Гыйләҗевнын "Бичура"сын. Иң элек әсәрнең татарлар турында булуы ышандырмый. Татар—ул үлгәнче эшли торган кавем, ә болар сүлиләр дә сүлиләр... Авылга кайткан хатыннар да, безнең милләттән булсалар һич югы тизрәк өй юарга керешергә тиешләр иде. Ә болар җәелеп утырып тәк такылдауларын белә... Мина калса, әсәр урыс-марҗа тормышыннан һәм ул рус театрларын күздә тотып язылган, әмма алучы таба алмагач, татарчага тәрҗемәләп Камал театрына "кияүгә биргәннәр" шикелле тоела. "Казан егетләре" дә урыс театры өчен язылганга ошап тора. Беренчедән, студент егетләрнең эчкән баштан кызыклы ситуациягә эләгүләреннән Эльдар Рязановның "Иронияce..." исе килә. Рус өчен эчү гаеп эш түгел. Ә татар өчен бүтән ситуация табу кулайрак булыр иде... Янә килеп авылда егетләрнең эчеп үлеп бетүләре, анда кызлар гына торып калуын алыйк. Рус мохиты өчен бу аңлатма бәлкем житкелекледер? Ә татар авылларында фактта кызлар юк, ә егетләр көтү-көтү. Ләкин төп хикмәт монда да түгел, әсәр бит комедия, авторның ситуацияне астын-өскә әйләндерергә хокукы бар. Әмма кай төшендә көләсе соң бу әсәрнең? Камал театры сәхнәсен шундый спектакльләр дә биләде дип, каһкаһә беләндер бәлки?

Туфан Миннуллинның автор күкләргә чөйгән "Хушыгыз"ын алып карыйк. Героиня безнең мәшһүрәбез—башта жырчы, аннары композитор булып дан казанган, бернинди кыенлыкларга бирешмәгән, халкыбызны өзелеп яраткан, аннан бернинди әҗер дауламый бары хезмәт иткән, шуны бәхет санаган Сара апабыз Садыйковага тамчы да ошамаган. Ул кемнәргәдер үпкәле. Социалистик реализм кысаларында режимга тугры хезмәт итеп тә "жимле тагарак"тан коры калдырган хакимият һәм хәтта халык адресына да үпкә янгырый бу әсәрдә. Имеш, кадерен белмиләр... Ханым—бисмилласыз кеше. Халкыбыз гореф-гадәтләрен тотмый. Хәер, профессиясенә тугрылыклы, хәтта үләр алдыннан да роль уйный һәм без, тамашачылар, моңа сокланырга тиеш. Аны күмүнең исламча уздырылуына бер ишарә дә юк, хәтта киресенчә... Һәм шушындый әсәр табышмы? Әлеге проблема уңаеннан драма урынына мәкалә язу урынлырак булмас идеме соң?

Ә менә шушы ук авторның "Диләфрүзгә дүрт кияү" әсәренә карата бер газета аша Зөлфәт Хәким тарафыннан әйтелгән тәнкыйть белән тамчы да килешәсе килми. Зөлфәт Хәким Диләфрүзнең иң хәлсез егетне сайлавын авторның, йомшартып әйтсәк, житешсезлегенә кайтарып калдыра. Ә минемчә, Т. Миннуллин үзе дә авыл егете буларак "үз авылы патриоты" һәм ул кызны чит авыл егетенә "ятларга" биреп җибәрүне өнәми. Аның мондый патриотлыгы авылда үскән һәркемгә, шул исәптән миңа да якын, әсәрне ул авыл егете булып язган һәм барысы да нәкъ егетләрчә килеп чыккан да!

Закиржанов телгә алмаган, кырыс жюри иләге аша узып беренче урынны яулаган "Телсез күке" (Зөлфәт Хәким) хактан да камил әсәр һәм аның куелуы Камал театрының киләчәге өчен борчылуларны баса төшә...

Дискуссия барышында татар прозасындагы икенчеллек турында да сүз булды. Ә кайда икән ул икенчеллекнең чишмә башы? Бәлкем кириллица көчләп тагылу зыйһенебезгә суккандыр? Әйдәгез сүзне баштан, нигездән, татар теленең имля кагыйдәләреннән үк башлыйк әле. Гамәлдәге кагыйдәләр буенча чит телдән, беренче чиратта рустан кергән алынма сүзләр русча янгырарга тиеш (революциягә кадәр андый хурлыклы кагыйдә булмаган, әйтик, "гостинец" дигән сүз татар телендә "күчтәнәч" булып яңгыраган) һәм шул максатта татар алфавиты татар теленә гел кирәкмәгән хәрефләр асрарга мәхкүм ителгән. Икенчеләй әйтсәк, гамәлдәге имля кагыйдәләре бер телнең икенчесенә тез йөгенүен, коллык итүен тәэмин итә... Әлбәттә мондый хәлдәге телне дәүләт теле дәрәҗәсенә менгерү мөмкин түгел. Ә татар теле галимнәре бу хәл белән ризалашкан. Ник алай икәнен аңлау өчен артык киң маңгай кирәкми, татар һәм рус теле грамматика китапларын янәшә куеп, чагыштырып карау да житә. Галимнәребез татар теле имля кагыйдәләрен рус теле кагыйдәләренә куеп "ижат" иткәннәр түгелме? Бөтенләй дә татарча янгырашка ирешмәгән, кургаштай авыр, очына чыкканда башында ни хакында сүз барганын оныттыра торган кушма җөмләләрдән төзелгән тимер-бетон кагыйдәләрне бәлкем уңышсыз тәрҗемәләр дип аңларгадыр? Бит татар теленә кагыйдә "ижат" итүчеләр рус телендәге аталышларның байтагын татарчага күчерергә дә иренгәннәр. Укыгыз татар теле

имля кагыйдәләрен—ул беренчедән татар теле грамматикасы дип атала, тыныш билгеләре—пунктуация, жөмлә, ижек, аваз тѳзелеше—синтаксис, морфология, фонетика дип тәгаенләнгән. Анда хәтта, кем әйтмешли, "о, туган тел!", синтаксик синоним дигән билгеләмә бар! Татар телендә укучы балалар инша һәм бәян түгел, ә сочинение һәм изложение язалар... Алыгыз кулыгызга татарча-русча (һәм киресенчә) сүзлекләр, анда абажур-абажур, синтаксис-синтаксис кебек әйләндерелешләргә юлыгырсыз. Тел галимнәребез үзләрен филологлар дип атый, һәм минем карашка, татар әдәбиятындагы икенчеллеккә нигезне иң әвәл татар теленең телче галимнәре имля кагыйдәләре аша кодлаштыралар... Ниндидер аборигеннарның телен үз халкы вәкилләре аңласын өчен колонизаторлар яки колонистлар гына шушы ысулда мондый дәреслекләр яза ала. Әмма андый дәреслекләр аборигеннарның үзләре өчен кулланма була алмый. Ә татар галимнәре шул эшләнмәләрен туган телдә белем алучы балаларга адреслый!.. Әлбәттә мондый әсбаплар бәлкем татар телен өйрәнергә теләүче ятлар, һәм телне белмәүче үз милләттәшләребез өчен кулланма була аладыр. Әмма татар телен белүчеләр өчен бүтән китап кирәк). Телебезнең шушындый хәлгә куелуы, ятлардан куып "фәнни хезмәтләр" калыплау өчен генә кулай һәм латинга күчүдәге тоткарлыкны да шушы "белгечләр" тикмәгә генә китереп чыгармады. Ил, халык үз каһарманнарын белергә тиеш, закон проектын әзерләүне ун елга сузып, әлеге канунны кире кагарлык Дума депутатлары килгәнче латин хәрефләренә каршы "героик" оборона тотучыларның тулы исемлеген бастыру сорала.

Янә бер галимә Дания Заһидуллинаның "Безнең заман герое" дискуссиясе рубрикасы астында 2004 елның 10 санында "Унай герой югалу: сәбәпләр, нәтижәләр" дигән язмасы дөнья күрде. Марк Твенның "Мин ничек авыл хужалы газитен редакцияләдем" дигән хикәясендә төп герой кабак турында яхшы белә. Һәм ул нинди яшелчә турында язарга туры килсә дә, башта аның кабакка ошаган билгесен табып күрсәтә, аннары "ә кабак" дип белгәннәрен бәян итә. Әлеге автор да "каеннан балан жыеп булмый, усакны яна елга бизәк итеп бастыру мөмкин түгел" кебек дәлилләр китерә дә, бәхәсебездә күтәрелгән төп проблеманы "һаман социалистик реализмга хас сыйфатлар эзләп, башка кануннарга нигезләнеп язылган әсәрләрне үзебезгә мәгълүм ноктадан карап кына бәяләүне" дәвам итүебезгә кайтарып калдыра. М. Кәбировның "Сары йортлар сере" әсәрен шул позициядән торып мактый һәм яшьләрнең португал язучысы Коэльо язган "Алхимик"ны нишләп яратуларына үз аңлатмасын бирә...

"Булат абый ачуланма, мин надан кеше",—ди "Зәнгәр шәл" драмасының бер персонажы. Галимәбез дә ачуланмасын иде, чөнки танырга тиешмен, әдәбият фәне өлкәсендә мин дә надан кеше. Әмма "тозсызны күзсез дә күрә" дигән мәкаль бар һәм күзгә бәрелеп торганын гына әйтмәкчемен. Иң әвәле шунысы мәгълүм булсын: М. Кәбиров әсәренең шәплеген "кадими" ысулны куучылар да инкарь итмәде. Дискуссия барышында модадагы яңа ысулларны телгә алып тормау, аларны һичкем аңламый дигәнне аңлатмый, ә мөһимлеге дәрәжәсен генә тәгаенли. Автор усак белән чыршыны чагыштыргач, Бауман урамында капма-каршы ике бина бар, берсе—матбугат йорты—конструктивизм, ә каршыдагысы—Париж күлмәкләре сата торганы—модернизм стилендә ди. Шуннан этенеп, яңа ысулда язганда геройның булуы мәжбүри түгеллеген әйтә. Беренчедән, һәр ике бинага да нигезне, фундаментны модага таянып түгел, ә шулар урнашкан жирнең геологик киселешеннән чыгып, ныклык тәэмин ителерлек дәрәжәдә булганын сайлаганнар. Икенчедән, ике очрак өчен дә каркас ныклыгы һәм тотрыклылыгы хәл ителә. Һәр икесенә кирәкле коммуникацияләр уртак таләпләрдән чыгып ялгана. Бинаның һәр икесе дә жылы тотарга, түбәсеннән су үткәрмәскә, тәрәзәләре тиешле табигый яктылыкны уздырырга тиеш. Мәкалә озын язылган һәм галимәдән үрнәк алып эш иткәндә бина котлованын казу турында гына да күп сөйләргә була. (Аны ничек, нәрсә белән киртәләү, жирнең геологик киселешен ачыклау, грунтның группасы нинди, казу өчен кулланылучы техникалар исемлеге, анда катнаша торган эшчеләрнең рәзрәте, котлованнан чыккан балчыкны кая куюу, моның өчен нәрсәләр хәл итү, һ. б., һ. б., һ. б.) Әмма озын озакка сузмыйк дисәк, теләсә кайсы бина күтәргәндә дә төп уртаклыклар үзгәрми. Ә аерма, нигездә, бизәлештәге төрле

формаларда, уртак таләпләргә җавап бирерлек яңа материаллар файдалануда һәм дизайнда. Әдәбиятта да—иске ысулда язылама ул, яңачамы—төп принциплар, намус, вөҗдан, кешелеклелек, гомумкешелек кыйммәтләре сакланырга тиештер дип анлыйм... Әсәрдә төп герой аламы ул йөкне, әллә модага кергән яңа ысул нәтиҗәсендә ул вазифа автор, хикәяләүче җилкәсенә каламы—барыбер: чын әдәбият—Кеше турында. Ә "Алхимик" әсәренең төп герое, Дания ханым язганча, сарык көтүче генә түгел, ул шул көтүнең хуҗасы, милекче ягъни, сәях җанлы ирекле кеше. Егет үз юлыннан хәтта мәхәббәте хакына да чигенми, аны, барлык каршылыкларны җиңеп азагынача үтә һәм аннары гына сөйгәне янына ашыга. Әсәр безнең бабайлар да мәдрәсәләрдә укыган гарәп хикәятенә таянып иҗат ителгән, ә төп герой бик тә сөйкемле килеп чыккан. Безнең тормышта бармы андый герой? Бар! Мин белгәне—Мөдәррис Әгъләмов. Ул да үсмер яшьтә дүрт ел рәттән авыл көтүен көткән. Бишенче елны, үз авылларында көтү эләкмәгәч, күрше урыс авылына барып дуңгыз көтүе алган. Һәм Мөдәррис гомере буе үз сукмагыннан чыкмады. Һәм ул да хәзинә тапты. Ә ул тапкан байлык—Тукайлар катламына төшеп чыгарылган саф шигърият чишмәсе—халыкка иреште.

Мин әлеге мәкаләне хурламыйм, ул кызык, бигрәк тә шушы агымны үз итүче каләм ияләре, яки шушы предметтан имтихан тотучы студентлар өчен, ихтимал, бәһа биреп бетергесездер, әмма дискуссиягә мөнәсәбәте турыдан-туры ук түгел шикелле.

Михаил Булгаковның "Мастер һәм Маргарита" романында, юләрләр йортында шагыйрь Иван Бездомный белән Мастерның әңгәмәсе гыйбрәтле. Мастер, яңа танышыннан кем булып эшләвен сорый.

"—Шагыйрь—ди Иван. Бүтән чакта үз шөгылен горурланып, чатнатып әйтә торган булса, бу юлы ул моны теләр-теләмәс, уңайсызланып хәбәр итә.

—Нишләп гел миңа гына кәкере суга соң?—дип ах-ух килә Мастер.

—Сез минем шигырьләрне укыганыгыз булдымыни?—дип гаҗәпләнә Иван.

—Бернинди шигырьләрегезне дә укыганым юк минем!

—Ә нишләп алар сезне хафаландыра соң?

—Әйтерсең мин бүтән шигырьләрне укымаган. Хәер, расласагыз сүзегезгә ышанырмын. Сез әйбәт шигырьләр язасызмы?

—Өч тиенгә тормаган шигырьләр язам,—диде кинәт танымаслык булып үзгәргән Иван.

—Язмагыз бүтән.

—Вәгъдә—иман..."

Бездә дә яраксыз тезмә әсәрләр калыплаучылар бардыр. Бигрәк тә җыр текстларында бу күзгә ташлана. Әмма халкыбызның гаебе юк. Безнең татарларда "Китәсез дә мени аккошлар" кебек җырлар популяр булган чаклар бар иде. Инде ничә еллар такмакчылар "шигърияте" сәхнә тотып милләт зәвыгын боза һәм моның тәэсире булмый калмый билгеле...

Алай да шигъриятебезнең тамырлары тирән. "Мастер"ларыбыз да берәү, икәү генә түгел... Аннары бит чын шигырь укып үскән буын вәкилләре, Айдар агай әйтмешли, без—исән!..

Техник белем бирүче вузлар тәмамлап эшкә башлаган чорыбыз, без—яшь белгеч егетләр, Сельхозтехника тулай торагы бүлмәсенә җыелып шигырь укыганнар истә...

Зиннур Насыйбуллинның:

*Сафлык бит ул намус өчен кирәк,*
*Тормыш өчен кирәк, җыр өчен...*

Равил Фәйзуллин:

*Гөмбәзләре Кояшмени, сары алтын чиркәү,*
*Бабайларның күз яшьләре менә кайда икән...*

Гамил Афзалның:

*Кәгазь чәчәк тотып, ясалма дус килә,*
*Синтетик сүзләре күңелгә хуш килә...*

Зөлфәтнең Мөдәрриская атап язган:

*Их син, сәях дустым, нәни гигант*
*Карлар ямый карлар тик тора,*
*Тирбәлгәләп өскә күтәрелә,*
*Безнең шушы иске йорт кына...*

Эдуард Мостафиннын:

*Моңым белән үз дөньямны корган,*
*Мин бишенче фасыл—асылда!—*

һәм башка бик күп тезмә әсәрләрен укып хушлана идек. Әлбәттә, табыныбыз буш ук булмагандыр, әмма шигырьне дә үзебездән калдырмадык. Хәзер, еллар үткәч шушы шәп шагыйрьләребезгә, марканы төшермәгәннәре, нәрсә язсам да басалар дип чүп язып үзләрен очсызламаулары, поэзиябезнең матур киләчәге хакына якты маяк булып калулары өчен рәхмәт әйтәсе килә.

Француз әдәбиятында Теофил Готье атлы язучы бар. Ул да романтик сюжетларны нигез итеп алып, мавыктыргыч романнар язган. Әмма әлеге авторны олуг иткән нәрсә, язганнарының эчтәлеге түгел, ә француз теленең гүзәллеген ачуы. Марсель Галидән дә ниндидер сюжетлар, характерлар тудыру таләп итмәскә иде, минемчә. Нәрсә язса шуны язсын. Япониянең күп кешеле шәһәрләрендә сулар өчен пакет белән кислород сатып бирәләр имеш. Корама тел чолганышыннан тәмам алҗыгач, әнә шул кислородлы пакетлар сыман Марсель Галине укыйм мин, Әмирхан Еники томнарын таба алмый торган мәлләремдә...

Әйе, татар поэзиясенең тамырлары тирән, ә проза һәм драматургиябез, таныргa тиешбез, рустан үрнәк алып, унтугызынчы гасырда яралды. Ә менә Еники һәм Галиләр прозасы, борынгыга, шигъриятькә ялганган... Димәк шәп проза әсәре тудыру өчен шигъриятебезгә баш орып кыйбла дөресләү ул юл.

Ә прозада хәлләр әлегә мактанырлык түгел. Тәнкыйтькә эләккән Роза Хәбибуллина һәм Әсгать Сәлахов әсәрләре менә дигән образлы йөгерек тел белән язылган, бер тын белән укылалар. Кимчелек-геройларның тик инстинкт ихтыярында, аннан бәйсез булуларында диделәр... Укыйсы иде авторларга мәгънәле шигырьләрне. Әйтик шул ук Зиннур Насыйбуллинның сафлык турындагысын... Ярый, болар шулай булсын. Ә традицион ысулдагы мәкаләләрдә даими макталган, тәҗрибәле язучы статусына ия булган авторларның унай бәяләнгән әсәрләрен бөтенләй укып булмый бит. Тел фәкыйрь, фикер сай, сүз тәме юк, әңгәмә тел чарлауга кайтып кала һәм геройларга да җан иңмәгән. Бар булган түземлегемне җыеп мәгълүм авторыбызның тарихи әсәрләрен укыйм. Нишләп соң ул геройларның берсе дә тирән кичерешләрдә бәргәләнми, ялгышлар ясап өзгәләнми, аны төзәтәм дип яна бәлаләргә тармый? Ник, үзгәрмиләр, үсмиләр? Нишләп соң алар яшәми? Айдар Хәлимнең геройлары бар да тере әнә. 2004 елның 7 нче санында анын өч хикәясе басылды. Өч хикәяне дә уртак герой, Кәнагать исемле малай берләштерә. "Трофей" атлы өченче хикәядә (ә ул җырчы Таһир Якупов истәлегенә дип тәгаенләнгән) Кәнагатьнең әнисен Җинүнең бер еллыгына тантаналы җыелышка күрше авылга дәшеп алып Германиядән кайткан трофей ашъяулык тапшыралар. Ире сугышта һәлак булган хатынга бирелгән бүләк, уртасы умырыклы, ягъни баш зурлыгындагы тишекле булып чыга. Хатын әүвәл гарьләнеп елый. Сталинны, Гитлерны, шушы бүләкне тапшырган авыл советы рәисен каргый. Аннары ялгышуын танып Ходайдан ярлыкау сорый. Һәм сандыгын ачып, киндердән үзе тукыган һәм чиккән ашъяулыгын алып, ана яна бәйләгән оекбашларын өстәп, теге тишек ашъяулыкны да салып, кирәк икән Мәскәү Кремленә, кирәк икән Германына барырбыз дип улын ияртеп, авыл советына төбәп чыгып китә. Каһарманмы? Каһарман! Дәүләтнең чираттагы мыскыллавын күтәрә алмыйча, заманасы өчен баш китәрлек адымга бара әлеге хатын. Сәгыйдулла Хафизов "Кайда безнең рыцарьлар?" дигән мәкаләсендә заман герое юклыгы проблемасын әйбәт байларыбызны образлаштыру аша хал итүне куәтли. Игелекле фикер. Тарих фәненнән билгеле: милли азатлык хәрәкәте милли буржуазия җитәкләгәндә генә җиңү яулый... Әмма герой эзләү офыкларын алай тәгаенләү бик үк дөрес түгеллеген алда телгә

алынган хикәя дә кире кага. Бәлкем төп каһарманы бомж булган әсәрне халкыбыз тыны белән тартып алырдай булып көтәдер бүген?

Соңгы егерме елда басылган, мине иң нык тетрәткән әсәр—ул Фәрит Гыйльминең "Табеев куышы" исемле хикәясе... Автор күренекле совет эшлеклесе турындагы әлеге хикәясе аша бүгенге вәхшәтне кисәткән, аның тамырларын тәгаенләгән булып чыкты...

Дискуссиябездә дәреслекләр хакында да әйтелде. Мин үзем сигезьеллык мәктәпне күрше авылга йөреп укыдым. Истә, шунда йөргәндә олыраклардан әллә нинди оятсыз такмаклар отканым. Бер ишетүдә хәтердә калалар, чөнки алар ифрат халыкчан. Шунда ишетелгән дистәләрчә такмак әле дә онытылмый. Ә менә дәреслекләргә кертелгән, ни салам, ни печән тәме килмәгән шигырьләрне ятлавы бер бәла иде. Рус әдәбияты китапларындагы шигырьләр фонында аларның чүплеге бигрәк калку күренә. Анда мәңгегә кертелгән авторлар бар. Махсус начар, кызык түгел шигырьләр сайлыйлар кебек. Үз телендә укучы татар баласын үз теленнән биздерүне күздә тотып микән дип тә аптырарлык. Соң менә дигән шагыйрьләр бар чагында ник кирәктер тәти балалар турындагы йөзе-бите, уе, табышмагы, уята-әсәрләндерә торган образы юк сүз өемнәре... Берничә буынны тәмам маемлаткан авторларны берәр дистә ел бөтенләй кертми торсаң да ару буласы дәреслекләребезгә.

Әлбәттә теләсә кайсы әсәр турында прокурор мантиясе киеп тә, адвокат мөнбәренә басып та сайрап була. Ике очрак өчен дә дәлилләр табуның берние юк, чөнки авторлар хатадан хали түгелләр... Әйе, дәреслекләр хакында да төрлесен әйтү мөмкин. Әйтик, тарих дәресләрен укыганда иң нык күзгә ташланган нәрсә, руслар турында сүз барганда аларның һәр гамәле аклана, бу очракта тарихчы—адвокатка, ә башкалар турында сүз китсә, татарлар, чечен, поляк, яки бүтән нацмен, тарихчы прокурорга әверелә. Бер шәхеснең икегә бүленүе медицинада шизофрения дип атала бугай. Безнең тарих һәм әдәбият дәреслекләрен язучылар арасында да икегә бүленүче шәхесләр булмады дип кистереп әйтү кыен. Үзләре сәламәт булган очракта да хәл үзгәрми, мондый дәреслекләр балаларның психикасына бәрми калмый. Дәреслекләргә бәйсез экспертизалар үткәрү, шул исәптән психиатриягә караганы да кирәк. Көчсезлек, мескенлек, кушканны гына үтәүчәнлек, ягъни коллык тәрбияләүгә генә хезмәт итәләр икән, аларны зарарлы дип табып, мәгариф министрлыгының һәм киң җәмәгатьчелекнең кисәтелүе хәерле...

Бикә Рәхимованың мәкаләсендә яңгыраган кайбер фикерләр аерым тукталуны таләп итә. Әйтик һәр интервью алучы ятлар каршында милләтпәрвәрләребезнең асыл максатыбызны әйтеп "чишелүләре" турындагысы. Безнең халыкта "Тиледән туры хәбәр", "Сукмас олы күтәрер" дигән мәкальләр бар. Беркатлы кеше турында "эчендәге тышында" дип тә әйтәләр. Хактан да милләтпәрвәрләр ихласлыкларын яшерә белмиләр. Ә урысны күрегез, берсе дә "татарны яки башканы бетерү безнең максат" димәс. Иң гап-гади кешесе дә "бергә булыйк, дус-туган булып яшик" дип тәкърарлый. Ә эшләгән гамәлләре чәчләрне үрә торгызырлык! Хактан да: кәртне ачып уйнау оттыруга китерә. Бер тинтәк кенә мисал китерик, әйтик берәр колхоз Айга менәргә кирәк дигән максат куйса, моны житди кабул итмәячәкләр. Әгәр колхозчылар, чыннан да, Айга менәргә жыенып, шушы максатта Байконурдан космик кораб урларга ниятләсәләр, үзләренең декларацияләрендә бу хакта язмаслар, шунда үтеп керү өчен космонавтларны азык-төлек белән тәэмин итү турында килешү чарасын күрерләр иде... Сәясәтче милләтпәрвәрләребезгә генә түгел, язучыларга һәм аларның геройларына да андый садәлек, гадилек хас... бездә кешене гади дию, мактау буларак кабул ителә, ә төрекләр мәсәлән мондый бәя бирсән үпкәли икән... Алар аны "примитив" дигән мәгънәдә кабул итәләр булыр.

Бикә Рәхимова искәрткән кыйммәтле тагын бер фикер: татар әдәбиятының тулаем язучылар кулына калуы. "Жиң сызганып эшләргә вакыт" ди ул һәм моның белән килешми мөмкин түгел. Теләсә кайсы жанрда! Әмма "кирәкле шәй" тәнкыйтьне комырыкка куып кертмичә!

**Фатих Урманче**

*филология фәннәре докторы*

# ШИГЪРИ ОСТАЛЫК СЕРЛӘРЕ

Күңеленә нинди генә уйлар килсә дә, аларның һәммәсен шагыйрь Роберт Миңнуллин шигырьләре-җырларыннан, аларда ифрат та киң чагылыш тапкан, татар халкының милли һәм рухи асылын билгеләгән, шагыйрьнең иҗатын, тирән һәм киң дәрья кебек, тулаем инләгән милли моңнан табарга була. Шушы уңайдан Галимҗан Гыйльмановның "Шагыйрьнең моңлы чагы" мәкаләсе хәтергә килә. Мәкалә Р. Миңнуллинның "Талбишек" (1995) җыентыгына кереш буларак язылган. Анда Г. Гыйльманов Р. Миңнуллин иҗатының тирән әһәмияткә ия булган бер җитди үзенчәлеген түбәндәгечә билгели: "Әдәбият казанында азмы-күпме кайнаган кеше буларак, тәгәл әйтә алам: әдипләрнең асыл талантын билгели торган бер бизмән бар. Ул—аларның өлкәннәр өчен дә, нәниләр өчен дә бердәй талантлы әсәрләр иҗат итә алулары. Андый әдипләр, гадәттә, күп булмый: булганнары да гаять тыйнак, самими җан ияләредер... Роберт Миңнуллин әнә шундый шагыйрьләрдән". Үзенең бу сүзләрендә Г. Гыйльманов, һичшиксез, хаклы.

Биредә исә сүз, барыннан да элек, шагыйрь иҗатында чагылыш тапкан әкияти-эпик мотивлар турында барачак. Үз иҗатында әлеге мотивларның булуын бүгенге шагыйрьләрнең иң зур күпчелеге инкарь итә алмый. Шулай да Р. Миңнуллин иҗаты үзенчә. Ә инде мәсьәләне Р. Миңнуллин иҗатында халык әкиятләре традицияләренең чагылышы яссылыгына күчерсәк, сүзне төрки-татар дөньясында аеруча популяр булган Алып-батыр исеменнән башларга тиеш булабыз.

Алып батыр белән бәйле легендалар татар халкында әле хәзер дә яши. Шуларның күпчелеге—төрле җирләрдә, төрле якларда очрый торган таучыклар, курганнар белән бәйләнгән. Имеш, Алып батыр көне буена җир сөреп арыган да, ял итәргә туктаган. Җайлап кына ялга утыргач, чабатасын кага торган булган. Күрәсең, Алып батырның чабатасы шундый зур булган ки, ул чабатасын каккан җирләрдә таучык-курганнар пәйда булган. Ул сөргән җирнең мәйданы да шактый ук зур булгандыр, дип уйларга кирәк. Бер-берсеннән шактый ерак булган якларда да (әйтик, Идел буенда да, Түбән өлкәсендә дә!) очраган курганнарны әле хәзер дә "Алып батыр чабатасын каккан җир",—дип сөйлиләр. Бүгенге көн шагыйрьләре әсәрләрендә кайвакыт әнә шул Алып батырдан калган курганнар да телгә алына. Мәсәлән, Равил Фәйзуллин тарафыннан 1980 елда язылган исемсез бер шигырьдә тормышның төрле каршылыклары: тарих та, безнең заман галәмәтләре дә бергә кушылып бирелә. Шул уңайдан шагыйрь Алып батыр исеме белән йөргән курганнарны да телгә алып үтә:

*Гомер бакый Яхшы белән Яман*
*якалашкан, канда буталган...*
*Тарих сәер: хәтерендә рәттән—*
*изге җан да, зина кылган да.*
*Алып бабай өйгән курганнар да,*
*Герострат яккан храм да,*
*Клеопатра хатын патшаның*
*күкрәген чаккан елан да.*

Кайбер шагыйрьләр үз иҗатларында Алып-батыр исеме белән бәйләнгән һәм югарыда күзәтелгән легендаларның эчтәлеген тулысынча, хәтта беркадәр арттырып та, сөйләп чыгалар. Ренат Харис, мәсәлән:

*Кәвешеннән туфрак каккан—*
*Үзән җирдә тау калыккан.*
*Кайгысыннан бер елаган—*
*Елгаларның суы арткан.*
*Шатланып ул бер елмайган*
*Корыган үлән чәчәк аткан...*
*Дошманына бер селтәнгән—*
*Яулар кабер булып баткан.*
*Дуслары йөрер юлларда*
*Үзе күпер булып яткан.*

Китерелгән өзектән күренүенчә, биредә Алыпта булмаган сыйфатлар турында да сөйләнә. Әлеге сүзләрне укыгач, ирексездән казакъ халык эпосы "Ер Саин" һәм аның баш каһарманына хас үзенчәлекләр хәтергә килә. Дастанда сөйләнгәнчә, әгәр Ер Саин 90 яшьлек карчыкларга кагылса, алар яшь кызларга әвереләләр икән. Батырның күз карашы төшкән җирдә бөтен нәрсә яшәреп, төрле гөлләр чәчәк ата, имеш.

Р. Миңнуллин исә бик күп төрки халыклар иҗатында киң таралган Алып батыр образының ифрат та тирән иҗтимагый-сәяси мәгънәсенә игътибар итә. Дастанның күп санлы төрки версияләрендә мөһим урын алып торган төп идея-төп фикер: Алып батырның (аерым милли версия-вариантларда ул ничек кенә аталса да) үз гаиләсе, ыруы, кабиләсе, ахыр чиктә үз ил-халкының азатлыгы, иминлеге өчен туктаусыз көрәше, кирәк булса—көчле сугыш алып баруы. Нәкъ әнә шуңа күрә ул халык мәхәббәтен яулап ала, халык күңелендә мең елдан артык яшәп килә. (Моны дәлилләү өчен түбәндәге вакыйгаларны искә алып китәргә кирәк. 1999 елның көзендә Үзбәкстанда, конкрет алганда: Ташкент, Хиуа һәм Термез шәһәрләрендә "Алпамыш" дастанының 1000 еллыгына һәм Чыңгыз-хан гаскәренә каршы 10 ел буена көчле көрәш алып барган Җалалетдин Мангубердиның 800 еллыгына багышланган ике зур Халыкара фәнни конференция булып узды. Анда АКШ, Германия, Италия, Төркия, Пакыстан, Әфганстан һәм башка илләрдән килгән 123 галим катнашты. Үзбәкстан Президенты Ислам Кәримов, әлеге конференцияләрнең икесенә дә махсус килеп, чыгышлар ясады. Шул конференцияләр алдыннан Хиуада—Җалалетдин Мангубердигә, Термезда (легендалар буенча, батырның туган илендә)—Алпамышка махсус, әллә каян күренеп торган, алтын белән капланган зур һәйкәлләр куелган иде. Конференцияләр дәвамында төрле җирләрдә сәгатьләр буена дәвам иткән концертлар оештырылып, бик күп һәм затлы китаплар чыгарылган иде. Безгә анда Татарстан Республикасының "бер кешедән торган махсус делегация"се буларак катнашырга насыйп булды...)

Дастанның һәм Алып батыр көрәшенең конкрет мәгънәсе нинди генә киң һәм тирән булса да, Роберт Миннуллинның Алып батыр исеме дә кулланылган беренче шигыре үк мәсьәләне тагын да киңрәк яссылыкка, чын фәлсәфи, әйтер идем, халыкара мифологиянең глобаль проблемалары югарылыгына күтәрә. Дөресен әйткәндә, әсәрнең исеме үк шагыйрьдән шуны таләп итә: "Дөнья бит ул". Дөнья сүзе биредә ифрат та киң, ә бәлки язмыш мәгънәсендә кулланылгандыр?! Бу дөньядан да, язмыштан да әллә нәрсәләр күтәргә мөмкин, хәтта бернәрсә күтмәсәң дә, ул барыбер синең җилкәгә килеп төшә: бәхете дә, фаҗигасе дә! "Дөнья бит ул" дигән кыска гына җөмләнең үзе үк, шактый "авыр яңгырап", ниндидер, бигрәк тә безнең көннәрдә, куркыныч шом, кайгы-хәсрәт турында хәбәр итәдер сыман. Нәкъ әнә шуңа күрә бу сүзләрдә Казан ханлыгын үз кулына корал тотып, башкаланың һәм ханлыкның азатлыгын яклап һәм саклап калу өчен канлы сугышта дастан батырларынча һәлак булган Кол Шәриф, шуңа якын язмышка дучар ителгән даһи талант иясе Дәрдемәнд (1859-1921) шигъриятләренең аһәңнәре дә сизелеп куя. Кол Шәрифнең филология фәннәре докторы, профессор Әнвәр Шәрипов тарафыннан төзелгән җыентыгы "И күңел, бу дөньядыр..." дип атала. Анда "И күңел, биленне бума..." дип башланган һәм тулаем бетмәс кайгы-хәсрәт рухы белән сугарылган газәлдә түбәндәге юллар да бар:

*И күңел, билеңне бума (дөнья дип), күпне кичергән дөнья бу,*
*Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөнья бу.*

*Син уйлама, дөньяда мин мәңгегә калырмын дип,—*
*Күп янар вакытта утлар очырган дөнья бу.*

Роберт Миңнуллинның "Дөнья бит ул" шигыре дә шундый ук тирән фәлсәфи мифологик рухта яңгырый. Ул түбәндәге сүзләрдән башлана:

*Елата да, көлдерә дә,*
*Баета да, бөлдерә дә—*
*Дөнья бит ул.*

Биредә барыннан да элек күзгә ташланганы, күрәсең, дөнья сүзенең язмыш сүзе белән авstation аваздаш яңгыравы. Язмыш та бит, дөнья кебек үк, кешегә тик бәхет кенә китереп тормый. Биредә тагын да бер ифрат та мөселманнарның изге китабы Коръәнне "Язмыш китабы" дип атау да бар бит! Моның шулай булуын югарыда Кол Шәриф газәленнән китерелгән өзек аеруча ачык күрсәтә.

Р. Миңнуллин шигыренең икенче куплеты, әсәрнең серле-сихерле мәгънәсен саклаган хәлдә дә, безне Илаһи Күктән гади һәм гадәти, без дә гомер кичереп яткан Җир йөзенә алып төшәдер сыман:

*Бер сораусыз яраттыра,*
*Бер ямьсезгә карагтыра—*
*Дөнья бит ул.*

Шулай да әлеге өч юл әсәрнең шигъри тукымасына "сыеп бетми". Моны шагыйрь үзе дә бик яхшы белә, сизә, аңлый булса кирәк: нәтиҗәдә шигырьнең соңгы юлларын ул Илаһи бер бөеклеккә күтәреп, барыннан да элек төрки-татар дөньясында киң таралган, гомерләре буена ил-халык бәхете өчен көчле көрәш-сугыш алып барган Алыплар чорына—Алыплар дөньясына алып китә; икенчедән—шигырьнең соңгы юлын халыкара мифологиянең иң мөһим атрибутларыннан берсе булып, төрле халыклар телендә-күңелендә гасырлар-меңъеллыклар буена яшәп, аларны һәрвакыт, бигрәк тә картая башлагач, туктаусыз борчып-бимазалап торган Үлем һәм Үлемсезлек проблемасына китереп куша.

*Берәүләрне Алып итә,*
*Тик барыбер алып китә—*
*Дөнья бит ул...*

Шагыйрьнең аерым әсәрләрендә Алып исеме билгеләмә, чагыштыру формаларында да телгә алына. Аның югарыда китерелгән "Халык шагыйрьләре" дип аталган шигыре "Сибгат ага Хәким истәлегенә" багышланган. Анда ул чыннан да Халык шагыйре дәрәҗәсенә ирешкән затларны Алып батыр белән тиңләштереп, калганнары гади халык арасында гына яши, дигән фикер уздыра: "Әй, татарның Алып шагыйрьләре!.. Һәркем сыймый андый калыпка. Халыкныкы алар! Шагыйрьләрнең калганнары керә халыкка".

Хәзер инде Идел буенда яшәүче милләттәшләребездә генә түгел, татарлар яшәгән һәрбер төбәктә, бүгенге көндә безнең тугандаш төркиләр гомер иткән Казакъстанда, Үзбәкстанда, Кыргызстанда, хәтта саф славян илләре Украинада һәм Белоруссиядә, ерак чит илләр дип саналган Польшада, Австралиядә ел саен, ә кайвакыт елына берничә мәртәбә татар халкының бик күптәнге һәм саф милли бәйрәме булган Сабантуй уздырыла. Табигый, бу бәйрәмгә дә Р. Миңнуллин күп санлы махсус шигырьләр багышлый: "Сабантуйны күрми калганмын", "Илеш сабантуе", "Сабантуйда" һ. б. ("Сабантуй" дигәннән, 1998 елның августында шагыйрь туып үскән Шәммәт авылы янында (Башкортстанның Илеш районы) чын мәгънәсендә Роберт Миңнуллин Сабантуе булып узды. Шул районның администрация башлыгы 1998 елны "Роберт Миңнуллин елы" дип игълан иткән иде. Сабантуйда Башкортстаннан һәм Татарстаннан килгән артистлар-сәнгатькәрләрдән кала, бик күп язучылар да бар иде. Татар язучыларын Казаннан "Икарус" автобусының ин зурысы алып барды. Язучылар арасында: Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Татарстанның халык шагыйрьләре, Р. Миңнуллинның остазлары Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һ. б. бар иде.) Шагыйрьнең шул ук темага язылган "Яшь батырлар"

шигыренә "Балтач белән Арчаның яшь батырларына" дигән багышлама бирелгән. Һәм бу аңлашыла да. Чөнки Сабантуйда һәркемнең күңелен тарткан, аны борчыган, дулкынландырган иң мөһим һәм мавыктыргыч күренеш—милли көрәш. Бу күренеш шагыйрьне дә тәэсирләндерә. Ул шушы хакта рәхәтләнеп, үзе дә дулкынланып яза:

*Яшь батырлар—үзебездә,*
*Эзләмәгез әллә кайдан.*
*Тик аларга кирәкми дан,*
*Кирәк мәйдан,*
*Киңрәк мәйдан!*

Әсәрдә Алып батыр образы да бар. Алып батыр исә үз җилкәсендә тик глобаль проблемаларны гына "күтәреп йөри ала". Вак-төяк мәшәкатьләр аны кызыксындырмый...

*Кирәк булса дошманнарны*
*Алар алып атырлар да,*
*Үсеп җиткәч, әйләнерләр*
*Беркөн Алып батырларга.*

*Үзенең чын батырларын*
*Халык зурлар, ил олылар...*
*Менә ничек көрәшергә*
*Кирәк безгә,*
*И, олылар!*

Роберт Миннуллинның шигърияте, аның үз биографиясенә бик тә якын. Аның шигырьләре арасында үзенә, үзенең туган көннәренә, аеруча—билгеле бер юбилей даталарына, энекәшләренә, сеңелесе Люциягә, бигрәк тә сөекле Әнкәенә, төрле туган-тумачаларына атап яки бихисап дуслары-коллегалары юбилейлары унаеннан язылган һәм юморга да иситкеч бай шигырьләрен, дүрт, биш, алтыюллыкларын, эпиграммаларын да искә алсак, шагыйрь биографиясенең тулаем булмаса да, яртысын, һич югы—мөһим бер өлешен күз алдына китерергә мөмкин. Шундыйлардан биредә безнең күңелне аеруча җәлеп иткәне—"Энекәшләр" шигыре. Ул бик конкрет фактларны күрсәтүдән башлана:

*Берегез—Фән! Берегез—Рим!*
*Берегез—Ким!*
*Горур булыйк, энекәшләр,*
*Без кемнән ким?!*

*Пәһлеван сез минем янда*
*Өчегез дә,*
*Әкияттәге шикелле*
*Көчегез дә.*

Әйе, эпик батырлар турындагы легендалар (ихтимал, эпик дастаннар да!) Болгар чорында шактый киң таралган була. Башка төрки телләрдәге кебек үк, болгар-татар телендә дә әлеге эпик батырны "алып" дип атыйлар. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында да батыр "алып" исеме белән йөри. Бу атаманың тагын да борынгырак тарихи тамырларын ачыкларга теләсәк, без Орхон-Енисей язмаларына мөрәҗәгать итә алабыз. Уйбаттагы беренче һәйкәлдә теркәлгән "алып" сүзе аның язмадагы иң борынгы кулланылышы булса кирәк. Әлеге язмаларда бу сүз конкрет батырның исемендә дә, гомумән батырлыкны билгеләүче сүз рәвешендә дә очрый (Йигин-Алп-Туран һәм Инанчу алып). Борынгы төрки язмачылык чорыннан башлап, димәк, "алып" сүзе борынгы һәм Урта гасырлар язмачылыгы, халык иҗаты һәм язма әдәбияты аша үтеп, безнең көннәргә хәтле килеп җитә һәм бүгенге татар шигъриятендә дә шактый актив яшәвен дәвам итә. Моны, башка байтак шагыйрьләр белән бергә Роберт Миннуллин иҗаты да ачыктан-ачык дәлилләп тора. Аның югарыда күзәтелә башлаган "Энекәшләр" шигырендә түбәндәге сүзләр дә бар:

*Салсал батыр, Камыр батыр,*
*Алып батыр*
*Көрәшләрдә дошманнарны*
*Алып атыр.*

Роберт Миннуллиннын Алып батыр исеме кулланылган шигырьләре арасында бик тә үзенчәлекле, башка бер генә шагыйрьдә дә, татар халык иҗатында да булмаган алымга мөрәҗәгать итү дә бар: Алып батыр образын ул хәтта сатирик планда да сурәтли. "Тукайга багышланган күргәзмәдә" шигырендә ул бөек шагыйрь образын гәүдәләндерү нияте белән ясалган портретларга-сыннарга тукталып, һәркайсына үзенчә бәяләмә биреп үтә: "Берсе—таза, берсе—озын, Берсе Алыптай көчле". Бирелә без Тукай образын тудырырга тырышып-тырмашып та, адәм рәтле нәтиҗәләргә ирешә алмаган рәссам-скульпторлардан ироник көлүдән башка берни дә күрмибез.

Алып батыр образын сатирик планда сурәтләү җәһәтеннән шагыйрьнен алда инде бер тапкыр күзәтелгән "Яшьләр" шигыренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Аңлавыбызча, шигырьдә сүз хәзерге "крутой" яшьләр турында бара. Анда шундый сүзләр дә бар: "Инбашлары, күкрәкләре нинди?!—Алыплармы килә урамнан?" Юк, Алыплар турында түгел бу шигырь! Анын "каһарманнары" төрки халыклар күнелендә гасырлар дәвамында сакланып килгән батыр, ил һәм халык гаме белән яшәүче көчле, мәрхәмәтле, шул ук вакыт кыю һәм гайрәтле асыл зат—Алыптан шактый ерак торалар.

* * *

Әйе, татар халык әкиятләре белән бәйле сюжетлар, мотивлар, күренешләр, әкияти яки әкияти-мифологик персонажлар Р. Миннуллин иҗатында ярыйсы ук еш очрый. Роберт Миннуллин иҗатында очраган һәм әкият мотивлары белән дә аваздаш әсәрләрне берничә төркемгә бүлеп күзәтергә мөмкин. Әкиятләрнең байтагын булмаса да, берничәсен һәркем белә дип уйларга кирәк. Гомумән, сабый чагында бер генә әкият тә ишетмәгән бала бармы икән дөньяда? Юктыр, күрәсең! Бәлки шуна күрәдер, шагыйрь кайвакыт әкият сүзен, аңа әлләни тирән мәгънә салмыйча гына, юл унаеннан гына телгә аладыр сыман. Әйтик, "Бөре шәһәре белән хушлашу" шигырендә:

*Метролар юк синдә, трамвайлар юк,*
*Ыгы-зыгылар юк, шау-шулар.*
*Нинди тыныч әкияти шәһәр!*
*Якындыр да, бәлки, син шуңар.*

Әйе, Бөре—чыннан да, шәһәр. Анда гадәти шәһәргә хас барлык сыйфатлар да бар. Тик анда баш-күзне әйләндергән, миенне кайнаткан, урамда гади кешеләрчә йөрүдән мәхрүм иткән коточкыч шау-шу, хисапсыз җинел машиналарның, автобус-грузовикларның, туктаусыз үкереп, ыжгырып-ажгырып, сызгыртып-чинатып, хәзер таптыйм-басам-изәм дип важылдап узган кап-кара машиналарның, дангыр-донгыр остерәлеп килгән трамвайларның гына куркынычы юк. Болары инде аның Казан, Уфа, Чаллы, Әлмәт кебек шәһәрләргә. Ә менә Бөре кебек зур булмаган, әмма яшәү өчен җайлы, чын мәгънәсендәге әкияти шәһәр—шәһәрчекләр Татарстанда да аз түгел бугай!..

Эзләнүләр барышында Роберт Миннуллин китапларын кат-кат актарып, өйрәнеп, аерым очракларда бик тә үзенчәлекле әсәрләрен, икенче бер вакыт тулы җыентыгын, мәсәлән, "Кучтәнәч", "Әнкәй безне Сөннән алып кайткан" кебек китапларын рәхәтләнеп, янадан укып чыгасын. Шигырь бит ул укучы күнеленә катлаулы вакыйгалар, мавыктыргыч сюжет белән генә кереп калмый. Шигырьнең төп максаты—укучының күнеленә, йөрәгенә, бәгыренә үтеп кереп, анын уйларын тирәнәйтү, башын әйләндерү, кычкыртып яки акрын гына үксеп-үксеп җылату һәм җырлату. Борынгы һәм Урта гасырлар Шәрекъ шигъриятендә шундый бер гыйбарә бар. Әгәр сүз ифрат зур эмоциональ көчкә ия булган шигъри сүзнең тәэсире турында бара икән, анда: "Анын гәүдәсендәге һәрбер чәч бөртеге үрә торды!"—"Восстали все волоски на теле!" диләр. Борынгы Шәрекътә сүз-шигырьне моннан да югары бәяләү юк, күрәсең! Конкрет мисал рәвешендә бирелә Котбның "Хөсрәү вә Ширин" романыннан

Хөсрәүнең мөлке харап булуы белән бәйле түбәндәге сүзләрне китерергә мөмкин:

*Ачуыннан эчендә үте ташты,*
*Йөрәккә-үпкәгә утлар тоташты.*

*Котырган этмени—күзе каныкты,*
*Тәнендә сөңгедәй төкләр калыкты.*

Р. Миннуллинның исемендә үк "әкият" сүзе дә кулланылган махсус шигырьләре дә юк түгел: "Әкияттәге үги кызга", "Ак әкият"; ә бер әсәрен шагыйрь татар халык әкиятләренең иң матурларыннан берсе булган "Ак бүре" исеме белән атый. Сүзне әлеге әсәрләрнең берсеннән—"Ак әкият"тән башлыйк. Биредә, дөресен әйткәндә, әкиятләрдәге сюжет-мотив-персонажларның да, каршылыклы, куркыныч вакыйгалар барышының да, Жир яки Су асты патшалыкларында булган мажараларның да, Дию-Аждаһаларның да—берсе дә юк! Сүз тик ак әкият турында гына бара:

*Ак тынлыкта*
*Тын калганнар*
*Ак чаганнар,*
*Ак чыршылар.*

*Кагыл гына*
*Бу тынлыкка—*
*Ак җыр, ак моң*
*Ташып чыгар!*

Китерелгән өзектә генә дә ак сүзе биш мәртәбә кабатлана. Хикмәт нәрсәдә соң? Шул ак сүзендә булса кирәк: ак әкият, ак тынлык, ак чаган, ак чыршы, ак жыр, ак моң! Бу аклык—шулкадәр чиста, саф, пакъ, тыныч ки, аңа берничек тә кагылырга ярамый! Ә инде нинди дер саксызлык күрсәтеп, кагыласың икән, анда да бернинди дә фажига яки катастрофа булмаячак! Моны ак төс үзе рөхсәт итмәячәк. Аннан—аклык-пакълектән тик ак жыр, ак моң гына ташып чыгарга мөмкин! Башкасына ак төс юл куймый.

Роберт Миннуллин, балалар язучысы буларак, татар халык әкиятләрен, бигрәк тә бала-чага репертуарын, аларның эчтәлеген, сюжет кору закончалыкларын, әкиятләрнең традицион башламнарын һәм бетемнәрен бик яхшы белә, хәтерли, байтак әсәрләрендә кирәк дәрәҗәдә оста файдалана. Бу яктан аның "Матчадагы талчыбык" шигыре аерым бер игътибарга лаек. Шигырьнең исеме үк аерым әкиятләрдә чагылыш тапкан традицион бер мотивтан алынган. Фәндә ачыкланганча, байтак тылсымлы әкиятләрнең, батырлык эпосы әсәрләренең үзәгендә кәләш эзләү һәм, бик күп мажаралардан соң, аны табып, гаилә кору проблемасы тора. Чөнки гаиләнең төрле формаларын кичереп, моногам—ике кешедән генә торган гаилә коруга килеп житү—кешелек тарихындагы иң әһәмиятле социаль, гаилә-никах өлкәсендәге иң зур казанышлардан берсе дип санала. Татар халкының "Турай батыр" әкиятендә, әйтик, шул ук мәсьәлә үзәккә алына. Әкияттә сөйләнгәнчә, гәүдә-кыяфәт, матурлык, батырлык ягыннан тирә-якта дан тоткан Турай батырның бер кайгысы бар—аның хатыны юк икән. Әкият моның сәбәбен түбәндәгечә анлата: "Алачыкта торган кеше кайда килен төшерсен дә, кайда бала үстерсен?" Аптырагач, егет анасына: читкә чыгып, "ил-көн күреп дөнья гизеп йөрим. Бәлки кулга мал төшәр, бәлки бирәр кыз очрар, сиңа килен, миңа хатын чыгар",—дип ялвара. Халык әкиятләрендә һәм дастаннарда кабул ителгәнчә (казакъ дастаны "Кобланды-батыр", күп кенә төрки халыкларда киң таралган "Күзы Күрпәч белән Баян-сылу", "Идегәй" һ. б.), әнисе Турай батырның бу ниятенә кискен каршы чыга:

"—Ай, улым, китүен китәрсең анысы, син бит минем бер генәм. Китеп югалсаң, синсез нишләрмен, сиңа ул-бу булса, хәленне ничек белермен?

Жегет каз каурыен алган да матчага кыстырган:

—Син кайгырма, әни,—дигән,—мин югалмам. Әгәр инде миңа ул-бу була калса, шушы каурыйдан кан тамар".

Түбә матчасына кыстырып калдырылган каз каурые—әкият сюжетының пассив

бер элементы булып кына калмый, ул әлеге вакыйгалар барышында турыдан-туры катнашып, батырның язмышында хәлиткеч роль уйный. Һәм чыннан да, Үзе бер карыш—сакалы биш карыш белән орышта Турай батыр җинелә һәм һәлак була: "Үлде бит инде Турай батыр,—дип дәвам итә әкият.—Аның үлүе була, матчага кыстырган каурыйдан кан тама башлый. Турайның анасы моны күреп ала да зар елап юлга чыгып китә". Эзләп таба әнисе берданбер улының үле гәүдәсен һәм, үзенә хас тылсым көче белән баласын терелтә. Бу инде—халык әкиятләрендә киң таралган вакытлыча үлем мотивының бер конкрет чагылышы гына. Әкият ахырында Турай батыр үз максатына ирешә—эзләгән кәләшен таба. Әкият, гадәттәгечә, тантаналы туй белән йомгаклана. Гомумән, әкиятләр беркайчан да фаҗига-үлем белән бетми. Шулай итеп, әкиятләр—Кешелекнең күп меңьеллыклар дәвамында күңелендә яшәп килгән Үлемсезлек турындагы хыялның конкрет һәм иң мөһим бер чагылышы. Билгеле булганча, Дөньядагы (Конфуцианстводан башка) барлык, шул исәптән Иудаизм, Христианлык, Ислам кебек халыкара классик диннәрнең дә нигезен шул ук Үлемсезлек идеясе тәшкил итә. Бәлки бу идея төрле диннәргә халык иҗатының иң борынгы жанр-төрләреннән булган мифлардан һәм әкиятләрдән үтеп кергәндер?!

Ә инде әлеге каз каурыеның нигә матчага кыстырып калдырылуы мәсьәләсенә килсәк, моның да билгеле бер этнографик нигезләмәсе булырга тиеш. Матча—өй түшәменең уртасында булып, шул түшәмне тотып торган төп бүрәнә. Нәкъ әнә шуна күрә татар-мишәрләрдә, мәсәлән, никах туен оештыруда мөһим роль уйнаган шәхес—башкода—кыз кода булып килгәндә, "өйгә кергәч, матча турысына утырырга тырыша һәм сиздермичә генә бу өйдәге нәрсәне дә булса (сөлгеме, бүрекме) астына салып утыра, янәсе сүзе өстен булып кала. Бу гадәт, ягъни кыз сорарга килгән кешенең матча турысына утырырга тырышуы славян халыкларында да булган, матча турысына утырмасаң бу гаиләдә татулык һәм бердәмлек булмый, дип ышанганнар". Икенче төрле итеп әйткәндә, биредә дә сүз күп кенә әкият-дастаннарның төп проблемаларыннан берсе булган гаилә кору, аның ныклыгын саклау турында бара...

Р. Миңнуллинның "Матчадагы талчыбык" шигыре дә халык әкиятләренең әнә шул мотивына нигезләнә кебек. "Зөфәр абыйга" багышланган әлеге шигырь нәкъ әнә шул мотивтан башлана да:

*Менә аның әтисен дә*
*Сугышка озаталар.*
*Кочаклашып, сүзсез генә*
*Тордылар озак алар.*

*—Әниеңне тыңла,—диде,—*
*Олы малай инде син!*
*Һәм кыстырды матчага ул*
*Талчыбыкның җиллесен.*

* * *

Р. Миңнуллин—әтисез үскән бала. Бәлки шуңа күрәдер, аның шигърияттендә дә, публицистикасында да, хәтта конкрет эшләрендә-вазифаларында да ятимнәр, аларның ачы язмышы, гомумән, безнең көннәрнең иң актуаль, кырыс, киеренке проблемаларыннан булган ятимлек мәсьәләсе, ятимнәр язмышы зур урыннарның берсен алып тора.

Татар әкиятләрендә дә Үги кыз образы нигездә бер үк сюжетка корылган берничә әкияттә кабатлана: без биредә аларның эчтәлеген сөйләп тормастан тик исемнәрен генә күрсәтеп үтәбез: "Үги кыз", "Үги кыз белән сихерче карчык", "Әйдә, кызым, безгә", "Кыйгак каз" һ. б.

Роберт Миңнуллин да бу темага берничә мәртәбә мөрәҗәгать итә. Тик ул әлеге әкият сюжетларының берсен дә кабатламый, ә бөтенләй башка вакыйгалар-хәлләр турында сөйли. Мәсәлән, "Көз. Дингез. Гөл" шигырендә:

*Кар эчендә ята елап*
*Диңгезнең көзге гөле—*

*Дингезнең нечкә күңелле*
*Фирүзә күзле гөле.*

Кышкы салкында, карлы-бозлы дингездә калган гөлнең хәле бик тә кызганыч, билгеле! Ул гөл үлгәнме, әллә әлегә тереме? Бусы да билгеле түгел. Шулай да ул әле тере бугай: "Ә гөл сула... Ул мөлдерәм Карый минем күзләргә". Үлем алдында калган гөл кешедән ярдәм сорый кебек. Әнә шул уңайдан шигырьгә традицион Үги кыз образы килеп керә дә: "Коткарыйк, дингез, без аны, Үги кызны-гөленне. Әллә ул гөл сиңа бер дә Жәл, кызганыч түгелме?"

Роберт Миңнуллин беркайчан да һәм беркемне дә, шул исәптән—халык иҗаты әсәрләренең дә сюжетын, эчтәлеген, персонажларын, әдәби-символик образлар системасын тулысынча кабатлау юлыннан бармый. Ул үз иҗатында аңардан элегрәк иҗат ителгән әсәрләрнең бер каһарманын, сюжет агышының иң җитди мотивын, әдәби-шигъри алымнарының иң матурын, күңелдә калырдаен ала да, шул нигездә үзенең тулысынча мөстәкыйль әсәрен иҗат итә. Әлеге шигырьдә дә шул ук алым кулланыла. Бу—Р. Миңнуллин иҗатына хас принципиаль үзенчәлекләрнең тагын берсе! Әлеге шигырь түбәндәгечә дәвам итә: "Ничек ярдәм итим гөлгә?.. Тыя алмый үземне, Учларыма алдым гөлне. Өздем, өздем... өзелде". Аңлашыладыр, өзелгән гөл—үлгән, инде тәмам шиңгән гөл дигән сүз.

Билгеле булганча, халык әкиятләре, хәтта аларның Үги кыз образы белән бәйләнгәннәре дә, фаҗигале төстә бетә алмый: моны әкият поэтикасы рөхсәт итми. Татар халык әкиятләрен яхшы белгән Р. Миңнуллин да моны бик дөрес аңлый, билгеле. Шул ук вакыт аның әсәре дә әкият түгел, ә бәлки мөстәкыйль шигырь. Аның тирән, әмма нинди дер яктылык белән өртелгән соңгы юллары да бик табигый яңгырый:

*Елмайды гөл сөенечтән,*
*Белсә дә ул үләсен.*
*Сулды учта... Гөл бәхете*
*Шулдыр инде, күрәсең.*

Шагыйрьнең шул ук Үги кыз образы белән турыдан-туры бәйләнгән махсус шигыре дә бар—"Әкияттәге Үги кызга". Шигырьдә халык әкиятләренең нигезен тәшкил иткән сюжет турында бер сүз дә юк. Әмма шуңа карамастан, анда баштан ахырга хәтле сүз кимсетелгән, кыерсытылган кыз турында бара: "Күзләремә күренәсең, Төшләремә керәсең. Бу чаклы ук булмас идем, Мин гашыйктыр, күрәсең". Әгәр шигырьнең исемендә үк Үги кыз телгә алынмаса, әле генә китерелгән өзек нигезендә без аны тик гадәти бер мәхәббәт шигыре дип кенә кабул итәр идек. Юк, эш алай җиңел хәл ителми икән. Мәсьәләгә билгеле бер ачыклык кертү өчен шагыйрь Үги кызның ачы язмышын күз алдына китерердәй сүзләр әйтә: "Кимсетүгә, җәберләүгә Ничек кенә түзәсең? Ничек кенә йолып алыйм?—Үзәкләрне өзәсең". Биредә без Роберт Миңнуллин иҗатының буеннан-буена узган тагын бер үзенчәлек—күркәм сыйфат белән очрашабыз. Аның шигырьләрендә, публицистик мәкаләләрендә һәм төрле аудиторияләрдә яңгыраган чыгышларында мәрхәмәтлелек—тормыш-язмыш тарафыннан ничектер кыерсытылганнарга, кимсетелгәннәргә, үгисетелгәннәргә мөмкин булганча ярдәм күрсәтү, һич югы юату, тынычландыру теләге кызыл җеп булып уза. Әкияттәге Үги кызга да ул нинди дә булса ярдәм күрсәтү юлларын эзли:

*"Тәгәри китте йомгагым,*
*Күрмәдеңме, егетем?"—*
*Дип әйт кенә, йомгагыңны*
*Китерермен йөгертеп.*

Әкияттәге йомгакны табып, аны иясенә китереп бирү—әкият каһарманы өчен бик тә зур, могҗизалы ярдәм, әлбәттә! Тик ни әйтсәң дә, бу—саф әкияти-мифологик фантастика-уйдырма гына! Әкияттә ул шулай булырга тиеш тә! Ә бит Р. Миңнуллинның үзе дә, аның лирик герое да—ахыр чиктә безнең көннәрнең реаль персонажлары. Мәсьәләнең әнә шул ягына игътибар итеп, автор аны "тормышчан калыпка" сала. Һәрхәлдә, үзенең сансыз күп җыр персонажларының берсе итәргә тырыша: "Әкияттән җырларыма Алып сине китәрмен". Тик Әкияттән җырга күчерү

генә әлеге катлаулы мәсьәләне хәл итә алмый. Мәсьәләне ничектер башкачарак хәл итәсе иде... Һәм әле генә китерелгән юлларның дәвамы конкрет бер юнәлеш ала: "Үги итмәм, үз итәрмен, Үземнеке итәрмен..."

Әкиятләр—татар халык прозасының иң зур өлешен тәшкил итә; барыннан да элек—тылсымлы әкиятләр, әлбәттә! Соңгылары арасында күләме ягыннан иң зур (китапта—30 бит!), сюжеты буенча—иң катлаулы, киеренке, кырыс, теле-стиле искиткеч матур "Ак бүре" әкияте аерылып тора. Безгә билгеле мәгълүматларга караганда, башка бер генә халыкта да шундый матур һәм шундый зур күләмле әкият юк. Хикмәт нәрсәдә соң? Мәгълүм ки, без белгән бүреләрнең берсе дә ак булмый, без тик соры бүреләрне генә беләбез. Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләрендә гәүдәләнеш тапкан бүреләрнең барысы да соры... һәм аларның барысы да тик тискәре яктан гына сурәтләнәләр. Ак бүре образына исә халык әкиятләре бөтенләй башка мәгънә сала: ул баштан ахырга хәтле тик уңай герой буларак кына хәрәкәт итә. Чөнки ул барыннан да элек—барлык бүреләрнең патшасы, хөкемдары. Әйтик "Елан патшасы Шаһмара", "Ак елан" әкиятләрендә чагылыш тапкан Ак елан; төрки халыклар мифологиясендә һәм әкият-җырларында киң урын алган Аккош, Акбүзат, борынгы һинд мифологиясендәге Ак фил һ. б. кебек үк. Ягъни, халыкара мифологиядә ак төстәге хайваннарның барысы да шул төрнең патшалары-хөкемдарлары, кайвакыт хәтта Аллалары да!

Әгәр Ак бүре—бүреләрнең патшасы икән, димәк, ул—шул ук бүреләр (бу очракта сүз гадәти соры бүреләр турында бара) яшәгән урманның да хуҗасы. Төрки-татар халыкларының байтагында Ак бүре, Ак елан, Аккош, Акбүзат—шул халыкларның тотемы. Ягъни Ак бүре образы дини-мифологик карашларның иң борынгыларыннан берсе булган тотемизм белән турыдан-туры бәйләнгән. Күрсәтелгән терминнарга Академик сүзлек түбәндәгечә аңлатма бирә: "Тотем. Борынгы дини ышанулар буенча: билгеле бер төркем кешеләр белән туганлыкта булган һәм шул кешеләр табына торган хайван, үсемлек, әйбер яки табигать күренеше (мәсәлән, эт, бүре, ат, яшен һ. б.)". "Тотемизм. Ыру-кабилә җәмгыятендә: билгеле бер төркем кешеләр үзләрен тотемнар (хайваннар, үсемлекләр, әйберләр яки табигать күренешләре) белән кардәшлектә тора дип фантастик күзаллауга нигезләнгән ышанулар, мифлар, йолалар һәм гореф-гадәтләр җыелмасы". Бу һичшиксез дөрес билгеләмәләр нигезендә шундый нәтиҗәләр ясарга мөмкин: 1. Ак бүре—төрки-татарларның ата-бабасы; 2. Шул ук Ак бүре—Күктән төшкән Алла дәрәҗәсендә торган изге бер зат. Шуңа күрә кайчандыр аңа табынганнар да. Ә инде ата-бабаның һәм Алланың вазифалары турында сүз чыккач, аларның һәркайсы үзләренең якын туганнары—нәсел-нәсәбе яки үзләре яраткан (Борынгы шәрекъ мифологиясендә—балчыктан, туфрактан ясаган) кешеләр турында һәрвакыт кайгыртучанлык күрсәтеп торырга тиеш. Боларның барысын шагыйрь Роберт Миңнуллин да бик яхшы белә һәм бу хакта берничә шигырендә махсус әйтеп үтә. Мәсәлән, "Күрерсең" дигән шигыре гадәти мәхәббәт турында сөйлидер сыман.

Ләкин ул да тулысынча мифологик фикерләүгә нигезләнгән. Р. Миңнуллинда абстракция шактый югары дәрәҗәгә күтәрелә: егет Урман кызын берничек тә урлый да, таба да алмый. Чөнки, беренчедән, Урман кызы, билгеле бер дәрәҗәдә мифологик персонаж буларак, үзе дә тылсым иясе. Димәк, ул гади бер егеттән качып киткән икән, аны инде хәзер беркем дә таба алмаячак. Икенчедән, мәхәббәттән башы әйләнгән егетнең берминди ярдәмчесе дә юк. Ә менә шушы уңайдан шигырьгә мәрхәмәтле һәм ярдәмчел Ак бүре образы килеп керә дә инде:

*Сихерләдең бугай—газапларның,*
*Сагышларның миндә ак төре.*
*Ярдәм итәр иде—кирәк чакта*
*Килеп чыкмый шунда Ак бүре!*

Шулай булгач, ягъни Ак бүре дә ярдәмгә килә алмагач, егет сөйгән кызын таба да, урлый да алмаячак, билгеле. Шуңа карамастан, егет бөтенләй үк өметсезлеккә бирелми. Тик хикәяләү генә тулысынча мифологик фикерләү яссылыгына күчерелә: "Һич югында мин урлармын синең Сөюеңне—менә күрерсең". Бусы инде, чыннан да, конкрет көнкүрештән ерак торган уйдырма-хыял гына! Яраткан кызының үзен

тапмый-күрми торып, ничек аның сөюен, хис-кичерешләрен урларга мөмкин?— дигән сорау шагыйрьне һич тә борчымый. Һәм моның кирәге дә юк! Сүз бит гадәти хыял турында гына бара! Димәк, аның реаль чынбарлыкка туры килүе яисә килмәве— бусы инде бик вак мәсьәлә... Шигырь түбәндәге матур юллар белән тәмамлана:

*Сөюеңне эзләп аннан үзең*
*Ишегемне ачып керерсең.*
*Күрерсең!*

1994 елның июлендә Роберт Миңнуллин татар халкының иң матур әкияте исеме белән аталган "Ак бүре" шигырен яза. Аңа ул түбәндәгечә махсус багышлама бирә: "Акбүре авылы егете Әнвәр Мәхмүт улы Залаковка". Хәзер инде бу авыл шул Ак бүре исеме белән татар энциклопедиясендә, энциклопедик сүзлектә дә үзенә лаек урын алган.

Р. Миңнуллин шигыре исә чын мәгънәсендәге дастани рухта язылган. Һәм моның берничә мөһим сәбәбен күрсәтеп үтәргә мөмкин: 1. Татар халкының "Ак бүре" әкияте күләме ягыннан да, эчтәлеге белән дә төрки-татар дастаннарына якын тора; 2. Шигырь авторы әлеге әкиятнең үзен дә, аның тарихи-этнографик нигезләрен-мәгънәсен дә бик яхшы аңлый; 3. Шигырь күләме, кеше саны ягыннан шактый зур авыл тормышында булып узган вакыйганы—XVIII гасырдан килгән Тат. Волчья авылының исемен саф татарчага алыштыру күренеше хакында сөйли. Гомумән исем алыштыру, бигрәк тә сүз адәм балалары турында барса, барыннан да элек борынгы миф һәм дастан атрибуты буларак гәүдәләнә. Әйтик, төрки-татарларның мәшһүр дастаны "Идегәй"дә: Кобогыл—Идегәй; үзбәк халык дастаны "Алпомиш"та: Хаким—Алпомиш һ. б.

Күрсәтелгән сәбәпләр белән бәйле рәвештә, әлеге вакыйга авыл туе—Сабан туе рәвешендә бара. Бу үзе шигырьне дастани рухта язуны таләп итә:

*Җыелгансыз бөтен авылдашлар*
*Авылыгызның исем туена,—*
*Тарих битләренә сезнең авыл*
*"Ак бүре" дип бүген уела.*

Әлеге зур, чын мәгънәсендәге эпик тасвирлауга мохтаҗ вакыйганың—авыл исемен алыштыруның мәгънәсен һәм тарихи әһәмиятен ачыклаганнан соң шагыйрь Ак бүре образына, аның югарыда күрсәтелгән дини-мифологик һәм тарихи-эпик мәгънәсен ачыклауга күчә: "Тарихлардан килә ул Ак буре—Төркиләрнең изге җанвары. Ак бүрене изге санаганнар Бабайларның изге җаннары".

Ак бүре образының дини-мифологик карашларның иң борынгыларыннан саналган ата-бабалар культы белән турыдан-туры бәйләнешен ачыклаганнан соң, автор әлеге образга, бик хаклы рәвештә, ифрат та югары бәя биреп, түбәндәгечә яза: "Ул исемнән бөркелепләр тора Аклык, дәһшәт һәм дә горурлык: Дус-ишләрне дәшеп торырлык ул, Дошманнарны кире борырлык". Күргәнебезчә, халык әкиятендә дә Ак бүренең шигырьдә атап кына үтелгән сыйфатлары турында аерым күренеш-мотивлар ярдәмендә тәфсилләп сөйләнә: Ак бүре, аны тыңламаучылар, аның сүзләренә каршы чыгучылар алдында рәхимсез һәм коточкыч куркыныч зат. Ә инде аны тыңлаганнарга, аңа берсүзсез буйсынганнарга (уйларга кирәк—аңа табынганнарга) ул һәрвакыт һәм хәлиткеч ярдәм күрсәтергә әзер.

Алга табан шагыйрь әлеге яңа исем алган авыл хәлләрен тасвирлауга күчә. Аңлашыладыр, шигырьнең эмоциональ янгырашы тулысынча тантаналы мәдхия-гимн төсен ала:

*Дусларыгыз сездән өзелмәсен,*
*Ә дошманнар бераз шүрләсен!*
*Ак бәхетләр иңсен өегезгә,*
*Кара кайгы берүк кермәсен!*

Шулай да Ак бүре образы шигырьдән төшеп калмый гына түгел, ул аның башыннан ахырына хәтле дәвам итә: "Егетләрегезнең мәгърурлыгы Әллә каян тора күренеп. Юкка гына сез Ак бүре түгел, Бардыр сездә, бардыр бүрелек". Һәм ниһаять, шигырь авыл туе—Сабан туенда—янгыраган күтәренке күңелле җыр кебек, авыл тарихы өчен мөһим вакыйганы данлау сүзләре белән тәмамлана:

*Ә бүген без сездә Сабан туен,*
*Авыл туен бәйрәм итәбез...*
*Тат. Волчьяга килеп төшкән идек,*
*Ак бүредән чыгып китәбез!*

***

Гомумән алганда, Р. Миңнуллин үзе бик тә тыныч холыклы кеше булса да (ә бәлки нәкъ әнә шуна күрәдер) аның иҗатында табигатьнең болыт, жил, давыл кебек дәһшәтле күренешләре ярыйсы ук зур урын биләп, шигъриятенә, аерым әсәрләренә үзенчәлекле энергия, гайрәт өстәп, аларның эмоциональ яңгырашын көчәйтеп, интонациясен югары бер әдәби-эстетик дәрәҗәгә күтәрә.

Р. Миңнуллин шигъриятендә болыт, бик борынгыдан килгән серле мифологик категория буларак, төрле, еш кына капма-каршылыклы шигъри ассоциацияләр тудырырга ярдәм итә. Һәм Р. Миңнуллин бу мөмкинлекләрдән еш кына һәм кирәк дәрәҗәдә оста файдалана.

Р. Миңнуллинның "Кара көз" шигыре түбәндәге шактый кырыс юллардан башлана:

*Ниндидер көч йөри җирдә!*
*Ул үзе җил кыяфәтле.*
*Бәгырь аша уза ул җил,*
*Әйтерсең лә ул афәтле.*

*Ул, ахры, көз ияседер—*
*Чыгарганнар терелдереп.*
*Болытны, хәтта кояшны*
*Йөртә ул бөтерелдереп.*

Шигырьдән китерелгән шушы сүзләрдә генә дә табигатьнең иң дәһшәтле күренешләреннән берсе булган җилнең төп тормышчан һәм шул ук вакыт мифологик сыйфатлары чагыладыр сыман: барыннан да элек җил—ниндидер, адәм баласы аңлап бетерә алмаган серле-сихерле, шул ук вакыт—бик тә куәтле, җегәрле көч! Ул афәт, фаҗига китерергә дә сәләтле: ул—көз иясе. Чынбарлыкта да бит ул шулай: илдә булган зур һәм куркыныч тарихи вакыйгалар куерган елларда барлыкка килгән "Көзге ачы җилләрдә" җырын гына искә төшерик... Ул хәтта болытның гына түгел, Кояшның да хөкемдары—аларны "бөтерелдереп" йөртә ала!

Р. Миңнуллин кайвакыт Җилнең "унай" һәм "тискәре" сыйфатларын бергә укмаштырып бирә. "Иртәнге пейзаж"да, мәсәлән, түбәндәге сүзләр дә бар: "Таң җилләре таң чыкларын Өрә-өрә сүндерә". Әйе, таң чыклары үзләре дә бик матур, үзенчәлекле күренеш. Әмма аларның гомере беркайчан да озын булмый: таң чыкларын—Җил булмаса, Кояш киптерә.

Аерым шигырьләрдә Җил образына мөрәҗәгать итү әсәрнең эмоциональ яңгырашын, көч-куәтен, җегәрен илаһи бер югарылыкка күтәрәдер сыман. "Ан—2" тәрҗемә-шигырендә шул исемдәге самолетта Себер тайгасын, урман-кырларын, Себер кешеләренең эшләгән эшләрен күреп, шагыйрь шакката:

*Кайный Себер җире! Кайнар—җиле!*
*Ә офыкта ал таң сызыла.*
*Көнчыгышның кан тамырлары кебек*
*Себер аша торба сузыла.*

*Эшчеләрнең бу—гадәти көне.*
*Алар инде монда күптәннән,*
*Корыч кебек җилдә кайный-кайный,*
*Себер халкы булып беткәннәр.*

Тик кайвакыт, хәтта бик кирәктә дә, илаһи бер кодрәткә, көч-куәткә ия булган Җил дә адәм балаларына ярдәм итә алмый. "Яңгырсызлык" шигырендә сүз нәкъ әнә шул хакта бара: "Әллә инде онытты ул юлын, Әллә инде юлда адашты? Җилләре

дә килеп житкән иде—Юк, яумады янгыр, алдашты". Аерым очракларда шагыйрь Жил образыннан шаян-юмористик яссылыкта файдалана. Мисалга, "Төнге дингез. Маяк. Йолдызлар" да: "Йөрәкләргә дәшә күнел—Кешеләр йөрәгенә. Ә тозлы жил, сүндерәм дип, Маякка өрә генә!..". Жилнең "вакытсыз шаяруы" жинелчә рәнжү уятырга да мөмкин. "Соңгы яфраклар" шигыре түбәндәге сүзләрдән башлана: "Яфракларның күчеш чоры—Куктән жиргә, туган жиргә. Үпкәләре көзгә түгел, Ә үзләрен куган жилгә".

Жил образының шигъри-эстетик вазифаларын ачыклауга багышланган сүзне йомгаклау өчен чын мәгънәдә оптимистик рухта язылган "Яз. Чәчү алды" шигыренең соңгы юлларына тукталып үтик:

*Җилләр әзер*
*Кояш нурларында*
*"Яшәү" дигән көйне башкарырга.*
*Яңгыр!*
*Кояш!*
*Ташламагыз җирне—*
*Иң изге эш тора башланырга!*

* * *

Роберт Миңнуллинның кискен-киеренке рухта язылган шигырьләрен, бигрәк тә илебездәге бүгенге авыр тормыш шартларына кагылган әсәрләрен укыганда, кайвакыт: "бу шигырьләрне дә Роберт Миңнуллин иҗат итте микәнни?"—дип, аптырап та каласың. Буран-давыл җилсез булмый дигәндәй, без биредә Р. Миңнуллин шигъриятендә киң чагылыш тапкан Давыл-Буран образына да килеп җиттек.

*Давыл көткән җаным*
*Давылларның*
*Кукрәгенә барып капланыр.*
*Тиз тынмас ул давыл.*
*Озак көннәр*
*Нәкъ шундый ук һава сакланыр.*

Роберт Миңнуллин шигъриятендә зур, илаһи вакыйгалар сурәтләнми кебек. Ләкин ул табигатьтәге, җәмгыять-ил тарихындагы, бигрәк тә үзенең күңелендә-җанында булган кискен-кырыс үзгәреш-борылышларны сурәтләгәндә шул ук Җил—Давыл, Буран белән бәйле символик-шигъри ассоциацияләргә мөрәҗәгать итәргә ярата, һәм шул ук дәһшәтле күренеш-образларга кат-кат туктала. Барыннан да элек шагыйрь Буранны, мәсәлән, табигатьнең бер күренеше, лирик геройның тыныч кына барган тормышына билгеле бер үзгәрешләр китергән халәте итеп сурәтли. "Сагынам мин Яркәеңне"дә сүз кайчандыр булып узган, ләкин һич тә онытылмаган яшьлек мәхәббәте турында бара. Әнә шул көннәрне сагынып, лирик герой болай дип тә куя: "Яшьлек гел шундадыр кебек—Яркәй урамнарында. Исеңдәме, йөри идек Яркәй бураннарында".

Шагыйрьнең ак төсне, ак каенны, ак карны яратуы, аларга тирән ихтирам белән каравы турында югарыда шактый язылган иде инде. Шагыйрь ак кар белән бәйле буранга да шундый ук мөнәсәбәт саклый. Күрсәтелгән шигырьнең түбәндәге сүзләре нәкъ әнә шуны раслап тора: "Күмеләсе килә көртләренә, Ураласы килә буранга. Ярсуларны тыеп буламыни, Янәшәдә буран булганда..." Кайбер очракларда шагыйрь үзен һәм үзенең шигъриятен ак бураннардан тыш гомумән күз алдына китерә алмый. "Бураннарым белән барам" шигыренең исеме үк шуны раслап тора: "Ак урамнар буйлап килә Ак бураннар эченнән. Гомеремдә әнә шулай Күпме буран кичелгән"... Әлеге шигырьдә генә дә буран сүзе ун тапкыр кабатлана. Бер карасаң, шагыйрь үзенең көндәлек тормышын да, иҗатын да, күрәсең, киң мәгълүм сәяси эшчәнлеген дә бураннарсыз күз алдына да китерә алмый: буран аңа кагылмаса, ул үзе барып, балаларча буранга бәйләнә (Р. Миңнуллинның күптән танылган балалар язучысы да булуын онытмыйк!). Моны ул үзе, бик хаклы рәвештә, үзенең иң гүзәл сыйфатларыннан берсе дип саный: дөрестән дә, ул бит кешеләргә бәйләнми

(гомумән, аны бу сыйфатта берничек тә күз алдына китереп булмый!); сүз бит табигать күренеше турында бара. Күрсәтелгән шигырендә ул болай ди: "Күңел булмый—бураннарга Чыгып бер бәйләнмәсәм. Жанда—буран. Ярый инде Буранга әйләнмәсәм". Шигырьдә алга табан әйтелгәнчә, шагыйрь үзе бураннарга буйсына, әмма аларны буйсындыра да ала. Чөнки буран аның жанында-канында:

*Кышның утлы бураннары*
*Ярсып уйный канымда.*
*Кызу канлы бураннарны*
*Тыялмый бер канун да...*

Шул рәвешчә, шагыйрьнең үзе дә, халәте-шигърияте дә кар-бурансыз яши алмый...

Давыл образы Р. Миннуллин шигъриятендә бураннардан сирәгрәк очрый кебек. Рәдиф Гаташка җавап рәвешендә язылган "Дуска җавап" шигыре, мәсәлән, шундый юллардан башлана:

*Үпкәләгән хатың килгән.*
*Үпкәләргә бармы хакың?*
*Давыл тулы, ярсу тулы,*
*Бәхәс тулы синең хатың.*

Һәм бу сүзләр Рәдиф Гаташның үз-үзен тотышына, холкы-характерына гына түгел, шигъриятенә дә төгәл туры киләдер кебек. Шул ук вакыт шагыйрь үз иҗатының һәм Р. Гаташ шигъриятенең аермаларын да бик яхшы аңлый һәм болай ди: "Мин тын аккан елга кебек. Язгы Идел—синең күңел. Мин сыям үз ярларыма, Ә син менә андый түгел".

1991 елда Нажар Нәжми Роберт Миннуллинның үзе һәм шигърияте турында түбәндәгечә язган иде: "Роберт Миннуллин шигырьләре бик тә йөрәккә ята торган шигырьләр. Ни өчен соң алар шундыйлар? Иң башта шагыйрьнең табигате, холкы, җан сулышы, эчкерсезлеге шигырьләренә күчүендә, үзендәге бар мөмкинлекне туачак шигыренә бушата белүендә, талантында, осталыгында. Шагыйрьнең тормышта нинди булганлыгын белгәнгә күрә, үз табигате белән шигырьләре арасында аерма таба алмыйм, шигырьләре дә үзе шикелле—"Мин фәлән-төгән!" дип күкрәк какмый, кычкырмый, шау-шусыз, салмак һәм акыллы".

Роберт Миннуллинның Давыл образы белән нисбәтле шигырьләренең иң көчлеләреннән берсе—"Дуамал егет турында баллада". Анда сүз Чили патриоты, Пиночетның хәрби диктатура урнаштыруына каршы баш күтәрүчеләрнең беренчеләреннән булган шагыйрь һәм җырчы Хара турында бара. Шуңа күрә, табигый, "дуамал егеткә" багышланган балладаның беренче юлларына ук Давыл образы килеп керә:

*Ул дуамал иде давыл кебек,*
*Ул җилбәзәк иде җил кебек.*
*Ул тын гына яши белми иде,*
*Яши иде җирдә җен кебек.*

Башта әлеге дуамал Егет гитарада уйный да, җырлый да белми. Ачуланып-гарьләнеп, ул гитара кылларын чиертә башлый. Тора-бара аның уйнавы "нәфрәт давылына" әйләнә: "Җиде кылдан чыккан җиде аваз Җидесе дә бергә буталып, Әйләнделәр нәфрәт давылына, Егет йөрәгеннән ут алып!"

Чилида әле генә урнашып килгән тоталитар режимга кискен каршы чыккан Хараны үтерәләр һәм гитарасын челпәрәмә китерәләр. Шигырьнең беренче строфаларын укыгач та: элегрәк ишетеп тә белмәгән Виктор Хараның безнең илдән меңнәрчә чакрым ераклыкта, океан артындагы Көньяк Американың да ерак көньягында урнашкан Чилида булган киеренке вакыйгаларның безгә ни катнашы бар?!—дигән сорау туарга мөмкин. Бу сорауга җавап рәвешендә шуны әйтик. Беренчедән, ул елларда Чилида булып узган киеренке вакыйгалар бик күп илләр-халыкларның игътибар үзәгендә иде; икенчедән, әлеге сорауның туу мөмкинлеген аңлаган Р. Миннуллин үз шигырен икенче бер җитди сюжет белән дәвам итә: сүз гитарада уйнаган икенче бер Егет язмышына күчә. Бу егетнең үзенең дә, аның гитарасының да язмышы Хара фаҗигасен хәтерләтә. Егет тә шашынып гитарада уйный:

*Бәргәләнде тездә яшь гитара—*
*Бер елады ятып, бер көлде.*
*Ә аннары тынды.*
*Кинәт кенә*
*Юкка чыкты Егет беркөнне...*

Бу Егет ерак Себер ягына киткән булган икән. Һәм бераздан авыр хәбәр килә: "Батырларча һәлак булган Егет—Эшләгән ул жаны кушканны". Элегрәк гитарада белер-белмәс уйнап йөргән Егеттән көлгәннәр: чөнки ул гитарасын беркайчан да үзеннән калдырмый торган булган. Ә инде ул якын дусларын коткарганда батырларча һәлак булгач, төрле халыкларда бик борынгыдан килгән изге, билгеле бер дәрәҗәдә мифологик йола буенча: "Ә күмгәндә Тантаналы төстә Гитарасы белән күмгәннәр!"

Беренче карашка, "Дуамал Егет турында баллада" бер-берсе белән бәйләнмәгән ике сюжеттан тора сыман: ерак Чилида һәлак булган Хара һәм шулай ук ерак Себердә фаҗигагә дучар булган Егет. Тик аларның беренчесе илдәге түнтәрелеш чорында үтерелсә, икенчесе тыныч тормыш чорында батырларча һәлак була. Әмма әлеге балладага рухи-әхлакый, вөждан, бернинди куркыныч каршылык-киртәләргә карамастан үз бурычыңны үтәү яссылыгыннан якын килсәк, балладаның һичшиксез эзлекле һәм баштан ахырга хәтле бик тә югары шигъри, эмоциональ рухта яңгыраганын күрербез.

*Җиде кылдан чыккан җиде аваз*
*Бер моң булып җиргә тарала.*
*...Кыяфәте, йөзе белән дә ул*
*Бик охшаган иде Харага...*

Р. Миңнуллинның "Марафон" дигән бик мәгънәле шигыре бар. Ул баштан ахырга хәтле татар халкының тарихына һәм киләчәгенә багышланган!

*Син дә, халкым, киткәнсең дә*
*Кешелеккә ияреп,*
*Киләсең ерып чорларны,*
*Алдыңда баш иярлек.*

Әйе, татар халкы, аның ата-бабалары узган юл чыннан да озын-озак, берничә мең елга сузылган һәм төрле-төрле илләр, халыклар язмышы белән бәйләнештә барган. Ул Җир шарындагы материкларның яртысы аша узган. Нәкъ әнә шуңа күрә хәзер безнең зыялылар арасында "Евразия" сүзе татар халкы язмышы белән бер бәйләмдә кулланыла башлады. Шагыйрь бу хакта болай ди: "Абынып та егылгансың, Чалып та екканнардыр. Шуңа кайчак кайберәүләр Алга да чыкканнардыр"... Татар халкының тарихи язмышына багышланган бу шигырьгә алга таба "марафон", "финиш" кебек спорт сүзләре килеп керә. Ә шигырьнең соңгы дүртьюллыгы түбәндәгечә яңгырый:

*Сокланып сиңа гасырлар,*
*Чорлар кул болгаячак!*
*Марафон дәвам итә.*
*Тик*
*Финишы булмаячак...*

Шулай итеп, Роберт Миңнуллин үзе дә, аның шигърияте дә, Жил-Давыллар һәм Кар-Бураннар аша үтеп, үсешен уңышлы дәвам итә. Шагыйрь язмышы татар халкы, аның зур тарихи юлы—үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге—белән турыдан-туры бәйләнгән. Шагыйрьнең тормыш юлы, шигърияте һәм публицистикасы, актив сәяси эшчәнлеге нәкъ әнә шул хакта сөйли!..

Ғәп
Фән

**Сәвия Михайлова**
*тарих фәннәре докторы, профессор*

**Рөстәм Циунчук**
*тарих фәннәре кандидаты, доцент*

# БАШКАЛАБЫЗ КАЗАН

*Казан шәһәре 2005 елның август ае азакларында шаулатып-гөрләтеп үзенең мең еллыгын бәйрәм итте. Әлбәттә, шәһәр кадәр шәһәр бер елда гына барлыкка килмәгән, аның тарихи үткәне дә, бүгенгесе дә гаять катлаулы. Ул дөнья цивилизациясе тарихында үзенчәлекле бер урын алып тора. Монда бит Европа белән Азия очраша, шуңа бәйле рәвештә, табигате дә урманлы һәм далалы җирләргә бай. Биредә төрле телле халыклар һәм ислам белән христиан диннәре тату үзара килешеп яши. Болар барысы да Европаның көнчыгышында урнашкан борынгы, шулай ук хәзерге Россиядә иң зур шәһәрләрнең берсе һәм Татарстанның башкаласы булган Казанның үзенә генә хас йөзен билгеләгән.*

## Шәһәрнең барлыкка килүе

Казан шәһәренең барлыкка килүе аның төрле цивилизация һәм мәдәниятләрнең үзенчәлекле бер төбәгендә урнашуына бәйле. Казан тарихчысы Н. Ф. Калинин үзенең хезмәтләрендә бу урынның Урта Идел буендагы Европаның иң зур елгалары Идел белән Чулман (Кама) тирәсендә булуын билгеләп үтә. Йөгрек Казансу елгасының куәтле Иделгә кушылган тамагы тирәсенә төрле халыклар бик борынгыдан ук тартылганнар, алар әле таш гасыр заманнарыннан ук Кремль калкулыгы белән якын-тирәдәге яр буйларына туплана башлаганнар. Безнен эрага кадәрле ике меңенче елларда, бронза гасыры башында ук, булачак Казан тирәләрен төрле кабиләләр үзләштергән. Бронза чорыннан башлап фин-угор урман кабиләләре көнчыгыштарак яшәгән балтыйк-алман-славян кабиләләре, ә көньяктан һинд-иран һәм борынгы төрки кабиләләр йогынтысына бирелә башлаганнар. Ике арада сәүдә алмашу, үзара аралашу көчәя: төньяктан мамонт тешләре-сөякләре, көньяк-көнчыгыштан бронза һәм бакыр, көмеш һәм тимер керсә, көнбатыштан мәгъдән, пыяла һәм гәрәбә эшләнмәләре килә. Күчмә төрки һәм сармат-алан кабиләләренең йогынтысы коралларда, кием-салымнарда, ат дирбияләрендә чагыла. VI-VIII гасырларда Идел, Чулман, Казансу яр буйларына Болгар төркиләре күтәрелә, алар инде күчмә дала кабиләләре генә булмыйча, бәлки Төньяк Кавказ һәм Кара диңгез буйларындагы Бөек Болгар белән Хазар каганатларыннан күреп, игенчелек, сәүдә-һөнәр эшләре белән дә шөгыльләнәләр.

Болгарлар X гасырда Татарстан төбәгендәге беренче зур дәүләткә—Идел Болгарына нигез салганнар. Бу чорда Идел-Урал төбәгенең хуҗалык итү, мәдәни-этник һәм геосәяси үзенчәлеге ачыклана башлый, бу үзенчәлек алга таба мөстәкыйль алгарыш-үсешкә нигез була.

Идел белән Казансу кушылган урында Казан шәһәре барлыкка килүнең төп

алшарты булып Идел—Хазар сәүдә юлындагы сәүдә үсеше тора. Безнең эраның беренче мең еллыгы ахырына бирелдәге сәүдә эшләре "варяглардан грекларга" дип аталган сәүдә юлындагыдан һич тә ким булмый. Шулай итеп, Идел Болгарының төньягында Казан шәһәре калкып чыга. X гасыр азагы—XI гасыр башларында Казан җирле һәм килеп-китеп йөргән сәүдәгәрләрнең игътибарын кальга-кирмән һәм сәүдә үзәге буларак җәлеп итә. Моны Казан Кремлендә соңгы елларда алып барылган казу эшләре вакытында табылган әйберләр дә раслый. Анда җирле һөнәри эшләнмәләр—керамика, корал, хезмәт кирәк-яраклары, бизәнү әйберләреннән тыш, X гасырның беренче яртысына караган саманидлар дирхәме, X гасырның беренче чирегендәге чех денарие, балтыйк буе гәрәбәсе, иран савыт-сабалары, Киевтән килгән пыяла беләзек, венгрларга хас бронза эшләнмә, ахак муенса кебек әйберләр дә була.

Болгар чорында ук Казан үзенең үсешендә төрле халыкларның аралашу үзәгенә әверелә. Башлыча төрки һәм фин-угор телле кабиләләр төбәгендә урнашуы аның мәдәни-этник үзенчәлеген дә билгели. Гарәп-фарсы сәяхәтчесе Ибн-Руста X гасырда Болгар дәүләте турында беренче мәгълүматларны китерә, ул: "Болгарлар Хазар дингезенә коя торган Итил елгасы яр буйларында яши, әлеге елга хазар һәм славян җирләре аша да уза",—дип яза. Казанлылар Русь белән, Урта Азия, Шәрык илләре һәм Византия белән сәүдә алып баралар. 922 елда Болгар ханы Алмыш Идел Болгарында дәүләт дине итеп ислам динен кабул итә. Шул рәвешле, Казан, дини яктан ислам-христиан-мәҗүси диннәр катнашмасыннан торса да, иң төньяктагы ислам шәһәре булып таныла. Шәһәрдә Идел буйлап килгәндә дә, Казан Кремленә таба коры җирдән атлаганда да күренә торган мәчет манаралары калкып чыга. Ислам динен кабул иткән ханлыкта гарәп язуы гамәлгә керә, мәктәп-мәдрәсәләр дини мәгърифәт һәм белем учакларына әверелә, укымышлы кешеләр гарәп-мөселман дөньясындагы мәдәни вә гыйльми белемнәр белән таныша башлый.

## Казан урта гасырда

XIII гасырда Батый хан гаскәрләре һөҗүме аркасында Идел Болгары дәүләт буларак үзенең мөстәкыйльлеген югалта, аның күп шәһәрләре юк ителә, халкы төрле якларга, нигездә Казан якларына күчеп китә. Шулай итеп, Казан Болгар дәүләте традицияләрен саклап калган һәм аны алга таба үстергән үзәккә әверелә. XIII-XIV гасырлар чигендә элекке Идел Болгарының төньяк-көнбатыш ягында башкаласы Казан булган Казан ханлыгы барлыкка килә. Ханлыкның төп халкы төрки телле мөселманнар булып, болгар-кыпчак кабиләләре нигезендә оеша. Шул чордан халык үзен "мөселманнар", бераз соңрак "Казан татарлары" дип йөртә башлый.

Казан шәһәренең яңа үсеш чоры, шул рәвешле, 1438 елда Казан ханлыгы оешу белән башлана һәм 1552 елда Рәсәй патшасы Явыз Иванның Казанны яулап алуы белән тәмамлана. Йөз елдан бераз гына артыкка сузылган бу тарихи аралыкта Казан дөнья тарихында Идел Болгарының икътисади һәм мәдәни мирасын кабул иткән яңа дәүләтнең башкаласы буларак билгеле. Шул ук вакытта инде чыңгызлылар нәселе җитәкчелек итә башлаган Казан ханлыгы, Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң, Идел—Хазар сәүдә юлында һәм Көнчыгыш Европада өстенлек итү өчен сәяси көрәшкә тартыла. Казан зурлыгы ягыннан Көнчыгыш Европа шәһәрләре арасында өченче урында санала. Венеция сәүдәгәре дипломат Иосафат Барбаро, XV гасыр уртасында Көнчыгыш Европага сәяхәт кылып, Казан турында болай дип яза: "Ул—сәүдә шәһәре: аннан Мәскәүгә, Польшага һәм Пруссиягә гаять күп мехлар чыгарыла".

Читтән килгән сәүдәгәрләр гадәттә Кунак утравында ("Маркиз" утравы) тукталалар, анда һәр елны халыкара ярминкә уздырыла, ә төп җирле ярминкә Кремль буендагы Ярминкә мәйданында ("Ташаяк" ярминкәсе) үтә. Арча кырындагы ярминкә дә сәүдә урыны булып таныла. Чит сәүдәгәрләргә Казан һөнәрчеләре һәм сатучыларының тәкъдим итеп кызыктырырлык товарлары күп була. Тимерчелек һәм корал ясау эшләре дә югары дәрәҗәгә күтәрелә. Болгар традицияләрен дәвам иткән казанлылар зәргәрлек һәм декоратив эшләнмәләр сәнгатен үстерәләр.

Шәрык белән Гареп йогынтысын үзләштерә барган Казанның архитектурасы да янара. Казан Кремленең мәйданы зурая, анда Хан сарае һәм таш Хан мәчете белән беррәттән Җәмигъ мәчете (Кол Шәриф мәчете) дә төзелә, Ширин әмирләре сарае, Нургали мәчете, Казан ханнарының таш мавзолейлары корыла. Кремльгә халкы һаман күбәя барган бистә терәлеп тора. Андрей Курбский, матурлыгы ягыннан Көнчыгыш Европа башкалаларының берсе дә Казан белән тиңләшә алмый—ни Мәскәүе, ни Бакчасарае, ни Сарай шәһәре, дип раслый.

Казан ханлыгы да, табигый ки, аның башкаласы да күпмилләтле булуы белән аерылып тора. Мона шул ук рус воеводасы Андрей Курбский да игътибар итә. Ул: "Әлеге патшалыкта, татар теленнән кала, тагын биш төрле тел—мордва, чуаш, чирмеш, ар һәм бишенчесе башкорт телләре",—дип яза. Шәһәрдә чит ил сәүдәгәрләренең берничә төбәге—әрмәннәрнеке Беренче тау тирәсендә, русларныкы Федор калкулыгы белән Адмиралтейство бистәсендә, бохаралыларныкы Төзек күпер янында урнашкан була. Казанда шулай ук чыгышлары белән Кырымнан, Төркиядән, Кавказдан (Шемахадан) булган халыклар да байтак яши.



*Казан Кремленең Казансу елгасы ягыннан күренеше. XVIII гасыр.*

Әйе, Казан ханлыгы чорында Казан каласы эре сәяси һәм административ үзәккә әверелә. Ул дәүләтнең югары хакимияте һәм ханнар резиденциясе булып санала. Алтын Урдадан мирас итеп алынган сәяси традицияләр, Шәрык исламы шәһәрләренә хас рәвештә, яңа сәясәт һәм хакимият оешмалары тууга китерә. Хакимиятнең иң югары баскычында хан һәм аның гаилә әгъзалары тора, алар Кырымны, Нугай Урдасын һәм Алтын Урда дәүләтен башка илләрдәге Чыңгыз нәселләрен туганлык җепләре белән бәйли. Хан сарае тирәсенә бәкләр, әмирләр, морзалар, ханлыкка караган халыкларның кенәзләре туплана. Мөһим дәүләт эшләре иң атаклы нәселле дүрт гаилә вәкилләре тарафыннан диванда, ягъни югары киңәшмәдә кабул ителә. Башка Шәрык дәүләтләрендәге шикелле, биредә дәүләт һәм хан сарае тормышы белән вәзирләр идарә итә. Шәһәр халкының бер өлеше казна кешеләре—хаттатлар, тылмачлар, тамгачылар (салым җыючылар), күзәтеп торучылар. Хәрбиләр—хан гвардиясе, угланнар, баһадирлар, эчке казаклар да аз булмый.

Дәүләтнең башкаласы буларак Казанда мәхкәмә (суд) һәм дини оешмалар да туплана. Хөкемдарлар кадый вә казыйлардан булса, руханилар исә башында сәет булган муллалар, хаҗилар, дәрвишләрдән тора.

Шулай итеп, Казан Көнчыгыш Европадагы иң зур мәгърифәт, фән һәм мәдәният үзәгенә әверелә. Ислам руханилары карамагында күпсанлы мәктәп вә мәдрәсәләр ачыла, шәһәр халкы укымышлылыгы белән таныла. Җәмигъ мәчете каршындагы Кол Шәриф мәдрәсәсе шәкертләренең 1552 елда Явыз Иван Казанга һөҗүм иткән вакытта батырларча каршы торганлыклары билгеле. Шәһәрдә китапларны күчереп язу һәм төпләү остаханәләре пәйда була. Хан сарае янында күчереп язучы хаттатлар, галимнәр һәм шагыйрьләр бергә җыелып эш алып бара торган бик бай китапханә була. Казан шагыйрьләре Мөхәммәдьяр, Өммикамал, Мөхәммәдәмин, Гарифбәк һәм Кол Шәрифләрнең даны еракларга тарала.

XV гасыр уртасыннан алып XVI гасырның беренче яртысына кадәр Казан Көнчыгыш Европаның халыкара сәясәтенә актив катнашып килә. Бу сәяси һәм хәрби көрәш Көнчыгыш Европада өстенлек итәргә, Идел—Хазар сәүдә юлын үз

кулында тотарга омтылучы дәүләтләр арасында аеруча көчәеп китә. Көрәштә эре дәүләт берләшмәләренең өчесе катнаша. Беренчесе Кырым ханлыгы белән берлектә Казан ханлыгы үзе булса, икенчесе—Польша белән берлектәге Бөек Литва кенәзлеге һәм өченчесе Мәскәү дәүләте була. Төп өстенлекне үзәкләшеп-көчәеп килүче Мәскәү дәүләте яуларга омтыла. Мәскәү белән Казан бер-берләренә каршы һөҗүм арты һөҗүм оештыра башлыйлар. 1461 елдан 1552 елга кадәр казанлылар рус шәһәрләренә сигез тапкыр һөҗүм итсә, руслар исә шул вакыт эчендә егерме биштән артык һөҗүм ясыйлар, еш кына Казанны алып, аны җимереп, талап китәләр. Идел-Хазар сәүдә юлын тулысынча үз кулына алырга, Казан ханлыгының бай җирләренә хуҗа булырга, Себерне дә яулап алу өчен юл ачарга тырышкан рус патшасы Явыз Иванның хәрби-сәяси максаты һаман ныграк ачыклана бара. Ул 1545 елдан башлап Казанга һич тынгылык бирми, даими һөҗүм итеп тора.

1547—1950 еллардагы рус һөҗүмнәре уңышсызлыкка очрый. 1552 елның август ае ахырында йөз илле менле рус армиясе Казанны камап ала һәм ай буе сугыша. Көчләр тигез булмый, Казанга ярдәмгә ашыгучылар да күренми, казанлыларның батырларча каршы торуына карамастан, Кремль диварларын шартлатканнан соң, руслар шәһәрне басып ала. Казанны талап-яндырып бетерәләр. Исән калган татарларның күбесен кырып, бер өлешен әсирлеккә алып китәләр. Ни кызганыч, Казан ханлыгы шул рәвешле юкка чыгарыла.

## Яулап алынган Казанның алдагы хәле

Казан ханлыгын хәрби юл белән көчләп үзенә кушкан Россия дәүләте Евразия державасына әверелә. Казан татарларының дәүләтчелеген бетерү рус империясенең көнчыгышка һәм көньякка таба экспансия ясавында беренче адым була. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап Россиянең мондагы сәясәте татарларны көчләп чукындыру һәм руслаштыруга кайтып кала.

Шулай да Казан яңадан аякка баса башлый, әмма йөзе үзгәрә инде. Шәһәр нигездә рус шәһәренә әйләнә, татарлар Болак һәм Кабан күле артына куыла, анда Татар бистәсе барлыкка килә. Мәскәү, Түбән Новгород, Вятка һәм башка төбәкләрдән Казанга руслар күпләп килеп тула. Бистәдә исә, татарлардан тыш, нугай, әрмән кебек шәркый халыклар белән бергә немецлар, поляклар, яһүдләр дә күренә башлый. XVII гасырның утызынчы елларында немец сәяхәтчесе Адам Олеарий Казан турында болай дип яза: “Бөек кенәз бирелә Кремльгә воевода утыртып кына калмый, шәһәргә дә халык белән теләгәнчә идарә итә торган махсус шәһәр башлыгын куя. Шәһәр руслар һәм татарлар белән тулган, ләкин Кремльдә бары тик руслар гына, анда бер генә татар да булмаска тиеш, юкса аңа үлем куркынычы яный”.

Шул рәвешле, Казан икегә бүленеп яши башлый, әйтерсең, ул ике шәһәр. Беренчесе – рус-христиан шәһәре, икенчесе—мөселман татарларыныкы. Кабан артындагы “татар Казаны”, кысу-тыюларга да карамастан, үз гореф-гадәтләрен саклап калучы үзәк кенә булмыйча, әкренләп төрле этник-мәдәни аралашу төбәгенә дә әверелә.

Идел буе халыкларын колониальләштерү һәм буйсындыру максатында Казанның торгызылуы хәрби-административ үзәк булуы белән аңлатыла. Казан ханлыгының җимерелгән ныгытмалары урынына Кремльнең диварларын һәм манараларын таштан төзи башлыйлар, сарайлар һәм мәчетләр урынына аларның нигезләре өстендә чиркәүләр һәм административ биналар пәйда була. Казан Кремлен һәм чиркәүләрне төзү өчен Псковтан атаклы рус төзүчеләре Постник Яковлев белән Иван Ширяй җитәкчелегендәге ике йөзләп төзүче килә. Шунысы кызыклы: шәһәрнең яңа архитектурасы рус шәһәр төзелеше булып кына калмый, җирле татар милли-мәдәни төзелеше сыйфатлары да күзәтелә.

Казан архитектурасының гүзәл үрнәге—Сөембикә манарасы. Ул рус һәм татар халыклары архитектурасы һәм төзелеш техникасының уртак һәм иң яхшы казанышларын чагылдыра.

Һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак Казанның хуҗалык эшчәнлеге гомумроссия

икътисады белән тыгыз бәйләнештә була. Идел—Хазар сәүдә юлы бөтенроссия базарының төп юлына әверелә. Ул Казанны Мәскәү, Түбән Новгород, Әстерхан белән бәйләп тора. Мәскәү, Бөек Устюг, Архангельск шәһәрләре аша казанлылар Көнбатыш Европа базарларына, Әстерхан аша Кавказ илләренә, Иранга һәм Урта Азиягә барып чыгалар. Себер белән, бигрәк тә шәркый мөселман илләре белән Россия арасында икътисади арадашчы булган Казанда татар сәүдәгәрләренең йогынтысы аеруча көчәя.

Рус дәүләтенең Казандагы һәм Казан төбәгендәге татарларны һәм башка халыкларны көчләп чукындыру сәясәте иң мөһим һәм хәлиткеч сәясәт булып тора. Казан алынып озак та үтми, административ-чиркәү идарәсен булдыру максатыннан Казан дини епархиясе оештырыла, аны тотуга татарлардан җыелган барлык салымның уннан бер өлешен биреп бару карала. Чиркәүләр төзелә башлый, Кремльдәге Благовещение чиркәве таштан салына, рус руханилары һәм монахлары бик тиз ишәя. Христианлаштыру үзәкләре буларак Казан һәм аның тирәсендә монастырьлар—Спас-Преображение, Йонан-Предтеча, Богородицкий, Раифа һәм Елантау монастырьлары калкып чыга. Аларга зур-зур җир һәм урман биләмәләре бүлеп бирелә. Рус миссионерларының тырышлыгы бушка китми—XVI гасырда татарлар арасында керәшеннәр барлыкка килә. Рус патшасы Федор Иванович 1593 елда, мәчетләрне, шул исәптән татар бистәсендәгеләрен дә юк итәргә, керәшеннәрне мөселман татарлардан аерып утыртырга, дигән фәрман бирә. Моңа җавап төсеннән бик күп Казан татарлары Урал якларына күчеп китә.



*Сөембикә манарасы. XIX гасыр.*

Казан үсешендәге яңа чор XVIII гасырда башлана. Рус патшасы Петр I дәүләт тормышын заманга ярашлы итәргә омтыла, крепостнойлык көчәя, самодержавие ныгый, илне тагын да кинәйтү-зурайту максатыннан армия һәм флот төзелә. Петр I Россияне империя дип игълан итә, Казан ул оештырган сигез губерна үзәкләренең берсенә әверелә. Баштарак губерна күпмилләтле Идел буе һәм Урал алды җирләреннән тора, аның чикләре элекке Казан ханлыгы чикләреннән күпкә зур була.

Казан губернасы оештырылгач, шәһәрдә административ идарәнең яңа бюрократ түрәләре һәм хәрбиләр күбәя. XVIII гасыр азагына бер Казан губерна канцеляриясенә генә дә иллегә якын чиновник түрәләр, ә Казан гарнизонында өч пехота һәм бер драгун полкы була. Реформатор патша Петр I Кремльне һәм шәһәр үзеген "регуляр төскә керде" дип әйтергә ярата. Агач тротуарлар, яңа күперләр төзелә, шәһәр фонарьлар белән яктыртыла башлый. Кремльдә һәм аның тирәсендә таш биналар—губернатор йорты, губернатор канцеляриясе, монастырьлар идарәсе, арсенал калкып чыга. Петр I Казанга аяк баскан беренче рус императоры була, ул анда 1722 елда, Персиягә хәрби походка барганда туктала һәм үзенең илле яшьлеген бәйрәм итә. Аның килүе хөрмәтенә Казанда Петропавел чиркәве төзергә керешәләр, ул рус бароккосы стиленең гүзәл үрнәге була.

Патша Казанга килгән чорда бирелдә инде аның фәрманы белән төзелгән казна һәм шәхси мануфактура фабрикалары гөрләп эшли. Дәүләтнең иминлеген саклау хаҗәтеннән, Казансу елгасы аръягындагы Елантау монастыренең җирләре тартып алынып, анда җилкәнле һәм башка төрле кораблар ясау өчен Адмиралтейство оештырыла. Ул шәһәр сәнәгате үсүгә зур этәргеч бирә, Елга аръягы (Заречье)

бистәләре бернича йөз елларга шәһәрнең төп эшче районы булып кала. Казанга инженерлар, сызым сызучылар, кораб төзү осталары, башка төрле һөнәр ияләре китерелә. Казна Адмиралтействосында эшләргә бик күп дәүләт крестьяннары, нигездә татар, мари, чуаш халкы тартыла, алар кораблар төзү өчен урман кисәләр, агач чыгаралар. Бу мәҗбүри эш күп кенә татар авыллары өстенә авыр йөк булып төшә. Адмиралтействога Азов, Идел һәм Каспий флотлары өчен кораблар төзү бурычы куела. Нәкъ менә биредә ясалган корабларда барып, Петр I Каспий диңгезе буйларындагы Дербент, Баку һәм башка шәһәрләрне яулап ала.

Шәһәрнең икенче эре сәнәгать төбәге Суконный бистәсе була, ул Кабан күленнән ерак түгел мануфактура фабрикасы тирәсендә үсеп чыга. Армияне тәэмин итү өчен 1714 елда казна предприятиесе итеп төзелгән мануфактура фабрикасы 1720 елларда шәхси кулларга тапшырыла. Суконный бистәсенә шул фабрикада эшләү өчен крестьяннар һәм һөнәрчеләр тартыла, авыр тормыш шартлары аркасында алар хуҗаларына каршы еш кына баш күтәрәләр.

XVIII гасырда Казан һөнәрчеләр-эшчеләр яшәгән бистәләр исәбенә үсүен дәвам итә. Шәһәр һәм шәһәр тирәләрендә татар халкы ишәя. Шул ук гасыр уртасында рус миссионерлары тырышлыгы белән башка халыкларны көчләп чукындыру янадан көчәеп китә, Иске татар бистәсендәге татарларның бер өлеше Яңа татар бистәсенә күчереп утыртыла. Шулай да XVIII гасыр азагына таба дини кысулар йомшый төшә. Әби патша Екатерина II янадан мәчетләр төзергә рөхсәт бирә. 1552 елдан соң салынган беренче таш мәчетләр Мәрҗани һәм Апанай мәчетләре була. Мәрҗани мәчете Әби патшаның шәхси рөхсәте белән 1766—1970 елларда төзелә.

1780 елда Екатерина II төрле диннәргә түзем караш булырга тиеш дип белдерә, мөселманнарның Диния нәзарәтен оештыра, татар морзаларын рус дворяннары хокуклары белән тигезли, татарларга сәүдә һәм сәнәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт итә. Шул чорда татар җәмгатьчелегендә эшмәкәрләр сыйныфы оеша башлый. 1796 елда Казанда 976 рус һәм 595 татар сәүдәгәре була.

Казан, Россиянең Европа өлешендәге губерналары белән сәүдә элемтәләрен өзмәгән хәлдә, шәркый илләр белән сату итүдә дә үзәк булып кала килә. XVIII йөзнең беренче яртысында Казанның чит илләр белән сәүдәсендә көньяк Каспий базарлары өстенлек итсә, гасыр урталарында инде Казан татарлары Казакъстан һәм Урта Азия базарларына юл торалар. Чөнки ул вакытларда рус сәүдәгәрләренә шәркый ислам якларына юллар ябык була, ә татар сәүдәгәрләре рәхәтләнеп йөри. Алар еш кына дипломатлык һәм тылмачлык вазифаларын да башкаралар. Казан татарларының төп товарлары кораблар төзү өчен агач, балавыз, бал, шәм, сабын, төрле күн әйберләр, киндер, постау, комач була. Европадан зиннәтле бизәнү әйберләре, тукымалар, шәраб, җиләк-җимеш, корал керсә, шәрыктән ефәк, фарфор, чәй, төрле тәмләткечләр, келәмнәр килә. Шулай итеп, Казан Гареп белән Шәрык илләре арасында сәүдә күпере хезмәтен үтәүне дәвам итә. Ул шулай ук мулдан икмәк тә сата, Казан губернасының авыл хуҗалыгы ел саен биш миллион сумлык икмәк биреп тора. Ул икмәк Петербург, Әстерхан, Таганрог һәм Черкасский якларына озатыла.

Казан һаман үсә, һаман янара бара. 1767 елда Идел буйлап сәяхәт кылган Екатерина II Казан турында: "Бу шәһәр, бәхәссез, Россиядә Мәскәүдән кала беренчедер... Казанның зур патшалык башкаласы икәнлеге әллә кайдан күренеп тора",—дип яза. 1788 елда шәһәрдә өч меңгә якын йорт һәм йөз илледән артык завод-фабрикалар була. Төрле янгыннардан һәм Емельян Пугачев отрядлары талау-җимерүләреннән соң, 1774 елда шәһәрнең генераль планын эшләү тизләтелә, ул 1782 елда раслана, шәһәрнең үзәк урамнарында кирпечтән салынган йортлар күтәрелә.

Үзе килү хөрмәтенә оештырылган бәйрәмнән чиксез канәгать калган Екатерина II француз философы Вольтерга болай дип яза: "Мин сезгә берәр азиат шәһәреннән хат язармын әле дип янаган идем, хәзер шул сүземне үтим, мин хәзер Азиядә. Биредәге шәһәрдә егерме төрле халык бар, алар бер-берләренә һич тә охшамаганнар... Гомуми уртак башлангычларын гына табарга мөмкин... Бу бөтен бер дөньяны бар итеп, урнаштырып, саклап калу шикелле!".

## Яңа чор Казаны

XIX-XX гасырларда Казан шәһәре Россия сәнәгате, сәүдәсе, мәгърифәте, фәне һәм мәдәниятенең әйдәп баручы үзәкләреннән берсе була. 1804 елда Казанда университет ачылу бик мөһим роль уйный. Мәскәү һәм Лейден университетларын тәмамлаган М. И. Невзоров "1800 елда Казанга, Вяткага һәм Оренбургка сәяхәт" дигән китабында шәһәребез һәм аның кешеләре турында тәфсилләп яза. Ул Казанны "Мәскәү белән Петербургтан кала, бөтен Россиядә иң матур, иң яхшы шәһәр" дип сурәтли. "... Шәһәрдә төп 20 урам, икесе таш, икесе агач 4 мәчетле ике татар бистәсе бар, һәртөрле хәлдәге 22 меннән артык халыклы..., хәрбиләрне дә санаганда, 30 меннән артыктыр",—дип яза. Сәяхәтче "Казан губернасындагы татар авылларының рус, чуаш һәм чирмеш авыллары арасына чәчелеп утыртылган" икәнлегенә дә игътибар итә. Казанда татарлар Иске һәм Яңа бистәләрдә яшәп, сәүдә һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнәләр, "аларның күпчелеге сабын кайнату һәм күн эшкәртү заводлары тота, һөнәрчеләр сәхтиян күнгә алтын каеп чигү белән шөгыльләнәләр",—дип яза. Шәһәр татарлары белән танышкач, ул, аларның "итагатьлелеген мактамый калдыра алмыйбыз", дип билгеләп үтә.

XIX йөз урталарына Заманов, Арсаев, Апанаев һәм Якубов заводларында 50 мең потка кадәр югары сыйфатлы сабын кайнатыла. Заманов заводы сабыны 1831 елда Мәскәүдәге сәнәгать күргәзмәсендә медаль белән бүләкләнә. Апанаев, Юнысов, Усмановларның күн эшкәртү заводлары бер елда 150 шәр мең мөгезле эре һәм вак терлек тиреләрен эшкәртәләр. Арсаев белән Юнысов заводлары елына 20 мең пот шәм эшләп чыгара. Татарлар кулында 5 текстиль фабрикасы булып, алар комач һәм "кытайнықы" дигән киже-мамык тукымалар житештерәләр. 1851 елда Казанда 762 татар сәүдәгәре була, алар барлык сәүдәгәрләрнең 34 процентын тәшкил итә.

Казан ислам диненең яңартылуы, татарлар арасында уку-укытуның үсеш алуы белән дә аерылып тора башлый. XIX гасырга кадәр татар мөселман руханилары Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укып кайталар. Алар Казан җәмәгатьчелеге арасында Урта Азия халыкларының ислам гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен тараталар. Тирән белемле татар имамнарыннан Г. Утыз-Имәни, Г. Әл-Курсави һәм бигрәк тә Шиһабетдин Мәрҗани исемнәре киң билгеле, алар татарларның рухи тормышына яңа юнәлеш бирәләр. Атаклы дин галиме, философ, тарихчы, Казандагы беренче Җәмигъ мәчете имамы, аннары шәһәрнең мөхтәсибе Ш. Мәрҗани утыздан артык фәнни хезмәт яза. Ул, Болгар һәм Казан тарихына караган әтрафлы мәгълүматлар туплап, татар халкының тарихы турында фәнни тикшеренү ясый, аны нәшер итә. Үз хезмәтләрендә Мәрҗани дини реформаторлык һәм мәгърифәтчелек фикерләрен үткәрә. 1876—1884 елларда ул Казандагы Укытучылар мәктәбендә мөселман дине дәресләре алып бара. Казан университеты каршындагы Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте әгъзалары арасында Ш. Мәрҗани беренче мөселман галимнәреннән була.

XIX йөз башына Казан Россиянең Шәрыкка үтеп керүендә хәрби һәм дипломатик әһәмиятен югалта. Аның урынына ул мәдәният һәм мәгърифәт өлкәсендә житди урын тота башлый. Бу максатка Казан университеты бик ярашлы була, ул Россия империясенең шул чордагы бердәнбер шәркый уку йорты булып тора[1].

Шуны гына искәртеп үтәбез: Казан университетында укучы татар һәм башкорт шәкертләре әкренләп ишәя—1840—1860 елларда аларның саны утызга житә. Каюм Насыйри белән Хөсәен Фәезханов анда иректе тыңлаучылар була. К. Насыйри татарларның киң белемле энциклопедист галиме була, 1871 елда Казанда үз мәктәбен ача. Ул хәзерге татар телен өйрәнү нигезләрен билгели, грамматика, әдәбият, география, арифметика, алгебра, физика, ботаника, медицина һәм башка фәннәр

[1] Казан университеты турында тулырак мәгълүматны С. Михайлованың "Казан утлары" журналында 2004 елның 12 нче санында басылып чыккан махсус мәкаләсеннән укып белергә мөмкин. Редакция.

буенча сүзлекләр һәм мәктәп дәреслекләре төзи. Казан татарларының әкиятләрен, җырларын, мәкальләрен җыеп бастыра.

Хөсәен Фәезханов исә Ш. Мәрҗани шәкерте буларак билгеле, ул 1840 елларда университетның И. К. Березин, А. К. Казем-Бәк кебек шәрыкчеләре белән хезмәттәшлек итә, Петербург университетында татар телендә лекцияләр укый, борынгы татар документларын рус теленә тәрҗемә итә, татар мәктәпләрен үзгәртеп кору проектын эшли.

Әйткәнебезчә, XIX йөз ахырына Казан татарларның мәгарифен реформалаштыру үзәгенә әверелә. Бирелә Россия мөселманнары арасында киң танылу алган яңа ысуллы "Касимия" (ул XVIII йөздә үк Апанай мәчете каршында ачыла), "Мәрҗания" (Ш. Мәрҗани тарафыннан 1870 елда нигез салына), "Мөхәммәдия" (1882 елда ачыла) мәдрәсәләре нәтиҗәле эшли. "Мәрҗания" мәдрәсәсе Россиядәге иң зур мәдрәсәләрнең берсе була, анда С. Айдаров, Ә. Сәгыйди, С. Сәйдәшев, Х. Ямашев кебек шәкертләр укый. "Касимия" мәдрәсәсендә Ш. Мәрҗани, З. Вәлиди, Г. Колахметовлар укыта, шәкертләре арасында З. Бигиев, М. Бигиев, Г. Исхакый, С. Максуди кебек киләчәктә танылачак шәхесләр була. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен 1905—1906 елларда Г. Баруди нигезли һәм ана җитәкчелек итә. Бу мәдрәсә алдынгы карашлары белән аерылып тора, анда әдәбият һәм драматургия түгәрәкләре эшли, кулдан язылган газетлар чыгарыла, Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш, М, Гафури, Н. Исәнбәт, С. Габәши, Б. Урманче кебек, XX гасырның беренче яртысында татар зыялыларының каймагы булачак шәхесләр укый. 1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәбе ачыла. Аның ачылуында Ш. Ахмеров, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, И. Терегулов кебек татар мәгърифәте һәм мәдәниятенең күренекле вәкилләре катнаша. Бирелә Г. Исхакый, Г. Камай, Г. Колахметов, С. Максуди, Н. Мөхетдинов, М. Фазлуллин, Х. Ямашев шикелле танылган шәкертләр укый.

XX йөздә Казанда милли татар әдәбияты ныклап аякка баса һәм үсеш ала. Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, С. Рәмиев, Г. Ибраһимовлар әдәби җәүһәрләрен иҗат итәләр. 1906 елда беренче профессионал татар театры оештырыла, ул 1908 елдан Казанда төпләнә, кышкы сезондагы спектакльләрен шунда күрсәтә. Бу чорда шәһәр милли татар матбугаты үзәге булып та таныла. Казанда басыла торган газет-журналлар арасында "Казан мөхбире" (нашире—Россиянең I Дәүләт Думасында депутат булачак С. Алкин), "Йолдыз" (нашире һәм мөхәррире—Һади Максуди), Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Ш. Мөхәммәдьяровлар язышып килгән "Таң йолдызы", мөхәррире Г. Камал булган "Азат халык", аталы-уллы Ә. һәм М. Сәйдәшевләр газеты "Бәянелхак", аннары "Әлислах", "Әхбәр", "Тавыш" газетлары янында "Ан", "Ялт-Йолт" кебек байтак журналлар нәшер ителә. Казанда "Мәгариф", "Милләт", "Сабах" нәшриятлары һәм типографияләре эшли.

Башкалабызда поляк, немец милләте вәкилләре дә күпләп яши. Алар арасында бик күренеклеләре дә була. Һәммәсенә дә тукталып тормастан, медицина профессоры, 1820 елларда университитет ректоры булып торган немец Карл Фукс турында гына бераз мәгълүмат биреп үтәбез. Ул үзлегеннән татар телен өйрәнә, Казан татарларының мәдәниятен һәм көнкүрешен тикшерүче галимнәрнең беренчеләреннән була. 1817 елда "Кыскача Казан тарихы", ә 1844 елда "Статистик һәм этнографик мөнәсәбәтләрдә Казан татарлары" дигән хезмәтләрен нәшер итә. Фукслар йортында бик зур китапханә була, анда татар һәм рус телләрендә басылган яки кульъязма хәлендәге китаплар саклана, рәсемнәр галереясе, шулай ук зоология, ботаника, минералогия коллекцияләре туплана. Ул елларда Казанга килеп киткән барлык күренекле шәхесләр дә Карл Фукс өендә булмый калмыйлар, бөек рус шагыйре А. С. Пушкин, табигать белеме галиме Александр Гумбольдт һәм башкалар әнә шундыйлардан була.

XIX йөз ахыры—XX йөз башларында Казан шәһәренең архитектурасы төрле стильләр һәм формаларны чагылдыра. Милли татар һәм шәркый традицияләр үрнәгенә якын булган Апанайлар йортын, Шамил йортын, "Болгар" номерларын, Әҗем мәчетен, Борнай мәчете манарасын күрсәтеп үтәргә кирәктер. Соңгысы Борнайларның теләге белән Каһирәдәге бер мәчет манарасыннан күчермә итеп эшләнгән.

Инде XVIII гасырдан ук Казан турында замандашлары соклану хисләре белән сөйли һәм яза торган булганнар. Якташыбыз шагыйрь Гавриил Державинның “Отечества и дым сладок и приятен” дигән атаклы шигыре нәкъ менә Казанга багышланган. Әби патша Екатерина II нең Казан белән соклануын искәртеп киткән идек инде. Гомеренең соңгы елларында күренекле җырчы якташыбыз Федор Шаляпин да: “Дөньяда яхшы шәһәрләр күп, ә Казан барысыннан да яхшырактыр”,— дип искә ала.

## Революцияләр чорындагы һәм хәзерге көндәге Казан

Россия империясенең барлык төбәкләрендә үсеш алган социаль-сәяси каршылыклар күпмилләтле Идел-Урал төбәгендәге Казанда да XIX-XX йөзләрдә азатлык хәрәкәтен көчәйтеп җибәрә. XIX йөз урталарыннан ук инде Казан берничә революцион күтәрелеш белән таныла.

Казан университетының тарих укытучысы Афанасий Щаповның алпавытларга һәм хөкүмәткә каршы Бездна авылы крестьяннары кузгаткан фетнә хакында 1861 елда ясаган атаклы нотыгы билгеле. 1861—1863 елларда Казанда “Земля и Воля” (“Җир һәм Ирек”) дигән яшерен оешма эшли. Аның 1863 елның язында, Польша, Литва һәм Белоруссиядәге милли-азатлык хәрәкәтенә теләктәшлек белдереп, Идел буенда да крестьяннарны фетнә күтәрергә котыртуы “Казан заговоры” дигән исем ала һәм Россия белән Польшада киң яңгыраш таба. Патша Александр II гә һөҗүм оештыруда катнашканы өчен Казан университетыннан студент Д. В. Каракозов куыла. 1880 еллар ахырында Казанда яшерен марксистик түгәрәкләр эшли башлый, аның оештыручылары Казан гимназиясен тәмамлаган Н. Е. Федосеев һәм башкалар була. 1887 елда Казан университетында атаклы студентлар сходкасы үткәрелә, студентлар уку-укытуда демократик үзгәрешләр булдыруны таләп итәләр, анда В. И. Ульянов-Ленин да катнаша. 1890 елларда Казанда яшерен социал-демократик түгәрәкләр эшли башлый, РСДРПның һәм эсерларның Казан комитетлары төзелә. 1905 елгы рус революциясе чорында кыска гына вакытка булса да революцион үзидарә органы буларак Казан шәһәр коммунасы оештырыла.



*Проломная (хәзерге Бауман) урамы. XX йөз башы.*

Либераль партияләр дә берләшә башлыйлар. 1906 елда Россия Дәүләт Думасы төзелгәч, Казанда сайлаулар үткәрелә, Думаның I-II чакырылышларына казанлылар үз депутатларын үткәрүгә ирешәләр.

1905—1907 елгы рус революцияләре чорында Казан Россия мөселманнарының сәяси хәрәкәте үзәгендә тора. Казан сәясәтчеләре һәм җәмәгать эшлеклеләре С. Алкин, Й. Акчура, М. Бигиев, Һ. Максудов, С. Максудов, А. Апанаев һәм Г. Барудилар беренче гомумроссия мөселман партиясе Иттифак Әл-мөслимин”не оештыралар, аның идеологлары булалар. “Иттифак Әл-мөслимин”нең Казан бүлекчәсе илдә иң абруйлылардан санала. Казан губернасы депутатлары С. Алкин, С. Максудов, Г. Еникеев һәм башкалар Дәүләт Думасының Мөселман фракциясендә дә зур урын тоталар.

XX гасырның башларында Казан кискен социаль-сәяси каршылыклар мәйданына

әверелә. Россия дәүләтенең кризисы һәм җәмгыятьтәге тирән каршылыклар 1917 елгы Февраль һәм Октябрь түнтәрелешләрен китереп чыгара, татар халкының да милли-азатлык хәрәкәте көчәя, аның үзәге, әлбәттә, Казан була. Казанда совет хакимияте урнаштырыла, милли-дәүләт төзелешенең яңа проектлары тикшерелә. Большевиклар илдәге хакимиятне үз кулларына алгач, гражданнар сугышы кабынып китә, ул Идел буенда аеруча көчле була. 1918 елның җәендә Казан әле аклар, әле кызыллар кулында булып тора, сугыш хәрәкәтләре һич тынып тормый.

Большевиклар тәмам җиңеп чыккач, милли-дәүләт төзелешенең совет моделе гамәлгә керә, 1920 елның 27 маенда Казан РСФСР составындагы Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының башкаласы дип игълан ителә. Совет системасы кысаларында Казан яңача үсеш ала, шул ук вакытта ул татар халкының күпмиллионлы милли-мәдәни шәһәре булып кала бирә. Югары уку йортлары, мәгариф һәм мәдәният оешмалары арта. 1920—1940 елларда шәһәр бик нык индустриальләшә, бу бигрәк тә Бөек Ватан сугышы чорында бирегә оборона сәнәгате заводлары күчеп килгәч көчәя. Сәнәгать районнарының киңәюе һәм халык санының артуы, Куйбышев сусаклагычы төзелеп, Иделдә һәм Казансуда су күтәрелү шәһәрнең йөзен тагын тирән үзгәртә. Казан архитектурасына европача һәм азиячә үзенчәлекле төс биреп торган күп кенә сыйфатлар югала бара, шәһәрдә бер типтагы биналар, йортлар ишәя, халык аларны "хрущевкалар", "шырпы тартмалары" дип кенә атап йөртә. Әлбәттә, бу хәлләр бик аяныч.

1980 ел уртасына Казан миллион халыклы күпмилләтле шәһәргә әверелде, аның сәнәгате, фәне, мәдәнияте һәм мәгарифе нык үсте, ул Идел буендагы иң зур шәһәрләрнең берсе хәзер. Җәмгыятьнең гомуми демократлашу процессында һәм Татарстан Республикасы яңа статус алгач, 1990 еллардан Казанның исеме Россиядән бик еракта гы чит илләргә дә билгеле булды. Шәһәрнең тарихи үткәне, аның мирасы, анда яшәүче халыкларның тормыш-көнкүреше белән кызыксыну көчәйде. Максатчан тарихи һәм археологик эзләнүләр Казанның мең еллык шәһәр икәнлеген фәнни нигезләргә мөмкинлек бирде. Халыкара квалификациядә бүгенге Казан шәһәре тарихи-мәдәни кыйммәтен һәм мирасын саклау буенча, Мәскәү белән Санкт-Петербург шикелле үк, "А" класслы шәһәрләрдән санала. Казан Кремле исә 2000 елның декабреннән ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде.

Татарстан Республикасының башкаласы Казан үзенең ике меңенче еллыгын, тарихи-милли мирасын саклап һәм торгызып, иртәгәге көнне зур ышаныч һәм өмет белән каршылый.

***Марс Шабаев тәрҗемәсе.***

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***НӘБИ*** *г.* — Пәйгамбәр; хәбәр китерүче. Бу сүзнең асыл мәгънәсе *уятучы, кисәтүче, зиһенне ачучы* булса кирәк. *Рәсүлнең* дәрәҗәсе нәбинекеннән артыграк, чөнки нәбинең Алладан иңгән китабы юк диләр. "Рисаләи Газизә" әсәрендә Җәбраил галәйһиссәламнең нәбиләргә йокыда хәбәр бирүе, ә Рәсүлләргә уяу вакытларында килүе әйтелгән.

***НӘБИЙЙУЛЬ-ӨММИЙИ*** *г.* — Өмми пәйгамбәр, ягъни укырга-язарга өйрәнмәгән пәйгамбәр. Бу исем Мөхәммәд Пәйгамбәргә карата кулланылса да, хәзерге тикшеренүләр бу мәсьәләне кистереп кенә хәл итмиләр. Чөнки, мәсәлән, "Пәрдә" сүрәсенең (7) 157 нче һәм 159 нчы аятьләрендә әйтелгән "Укый-яза белмәгән рәсүлебез-Мөхәммәд" һәм "Аллаһуга һәм укый-яза белмәгән Рәсүленә ышаныгыз!" сүзләрен "укый-яза белмәгәннәр Рәсүле" дип тә тәрҗемә кылырга бик мөмкин. "Җомга" (62) сүрәсенең 2 нче аяте "Ногмани тәфсире"ндә түбәндәгечә бирелә: "...Ул — Аллаһ укый-яза белми торган каум эченнән үзләре кебек укый-яза белмәгән кешене — Мөхәммәдне дөньяның барча кешеләренә рәсүл итеп җибәрде". Ләкин Мәүлана Мөхәммәд Али тәрҗемәсендә бу урын "наданнар арасында тәрбияләнгән Илче" рәвешендә яңгырый. Бу аять Р.Батулла тәрҗемәсендә дә охшаш мәгънәгә ия. Кыскасы, күп кенә галимнәр Коръәннең үзендә бу хакта аермачык мәгълүмат юк дип исәплиләр. Өстәвенә беренче вәхийләр назил булган вакытта хәреф танымаган Пәйгамбәрнең соңыннан язу-сызуга өйрәнүе бер дә гаҗәп булмас иде.

***НӘГЪРӘ*** *г.* — **1**.Каты тавыш, ачы тавыш; акыру-бакыру (1931 елгы "Татарча-урысча сүзлек"тә: Нәгъръә-"возглас дервишей", ягъни "дәрвишләр авазы"). **2**.Барабан, литавра. *"Накры"* рәвешендә борынгы рус теленә дә кергән булган. // *Нәгърә ору* — кычкыру; набат сугу.

***НӘҖӘГАЙ, НӘҖӘГАЙ УЙНАУ*** — Күктә сөңге-*нәйзә* тоткан агай бар, шунын сөңгесе ялтыр-йолтыр уйный дигән борынгы ышанудан килеп чыккан сүз. Нәкый Исәнбәт 922 елда Болгарга килгән *Ибне Фазлан* язмаларында шушы күренеш телгә алына дигән фикерне алга сөрсә дә, моны раслардык дәлилләр китерми. Халык сүзенә караганда, нәҗәгай ашлык өлгереп җиткән җәйге төннәрдә тавыш-тынсыз гына уйный һәм, димәк, нәҗәгай Ибне Фазлан язганнарга туры килми, чөнки ул бу күренешне яз көне (хәзергегә күчерсәк, май аенда) тамаша кылган һәм бу вакытта үзенә бер төрле чытырдау тавышлары да ишеткән, ә аҗагай күренгәндә (котып балкышы вакытындагы кебек үк) тавыш-мазар ишетелми.

Телдә *аҗагай, аҗаган* сүзләре дә бар. Аны *арыш камчылау* дип тә әйтәләр. "Диалектологик сүзлек"кә (1969) караганда, Мәләкәс, Сергач, Чистай якларында нәҗагай *ырҗа йәшене* дип йөртелә икән. "Ырҗа йәшене арыш өлгергәч була" дигәндә русча "рожь" сүзенең ике әйтелештә катнашканлыгын күрәбез. Асылда боларны *коры яшен* термины берләштерә шикелле (төрле сөйләшләрдә — *ашлык яшене, кигәвен яшене, чикләвек яшене, чык яшене*).

"Объяснительный словарь иностранных слов" (1883) сүзлегендә *"Натагай"* дигән сүз теркәлгән. Аңа: "Татарларда тәңре, алар аны җирне һәм барлык мәхлүкатны тудыручы һәм аларның хуҗасы дип саныйлар" дигән аңлатма бирелгән.

***НӘЗЕР*** *г.* — Адарыну; шартлы вәгъдә, үз өстеңә алган эш. // *Нәзер әйтү* — башкарасы

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

эш алдыннан, әгәр ул эш уңышлы чыкса, кемгә дә булса бирәр нәрсә бирергә яки бирәр йөкләмә үтәргә (әйтик, фәлән сум садака бирергә, фәкыйрьләргә ризык өләшергә, өч көн ураза тотарга, мәчет төзетергә) күңелеңнән вәгъдә бирү.

*// Бер кеше Аллаһы Тәгалә әмеренә итагать кылу белән нәзер итсә, шул нәзерен үтәсен вә бер кеше Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ эш белән нәзер итсә, гөнаһ кылмасын.* Хәдис.

***НӘЙЗӘ, НАЙЗА*** *ф.* – Агач саплы, япьле һәм тешле сөңге; кечерәк сөңге; штык. Фарсыча *"сәрнәйзә"* дә штык. Р.Әхмәтьянов диалектларда "нәйзә" сүзенең *сәгать теле, угы* мәгънәсендә дә йөрүен әйтә. *// Нәйзә тоткан агай*– нәҗәгай (Н.Исәнбәттән).

***НӘКЫЛЬ*** *г.* – **1.**Күчерү, урынын алмаштыру. *// Дөньядин нәкыль кылды*– дөньядан күчте, үлде. **2**.Телдән-телгә сөйләү. *// Бер хикәят нәкыль итәйэм.* Мөхәммәдъяр. *Хан–акыл, халык-нәкыл(ь)* дигән мәкальдә халык *сөйләүче тел* белән чагыштырыла. **3**.Тәрҗемә. *// "Татарларны мәсихия иманына дүндүрмәк хакында Тобол вә Себер Антоний Стаховский дигән мокатдәс митрополиты илә нәкыл идүлмеш китабы".* **4**.Алынма, цитата. *// Нәкыльчелек*– "аңсыз рәвештә цитатага иярүчелек" (Нәкый Исәнбәт буенча).

***НӘМУНӘ*** *г.* – Үрнәк, өлге; нәзыйрә; тарыз; модель. *// Нәмунә мәктәпләре*– үрнәк (образцовая) мәктәп (мәс., андый мәктәпләрне Исмәгыйль бәк Гаспринский ачкан). *Хат язмак нәмунәсе.*

"Нәмунә" сүзен рус телендәге "типовой" мәгънәсендә кулланып булыр иде шикелле (*типовой проект, типопроект*– намунә проект, өлге проект).

*Нәмунә* язылышы да очрый.

***НӘНИ АБЫЙ*** *тар.* – Фатих Әмирхан сүзләренә караганда, Казанда Печән базары татарлары, ни өчендер, бер-берсенә *нәни абый* дип дәшә торган булганнар. Бу сүздә үзенә күрә ихтирам да бар сыман, әмма шул ук вакытта аңарда артык куштанлану да төсмерләнми. Казан татарларында бүгенгә кадәр өлкәнрәк, хөрмәткә лаек кешегә *дәү абый* дип әйтү сакланган, ягъни дәү абый, нәни абыйга караганда, дәрәҗәлерәк.

***НИКАХ, НИКЯХ*** *г.* – Өйләнешү.

Коръән-кәрим никахта торуны кеше өчен *нормаль халәт* дип саный һәм шуңа күрә барлык ялгыз кешеләрне никахка кереп яшәргә куша. Пәйгамбәр болай дигән: "Никахта булырга сәләтле һәркем өйләнергә тиеш. Чөнки никах тиешсезгә карамаска һәм намусыңны сакларга ярдәм итә." (Бохари буенча.) Чыннан да никах җәмгыятьтә әхлак дәрәҗәсен саклауның һәм күтәрүнең гарантиясе, шарты булып тора.

Коръән һәр ике җенестәге колларның да никахта булуларын таләп итә. Ислам никахсызлык дигән нәрсәне кире кага һәм һәр кеше ата яки ана булырга тиеш дип саный. Фәкать үзләренә пар (җефет) таба алмаучыларга яки гаилә тормышын тәэмин итә алмаучыларга гына никахсыз (җефетсез) яшәргә рөхсәт ителә.

"Никах вакытында әһәмият биреләчәк нәрсә мәһәр, туй, бирнә вә җиһаз түгел, бәлки һәр ике тараф арасында дин вә әхлак, тәрбия вә табигать тугрыларында муаффәкыять (уңыш) булудыр."

Хәләл җефет сайлаганда түбәндәге сыйфатларга игътибар иткәннәр:

1)Кызның пакь һәм яхшы гаиләдән булуына; 2)Бикер, ягъни гыйффәтле кыз булуына (тол яки талак кылынган хатынга өйләнмәгәндә); 3)Кызның мөслимә булуына һәм дини мәрасимнәрне үтәвенә; 4)Бала табарга сәләтле булуына.

Кызның бу сыйфатларга ия булуын үз кардәшләрең аркылы сорашып белешергә кирәк.

Шәригать буенча 4 хатын белән генә *даими никахта* торырга мөмкин. Электә кәнизәкләр белән *вакытлы никахлар* еш кына чикләнмәгән, ләкин алар белән даими никахлар санын 4 яки 2 белән чикләү дә кулланылган. Кол хәлендәге ирләргә 4 кол хатынга өйләнергә рөхсәт ителгән.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, гомер буена никахлар саны югарыда әйтелгәннән

чагыштыргысыз күбрәк булырга да мөмкин. Мәс, һиҗрә белән 423 елда (миляди 1031 / 1032 елларда) 87 яшендә үлгән бер буяучы, бер-бер артлы хатын аерып һәм яңа хатынга өйләнеп, 900 дән артык хатын белән никахта торган дип сөйлиләр. Пәйгамбәрнең оныгы Хәсән дә шул ук юл белән 100 дән артык хатынга өйләнгән һәм шуның өчен аңа "Митлак" ("Талак кылучы") дигән кушамат такканнар.

Йәһүдилек тә күп хатын алуга юл куйган (мәс., Йагкуб пәйгамбәр). Дөрес, мең ел чамасы элек рабби (хаким) Гершом, Тәуратка каршы килеп, Европа еврейләренә икенче хатын алуны тыйган. Рабби Гершомның бу тыюы мең ел мөддәт белән чикләнгән булуга да карамастан (ягъни бу тыю 1962 елда көчен югалткан булса да), Европа һәм Израиль раввиннары еврей халкына бер хатынлылык кагыйдәсен тагалар. Израилдә хәтта Шәрык еврейләренә дә икенче хатын алу тыелган.

XIX гасырның беренче яртысына караган татар никахлары турында кайбер мәгълүматларны Карл Фукс үзенең "Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях" дигән китабында бирә. Казан татарларыннан фәкать 55 енең генә 2 шәр хатыны, 6 сының 3 әр хатыны һәм 2 сенең генә 4 әр хатыны булган.

Ләкин татарлар арасында күп хатын алу чагыштырмача сирәк очраган. Әйтик, берничә авылга хезмәт күрсәтә торган мулла кайчагында башка авылда икенче хатын белән дә никахлашкан. Элекке Тукай районында Кошар авылы мөәззине Ш.Шаһиевның дүрт хатыны булган. Ул 12 сыер, шулкадәр үк курдюклы сарык асраган, кибет тоткан һәм сабын кайнату белән дә шөгыльләнгән. Аның һәр хатыны аерым йортта торган (Татары Среднего Поволжья и Приуралья, М., 1967).

Ир кеше никах төннәрен хәләл җефетләре арасында тигез бүләргә тиеш. Шуның белән бергә, тыңлаусыз хатынын ул үзенең назыннан мәхрүм итәргә дә хокуклы. Яшь хатыны гыйффәтле кыз булган очракта җиде төн рәттән ире белән йоклау хокукына ия, башка очракта ул бу хокуктан өч төн рәттән генә файдалана ала. Әгәр ир кеше ике ел буена хатыны белән якынлык кылмый икән, хатыны үзен аерып җибәрүне таләп итәргә хокуклы (Р.Шарль буенча).

Тарихчы Газиз Гобәйдуллин борынгы төрек әдәбиятында очрый торган "дули думрул" төшенчәсен телгә ала һәм: [ир кеше] "дули думрул" хатынына "син минем бер генә хатыным" дип хитаб кыла (эндәшә) ала" дигән аңлатманы бирә.

Хәзерге заман шартларында бу кагыйдәләр, әлбәттә, үзгәреш кичерде. Мәс., Йәмән җөмһүриятендә никахтагы хатыннар саны 2 белән чикләнә, ә Тунистә күп хатын алу гомумән тыелган. Кайчагында безнең вакытлы матбугатта аерым шәхесләр полигамияне (күп хатын алуны) яклап язып чыккалыйлар, ләкин бу, һичшиксез, тәрәккыятьтә артка чигенү булыр иде. Моны зарурият белән дә аклау мөмкин түгел, чөнки XX гасыр ахырында үзенең нәфесен авызлыклый алмаган мөселман хак мөселман була алмый.

Электә мөселман илләрендә никах килешүе тантаналы шартларда үткән һәм бу вакытта төрле йолалар һәм мәрасимнәр башкарылган. Мәс., никах килешүе барган бүлмәнең астында бушлык булмаска тиеш дигән шарт куелган һәм бүлмәгә фәкать бер тапкыр гына кияүгә чыккан хатыннар кертелгән. Килешү вакытында көзгегә бакканнар һәм ашъяулыкка билгеле бер мәгънәви галәмәткә ия булган әйберләр, нигъмәтләр һәм үләннәр куелган. Килешүгә ата-аналар һәм руханилардан бер шаһит кул куйган.

Никах мәҗлесләрендә "Әр-Рум" сүрәсенең 17-28 аятьләрен укырга мөмкин.

***НИКАХ БӘДӘЛ*** *г.* – Хатыннарны алыштыру. Җаһилият чорына хас.

***НИКАХ ИСТИБЗАГ*** *г.* – Ир хатынын баһадир, гыйлемле яки башка күркәм сыйфатлы кеше белән кавыштырып алу. Җаһилият чорына хас булган.

***НИКАХ-МАКТ*** *г.* – "Җирәнгеч никах". Исламга кадәрге чорда гарәпләрдә ата вафат булгач, үги ананы хатынлыкка алу гадәте. Ләкин бу төр никах яхшы гадәт саналмаган. Ислам дине никах-мактны бетерде: "Аталарыгыз никахында булган хатыннарга никахланмагыз" ("Ниса" сүрәсе, 22).

***НИКАХ ХИДР*** *г.* – Яшерен хәлдә сөяркә тоту.

***НИКАХ ШИГАР*** *г.* – Бер ирнең икенче кешегә, ул кеше дә аңарга кызын яки сеңлесен бирү шарты белән, үзенең кызын яки сеңлесен бирүе. Җаһилият вакытында гарәпләрдә еш очраган никах төре.

***НИКАХЕН МӨТГА*** *г.* – Вакытлыча никах (шигыйларда *нәшәргый никах*). Кара: ***СИГА***.

***НИШАН*** *фг.* – **1.**Билге, тамга; эз; рәсми кәгазьгә басылган мөһер. *//Хак юлында коллык өчен башын салса, Хак әмренә газиз җанын корбан чалса, Бу дөньяны бер сәгать тиб, фани белсә, Әүлиялык нишанлары бардыр анда. Мәүла Колый. Ук тимере җәрәхәтдән чыкар, вәли нишаны калыр.* **2.**Мишень. Рус теленә төрки телләрдән башта нишан рәвешендә (һәр ике мәгънәдә) кереп, фонетик үзгәреш кичергән сүз. **3.**Орден, аерымлык билгесе. **4.**Егет белән кызның бер-берсенә вәгъдә бүләкләре (балдак). Нишанлия – вәгъдәләшкән кеше.

***НОКРАТ*** – **1.**Болгар чорында сугылган көмеш акча. **2.**Болгар-татарда Вятка елгасының исеме (*Нократ Иделе*). Марилар Вятканы *Ноуград вич* дип атыйлар, ягъни алар телендә гидроним Новгород шәһәре атамасыннан алынган икән. Язучы Н.Фәттах бу фикер белән килешми, Нократ/Нукрат атамасын җиңел генә *нук* һәм *рат* иҗекләренә тарката да, аларны борынгы Мисыр Аллалары һәм патшалары исеме белән бәйләп куя. Моны без язучының уңышсыз этимологик тәҗрибәләре исәбенә кертәбез.

Киров өлкәсендәге Нократ авылындагы зиратта 1522 елда куелган таш бар.

***НӨФУС*** *г.* – Кешеләр, (яши торган) халык. *//Бу көндә Казан 140 мең нөфүсле бер зур шәһәр булып, бөтен Шәркый Русиянең, хәтта Кавказ, Урта Азия вә Сибирия вилайәтләре өчен дә һөнәр, санагать, гыйлем вә мәгърифәт хәзинәсе булып санала.* Г.Әхмәрев. *Тәзаеды нөфүс* – халык саны арту. *Тәхрире нөфүс* – халык санын алу (язу). *Диване нөфүс.*

***НУРЧАТЛАР*** – "Пенза өлкәсендә Кармалы авылыннан ерак булмаган җирдә табылган борынгы таңкәләр, беләзекләр. Таңкәләре ун тиенлек акча зурлыгында, ләкин озынча формалы һәм сабаклы, өсләрендә "мөселманча" язуы да булган." *("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969.)* XIV-XV гасырларда бу өлкәдә Наровчат авылыннан ерак түгел Алтын Урданың Мукшы шәһәре торган. Анда акча сугылганлыгы да билгеле. "Нурчат" сүзе белән *"Наровчат"* сүзе арасындагы бәйләнеш – шөбһәсез. Аннары Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә *нуграт, нухрат* – "бизәнү әйбере, ялтыравыклы вак таңкә."

***ОЛЫС*** *тар.* – Дәүләт, ил, төптә "югары совет" мәгънәсен белдерә торган борынгы сүз. "Древнетюркский словарь" белешмәсендә "улус" сүзенең торак җир, авыл мәгънәсе теркәлгән (*улус балык* – авыллар һәм шәһәрләр). Шунда ук *"улус – буддаларның тору урыны.* "Алтын Урда чорында олыс, ихтимал, җыен даирәсе белән тәңгәл булгандыр. "Олыс"ның "халык", "ил" мәгънәсе дә бар (*олыс тоту*-халыкны, илне идарә итү). Теге яки бу нойонга (бәккә, әмиргә) буйсынган халык күчеп йөри торган территория *йорт* дип аталган. *//Гадел кылса падишаһлар даим, ишет: Ил-олусы гадел берлә тапса мәшият, Барчага тикәр өлеш андин тәмам, Кылыр аның илә рәхәт хассы-гамь.* Мөхәммәдъяр.

Рус телендәге "волость" сүзе, димәк, монгол-татар чыгышлы. *//Батый олысы. Казан олысы. Рус олыслары. Себер олысы. Кырым олысы. Олыс би (олысбәк).*

Татарча "олы", "олуг" (өлкән, зур, бөек) сүзләре шушы "олыс" сүзенә барып тоташа (Р.Әхмәтьянов).

Тагын кара: ***УЛУС.***

*Дәвамы киләсе саннарда*

# Хисамеддин Тогач

## "БЕР БУЫННЫҢ ДРАМАСЫ" ӘСӘРЕННӘН ӨЗЕК

*Хисамеддин Тогач (1889-1975) 1915 нче елның январенда Кавказ фронтында әсир төшә. Иркутск шәһәре янындагы әсирләр лагерена җибәрелә. Беренче качышы уңышсызлыкка очрый. Икенче тапкыр качып китеп, Томск-Барнаул-Ташкент-Бохара-Баку аркылы узып 1918 нче елның январенда иленә кайтып ирешә. Истәлекләре "Бер буынның драмасы" исеме астында 1966 нчы елда басылып чыга.*

*Бу истәлекнен беренче уңышсыз качышы һәм тотылганнан соң төрле төрмәләрдә күргәннәрне тасвирлаган өлеше тәрҗемә ителде.*

"...Әсирлек әсирлек инде, ирекка капма-каршы хәл. Тәүлекнең 24 сәгате койма белән уратып алынган биналарның эчендә яки ишегалларында уза. Койма дигәнең кеше буеннан да биегрәк юан-юан бүрәнәләрдән ясалган, тышкы якны күреп булмый. Әмма лагерь эчендә хәрәкәтебез чикләнмәгән, теләгән вакытта йөренергә, спорт белән шөгыльләнергә, бүтән казармаларга барып килергә мөмкин. Без яши торган бина - офицерлар өе. Янәшәбездә кирпеч белән бетоннан төзелгән өч катлы солдат казармалары, командирларның һәм офицерларның рәсми хезмәт урыннары. Бөтен Себер буенча, бигрәк тә тимер юллар һәм чик буйлап, моның кебек хәрби биналар тезелеп киткән. Хәрби шәһәрчек дип аталган мондый урыннар бөтен зур шәһәрләрнең якынында һичшиксез бар. Кайбер кечерәк шәһәрләрнең янәшәсенә дә корылган алар.

Төрек офицерлары өчен хәрәкәт мөмкинчелеген арттырырга уңайлы сылтау килеп чыкты. Мөселманнар өчен җомга көннәрне мәчеткә барып гыйбадәт кылу кирәклеген руслар да кабул итә икән. Моңа рөхсәт бирделәр. Мылтыкларына сөңге таккан сакчылар без биш төрек офицерын һәр җомга көнне башта мунчага, аннары мәчеткә йөртә башлады. Мәчеттә барча кеше безгә игътибар күрсәтә. Һәрбер татар савап булсын дип безнең белән ике куллап күрешә, кочаклый. Сәлам биргәннән соң хөрмәт йөзеннән шундук чигенеп үз урынына китә. Мәчеткә беренче барышыбызда хәзрәт вәгазе беткәннән соң җәмәгатьне таратмыйча бер-ике сүз әйтте, шуннан соң идәнгә бер кульяулык җәйделәр, бу кульяулыкка акча куя башладылар. Көмеш белән кәгазьдән байтак кына акча җыелды. Бу акчаны безгә ярдәм өчен җыйганнар икән. Иптәшләр арасында иң югары дәрәҗәдәге кеше буларак, җавап бирү вазифасы минем өскә төште. Хәзрәткә һәм халыкка рәхмәт әйттем. Рус дәүләтенең безгә үзебезнең дәүләт хисабына жалованье биргәнен, мохтаҗлыгыбыз юк икәнен сөйләдем. "Мөселман туганнарыбызның илтифатлы ярдәмен кабул итәбез, бу акчаны безнең исемнән хәер җәмгыятенә тапшыруыгызны үтенәбез", дидем. Мәчет халкы бу гамәлебездән бик хушланды. Без дә, шул рәвешле төрек офицерларының дәрәҗәсен күтәрдек дип, эчтән шатланып, мәмнүн булдык.

Һәр җомга намазыннан соң Гыйниятулла исемле татар бае безне өенә чәй эчәргә алып китә иде. Әлбәттә, сөңгеле мылтыгын күтәргән рус сакчысы да артыбыздан калмый ияреп бара...

*Ахыры. Башы 10 нчы санда.*

Гыйниятулла байның гимназиядә укучы улы белән дә таныштык. Икенче улы Истанбулда Галатасарай лицеенда[1] укый икән. Мин гимназист егет белән дуслашып киттем. Гыйниятулла бай һәм аның улыннан ярдәм алып качып китү уе башыма кереп утырды. Ләкин анарчы бераз саулыгымны ныгытырга, көрәергә кирәк.

Гыйниятулла байның өендә чәй эчеп утырганда татарча газеталарны караштыргалыйм. Төрек армиясе Дарданелл бугазында каһарманнарча сугышып, дөнья тарихына яна сәхифәләр язып ята икән. Инглиз һәм французларның алга таба уза алмыйча ярда терәлеп калганын, төрекләрнең уңышлы атакалар оештыруларын рус газеталары да һәр көнне язып тора. Казармадагы алман иптәшләр төрек армиясенең каһарманлыгын мактап безне котлыйлар, үзләренә чәйгә чакырып сый-хөрмәт күрсәтәләр иде.

Кавказ фронтында да русларның әлләни эш майтара алмаганын, сугышларның һаман чик буенда барганын газеталардан укып белдем. Хәлбуки мин Сарыкамыштагы уңышсызлыктан соң төрек көчләренең тәмам тар-мар ителгәненә ышанып җиткән идем. Хәзерге өметле хәл кәефемне күтәреп җибәрде, көчем артып китте, тамырларымда каным шаулабрак ага башлады кебек тоелды...

(Тогач, мажар офицеры Франц Кара һәм алман офицеры фон Вернер белән бергә, идән астыннан казылган юлдан качып китүгә ирешә. Ләкин качкыннарга ярдәм итәргә тиешле кешене ул вакытта рус идарәсе инде төрмәгә ябып куйган була. Үзләре генә поездга утырып лагерьдан берникадәр ераклаша алган өч качкынны рус полицейскийлары бик тиз генә тотып алалар.)

...Жандарм гардианга[2] русча нидер әйтте. Гардиан кесәсеннән ачкыч чыгарып кечкенә ишек янына килде. Ишекнең тәрәзәчегеннән берәүнең йөзе шәйләнә иде. Ишек ачылгач, битенә, чәчләренә кан укмашкан бер егет килеп чыкты. Жандарм, бераз жикеренеп-сүгенеп алгач, аны иреккә чыгарып җибәрде. Егет урталай бөгелеп рәхмәт укый-укый чыгып китте. Жандарм, бушап калган бүлмәгә бармак белән күрсәтеп, безгә анда керергә ымлады. Кермәскә дип аяк терәп карасак та, гардианнар төрткәләп безне җәһәт кенә эчкә тыгып куйдылар. Ишекнең ярыкларыннан үтеп кергән яктылыкта бу кетәклекнең ике метр ярым чамасы озынлыкта булганын шәйли алдык. Идәннән бер метр биеклектә кеше буе озынлыгында бик шакшы сәке бар. Каршы стенада пыяласы ватык корымлы лампа, бер почмакта бик сасы ис килеп тора торган бәләкәй мичкә тора. Бу мичкәнең ни эшкә яраганын аңлый алмадым. Гардиан лампага ут элеп стенага асып куйды да ишекне бикләде. Без өч иптәш бер-беребезгә терәлеп сәкегә утырдык. Әсир офицерлар икәнлегебезне яшереп торуның мәгънәсе юк иде инде. Бәлки дә офицер икәнлегебезне сөйләсәк безгә файдасы күбрәк булыр, безне бу шакшы урыннан чыгарып кире Иркутскига җибәрерләр? Ләкин полковник Краличек белән аның иптәше[3] турында ләм-мим бер сүз ычкындырмаска сүз куештык. Фон Вернер ишекнең тәрәзәчегеннән гардианны чакырып алды. Жандармерия идарәсе әйтәсе сүзебез барлыгын белдерергә кушты.

Лампадан чыккан искә күнелебез болганды, карангыда утырсак утырырбыз, ичмасам бу истән котылыйк дип аны сүндереп куйдык. Тәрәзәчектән безне ара-тирә күзәткәләп торган гардиан, лампаның янмаганын күреп алгач, сүгенә-сүгенә ишекне ачты. Лампаны сүндерергә ярамаганын сөйләп өстебезгә җикеренде, төкерекләрен чәчеп сүгенде. Без нигә сүндергәнебезне әйтеп тормадык, эндәшмичә калуны унайрак күрдек. Гардиан лампага янадан ут элеп чыгып китте.

Сөргеннәр һәм тоткыннар иле булган Русия дәүләтенең идарәсе астындагы Себернең чын йөзен беренче мәртәбә шунда күрдек. Драмабызның чираттагы сәхнәсе иде бу.

Башлык килде. Безне бүлмәгә чыгардылар. Башлык дигәннәре бер кулы гарипләнгән, арык гәүдәле, сипкелле бер адәм икән. Иңнәрендә ике йолдызлы өлкән лейтенант

---

[1] Галатасарай лицее – (элеккеге исеме Мәктәби султани) Истанбулда Европа үрнәгендә оештырылган беренче мәктәп. 1868 елында ачылган бу лицейда укыту төрек һәм француз телләрендә булган, мөселман һәм христиан укучылар бергә укыганнар. Галатасарай лицее бүген дә эшли, Истанбулда абруйлы мәктәпләр арасында санала, укыту эшләре элеккегечә ике телдә (төрек һәм французча) бара.

[2] Гардиан төрекчә "надзиратель" дигән сүз. "Гардиан" сүзе кыскарак һәм отышлырак яңгыравышта булганга күрә, "надзиратель" дип тәрҗемә ителмичә, шул килеш калдырылды.

[3] Тогачлардан алдарак качып киткән ике мажар офицер.

погоннары. Варшава якынында яраланып гарипләнеп калганнан соң туган жиренә кайтарып пристав итеп куйганнар. Аз сүзле, сак кеше. Офицер икәнебезне әйттек. Бик тиз генә беркетмә төзегәннән соң безне тагын кетәклеккә тыгып куйдылар. Ул көн өчен үз акчабыздан егермешәр капик[1] бирделәр. Бу акчага гардианга икмәк белән сыр алдырдык. Тамагыбызны туйдыргач, гардианга 20 капик биреп, мич өстендә торган чәйнектән бирәр стакан чәй дә алып эчтек.

Бер сәгать узды. Сулышы капкан башлык янадан килеп безне тагын сораштыра башлады. Башлык безнең турыда Иркутскига хәбәр биргән, аннан килгән җавап телеграммасында өч түгел, биш кеше качканын, алар арасында Краличек дигән полковник та булырга тиешлеген язып җибәргәннәр. Башлык, арабызда Краличек белән иптәшенең юклыгын белеп алгач, аларның урынын әйттерер өчен безне төрлечә кыса башлады. Без авызыбызны кысып йомдык, бер сүз дә әйтмибез. Берничек тә максатына ирешә алмагач, түрә аптыраудан тирләп чыкты. Без дәшмәгән саен, аякта басып торган дүрт җандармның ачуы кабара бара, үз алларына үрсәләнеп торалар. Ахырда ачудан йөзе бүртенеп, күзе аларган озын буйлысы атылып чыкты. Уң кулын чигәсенә куеп сәламләгәннән соң: "Рөхсәт бирегез, мин боларның иманын өшкерим. Сез алҗымагыз. Бу германны (фон Вернерга төртеп күрсәтеп) миңа бирегез, биш минутта сайратмасам, теләсә нинди җәзага риза мин",—диде. Тегеләре дә сүзгә кушылды, берсе венгерны[2], икенчесе турукны (мине) сайлады. Кем белә, урта гасырдан калган әллә нинди газаплау чаралары белән бездән мәгълүмат кысып чыгарга җыендылар ахры болар. Бигрәк тә фон Вернерга теш кайраганы үз-үзенә урын таба алмый. Варшава тирәсендә алманнарның җирле халыкка җәбер-золым күрсәткәнен, гаиләсенең бу золымнан көч-хәл белән генә качып котыла алганын иптәшләренә кабат-кабат аңлатканда фон Вернерга нәфрәтләнеп карап-карап ала иде.

Башлык, көч куллануда файда юклыгына тәмам инангач, бу юлы ялварырга керешә. Полковникның урынын әйтүебезне үтенеп сорый башлады. Баштарак профессор Караны юмалап карады. "Әфәндем, сез сөйләрсез. Мажарлар әйбәт халык. Мине ялыктырмагыз, полковникның урынын әйтеп бирегез. Сезне бу шакшы кетәклектән коткарып, авылның иң яхшы йортында кунак итим, аннары беренче поезд белән Иркутскига җибәрермен". Профессор Кара кыска җавабын бирде: "Это невозможно". Түрә, профессордан өмет өзгәч, миңа борылды, кулын җилкәмә салып: "Син әйтеп бир. Төрекләр безнең күршебез. Икебез дә Азия милләте. Сугыш барыбер бетә ул, күршелек, дуслык гомергә кала", дип, күнелемне яуларга тырышты. Мин дә профессор әйткән сүзләрне кабатладым: "Это невозможно". Йөзе бүртенә башлаган түрә фон Вернерга да сүз кушты, ләкин ул да иләнгә карап "юк дигән мәгънәдә башын селкеде.

—Сез моңа бик нык үкенерсез! Себер бу, андый-мондый гына урын түгел! Монда кешене үргән камчы белән суктыралар, ач тоталар! Тиз сөйләгез, үзегезгә җиңеллек ясагыз!

Арабызда рус телен иң әйбәт белүче профессор Кара өчебез өчен дә җавап бирде: "Без әсир офицерлар, сездән качып китү безнең вазифабыз. Безне тотып, сез үзегезнең вазифаны җиренә җиткердегез. Сез сораган сорауга җавап бирә алмыйбыз, моңа хакыбыз бар. Безне теләсә нишләтегез, соңгы сүзебез шушы".

Түрә, башка чарасы булмаганын күргәч, безне янадан кетәклеккә яптырды.

Бу шакшы урында ябылып тотылуга күнелебез риза булмаса да, полковник Краличекләргә ничек тә зыян китермәү безнең өчен үз рәхәтебездән күпкә мөһимрәк иде. Руслар безне бергә качханнар дип уйлыйлар. Бу турыда "әйе" яки "юк" дип җавап бирсәк, качкан иптәшләрнең эзләренә төшәрлек җеп очын русларның кулына тоттырып куйган булыр идек. Без тотылдык, ичмасам тегеләр тотылмасын өчен иза чигәргә дә риза идек.

Узган ике төн йокламаган идем. Иптәшләр дә йокысызлыктан алҗыганнар. Өстенә катлам-катлам булып кер куныгы утырган сәкенең бер ягына пальтомны җәеп сузылдым. Иптәшләр дә минем кебек урнашты. Тышкы бүлмәдә гардиан мичкә утынны өстәп кенә тора. Дөнья башланып киткәннән бирле балта кермәгән урманнар—Себернең табигый хәзинәсе. Себердә яшәүчеләр бәхетле, гардиан рәхәтләнеп утыннарны мичкә

---

[1] Копейка. Тогач кайбер русча сүзләрне төрекчәгә тәрҗемә итмичә, исендә ничек калган булса шулай яза.

[2] Венгер (мажар).

тутырсын әйдә, урман кисү кайгысы да юк, тамак туйдыру хисабына гына эшләүче арзан кытай эшчеләре һәм дигәнче кисеп куя, тагын ни кирәк?

Дөрләп янган мич безне бик һәйбәтләп жылыта жылытуын, ләкин безнен белән беррәттән төрле хәшәрәтләргә дә рәхәтләнеп чабышып йөрерлек жылы бирә. Такта стенаның ярыкларыннан башта берән-сәрән генә, аннары төркемләп, ахырда көтү-көтү булып чыккан менләгән кандала, тагын әллә нинди гомердә күрмәгән бөҗәк төрләре өстебезне сырып алды. Секунд эчендә кулларым, битем, муеным бөҗәк тешләгәннән шешеп чыкты. Нихәтле генә тыгызлап төренсәң дә, әллә каян тәнгә үтеп кереп теңкәгә тияләр. Без дә каршы атакага күчтек. Ду килеп бөҗәк кырабыз, сытылган урыннарында кан таплары кала. Кем белә, бу керле такталар ничәнче тапкыр бу шакшы каннарга буялгандыр. Түзә алмаслык җирәнгеч искә лампаның корым исе дә кушылып китеп, косасыны китерә, ләкин чарасыз рәвештә боларга да күнегергә мәҗбүр идек...

Бөҗәк көтүләре белән сугышкан арада иҗтимагый мәсьәләләр турында әңгәмә корып җибәрдек. Уртак телебез алман теле. Мәдәнияттә алга киткән алман милләтенең теле монда да алга чыкты... Әңгәмәбез Төркия турында. Төркияне шактый әйбәт белүче профессор Кара безнең артка калганлыкның сәбәбен дини фанатиклыкта күрә икән. Аурупадагы кебек Төркиядә дә дин өлкәсендә реформа ясарга, җәмгыять тормышын дин кысаларыннан ычкындырып, замана ихтыяҗына күрә милли тәрбия оештырырга кирәк, ди. Фон Вернер дәшми, минем җавабымны көтә. Бу сүзләргә болай дип җавап бирдем: "Ислам дине дөньяви белемне кире какмый. Алга китүне, позитив фәннәрне хуплый. "Белемне Кытайда булса да өйрәнегез" дигән әйтем бар. Төркия инде йөз ел буенча бу юлдан бара. Аурупадагы тәрәккыйгә җитешергә тырыша. Фәкать бу юлында олы киртәләр тора. Иң башта Русия, аннан соң төрле тышкы көчләр. Төркия бераз кыймылдый башладымы, Русия, Англия һәм Франция алдына төшә. Моңа карамастан милләтче фикерләр, Көнбатыш культурасына нигезләнгән позитив фәннәр иске дини системаны кирегә таба этә бара. Лагерьдагы ике әфган[1]—хорафатларга инанган кешеләр. Ислам бу юл белән барса, дөнья шартларына һәм алга киткән милләтләргә каршы тора алмас. Мескеннәрчә баш ию психологиясе урынына позитив белемгә нигезләнгән, тырышып эшләүне максат итеп куйган ихтыяр көчен тәрбияләргә кирәк. Һәрбер төрек офицеры һәм зыялы милләтчесе шулай дип уйлый. Үзләрен мәдәни дип атаучы бер ише милләтләр алдыбызга киртә генә кормасын..."

Шул рәвештә җавап биреп, Франц Караның фикеренә кушылуымны күрсәттем. Фон Вернер кызыксынып тыңлый, сөйләгәннәрем аңа Төркиянең ул белмәгән чынбарлыгын ачып күрсәткәне сизелеп тора иде. Әңгәмә барышында бездәге хатын-кызларның хәл-әхвәлендә соңгы елларда барлыкка килгән мәдәни үзгәрешләрне дә сөйләп уздым, милли үзаңы үскән, культуралы хатын-кызларыбызның модерн тормыш кору юлында ирешкән уңышларына үрнәкләр бирдем.

"Әйе, күп кенә өлкәдә без артка калган милләт. Фәкать бай тарихыбыздан куәт алган көчле рухыбыз һәм милли горурлыгыбыз бар. Безгә киртә кормасалар, без бу артка калганлыкны җиңеп чыгарбыз".

Әңгәмәбез белән бергә хәшәрәтләр белән сугыш та очланды. Өч гайрәтле офицер, ягъни без, бөҗәкләрне кырып салдык.

Иптәшләрем мин аңлаткан әйберләрдән бик канәгать калдылар. Төркия алар өчен балачакта укыган "Мең дә бер кичә" әкиятендәге кебек серле ил түгел иде инде хәзер. Мажар дустымның минем өчен сөенече эченә сыймый иде. Фон Вернер исә төрек офицерларының үзе кебек укымышлы һәм культуралы булганына һаман ышанып җитә алмый. Минем кайда белем алганымны һәм минем кебек уйлый торган төрек офицерларының күпме, азмы булуын сорады. Мин авыз ачып өлгергәнче профессор Кара Вернерга җавап бирде, чыннан да, төрек офицерларының бик белемле, иҗтимагый дәрәҗәләре бик югары булганын, лагерьда танышкан башка төрекләрнең дә анда бик әйбәт тәэсир калдырганын сөйләп китте.

Сүз сугышка күчте. Фон Вернер кинаяле сорау бирде. Бу сорауның мин танышкан бөтен алман һәм австрияле офицерларның зиһенендә урнашканлыгын белә идем инде.

---

[1] Тогачлар качып киткән лагерьда тоткыннар арасында ике әфган кешесе дә була. Көн-төн дога кылучы, һәрнәрсәне Ходай тәкъдирендә күреп тормышта тәмам сүлпәнлеккә сабышкан, хәтта туганнарына хат язарга да теләмәгән бу ике үтә тәкъвә мөселман Тогач белән иптәшләренең качу тәкъдимен дә Аллага каршы килү, аның тәкъдиренә баш имәү буларак кабул итеп, кискен рәвештә кире кага.

Имештер, алманнар Әнвәр пашаны һәм Төркияне сугышка көчләп катнаштырганнар. Төрек халкы теләсә дә, теләмәсә дә Әнвәр пашаның кулы белән барыбер сугышка этеп кертеләсе иде. Ягъни Әнвәр паша алман агенты булып чыга. Минем бу гөманнарга бик эчем поша иде. Мона җавабым болай булды:

"Мина калса, без алманнарның хәтере калмасын дип яисә аларның көчләвенә буйсынып түгел, бәлки үз ихтыяҗыбыздан килеп чыккан мәҗбүрият сәбәпле сугышка кердек. Русларның безнең туфраклар турындагы уй-ниятләрен бик белеп торабыз. Балканнарда һәм Көнчыгыш Анадолуда чыккан сугышлар рус сәясәтенең безгә карата максатларын бик ачык күрсәтеп тора. Сәяси тарихыбыз мондый максатлардан килеп чыккан сугышлар белән тулган. Бездә бала-чагасына хәтле москофларга (русларга) тирән нәфрәт һәм үчлелек белән карый. Без бу сугышны форсат дип белдек. Рус баласын юкка чыгарыр өчен Алман-Австрия иттифагына үз теләгебез белән кушылдык. Алманнар Әнвәр пашаны котырттылар дигән сүз—чеп-чи ялган. Бу сугышка катнашу—безнең милли һәм хаяти мәнфәгатебездән килеп чыккан зарурлык".

Профессор Кара бу сүзләремне бик ошатты. Мин сөйләшкәндә "дөрес, бик дөрес" дип гел җөпләп торды. Фон Вернер исә әр-яна нәрсә өйрәнгәндәй бөтен игътибарын биреп тыңлады.

Без шулай дөньябызны онытып утырганда кинәт ишектәге йозак зыңгылдый башлады. Ишек ачылып китте, кара бүректән, кара киемнәрдән озын буйлы ябык кына берәү йөткерә-йөткерә эчкә узды. Ишек ябылды. Кергән адәм янәшәмә утырды. Утыз яшьләрендә булыр, йөзе чытык, кәефсез. Гөрҗү (грузин) икән. Җиде ел Себер төрмәләрендә ятканнан соң иреккә чыгарганнар, ләкин тагын биш ел буе Иркутск вилаяте чикләре эчендә яшәргә тиеш икән. Бүген бу авылга бер танышын күрергә килгән булган. Паспорты булмагач, моның безнең белән бергә качкан кеше булуыннан шикләнеп, монда китереп япканнар. Бичара боларны аңлатканда һәр сүздә хәле китеп буылып-буылып йөткерде, какырыклары идәнгә, диварларга, ишеккә чәчрәде. Аннары ютәле беравык туктап торды, еш-еш сулыш алган гөрҗү хәлсез башын күкрәгенә салындырды. Русларны сүгүдән туктамый, җиде ел буе менә шундый шакшы зинданнарда ятудан, күмер кебек "чорнохлеп" ашаудан юлбарыстай гәүдәсе эчтән черегән, менә хәзер үпкәсен дә чир кимерә башлаган икән. Ходайдан ахыллап гаделлек сорый иде.

Гөрҗү рус дәүләтенең һәм Себернең гомуми манзарасын чагылдыручы кечкенә генә кыйпылчык иде... Без үзебез бичараны җәлләсәк тә, шул ук вакытта бу тар бүлмәдә һәр якка чәчрәп торган какырыклардан пошаманга төштек. Ләкин ни хәл итәсең? Түзүдән башка чара юк...

Бераз вакыт узгач, ишек тагын ачылып китте. Болай да шыгрым тулы кетәклеккә тагын бер кунак килеп керде... Күрәсең, башлык авылдагы бөтен өйләрне тикшереп, паспорты булмаган шикле кешеләрне тотып монда җибәрә иде. Яна килүчеләрнең зиндан тормышына иялэшкән икәнлекләре күренеп тора, шундук үзләренә урын хәстәрләп сузылып яттылар. Мин иптәшләргә таба тыгызланып утырдым.

Төн уртасы җитте. Бераз йоклап алу исәбе белән өчебез дә сәкегә сузылдык, профессор Кара белән фон Вернер бераздан йокыга талды. Кандалалар һәм гөрҗүнең туктаусыз йөткерүе миңа йокы бирми. Бичара гөрҗү еш-еш торып утыра, кесәсеннән туфракка охшаш нидер чыгарып шуны кәгазь кисегенә төрә, моны лампага тотып төтәтеп җибәрә иде. Бу сыйфатсыз тәмәкегә махорка диләр. Исенә чыдарлык түгел. Мин берничә тапкыр укшыгандай булдым. Бер-бер артлы берничә махорка тартканнан соң сәкедән төшеп, гөрҗү иптәш сасы исле мичкәнең капкачын күтәреп шуның эченә шырылдатып сиде. Мичкәнең ни эшкә яраганын шул вакыт кына аңладым...

Вакыт авыр гына алга таба бара. Кайвакыт йокыга киткәндәй дә булам, үтергеч кычытуга да иялэшеп киләм инде. Ләкин колагымның төбендә генә гөрҗүнең үпкәләреннән гөрселдәп чыккан кискен ютәл тавышы онытылып китәргә ирек бирми... Беркайчан да бетмәс кебек тоелган бу озын төннең соңгы сәгатьләрен ярым саташып уздырдым.

Иртә булды. Озак кына ялварганнан соң гардиан безгә юыныр өчен тышка чыгарга рөхсәт бирде. Кар бөртекләре очып торган кискен суык һаваны үпкәләремә суырып алдым. Кичә ашаган ипи белән сырның калганын кәгазьгә төреп куйган идем. Кәгазьне ачып җибәргәч, бер көтү хәшәрәт төрле якка таралып кача башлады. Баксаң, "росс" дип аталган озын мыеклы бөҗәкләр көтүе төне буе безнең ризыгыбыз өстендә мәҗлес корган икән...

(Тогачны иптәшләре белән бергә якындагы шәһәрнең төрмәсенә озаталар.)

...Озын колгалардан оештырып ясалган ике канатлы капканы ике жандарм инбашлары белән этеп ачты. Гаҗәп зур канатлар шыгырдап ике якка ауды. Эчкә кердек. Ишегалдыннан бераз баргач, бүрәнәләре каралган бер иске өйгә кердек. Коридордан узып, диварлары тапланып беткән бер бүлмәгә барып кердек. Бүлмәнең бер ягында иске өстәл, почмакта иске аяк киемнәре, бирерәк иске-москы төрле әйберләр өелеп тора. Хезмәткәрләр бүлмәсе мондый хәлдә булгач, бу төрмәнең башка җирләре нинди рәвештә икән дип уйлап куйдым. Ай-һай, дуңгыз абзарыннан әлләни аермасы булмаган мондый бүлмәдә утыручы чиновниклар, мондый төрмәнең гардианнары тоткыннарга кешечә мөгамәлә күрсәтерлек бәндәләр түгелдер инде...

Бүлмәгә өс-башы керле, уртача буйлы жандарм килеп керде. Безне алып килгән жандармнар белән сөйләшеп алгач, безгә баштанаяк сөзеп карады да өстәл артына утырды. Тәрәзә төбеннән таушалган бер дәфтәр алып, ана исемнәребезне теркәде. Стенага ак буяу белән сызылган сызыклар янында баш киемсез басып тордык. Шул рәвешле буебызның үлчәве алынды. Төс-кыяфәтебез турындагы мәгълүмат та дәфтәргә теркәлде. Жандармнарның кесәсенә кучәрлек кыйммәтле әйберебез юк иде. Янадан коридорга чыктык. Коридор буенча калай белән тышланган биш-алты ишек тезелеп киткән. Һәр ишектә ат башы хәтле йозак һәм күзәтү тәрәзәчеге. Ишекләрнең иң аргысыннан килгән ихахайлап көлү, пыр тузып талашу, бала елаган тавышлар бөтен башка шау-шуларны күмеп тора. Анда хатын-кызлар камерасы урнашкан иде.

Гардиан бер ишекне ачып җибәрде. Камераның шыплап тулганлыгын күргәч, керергә базмыйча тәртелеп калдык. Гардиан безне этеп-төртеп эчкә тыгып куйды да ишекне бикләде. Ике кечкенә тәрәзәдән яктылык алган бу бүлмәдә уникe кешелек ятак урыны бар иде. Бер почмакта череп-каралып беткән бәдрәф мичкәсе, икенче якта кирпеч мич тора. Бәдрәф мичкәсеннән саркып торган сидек такта идәнне буйдан-буйга чылаткан, кайбер урыннар чери башлаган... Камерада без өч кешедән башка тагын уналты кеше бар. Тоткыннарның дәрәҗәлерәкләре сәкеләргә урнашкан, калганнары черек сасы идәнгә утырган. Без ишектән алга таба узмыйча шунда аягүрә басып калдык. Утырырлык урын карасам да таба алмадым. Дүрт-биш көнлек йокысызлыктан, арудан бик йончыган идем. Шунда берәрсе торып миңа ял итәргә урынын бирсә бик әйбәт буласы иде дә бит... Ичмасам шул идән бераз чистарак булып менә шунда гына ишелеп бераз йоклап алсаң иде... Үзем шуларны уйлыйм, үзем тоткыннарны күзлим. Сәкенең өстендә берничә сакаллы авыл агае икмәк чәйни, почмакта чал чәчле карт тирән уйларга талган. Шаровар белән күлмәк кигән берничә кытай түшләрен, култык асларын кашый-кашый идәндә әкрен тавыш белән сөйләшеп утыра. Арырак берничә кеше бет чүпли...

Шул вакыт ишек ачылып китте, бер жандарм тоткыннар заказ биреп алдырган ризыкларны китерде. Безгә дә тугызар капик акча бирделәр, шуның белән бераз икмәк белән сыр китерттек. Сәкенең бер почмагына утырып тамак ялгап алдык. Бераздан коридорга унбиш минутлык йөрешкә чыгардылар. Коридор тәрәзәсез булганга күрә, һавасының камералардагы һавадан әлләни аермасы юк иде. Коридорда йөргәндә бер әрмән егете белән таныштык. Бик бай кеше икән, гардианнарга акча биреп теләгән вакытында коридорга чыгып йөри, хезмәткәрләрнең бүлмәсенә кереп утыра, тыштан теләгән ризыгын алдыра. Профессор Кара бу әрмән белән дуслашып китте. Әрмәннең әйтүенчә, иртәгә мондагы тоткыннарны Иркутскига җибәрәселәр икән, ул үзе Иркутскида ireккә чыгасы ди. Франц Карага качып китәргә булышырга вәгъдә иткән, Иркутскида кайбер танышларының адресларын да язып биргән. Безнең өчен вакытлы документлар ясатырга да мөмкинчелеге бар имеш. Бу документлар белән без Себернең тышындагы башка вилаятьләргә дә китә алыр идек. Аннары ялган паспортлар ясатып Рәсәйдән чыгу мөмкинлеге дә булыр иде. Бу хыяллар күнелебезне күтәреп җибәрде. Ләкин русчаны бик әйбәтләп өйрәнмичә булмас. Иркутскида русча сөйләм телебезне камилләштерергә дип күнелгә беркеттек.

Кич җитте, калдык-постык азыклар белән тамак ялгап алдык. Сәкедәгеләр барысы да сузылып ятты. Идәннең корырак урынында утырышканнар арасында кытайлар, бер яһүди һәм бер дезертир чуаш бар иде. Без өчәү һаман аякта торабыз...

Сәкедәгеләр гырлап йоклый. Фон Вернер белән Франц Кара баскан урыннарында чүгәләделәр. Минем түзәр чамам калмады, сәкегә менеп, стена кырыенда йоклаучы бер авыл агаеның өстенә сузылып яттым. Бу төнне дә йокысыз уздырырга хәлем

калмаган иде. Агай мыгырданып минем астымнан янгарак шуышты. Мин түшем белән стенага терәлеп, ачылган урынга кысылдым. Шундук йоклап та киткәнмен... Бераздан тирләп-пешеп уянсам, барча түшемне бөҗәк сырып алган. Торып бераз кагынгач, икенче ягыма борылып яттым. Шул ятудан иртәнгә хәтле йокладым.

Иртәгесе көнне төнгә каршы тоткыннарны Иркутскига дип юлга алып чыктылар. Ертык юрганын, ямьшәйгән чәйнеген, сәләмә киемен төйнәп кулына тоткан яки сыртына күтәргән мескен рәвешле төркем булып төрмәдән чыктык. Безне биш-алты чанага утыртып сак астында станциягә алып килделәр. Суыктан керле юрганына яки ертык паласына төренгән яисә безнен кебек юка киемнәре эчендә куырылып бөрешкән бу тоткыннар Себернең гадәти манзарасын тәшкил итүче күренеш иде. Чатнап торган суыкта төнге күктән зәгыйфь нурларын җибәреп калтырап торган йолдызлар гына шаһит булды бу манзарага...

Ярты сәгатьтән соң поезд килде. Исемнәребезне укып вагоннарга берәм-берәм керттеләр. Эчтә 18-19 яшьләрендәге жандарм егетләр тоткыннарның кергән берсен тупас рәвештә бөтереп алып, киемнәрендә, кесәләрендә эзләнделәр,йөзекме, берничә тиен акчамы яисә буш бумажникмы, ни тапсалар шуны йолкып алдылар. Бездә таларлык әйбер калмаган иде. Шулай да соңыннан кесәләремне барлап, төрмәдә ризык акчасы итеп бирелгән тугыз капиктан жилләр искәнен күрдем. Вагонда һәрбер тоткын үзенә махсус урынга утыртылды. Жандарм кыяфәтле бу әдәпсез малай-шалай төркеме теләсә нинди сәбәп табып тоткыннарны янаклап кына тора. Бу хәлне күреп нервыларым соң чиккә каләр киерелде, шундый түбәнсетүләргә дучар булмас өчен үле кеше кебек кыймылдамыйча тып-тын утырдым.

Иртәгесе көнне кичкә таба Иркутскига барып ирештек. Качкан урыныбызга яисә һич булмаса хәрбиләр төрмәсенә илтеп куярлар дип көтеп торганда, безне һаман шул гомуми төркем эченнән аермыйча алып киттеләр. Вагоннардан төшкән 400 чамасы тоткынны дүрт колоннага бүлделәр. Тоткыннарның күбесе хаста, йөзләре саргаеп беткән, күз төпләре күм-күк. Аякларындагы кандалларны сөйрәрлек хәле калмаган зәгыйфьләрне, хатын-кызларны чаналарга утырттылар. Кыяфәте ыспай гына бер хатынның үзен утыртсалар да, 9-10 яшьләрендәге малаена, урын калмады дип, рөхсәт бирмәделәр. Укучы формасы кигән малайны әнисеннән аерып алдылар, аналы-уллы зинһарлап ялварсалар да колак салучы булмады. Иң ахырда әнисе чанадан төште, жандармнар икесен дә этеп-төртеп җәяүлеләр колоннасына, ир-атлар арасына кертеп җибәрделәр.

Без һаман безне аерып алып хәрбиләр төрмәсенә җибәрерләр дип өмет итеп тора идек. Әсир офицер икәнлегебезне, аерым мөгамәлә күрергә тиешлегебезне аңлатырга тырышып карасак та, файдасы булмады. Калын мыеклы сержант төкерекләрен чәчеп сүгенә-сүгенә безне тоткыннар рәтенә этеп кертте. Теге яшь жандармнар кылычларын суырып чыгарып колоннаның як-ягына бастылар. Каты тавыш белән кузгалырга әмер бирелде. Без дә рус тоткыннары белән бергә гади җинаятьчеләр тотыла торган гомуми төрмәгә таба юл тоттык.

Ярты сәгатьтән соң зур капкасының өстендә "Иркутская тюрьма" дип язылган бинаның алдыннан әйләнеп узып, яндагы ишеге төбенә килеп бастык. Тоткыннар коридорда кабул итеп торучы чиновникларның каршысыннан узып бер бүлмәгә керә башлады. Фон Вернерның чираты җитте. Фон Вернер баш киемен салмыйча гына узып барганда үзе тәбәнәк, үзе килбәтсез, кара туткыл йөзле бер чиновник кинәт кызып китеп фон Вернерга бәйләнә башлады. Фон Вернер үзенен әсир алман офицеры икәнен, баш киемен салмаска хакы барлыгын әйткәч, аракы исе аңкып торган бу сәрхүш чиновник аты-юлы белән сүгенеп үз буе хәтле кылычына ябышты. Тирә-яктагылар кулларыннан эләктереп аны тынычландырырга керește. Фон Вернер ничарадан бичара баш киемен салып узып китү ягын карады. Тоткыннарны кабул итү тәмамлангач, аларны исем белән чакырып чыгарып камераларга урнаштыра башладылар. Чиратыбыз килеп җиткәч, бүлмәдән чыгып күрсәткән урынга бастык. Башкаларны тикшереп тормасалар да безне анадан тума чишендереп эзләнделәр. Фон Вернерның монарчы яшереп килгән алтын сәгатен алдылар. Өч гардиан безне аерым-аерым юнәлештә алып китте. Мине тар коридордагы бер тимер ишек алдына китерделәр. Гардиан ишекне ачты, мин кергәч яңадан биклэп куйды.

Алдымда озынча бүлмә. Түшәмгә эленгән өч лампа бүлмәнең эчен көч-хәл белән генә шәйләрлек тонык яктылык бирә. Ике стена буенча сәкеләр тезелеп киткән, сәкеләрдә кешеләр ята, сәкеләр генә түгел, бөтен идән дә кеше гәүдәләре белән тулган,

үзе тып-тын. төрле рәвешләрдә ятып, утырып, һәм басып боручы кешеләрнең күренеше зиратны хәтерләтә. Әйтерсең, болар кеше түгел, янтайган яисә ауган кабер ташлары. Бары тик йөткергән тавышлар һәм кандал зыңгылдавы гына бу зиратның тынлыгын боза иде.

Мин һаман ишек янында басып торам. Барыр урын юк, ишек янындагылар бу чакырылмаган кунакка битараф күз карашы гына ташладылар. Янәшәмдә 7-8 бәдрәф мичкәсе. Болардан килгән жирәнгеч ис тәбәнәк түшәм астында тирбәлеп торган авыз исе һәм махорка төтененә кушылып китә, тоткынныраның эчкә иңгән зәгыйфь күкрәкләрендәге черек үпкәләренә тула иде. Шундук күңелем болгана башлады. Моңа хәтле күргән гомуми төрмәләрнең атасы иде бу. Ләкин ни хәл итәсең, сабыр итүдән башка чара юк.

Бүлмәнең теге очында стенага терәтелгән өстәл тора. Өсте чәйнек, кружка ише савыт-саба белән тулган. Бу өстәлгә таба юнәлдем, ятып торучыларның кулларына, аякларына басмыйм дип, буш урыннарны сайлап сикереп барам. Шулай да кайберәүләрнең әгъзаларына ялгыш басып әче сүгенүләргә коенып алдым. Руслар арасында иң еш колакка чалынган сүгенү рәвеше кешенең анасына тел тидерү.

Өстәлнең бер почмагында үземә кечкенә генә урын бушатып, шунда утырдым. Тоткыннарның кайберсе, өстәлгә сузылып ятарга чамалый дип уйлап, канәгатьсез тавыш белән мөгрәп алды. Берәү яныма килде. Азәри акценты белән төрекчә:

—Сән афисәрсен? (Син офицермы?)—дип эндәште. Сөйләү рәвешеннән әрмән икәнлеген аңлап алдым.

—Әйе,—дип жавап бирдем.

—Сәни харда тутуплар? (Сине кайда тоттылар?)

Жавап бирмичә башымны борсам да янымнан китмәде, өзми дә куймый мине сөйләштерергә тырыша. "Сакчыдан сорадым, син төрек офицеры икәнсең, мин Кавказлы әрмән. Син дә Кавказда булдыңмы?" дип. Тагын ике кеше яныма килеп басты, болар да әрмән икән. Сөйләшеп киттек. Сорауларын жаваплап әсирлегемә инде бер ел тулганын, качып китеп барганда тотылганымны әйттем. Боларга дүренчесе дә килеп кушылды. Төрекчә: "Төркиядә әрмәннәрне ник үтерәләр?" дип сорады[1]. Әрзурум чыгышлы бу әрмәннең соравы сөйләшүебезгә яңа юнәлеш бирде. Бу сорауга уйлап жавап бирергә кирәк иде. "Бу ялган сүз, рус газеталары юри шулай яза, шул рәвешле әрмәннәр белән төрекләрне бер-берсенә дошман итеп үзара сугыштырмакчылар. Берәр авыр гаеп эшләгән әрмәннең яки мөселманның үлем жәзасына хөкем ителгән булуы мөмкин. Сугыш чорында бу була торган хәл. Төркиядә жирле әрмән халкы имин яши",—дидем.

Мин әсир төшкәнчегә хәтле Төркиядәге әрмәннәр чыннан да имин яшәгән иде. Рус газеталарында язылган хәбәрләргә мин үзем дә ышанмый идем.

Әрмәннәр бу сүзләремне ышаныч белән кабул итеп, үзләрен бер сәбәпсезгә кырып яткан русларга ләгънәт укыдылар.

Мин боларга әтиемнең Кавказ чыгышлы икәне, балачагымнан бирле әрмәннәр белән күрше булып, дус яшәгәнебезне сөйләдем. Бик күңелләре булды, дуслашып киттек. Бер нәрсә игътибарымны жәлеп итте: монда руслар белән кавказлылар арасында дошманлык сизелә иде. Тоткыннар яңа кешене аксыл чәчле, аксыл чырайлы яисә кара туткыл йөзле, коңгырт чәчле булуына карап үз итәләр. Мин кара чәчле, кара

[1] 1915 елда Төркиядә ул вакытта дәүләт хакимиятен кулында тотучы "Иттихат вә тәрәккый" партиясе үзәк комитетының карары буенча (бу эшкә бигрәк тә Әнвәр һәм Тәлгать пашалар активлык күрсәтә) һәм аз санлы бер төркем дәүләт эшлеклесенең күзәтүе астында, руслар белән хезмәттәшлек итәләр дигән сылтау белән, Төркиянең көнчыгыш төбәкләрендә яшәгән әрмәннәрне Сириягә сөрәләр. Шул вакытта әрмәннәрнең бер өлеше үтерелә, маллары талана, әрмәннәрнең күпмедер өлеше юлдагы һәм сөрген урынындагы начар шартлар сәбәпле үлә. Әрмән сөргенендә бары тик бер төркем дәүләт эшлеклесенең генә катнашы булганы, төрек халкының тулаем алганда әрмәннәр белән тату яшәгәнлеген ассызыкларга кирәк. Әрмән сөргене барышында бу операциягә каршы килгән яки әрмәннәргә ярдәм итәргә тырышкан кайбер төрек чиновниклары эшеннән алына, хәтта актив каршылык күрсәткән берничәсе үтерелә. Әрмән сөргене мәсьәләсе бүген дә төрекләр белән әрмәннәр арасындагы мөнәсәбәтләрдә киеренкелек төенен тәшкил итеп тора. Әрмәннәр бу сөргенне "геноцид" дип атап, төрекләргә бик зур үпкә саклыйлар. Төрекләр исә бу турыда бүген икеләнүчән позициядә торалар. Бер өлеше әрмәннәргә карата начарлык эшләнгәнен кабул итсә дә, күпчелек бу сөргеннең ул вакыттагы сугыш шартларында кирәкле гамәл булганын, әрмәннәрнең русларга зур ярдәмнәр күрсәтеп Төркия дәүләтенең бу гамәленә үзләренең сәбәпче булганын сөйләп, төрек ягын хаклы күрсәтә.

күзле булгач, әрмәннәр кавказлы дип мине үз кеше итеп күрә башладылар. Үзләре дә кара туткыл, кара чәчле иде.

Бераздан әрмәннәр үз урыннарына киттеләр. Күнелсез уйларга чумып утырам. Күпмедер вакыт узгач, әрмәннәрнең берсе яңадан яныма килеп, монда бер кавказлы мөселман барлыгын әйтте. Күрештерергә сорадым. Озын буйлы, озын кара сакаллы, өстендә төрмәдә бирелә торган күлмәк-ыштаннан башка киеме булмаган берәү яныма килде. Ап-ак ябык йөзендә казналыклары беленеп торган бу кеше тоньк тавыш белән:

—А башыма дөнүм, ханжарысан, яхшысанмы?—диде.

Минем төрек офицеры икәнемне белеп алган бу азәри шулай ихлас һәм гади эндәшеп хәлемне белеште.

—Яхшыям, сән ханжарсан...

Бичара башын иеп:

—Нә дийим,—диде дә тынып калды.

Төрмәгә кайчан һәм ни сәбәптән эләккәнен сорадым.

1905 нче елда руслар мөселманнарны әрмәннәр белән сугыштырган вакытта бер түрә үтерелгән. Шул мәсьәләдән бу да кулга алынган, Себергә хәтле сөргәннәр. Шуннан бирле җанын асрап килә алган булса да инде тәмам бетәшкән, чыдамы калмаган. Җәзасы тәмамланган инде, ләкин карантин булганга гына тоталар, 20 көннән соң чыгарга тиеш, имеш. Ләкин үзе бөтенләй өметен өзгән, чыгасына ышанмый икән. Кавказлы боларны өзек-өзек, туктый-туктый көч-хәл белән аңлатты. Бичараның хәле чыннан да шәптән түгел иде. Яхшы теләкләр теләп, үз урынына кайтып ятарга, ял итәргә куштым. Моңайган кыяфәт белән китеп барды.

Аннан соң яныма бер татар килде. Бик елгыр, тере, шат күнелле кеше иде бу. Бик сусаган идем, татар миңа чәйнекләрдән сөзеп алып бераз су китерде. Бу су сусынымны басарга җитмәде, киресенчә, эчкән саен эчәсем генә килә иде. Татар миңа су җиткерә алмыйча аптырашка төште. "Син ачыккансың, шуңа күрә эчәсең килә, сина бераз чорнахилеп[1] бирим", дип, керле чүпрәккә төрелгән кечкенә генә икмәк кисәге алып килде. Чып-чын төрмә икмәге иде бу. Моңа хәтле ашаган чорнахилепләрнең берсенә дә охшамаган, әйтерсең күмер белән басканнар. Кабыгы әче, пешеп җитмәгән ябышкак йомшагына салам кисәкләре белән төрле чүп-чар да катнашкан. Бу ипи бармакларыма һәм тешләремә сыланды.

Татар Фәтхулла да янымнан китеп барды. Өстәлнең почмагына кагып куелган кебек утырып торам һаман. Ачлыкны, арыганлыкны сизмим дә, нервыларымдагы киеренкелек белән аякта торам. Әмма башым үтереп сызлый, аны кая да булса терисем килә.

Әрмәннәрнең берсе тагын яныма килде, "Безнең янга кил, сина урын аерырбыз",—диде. Шулхәтле сузылып ятасым килә иде ки, шундук ризалашып артыннан ияреп киттем. Миңа икмәк кисәге бирделәр, ашый алмадым. Әрмәннәрнең өчесе дә тезләрен аякларына тартып янга борылып яткач, аякларының очларында миңа буш урын ачылды. Мин шунда утырып башымны берсенең ботына салдым. Шул хәлдә бераз йокымсырап киткәнмен. Ләкин болай аларга да, миңа да унайсыз иде. Яңадан тураеп утырдым. Тирә-ягыма күз аттым. Бүлмәнең бер почмагында өч-дүрт кеше кәрт суга, берсе яктылык төшсен дип түшәмгә эленгән лампаны аларга төзәп тотып тора. Кәртләрне Инҗилдән ертып алган кәгазь кисәкләреннән ясыйлар икән. Калынрак булсын өчен бу кәгазьләрне ипи йомшагы белән икешәр-өчәр кат ябыштыралар. Кәртчеләрнең берсе яныма килде, кыяфәте шактый ыспай, үз-үзен тотышы әдәпле. Минем төрек офицеры икәнемне ишетеп калган. Ятып торыр өчен үз урынын тәкъдим итте, хуҗасы кәрт уйнаганга күрә урыны әлегә буш тора икән, теләсәм әзрәк ял итәргә мөмкин икәнлеген белдерде. Бу тәкъдимне шундук кабул иттем, әрмәннәргә рәхмәт әйтеп бу кеше күрсәткән урынга киттем. Яңа урыным нәкъ тәрәзәнең кырыенда иде. Тәрәзәнең бер почмагында пыяласы кителеп төшкән, аны капларлык берәр нәрсә таба алмадым. Итекләремне баш астына куеп, пальтома төренеп яттым. Күпмедер вакытка йокыга талганмын. Өстемдә ниндидер авырлык тоеп уянып киттем. Авыр гәүдәле берәү мине кысрыклап үзенә буш урын ачарга маташа икән. Ятакның хуҗасы килгәнлеген аңлап алып, урынымнан торып киттем. Яңадан өстәлгә утырып уйга чумдым. Шул хәлдә таң аттырдым.

Барча тоткын бик иртә уянды. Иң беренче эш итеп тоткыннар бәдрәф мичкәләрен чыгарып түктеләр, идәнне сөрткәләп, үзенә күрә чистарткан булдылар.

---

[1] Черный хлеб.

Бераздан ишек янадан ачылып китте, мичкә белән кипеток[1] китерделәр. Кайнар су мичкәдән өстәлдәге эреле-ваклы чәйнекләргә, кружкаларга күчте. Һәркемнең кулында такта кисәгенә охшаш чәй калыплары пәйда булды. Болардан бер кисәк сындырып суга салгач, чәй була. Шикәр юк, халык кичәгедән калган ипи кисәкләре белән чәй эчте. Бу эш тә шулай тәмам булды.

Ишек янадан ачылып китте, ике кеше күренде. Берсе гардиан, икенчесе медицина хезмәткәре икән. Авыру бармы, дип сорадылар. Янымда татар Фәтхулла утыра иде. "Авыруга салышсам, мине шифаханәгә салырлар микән",—дип сорадым. Фәтхулла көлеп җибәрде. "Синең йөзеңдә кан бар әле, чын авыруларны күрерсең хәзер. Аларны да шифаханәгә салмыйлар монда",—диде.

Баксаң, ишек янындагы сәкеләрнең астында бер көтү сырхау ауный икән. Боларда тиф, дизентерия, туберкулез—җаның ни тели, һәртөрле чир бар икән. Ташландык хәлдә үлем көтеп ята бичаралар. Килүчеләр сәке астында ике җансыз гәүдә табып алдылар. Үлеләрне чыгардылар, сәке астыннан сөйрәлеп чыгып фельдшерга ялварган авыруларга әйләнеп караучы булмады.

Аякта басып торса да үзен авыру дип әйткән берничә кешенең исемен дәфтәргә язып алдылар. Болары, күрәсең, йә акчасы, йә дәрәҗәсе булган мөһим тоткыннардыр. Шул рәвешле саулык тикшерү эше тәмамланды.

Күпмедер вакыт узгач, ишек янадан ачылып китте. Гардиан сыбызгы сызгыртты, шунда бүлмәнең эчендә әйтерсең давыл купты. Мин әллә җир тетриме дип торам. Бүлмәдәге халык ашыга-ашыга уртада дүрт рәт булып тезелде. Мин сәкедә утырган килеш боларга аптырап карап торам. Татар йөгереп яныма килде, "Абзый, абзый[2], кил, син дә рәткә бас, юкса кыйнарлар сине"—дип, мине тартып китереп янына бастырды. Гардиан каты тавыш белән нәрсәдер боерды. Старши[3] күренде. Тоткыннар беравыздан "Ходай әфәндебезгә озын гомерләр бирсен", кебегрәк бер дога укып, аннары старшины сәламләделәр. Старши сәламны алды, тоткыннарны санап чыкты. Шуның белән проверка тәмамланды.

Төш җитәрәк ишек кабат ачылды. Бу юлы тоткыннар коридорга чыгып тезелде, аннан ике рәт булып төрмәнең ишегалдына чыктык. 15 минутлык напрогулка[4] булды. Кырык сантиметр чамасы калынлыктагы карда көрәп сукмак ясаганнар, шунда бер рәт булып түгәрәк ясап әйләнеп йөрибез. Биек таш диварларның теге ягын күреп булмый. Бу стеналарны кат-кат итеп ясаганнар. Араларына тимерчыбык сузганнар. Почмакларда сакчы будкалары тора. Бу Себернең иң зур төрмәләреннән берсе булса кирәк. Без качып киткән хәрби лагерьга бер дә охшамаган. Монда җир астын казу яисә калын диварларга үрмәләү турында уйлама да. Түгәрәктә әйләнеп йөргәндә тирә-ягымны шул максат белән генә күзләдем. Кала диварлары кебек күккә омтылып торган стеналарның теге ягынданиләр барлыгын күреп тә, ишетеп тә булмый. Төрмә гүя кешелек галәме белән бөтен бәйләнешен өзгән аерым бер дөнья. Монда галимнәр, идеалистлар, сәясәтчеләр, җинаятьчеләр, садистлар, караклар, кыскасы, югары һәм түбән катлаудан төрле-төрле кешеләр бар. Гаепледәре дә, гаепсезләре дә бергә өелгән, патша диктаторлыгының символы булган бу дәһшәтле стеналарның эчендә, авыру һәм үлем аңкып торган бу урында бер үк язмышны уртаклаша. Менә без дә исерек чиновникның капризы аркасында монда килеп эләктек. Төрле йогышлы авырулар кайнап торган бу җиргә ябып, безне күрәләтә хасталык һәм үлем кочагына аттылар. Кем белә, капризларның, явыз ниятнең, садистлыкның корбаны булган тагын күпме кеше бардыр монда...

Бер төркем кешеләрнең башкаларның ирегең тартып алырга һәм аларны бу хәтле начар шартларда тотарга ни хаклары бар? Бу тормыш никадәр рәхимсез, никадәр катлаулы... Бу хәлне ничек җиңәргә соң?

Әйе, ничек җиңәргә? Ике юл бар. Йә "Язмыш бу, нихәл итәсең" дип, буйсынасың. Йә инде котылу чарасын эзлисең. Бәлки бу икенче юлның да ахырында үлем бардыр. Ләкин бары тик бу юл гына адәм баласына килешә. Мин дә үземне котылуны эзләү юлында атлап баручы итеп хис итә идем.

[1] Кипяток, кайнаган су.

[2] Тогач "абзый" сүзен башта аңламыйчарак тора, аннары "абый дип әйтә, ахрысы", дип дөрес нәтиҗә ясый (төрекчәдә дә "абый" сүзе бар, ләкин "аби" рәвешендә бераз нечкәртеп әйтелә).

[3] Старший.

[4] "На прогулку" дигән сүздән.

Аякларым кар эчендәге сукмактан атлый, башымда исә бу уйлар йөгерешә иде.

Төш вакытында ишек янадан ачылды, икмәк китерделәр. Бу икмәк кичәге кебек күмерле камыр түгел иде. Чәйнәп йотарлык. Аннары мичкаләр эчендә борщ килде. Борщ дип кәбестә кайнатмасын әйтәләр. Эчендә ит бар иде микән, белмим. Әрмән дустым миңа да өлеш алды. Минем кашыгым булмаганга күрә, аларның савытыннан үз өлешемне эчтем. Каяндыр табып миңа бер кисәк салкын ит тә бирделәр. Төнне йокысыз кичергәнгә күрә үтереп башым сызлый. Әрмәннәрнең буш сәкесенә ятып йокладым. Кичкә таба татар дустым мине уятты. Гардиан мине шактый көтеп торган, торып коридорга чыктым.Фон Вернер белән Франц Кара да коридорда басып тора иде. Аларны күргәч, бик сөендем. Гардиан камерадагы танышлар белән хушлашырга рөхсәт итмәде. Өчебезне дә алдына алып безне тышка алып чыкты. Төрмә ишегалдының ерактагы почмагында торган бер бинага илтеп куйды.

Яңа камерабыз бөтенләй башка төрле иде. Ике як стена буйлап ике сәке ясалган, бүлмәнең уртасы шактый иркен, киң булып калган. Түшәмгә ике лампа эленгән, бер почмакта мич тора. Бәдрәф мичкәсе юк, шунадыр, күрәсең, бүлмәнең һавасы саф. Зыялы күренешле унбишләп тоткын бар, кайберсенең аягына кандал тагылган. Сигез-унлап кеше Ләх иленнән (Польшадан) тотып китерелгән Алман һәм Австрия ватандашы икән. Болар арасында 16 һәм 18 яшьләрендәге ике лицей укучысы да бар. Мондагылар акча белән тыштан ризык сатып ала ала икән. Камерадагылар кайвакыт жыр жырлап хушланалар. Руслар бигрәк тә үзләренең мәшһүр композиторлары Чайковскийның арияләрен бик матур итеп хор белән көйлиләр. Безнең элеккеге камерада жыр жырлау кая, кычкырып сөйләшергә, бәхәсләшергә дә ярамый, гардианнар шундук тукмап ташлый иде.

Бу камерага тоткыннарны дыңгычлап тутырмаганнар, авыру да юк. Элеккеге урыныбызда фон Вернер да бер сырхауга арка терәп яткан, Франц Кара да минем кебек үзенә урын таба алмыйча тегендә-монда күчеп йөргән икән...

Алманнар һәм австриялеләр белән шундук танышып, дуслашып киттек. Болар Польшаның чик буена якын урыннарында яшәгәннәр. Руслар болардан шикләнеп Себергә сөргән.

Яңа урынымда рәхәтләнеп йокладым. Икенче көнне тыштан икмәк, сыр, халвә, балык консервысы ише әйберләр алдырып, мул ризыкка тиендек.

Тоткыннарны барлау вакыты килде. Старши килеп кергәч, бөтен кеше торып басты, без генә утырып калдык. Урта яшьләрдә, куе кара мыеклы, могтәбәр кыяфәтле старши безне гомуми төрмәгә тыккан сәрхүш кәрлә чиновник кебек кыйнап чыкмады. Тыныч һәм салкын тавыш белән торып рәткә басарга кушты. "Без утырып торсак та саный аласыз бит",—дип жавап бирдек. Гадәтләнгән тәртиптән тайпылырга исәбе юклыгы күренеп торган старши янә тынычлыгын жуймыйча гына безне бу сүзләр белән кисәтте: "Сезнең офицер булуыгыз миңа мәгълүм, фәкать бу бүлмәдә бар кеше дә тигез хәлдә. Хәтта генерал Куропаткин (1905 рус-япон сугышында баш командир булган кеше) да бу камерада тотылган вакытында мондагы тәртипләргә буйсынды. Әгәр сүз тыңламасагыз, карцерга жибәрербез. Андагы шартлар бик начар, басып яки утырып торырлык кына урын бар. Икмәк белән судан башка ризык та бирмиләр. Һәр көн 20-60 камчы да суктыралар".

Тәжрибәле һәм мөхтәрәм зат булуы күренеп торган старшиның безгә боларны яхшы ният белән аңлатканын төшенеп торып бастык.

Берничә көн узды. Безне монда тотарга рус идарәсенең хакы юк иде. Безне әсир лагерена яисә гаскәри хастаханәгә жибәрүләрен үтенеп, укырга газета, китап бирүләрен сорап гариза яздык. Күпмедер вакыттан соң безне офицерлар хастаханәсенә күчерделәр. Дүрт тимер карават торган бер бүлмәгә урнаштырдылар. Монда хәлебез әйбәт, кайнар аш, чәй бирәләр. Йомышларыбызны үтәргә бер яшь солдат та куйдылар. Качып киткән бүлмәбездә калган китапларны сорап, янадан гариза яздык.

Берничә көннән соң безне моннан да чыгарып, качып киткән урыныбызга кире кайтарып куйдылар. Иске бүлмәбезгә урнаштык. Без тишкән урыннарны ямап куйганнар..."

*Төрекчәдән тәржемә итеп,*
*Ләйсән ШАҺИН әзерләде.*

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# Ә

**ӘХМӘТГАЛИЕВ** Мөхәммәт Ибраһим улы (21.2.1920, Казан—27.8.1943), шагыйрь. 1938–41 елларда Казан пед. ин-тының биол. ф-тында укый. 1934 елдан башлап шигырьләре "Яшь ленинчы" г-тасында, "Пионер каләме" ж-лында, "Шат балалык" (1938), "Очкыннар" (1940) кебек күмәк җыентыкларда дөнья күрә. 1942 елда фронтка китә, Смоленск тирәсендә барган сугышларда һәлак була. Сугыштан соң Ә.нең балаларга багышланган әсәрләре аерым кечкенә китаплар булып басылып чыга: "Балык тотканда" (1957), "Тегүче куян" (1959), "Елак батыр" (1960).

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**ӘХМӘТҖАН** БОЛГАРИ (тулы исеме Әхмәджан ибне Шәмседдин әл-Абави әс-Самари әт-Тубыли) (1826, Сарабиккол а., хәзерге ТРның Лениногорски р-нында—1890нан соңрак, Тобол ш.), шагыйрь, дин эшлеклесе, туган авылында имам булып торган. Утыз Имәнинең кияве. 1871 елда нахак шикаять б-н кеше үтерүдә гаепләнеп, гомерлеккә Тобол шәһәре төрмәсенә утыртыла. 1886 елда җирле татар-мөселман җәмәгате үтенече б-н төрмәдән чыгарыла. 1889 дан Тобол шәһәре янындагы Ишай дигән авылның (хәзер юк) имам-хатибы һәм мөдәррисе. Ә.Б. иҗат мирасыннан төрмәдә чакта татар, гарәп, фарсы телләрендә язган шигырьләр җыелмасы, моннан тыш күп кенә шигъри хатлар, вафат булган замандашлары яисә туганнары (мәс., Утыз Имәнинең җәмәгате һәм улы, үзенең кызы Мәрвәрелҗиһан) истәлегенә язган мәрсияләр һ.б. жанрдагы әсәрләр сакланып калган. Арада мәхәббәт лирикасы да зур урын алып тора. Ә.Б. "Ләйлә вә мәҗнүн" кыйссасының татарча версиясе авторы буларак та билгеле. Ә.Б.ның поэзиясе фәлсәфи уйланулар һәм суфичылык мотивлары б-н сугарылган, шигъри стилендә Утыз Имәни поэзиясенең тәэсире нык сизелә. Кульязмалары ТРФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының Кульязмалар һәм текстология бүлеге фондында саклана.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. 1997. N 1.

Автор: *М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӘХМӘТҖАНОВ** Марсель Ибраһим улы (26.3.1939, Шөгер р-нының Шөгер а.), әдәбият галиме, археограф, филол. фән. д-ры (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1972 елдан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, 1986 елдан ин-тның кульязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсен җитәкли (1997 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тына карый). Г.Ибраһимов (т. 1–9, 1974–2000), Х.Такташ (т. 1–3, 1980–83), Ф.Әмирхан (т. 1–4, 1984–86) әсәрләрен бастыру өчен текстологик яктан әзерләүдә катнаша. Татар мәдәнияте тарихы проблемаларын өйрәнүдә, үзен күпкырлы фәнни тикшеренүче буларак таныта; әдәбият белеме һәм текстология өлкәсенең актуаль мәсьәләләренә багышланган язмалар авторы буларак билгеле. Хезмәтләре милли шәҗәрәләр, татар әдәбияты, теле, фольклоры, сәнгате, эпиграфикасы, кульязма китабы тарихына карый. Аның тарафыннан 3500 дән артык кульязма китап, 320 шәҗәрә, 1500 тарихи документлар җыела һәм тасвирлана.

Хезм.: Татарские шеджере (Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах по спискам XIX–XX вв.). К., 1991; Мөхәммәдъяр һәм аның чоры. К.,1997; Дастаннар китабы. К., 1999; Татар кульязма китабы. К., 2000; Үлгәннәрнең кадерен бел. К., 2000.

Әд.: Мәрҗанинең рухи варисы // Мирас. 1977. N 3; Рәмиев З. Күпкырлы гыйлем әһеле // Ватаным Татарстан. 1999. 16 апр.

**ӘХМӘТҖАНОВ** Миңнехан Газиз улы (25.8.1931, Мамадыш р-нының Акман а.), әдәбият галиме, пед. фән. д-ры (1996), проф. (1997), РТның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1959). Мамадыш (1948–63), Казан (1963–71) урта мәктәпләрендә рус теле һәм

әдәбияты укыта. 1971 елдан Милли мәктәпләр буенча фәнни-тикшеренү ин-тының татар филиалында эшли, 1977 дән Казан пед. ин-тында, 1988–99 да әдәбият каф. мөдире, 1999 дан рус, чит ил әдәбияты һәм аларны укыту методикасы каф. профессоры. Рус әдәбиятын укыту методикасы мәктәбе төзүчесе. Хезмәтләре рус әдәбиятын татар мәктәпләрендә укыту методикасына карый. Рус әдәбиятын татар һәм милли мәктәпләрдә укыту өчен язылган дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы.

Хезм.: Изучение литературных взаимосвязей в татарской школе. К., 1979; Вопросы преподавания русской литературы в национальной школе. Л., 1982 (автордаш.); Уроки внеклассного чтения в 4–7 классах национальных школ. Л., 1985 (автордаш).

**ӘХМӘТҖАНОВ** Рәшит Хәниф улы (14.4.1941, Баулы р-ны Татар Кандызы а. — 5.1.1995, Казан), шагыйрь, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1969-74 елларда ТАССР Мәдәният министрлыгында инспектор, "Яшь ленинчы", "Татарстан яшьләре" г-таларында әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара. 1980 елдан "Казан утлары" журналы редакциясендә. Әдәбиятка 1950 еллар ахырында килә. "Хыялларым үзем белән" (1965) дип аталган беренче шигъри җыентыгы белән үк поэтик тасвир һәм фикерләүдә мөстәкыйль, хисләргә бай лирик шагыйрь итеп танытты. Шигырьләренә үзгә бер моң, халык җырларынча җыйнаклык, музыкальлек хас. "Адымнар" (1969), "Ак канатлар" (1972), "Гомер чишмәсе" (1976), "Җан яктысы" (1980) җыентыкларында замандашларының уй-кичерешләрен, хезмәткә мөнәсәбәтен, җәмгыять, туган җир алдындагы бурычларын чагылдыра. Аның шигырьләрендәге лирик герой үзенең әхлакый сафлыгы, характерларның рухи бөтенлеге, ихласлыгы белән үзенә тарта. Илдә демократик үзгәрешләргә юл ачылган чорда, Ә. иҗатында тематик офыклар тагын да киңәйде, анда милли әчтәлектәге хис-мотивлар, тарихи-фәлсәфи гомумиләштерүләр аеруча активлашты. Бу сыйфатлар шагыйрьнең милли азатлык хәрәкәтен, республикабызның мөстәкыйльлеге өчен киеренке көрәшен чагылдырган "Кавышыр көн" (1985), "Йөрәк бәйрәме" (1988), "Моңлану" (1991), "Ачлык мәйданы" (1994) җыентыкларында бигрәк тә калку гәүдәләнә. Иҗтимагый-сәяси әчтәлекле "Йөрәк бәйрәме" һәм "Моңлану" шигъри җыентыклары өчен Ә.ка 1992 елда Гаяз Исхакый премиясе бирелде. Кайбер шигырьләре көйгә салынып, популяр җырларга әйләнде.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1998; Сәфәр ае. К.,2001.

Әд.: Туфан Х. Өметләрне аклады // Казан утлары. 1971. № 9; Әгъләмов М. Чәчәк җылысы // Социалистик Татарстан. 1981. 29 апр.; Батулла Р. Акчарлакның сагышы // Казан утлары. 1996. № 1.

**ӘХМӘТҖАНОВ** Роберт Вәли улы (1.4.1935, Балык Бистәсе р-ны Балык Бистәсе а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). 1959 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1962-63 елларда Татар опера һәм балет т-рында әдәбият бүлеге мөдире, 1964-68 дә "Социалистик Татарстан" г-тасында әдәби хезмәткәр. 1958 елда "Егерменче яз" исемле беренче җыентыгын бастыра. 1968 елдан әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Ә.нең шигырьләре публицистик пафосы, фикер-хисләренең киеренкелеге, романтик күтәренкелеге, форма һәм сурәтләү алымнарындагы яңача образлылык хасиятләре белән үзенчәлекле. "Страна Июнь" (русчага тәрҗемә, М., 1979), "Хәтер елгасы" (1980), "Гомер тирәге" (1985), "Җәяүле күбәләк" (1990), "Тургай тәрәзәсе" (1995) һ.б. шигъри җыентыкларында замандашларының бай эчке дөньясын тирән чагылдырган нечкә хисле лирик булып танылды. Туган ил, аны ярату, кайгырту, аның үткәне һәм бүгенгесе, сугыш һәм тынычлык темалары Ә. иҗатында үзенчәлекле гәүдәләнеш таба. Аның идея-әхлак позициясе, дөньяга фәлсәфи карашында чагыла. Татар поэзиясенең ерак гасырлардан килгән традицияләренә таянып, шигъри форма һәм сурәтләү чараларын баету юнәлешендә кыю эзләнүләр алып бара. Шигъри теле чагыштыруларга, метафораларга бай; ритмга салынган, музыкаль яңгырашлы. Кайбер шигырьләре, композиторлар М.Мозаффаров, Ф.Әхмәдиев, А.Монасыйпов, Р.Еникеев, Р.Яхин З.Гыйбадуллиннар тарафыннан көйгә салынып, халык арасында популяр җырларга әверелде. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2001).

Әсәр.: Идел-йорт: Шигырьләр, поэмалар. К., 1972.

Әд.: Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984.

**ӘХСӘНЕВ** Ильдар Гали улы (27.8.1935, Әлмәт а., хәзерге Әлмәт ш.), шагыйрь, журналист. 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1952 елдан матбугатта мәкаләләре басылып килә. Татар һәм рус телләрендә яза. 1955-92 елларда ТРның нефть чыгару предприятиеләрендә эшли, район һәм респ-ка газета-журналларында хезмәттәшлек итә. 1993 елдан "Нефтяник Татарстана" г-тасы хезмәткәре. "Кыйбла" (1985), "Ак дөнья" (1987), "Җирәбә" (1995) дигән китапларында кешенең туган җире алдындагы бурычы, нефть төбәге эшчеләре, шул төбәкнең экологиясе, киләчәк буын, мәхәббәт турындагы шигырьләре тупланган. Шигырьләре гражданлык хисе белән сугарылган, аларга нечкә лиризм хас. Ә. нең Татарстан Респ-касы нефть төбәге р-нарының социаль-экономик хәлен, аның экологик проблемаларын күтәргән "20 лет в пути" (1998), "Даль памяти" (1998) дигән публицистик очерклар җыентыклары социаль яктан әһәмияткә ия.

**ӘХТӘМЕВА** Роза (Рауза) Зәйдулла кызы (4.6.1947, Свердловск өлкәсе, Ревда ш.), шагыйрә, тәрҗемәче. Казакъ ун-тын тәмамлый (1973). Рус телендә яза. Яшьли сукырая. Алма-Атада яшәп, беренче шигырьләрен матбугатта 1970 елларда бастыра башлый. Иҗаты: Алма-Ата ш. чыккан "Көйгән йөрәк" ("Обожжённое сердце", 1994), "Язмышлар һәм хакимнәр" ("Судьбы и судьи", 1997) шигырьләр, "Яхшылык кыл" ("Сотвори добро", 1993) тәрҗемәләр, "Күңел күзе" ("Свет прозрений моих", 2001), "Хәтер тәрәзәсе аша" ("Через окно воспоминаний", 2001) очерклар һәм хикәяләр җыентыклары. Казакъ, әрмән, төрек, немец телләреннән рус теленә тәрҗемәләр авторы, татар шагыйрьләреннән М.Хөсәен, С.Сөләйманова, Г.Афзал, К.Булатова, Р.Миңнуллин шигырьләрен тәрҗемә итә. 2001 елдан Мурманск өлкәсендәге Аппатиты ш. яши.

Әд.: Судьбы и судьи // Вступ. Ст. Бадикова В. "А я из тех...". А.-А., 1997.

**ӘҺЛИУЛЛИНА** Фирдәвес Әсәдулла кызы (11.1.1954, Казан), язучы. 1974 елда Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый. 1978-79 елларда Казан курчак т-рында, 1981-85 елларда Татарстан кит. нәшриятында, 1996-99 елларда "Мәдәни җомга" г-тасында эшли. Татар мәдәниятенең күренекле шәхесләре турында "Йолдыз язмышы" (1986), "Әлмәндәрләр әманәте" (2001) һәм "Ай тулган төндә" (2001), балалар өчен "Ак күгәрчен" (1990) дигән әкиятләр, лирик шигырьләре тупланган "Кояш баласы" (1999) исемле китаплар авторы. Әсәрләре табигать матурлыгы тәэсирендә туган һәм символик мәгънәгә ия булган поэтик образларга бай. Кайбер шигырьләренә көйләр язылган.

**ӘЮПОВ** Харрас Гыйльмегали улы (21.8.1946, Мөслим р-ны Түреш а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1972-83 елларда "Татарстан яшьләре" г-тасы корреспонденты. 1983 елдан Татарстан китап нәшриятында: 1994 елдан баш мөхәррир. Әсәрләре 1962 елдан матбугатта басылып килә. "Ышаныч" (1980) дип исемләнгән беренче җыентыгында замандашларының бай рухи дөньясын чагылдыра. "Кояшлы яңгыр" (1983), "Каен балкышы" (1985) китапларында төп тема — авыл һәм аның кешеләре. 1990 еллардан Ә. шигырьләрендә татар халкының рухи традицияләрен, туган телебезне, мәдәниятебезне саклап калу мотивлары көчәйде. Бу темалар "рухи торгынлык", шәхеснең бөтенлеге, аның күңел дөньясы кебек проблемалар белән тыгыз бәйләнгән. Ә. иҗатында гади генә шигырь юллары бай метафоралар, романтик күтәренкелек реаль картиналар белән үрелеп бирелә: ("Таң суы", 1987; "Төнге кояшлар", 1989 һ.б.). Заман җилләренә йөзләрен куйган, тирән фәлсәфи эчтәлекле, бай образлы поэмалары һәм балладалары белән Ә. үз иҗатында сикереш ясады һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Соңгы елларда басылып чыккан "Сабыр савытлары" (1992), "Намаз" (1995), "Җәяүле буран" (1996) "Ут аркылы сикерү" (2004), "Йөз яктысы" (2005) җыентыклары шагыйрьнең иҗади үсеш нәтиҗәләре. Шигырьләре рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителде; кайберләре көйгә салынды.

Әд.: Зөлфәт. Тыелгысыз көч сере // Казан утлары. 1996. № 8; Әхмәтҗанов М. Нәселемнең мин бер тәрәзәсе... // Мәдәни җомга. 1996. 5 июль; Вәли Р. Гомерләрнең өйлә туры җиткән... // Шәһри Казан. 1996. 23 авг.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ТӘРҖЕМӘДӘ БЕРЕНЧЕ ТӘҖРИБӘЛӘР

XX гасыр башында татар әдәбияты үсешендә яңа агымнар барлыкка килә. Яңалыкның берсе—традицион Шәрык культурасының Гареб әдәби традицияләре белән кушылуы. Бу синтез татар әдәбиятына рус әдәбияты аша килеп керә. Публицистика, фәлсәфә, идеология, фән һәм әдәбият белән беррәттән, татар әдәбиятын баетуда мөһим бер фактор булып, Көнбатыш әдипләре әсәрләренең тәрҗемәләре тора. Билгеле ки, XX гасыр башына рус тәрҗемә мәктәбе югары биеклеккә күтәрелә, тәрҗемә теориясе камилләшә һәм әдәбиятның аерым бер жанрына әйләнеп бара. Татар әдәбиятында тәрҗемә өлкәсендә беренче адымнар ясалса да, аның кайбер шактый камил үрнәкләре белән дә очрашабыз: бу—Шекспир, Ж. Ж. Руссо, В. Гюго, К. Дойль, Д. Г. Байрон, Г. Гейне һ. б. көнбатыш әдәбият классикларыннан татар теленә тәрҗемәләр.

Көнбатыш әдәбияты шедеврларын XX гасыр башында татар халкына житкерүдә алдынгы урынны татар шагыйре, публицист, киң эрудицияле, тирән белемле тәрҗемәче Сәгыйт Сүнчәләй алып тора. Арадашчы ролен уйнаган рус вариантлары аша ул В. Гюго, Байрон, Г. Гейненың кайбер әсәрләрен тәрҗемә итә. Бездә ул тәрҗемәләрдән иң уңышлы килеп чыкканы, Генрих Гейненың "Әлмансуры" зур кызыксыну уятты. Бу әсәр тәрҗемәсе хакында ул заман татар интеллигенциясе арасында каршылыклы фикерләр йөрсә дә, "Әлмансур" Сүнчәләйнең иң уңышлы, күләмле һәм саллы тәрҗемәләреннән.

Сүнчәләйнең "Әлмансуры" аз өйрәнелгән, аның турында Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Мәһдиевнең публицистик мәкаләләрендә әйтелеп китә, шулай ук аның тәрҗемәләре Э. Нигъмәтуллин, З. Рәмиев һәм Р. Мусабековаларның кандидатлык диссертациясендә, фәнни-популяр басмаларында, фәнни мәкаләләрендә берникадәр яктыртылган...

Г. Гейненың "Әлмансур" трагедиясенә күз салыйк. Ул мөселманнарның урта гасыр Испаниясенең Реконсиста заманнары (католик инквизициянең мөселманнарга каршы сугышы) хакында бәян итә. Шул вакыттагы испанияле гарәпләрнең Испаниядән качулары, илдә калырга теләгәннәренең христиан диненә күчүләре, вөждан газаплары, гореф-гадәтләрне югалту турында сөйли. Һәм бу каршылыклы фонда төп персонажлар—бер-берсенә гашыйк Сәлимә һәм Әлмансур, аларның туганнары һәм дуслары—Әндәлес гарәпләре.

Әсәрнең сюжеты һәм кайбер тәрҗемә аспектлары хакында экскурс Р. Мусабекованың "Мәйдан" журналында чыккан фәнни мәкаләсендә ясалган иде. Без исә Сүнчәләй ясаган кайбер тәрҗемә ялгышлары, төгәлсезлекләргә һәм уңышлы урыннарга игътибарны юнәлттек. Бу ялгышларга үз заманында Фатыйх Сәйфи-Казанлы "Аң" журналының 1914 елгы саннарында игътибар итә. Безнеңчә, Сүнчәләйнең тәрҗемәсендәге төгәлсезлекләрнең сәбәбе берничә: Гейненың иҗатын тирәнтен белмәү, Реконсиста заманы Испаниясенең тарихы һәм мәдәнияте белән житәрлек дәрәҗәдә таныш булмау, тәрҗемә өлкәсендә житәрлек тәҗрибәсе булмау, "миллиләштерим" дип әсәрнең асылына зыян итү. "Әлмансурның" тәрҗемә нечкәлекләрен тикшергәндә, рус варианты белән чагыштырып анализ ясалды. Бу тикшерүнең кайбер нәтиҗәләрен алдагы мисалларда карап үтик.

Әсәрнең русчасында Педрильоның сүзләре болай яңгырый: "Клянусь Пилатом!" Сүнчәләйнең тәрҗемәсендә исә: "Ант әгәр дә—инде "ахшам" бетте!" Понтий Пилат—тарихи шәхес монда төшереп калдырылган.

Төп персонаж Әлмансурның католик чиркәүдә вакытындагы сүзләре:

*То распинали на кресте и острым*
*Копьем пронзали ребра—кровь и кровь*
*Лилась повсюду...*

*Тут голос я пронзительный услышал:*
*"Се кровь его"—и, оглянувшись, вижу...*
*Из чаши пьет какой-то человек.*

Сүнчәләй исә:

*Бер табакка—монда куйганнар аның канлы башын.*
*Һәркая баксаң да шул ир кайгылы, һәр сында кан!*

Күрәбез ки, "канлы баш" тәрҗемәдә каян пәйда булган, билгесез. Гейне "Гайсә каны" турында сөйли, христиан динендәге символ. Мәгънәгә зыян килгән.

Шулай ук теманы дәвам итсәк, Әлмансурның сөйгәне Сәлимә бер күренештә болай ди:

*"Чын мәхәббәт" тә мәгарәнең эчендә генә ятып,*
*Җирдә бер көлтә салам өстендә—әүвәл—башлана!*

Кем ул "чын мәхәббәт", аңлашылып бетми, Гейнеда исә сүз Гайсә пәйгамбәрнең могҗизалы тууы хакында бара.

Моңа өстәп, Сүнчәләй татарга аңлашылмаган көнбатыш мәдәнияте, тарихы һәм христиан дине белән бәйле образларны төшереп калдыра: Голгофа, орган, арфа, тост, вино, Яго Компостельский, Гименей, мирта һ. б. Ләкин ни сәбәпледер, тәрҗемәче Шәрык әдәбиятына караган образларны текстка кертми, мәсәлән: сады у Аль-Рашида, Шираза розы, кайбер географик атамалар. Ялгышып күп урыннарда испаниялеләрне "вәхши мөшрикләр" дип тәрҗемә итә.

Гейненың: "И карканье болотных птиц" дигәнен "Тик киек кошлар улавы" дип тәрҗемә итеп, мәгънәви хата ясый. Тәрҗемә татарча яңгырамый. Янә бер җирдә: "Аның тамырларын корт чукыштырган". Корт кимерә, йә ашый, ләкин чукымый, тәрҗемәче стилистик хата ясый.

Кайбер кимчелекләргә карамастан, Сүнчәләй рус текстын, асылына зарар китермичә, татар җанына, милли рухка якынайта ("адаптацияли"), андый очракларда аның "милли итәргә тырыштым" дигән сүзләре бик тә хаклы. Аларны тексттагы кайбер мисалларда аңлатып китик.

Әлмансур дусты Хәсәнгә болай ди. Гейнеда ул:

*Я мусульманин, несмотря на платье,*
*Я свой тюрбан ношу с собою в сердце.*

Сүнчәләй бу юлларны бераз үзгә тәрҗемә итә, аның варианты милли рухка якынырак. "Тюрбан" (чалманы) ул һәр татар-мөселманга якын, изге булган Коръән образы белән алмаштыра:

*Күпме мөшрикчә киенсәм дә—рәсүлнең сүзләрен,*
*Изге Коръәнемне, иманымны күңелдә йөртәмен!*

Алда янә бер уңышлы тәрҗемә. Төп персонаж Сәлимә әнисе хакында Гейнеда болай диелә:

*О мать моя, Фатима, до конца*
*Любила ты несчастное дитя!*

Сүнчәләйдә исә Сәлимә әнисен "Аллаһның өе"—мөселман Кәгъбәсенә тиңли:

*Йа миһербанлы ана! Син Кәгъбә, син изге идең!*
*Үз кызыңны син, Сәлимәңне сөйдең, мәңге сөйдең...*

Алдагы күренешләрнең берсендә без янә кызыклы юллар белән очрашабыз, Гейне Үлем фәрештәсенең тышкы сурәтен бирә:

*Но бледный ангел смерти*
*Пресек своим пылающим мечом*
*Абдуллы жизнь, а с ней и речь Абдуллы.*

Сүнчәләй яңадан безнең татар кешесенә аңлаешлы гыйбарәләр куллана: "Газраил! Алды жанын. Йомды гомергә күзләрен...". Тәрҗемәче мөселман мифологиясенә мөрәҗәгать итеп, "ангел смерти" образын Газраил фәрештә образы белән тулыландыра.

Трагедиядә Тень—"шәүлә" образы бар, Гейне тарафыннан тудырылган нейтраль образ. Ул яшь гашыйкларга бу кяферләр иленнән качарга куша һәм киләчәк матур тормышларын, бәхет илен сурәтли:

*Ул газиз илдә халык шат; анда пакь, саф һәр күңел;*
*Анда кичләрдә исә тәмле чәчәк—гөл исле җил;*

*Эсседә хөрмә агач ташлый күләгә җиргә гел.*
*Анда салкын чишмәләр зикер әйтәләр...*

Беренчедән, Гейне да, Сүнчәләй дә мөселман менталитетының бер гүзәл үзенчәлеген сурәтлиләр—һәр мөселман гомере буе җирдәге тормышын җәннәткә охшатып тәзисе килә, шуның өчендер Шәрык әдәбиятында бу киң таралган алым, чөнки ышәүнен һәр мизгелендә мөселман Аллаһны сизә, аның барлыгын аңлый. Тәрҗемәче гаҗәеп матур җанландыру кертә: "Чишмәләр зикер әйтәләр"—мондый юллардан Сүнчәләйнен оста, тәҗрибәле шагыйрь һәм урыны белән нечкә сиземләүче тәрҗемәче икәнлеге ачык күренә.

Алда Сүнчәләйнен тәрҗемәче интуициясенен бер гүзәл мисалы. Гейне җәннәт һәм җәһәннәм турында сөйли:

*Вот этот узкий мостик*
*Ведет из края скорби в край блаженства.*

Сүнчәләй бу юлларны татар укучысына тагын да аңлашылырлык итә:

*Сират күперем минем бу! Бу күпер*
*Аркылы михнәтле дөньядан рәхәт якка күчәм!*

Татарга бик тә якын ислам мифологиясенен бер мистик символы. Сүнчәләй мәгънәгә зыян китермичә, дөрес тәрҗемә биргән.

Гейнеда Әлмансурның мондый сүзләре бар:

*Обрежь орлу могучих два крыла,*
*И он, как червь, падет во прах на землю.*

Гейнеда "симург" ("сәмруг кошы") берничә тапкыр очрый. Гейне аны "орел" ("бөркет") сурәтендә бирә, симург—"сәмруг"—евразия мифологиясендә илаһи кош, җиргә күктән тормыш агачын индерүче кош формасында очрый. Күрәсен, Сүнчәләй Гейненың идеясен отып алып, "симург"ка, "орел"га, татар мифологиясендә дә булган сәмруг кошын туры китергән, бу—тәрҗемә иткәндә текстны татар теленә дөрес интерпретацияләүнең бер мисалы: "көчле сәмругның канатларын суырып...".

Трагедиядә (Гейнеда һәм Сүнчәләйдә дә) гашыйкларның диалоглары классик Шәрык поэзиясе традицияләрендә язылган. Урыны-урыны белән, татар шагыйре Гейненың чагыштыруларына, татар колагына ягымлырак яңгыраган сурәтләр таба.

*Меджнун я бедный, на скале сижу я*
*И забавляюсь с козочкой моей.*
*Ведь козочкой обернулась Лейла...*

Сүнчәләйнен Әлмансуры Сәлимәгә "җаным", "былбылым" дип эндәшә. Мисаллардан күренгәнчә, Сүнчәләйнен, гомумән алганда, шигъри һәм тәрҗемәче осталыгы ачык күренә, кимчелекләр дә очрый, чөнки тәрҗемә бервакытта да тулысынча тәңгәл була алмый. Тәрҗемәче оригинал текстны сүзгә-сүз күчерми, ә бәлки үз заманы, үз телендә, татар кешесе өчен яңа әсәр иҗат итә. Моңа өстәп, тәрҗемә вакытында яңа текстның тууына тәрҗемәченең үз шәхесе, дөньяны үзенчә күзаллавы килеп кушыла. Шулай ук, "Әлмансур"ның тәрҗемәсе аша без яңа әсәр туганны, Гарәп һәм Шәрык менталитетларының синтезын (кушылуын) күрә алабыз. Гейненың Европа кешесе булып мөселман дөньясын күзаллавын һәм татар-мөселман кешесенең—С. Сүнчәләйнең текстны "миллиләштерү"ен чагыштыра алабыз.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Европа классиклары тәрҗемәләре аша татар теленә яңа жанрлар килеп керә (трагедия, комедия, фантастика һ. б.), яңа стильләр (романтизм, символизм, дини, гыйсьянчылык мотивларына бай шигърият—Байрон, Гейне, Гете әсәрләре йогынтысында), реализм тууына этәргеч ясый, рус һәм Европа әдәбиятында камилләшкән әдәби алымнарның байтагы аңлы яки аңсыз рәвештә татар әдәбият дөньясына үтеп керә һәм тиз арада тәэсирен дә ясый.

**Нияз НӘГЫЙМОВ,**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, Әдәбият һәм Сәнгать институты аспиранты*

**Өмәр Өзҗан**

Төркия җөмһүрияте мәгариф министрлыгының укыту, тәрбия бирү советы әгъзасы.

# ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРАЛЫ ТУРЫНДА КАЗАНДА ЧЫККАН ЯҢА БАСМА

Патша хөкүмәте изүе астында яшәп, мәдәни геноцидка дучар ителгән төрки халыкларның фикер офыкларын киңәйтүгә зур көч салган, ул офыкларны үзенең мәгърифәт эшчәнлеге белән ачкан, үстергән Исмәгыйль бәк Гаспралы турында төрки дөньяның төрле почмакларында вакытлы матбугатта мәкаләләр бастыру һәм китаплар нәшер итү кебек нәтиҗәле бер эшчәнлек дәвам иттерелә.

Үзбәкстанда азатлык игълан ителгәннән соң беренче елларда ук җәдитчелек турында хезмәтләр язуны һәм бастырып чыгаруны башлап җибәрүчеләрдән булган галим Бегали Касыймов, "Төрек (төрки.—С. К.) фикерләренең йолдызлары" сериясендә И. Гаспралы турында бер җыентык нәшер итеп, бу бөек мәгърифәтче һәм журналистны үзбәк халкына таныту юлында күп көч куйды. 1944 елда Сталин тарафыннан ватаннарыннан сөрелгән кырым татарларының зур бер өлеше Урта Азиядә яшәгәнлектән һәм үзләре чыгарган "Йолдыз" журналы аша милләттәшләрен үз араларыннан чыккан зыялылар белән даими таныштырып торганга, әлеге тема җәмгыять фикере өчен ят түгел иде.

Совет системасы эчендә урын алган төрки өлкәләрдә Гаспралы турындагы материалларның иң күп нәшер ителүе—Татарстанда. Татарстан дәүләт архивының рәсми органы булган "Гасырлар авазы" журналында бу шәхес турында оригиналь документларга нигезләнгән мәкаләләр бастырылды. Шушы хезмәтләр белән бергә, яңа басма буларак, Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Фәридә ханым Гаффарованың "Исмәгыйль бәк Гаспринский" исемле хезмәте—мәкаләләр җыентыгы басылып чыкты *(Ф. Ю. Гаффарова. Исмәгыйль бәк Гаспринский.—Казан:—ТФАнең Тарих институты нәшрияты.—2004)*. Бер ел элек чыккан күренекле татар зыялыларының биографияләре бирелгән "Татар зыялылары" дигән мәкаләләр җыентыгында да Гаспралы турында язма бар *(Татар зыялылары. Тарихи портретлар.—Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2003, 56-63 бб.)*.

Моннан ике ел элек "Кырым" журналында (Төркия, Анкара.—С. К.) ике мәкаләсе басылган тарих фәннәре кандидаты Ф. Гаффарованың гыйльми эшчәнлеге, гомумән, XIX гасыр ахыры белән XX гасырның беренче чирегендәге татар милли Янарыш хәрәкәтен, аеруча сәяси һәм мәдәни, милли хәрәкәтнең лидерлары бертуган Һади һәм Садри Максудиларның эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган. Автор XX гасыр башында татар халкы биргән бөек шәхесләрдән Россиянең II, III Дәүләт думаларында милләтвәкил *(депутат.—С. К.)*, Эчке Русия төрек-татарларының милли-мәдәни азатлык хәрәкәте башлыгы, сәясәтчесе, дәүләт эшлеклесе булган Садри Максуди турында "XX гасыр башы татар халкы тарихында Садри Максуди" дигән темага кандидатлык диссертациясе яклавы белән мәгълүм иде. Аннан Фәридә ханымның "Садри Максуди" дигән монографиясе дә нәшер ителде *(Ф.Ю. Гаффарова. Садри Максуди.—Казан, 2001.)*. Ф. Гаффарованың дөнья күргән беренче хезмәте дә С. Максуди эшчәнлегенә багышланган *(Фәридә Гаффарова. Мин милләтемнең баласымын.—Казан: "Иман" нәшрияты, 1997)*.

Ф. Гаффарова, үзгәртеп кору чоры башланганнан соң, һәр ел саен Төркиягә барып, Истанбул һәм Анкарада мөһаҗирлектә яшәгән һәм шунда гомерләрен тәмамлаган сәясәтчеләрнең һәм гыйлем ияләренең якыннарында таркалган, тузган хәлдә сакланып калган архив материалларын өйрәнә, документлар эзли,

китапханәләрдә эшли. Әле хәзерге вакытта да ул Садри Максудиның оныгында сакланган архивын җентекләп тикшерүен, яна материаллар җыюын дәвам итә.

Бүген исә Фәридә ханым Садри Максудиның абыйсы—татар халкының мәгариф, матбугат тормышында зур роль уйнаган, мөһим урын тоткан галим, педагог, журналист, дәүләт эшлеклесе Әхмәдһади Максуди турында хезмәт яза. Һ. Максудиның Казанда яшәүче кызы Бәхрәмия Сәйфуллина һәм Мәскәүдә яшәүче оныгы Рөстәм Максудов шушы арада гына Һ. Максудиның үзләрендә сакланып калган архивын Ф. Гаффаровага бүләк иткәннәр. Галим булачак монографиясенең кечкенә бер өлешен, Һ. Максудиның 1920 елда туган кызы Бәхрәмия апа үзе исән-сау чагында атасы турындагы беренче хезмәтне укый-күрә алсын, дигән уй белән нәшер иткән иде инде *(Ф. Ю. Гаффарова. Әхмәдһади Максуди.—Казан, 2002.—Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты басмасы).* Ф. Гаффарованың Һ. Максуди эшчәнлеген яктырткан мәкаләсе югарыда әйтелгән мәкаләләр җыентыгына да урнаштырылган *("Татар зыялылары", 130-136 бб.).*

2001 елның март аенда Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институтында И. Гаспралының тууына 150 ел тулу мөнәсәбәте белән халыкара гыйльми конференция үткәрелә. Ф. Гаффарова, шушы конференция унае белән, Идел-Урал өлкәсендә нәшер ителгән "Сөембикә", "Шура", "Мәктәп" журналларында һәм "Йолдыз", "Кояш", "Ил" газеталарында Исмәгыйль бәк Гаспралы вафаты хакында 1914 елның октябрь, ноябрь айларында басылган мәкаләләрне җыеп, бер сайланма җыентык туплаган. Әлеге сайланма җыентыкка XX гасырның 30 нчы елларында Г. Исхакый тарафыннан Берлинда нәшер ителгән "Яңа милли юл" журналыннан шул темага бәйле материаллар да кертелгән. Милләте өчен яшәп, бөек эшләр башкарган бөекләр хакындагы хезмәтнең кирәклегенә ышанып, бу басманы төзегән һәм бастырып чыгарган Фәридә ханымның әлеге китабы үзе дә зур бер хезмәт булып тора. Бу китап Казанда мөһим ачыш буларак кабул ителмәскә дә мөмкин, чөнки җыентыкка кергән мәкаләләр басылган гәзит-журналларның Казандагы архивларда тулы коллекцияләре бар. Әмма шуны әйтергә кирәк: менә кадәр әлеге басмаларның Төркиядә туплам булып җыйналмаганлыгы сәбәпле, фән кешеләре, үзләренә кирәк булганда, бу мәгълүматларны табар өчен зур көч һәм күп вакыт сарыф итеп кенә ирешә алалар иде.

"Исмәгыйль бәк Гаспринский" җыентыгы татар вакытлы матбугатында язмалары белән танылган фикер ияләренең Гаспралы турындагы уйлануларын, бу бөек шәхескә һәм аның төрки халыкларга күрсәткән хезмәтенә бирелгән бәяләмәләрен бездәге (Төркиядәге) хезмәтләр белән чагыштыру мөмкинлеген дә тудыра. Җыентыкка мәкаләләре кергән фикер ияләре, Гаспралы нәшер иткән "Тәрҗеман" газетасының барлык төрки халыклар дөньясы өчен башкарган әһәмиятен аңлап, бу газетаның сакланып калынырга һәм алга таба да чыгып торырга тиешлеге турында уртак фикергә килгәннәр. Гаспралы турында үз фикерләрен язган авторлар, фикер иясе булып кына калмаганнар, укучыларының хиссиятен дә чагылдырганнар. Китаптан Һ. Максуди, Ф. Туктаров, Й. Акчура, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Биги, С. Максуди, Г. Буби, Г. Баттал-Таймас, Р. Фәхретдин, Н. Гасрый, С. Гыйффәт кебек язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе буларак танылган исемнәр бар. Сонарак бу затларның зур бер өлеше, Россиядәге советлар диктатурасыннан качып, Төркиягә китәргә мәҗбүр була. Бер өлеше юкка чыгарыла, илдә калганнары исә гомерләрен саклар өчен гыйльми, иҗади каләмнәрен ташларга мәҗбүр була.

Советларның таркалуыннан соң төрки дөньяның төрле почмакларында Гаспралы турында хезмәтләр язуга зур игътибар бирелә башлады. Аның артык озын булмаган гомеренең бик кыска гына кисәгендә төрки халыклар өчен башкарган зур эшләре турындагы хезмәт Казанда монарчы юк иде. Мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеге белән зур мирас калдырган И. Гаспралының хезмәтләре Казанда күп еллар буе тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән тема булып кала килде. Менә шул киң кырның эченнән алып, бер җыентык әзерләп чыгарган Фәридә Гаффарованы тәбрик итәбез. Аның әле башка хезмәтләре дә дөнья күрергә тора. Бу ниятләр дә тормышка ашар дип өмет итәбез.

*"Кырым" журналы, 2004 ел, ноябрь саны.*
*Төрекчәдән Сылу Камалова тәрҗемә итте.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*1974 елның май аенда Татарстан язучыларының VIII съезды булып узды. 24 май көнне алынган рәсем. Сулдан уңга—Илдар Юзеев, Рафаэль Мостафин, Диас Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Марс Шабаев, Аяз Гыйлаҗев, Фәнил Мансуров, Нил Юзиев, Әбрар Кәримуллин.*



*Укучылар белән очрашудан соң. Язучы Габдулла Шәрәфетдинов кунаклар кенәгәсенә кул куя. Уңда—Гомәр Бәширов, уртада—Гәрәй Рәхим. Үткән гасырның 80 нче еллары.*



*Кымыз эчү файдалырак та, күңеллерәк тә. Нәкый Исәнбәт һәм башкорт язучысы Сәгыйть Агиш. 1967 ел.*



*Казаннан килгән бер төркем язучылар, галимнәр, мәдәният хезмәткәрләре Риза Фәхретдин музеенда. Әлмәт районының Кичүчат авылы. 2000 ел.*



*Кинорежиссер Харис Фәхретдинов һәм шагыйрь Марс Шабаев. Актаныш. 1978 ел.*



*Шагыйрь Шәүкәт Гадельша (уртада) каләмдәшләре—Газинур Морат һәм Рафис Корбан белән үзенең якташлары янында. Түбән Әлкәсе. 2003 ел.*

*Юмор-сатира*

# Марат Закир

ХИКӘЯЛӘР

## КИҢӘШ

Шәһәр көне җитеп килә иде. Туган көнен бәйрәм итәргә әзерләнүче борынгы калада исә инде өч атнадан бирле күбекләнеп-коеп яңгыр ява.

Ява да ява...

Олы хуҗа җыелыш җыйды.

—Шәһәр көненә зур кунаклар чакырылган. Ямыйсын—ямап, буйыйсын буяп кына куйган идек—бөтенесен дә каһәр суккыры шушы янгыр ялап бетергән. Нишләтәбез бу яңгырны?—диде ул.

Озын-озак кына киңәшкәннең соңында, ниһаять, бер акыллыбашы— баш киңәшче самолет яллап, шәһәр өстендәге болытларны пыр туздырып куып таратырга тәкъдим итте һәм бу фикер һәммәсе тарафыннан да җөпләнде.

Шулай иттереп, биш миллионга төшереп, болытларны тәмам пыран-заран китерделәр.

Шәһәр көне матур үтте.

Ә менә шуннан соң... Инде менә шуннан соң калада чиллә хакимлеге урнашты! Күз башларында бик тә сирәк була торган искитмәле эссе чиллә иде бу!

Олы хуҗа янә җыелыш җыйды. Уртанчы киңәшче шәһәр өстенә самолет белән болыт куып китерергә киңәш итте.

Шулай иттереп, калада тагын яңгыр ява башлады. Бер көн яуды, ике көн, атна, атна ярым... Ун миллионга "чакырып" китерелгән кунак болыт исә көннән-көн әрсезләнә, азына гына барды сиңайтим!

Өч атна буена яуса да, яңгыр җәнабләре һич кенә дә туктарга уйламый. Нишләргә? Олы хуҗа янә җыелыш җыйды. Хәер, җыелышта кечтеки киңәшченең нинди киңәш бирәчәген ул инде болай да бик яхшы белә иде...

## СЕБЕРКЕГӘ САП КИРӘК...

Каланы чүп-чар басты. Кем гаепле? Бу сорауга җавап табуны кала хакиме үзенең урынбасарларына йөкләде. Болар рәисне, аның егерме сигез урынбасарын һәм дә әле генә эшли башлаган бер яшь белгечне дә кертеп, утыз кешелек комиссия төзеделәр. Гаепләне табу исә, әлбәттә инде, иң яшь белгечкә тапшырылды.

Тиз арада исемен җисеменә туры китерергә ант иткән Хаким атлы бу яшь белгеч шундук җиң сызганып эшкә дә керешә. Каланы чүп баскан икән, димәк, кем гаепле? Урам вә ишегалды себерүчеләр, әлбәттә! Һәм шулай булып чыкты да бит әй, рәхмәт төшкере! Әмма себерүчеләрнең дә җавабы әзер иде:

—Рәхәтләнеп себерер идек тә, себерергә себерке саплары юк шул!

Нишләмәк кирәк, Хаким ары таба китте. Ягъни торак-коммуналь хуҗалыгына!

—Каланы чүп баскан! Җыештырырга себерке кирәк! Ә себеркегә сап юк! Кем гаепле?—дип, егет үгезне мөгезеннән алды.

Болары исә:

—Урман хужалыгы белән безнең килешү төзелгән! Директорлары Сәлим Мәсәгутебич гаепле! Шуннан сорагыз!—дип, ярып салдылар.

Инде яшь белгеч урман хужалыгы башлыгын эзләргә керeште. Тик таба гына алмады. Кара диңгез буенда үсә торган урман белән танышырга киткән икән директор. Шулай да, анын урынына вакытлыча калып торган бер агай кем янына, кайсы тарафка барасын тәгаен төшендереп бирде.

Инде Хаким урманга юл тотты. Урман эченнән шактый гына бара торгач, бер алан күренде, трактор тавышы да ишетелгәндәй тоела. Әһә, булды болай булгач! Әмма... Алан уртасындагы киселгән агач төбендә берәү, каен себеркесен мендәр итеп кочаклап, тирә-юньне де-р-р селкетеп гырлый-гырлый йокы симертә иде. Менә сина трактор! Ялыктыргыч кояшның дымга сусаган нурлары таралышып яткан буш шешәләрне ялаштыра иде...

—Менә кем гаепле икән бит, яп-птыр-р малахай!—дип сүгенеп куйды егет.

Агач төбеннән карлыккан тавыш ишетелде:

—Мин гаепле түгел!

—Кем гаепле соң алайса?!

—Х-хатын!—диде сәрхүш тотлыгып, бер күзен яртылаш ачып, күккә ымлады... —Хатын гаепле! Мәсәгутебичкә ияреп Кара диңгез буена очкан! Йөри шунда себерелеп, себерке тәре! Менә шуна үч итеп ятам әле...

## МӘХӘББӘТ СЕРИАЛЫ

Әле моннан өч ай элек кенә өйләнешкән яшь гаиләдә тавыш чыкты. Әнә шул хәерсез Тавыш хөртиҗанәпләре сабыр кошы дип аталган һичбер гаепсез гаилә күгәрчененең каурыйларын берәм-берәм йолкырга керeште дә инде.

—Китәм! Бүген үк чыгып китәм!

—Жә, ни булды инде? Тагын ни житми сина?

—Ни булды, имеш... Ашарга да пешерә белмисен!

—Жә-жә...

—Туйдым! Жә дә жә, жә дә жә... Болай буласын белгән булсам!

—Әйткән ие аны әни...

—Мина да әйткәннәрие дә...

—Шуннан?

—Шуннан шул менә: туйдым. Аңлыйсыңмы син, юкмы—туй-дым! Токмач та—бәрәңге, бәрәнге дә—токмач... Көн саен шул бер нәрсә. Пилмән ашыйсым килә!

—Сон, ярар, иртәгә алырбыз.

—Кибет пилмәне түгел, өй пилмәне ашыйсым килә минем. Ит пәрәмәче белән гөбәдиянен, өчпочмакның инде тәмен дә хәтерләмим!

—Ярар сон, иртәгә өчпочмак пешерермен алайса.

—Синен барыбер әни пешергән шикелле килеп чыкмый ул...

—Сон, жаныкаем, әле өйләнешкәнгә өч кенә ай лабаса. Өйрәнермен. Үзең дә булышырыен бераз.

—Мин эштән арып кайтам.

—Ә кем арып кайтмый? Әле менә кайткач та бер генә дә тик торган юк. Ә син, диванга кырын ятып, йә телевизор карыйсын, йә китап укыйсын...

...Шулай диде дә яшь ир Әмир, яшь хатыны берүк сикереп торып кызып китә күрмәсен дип, ашыгып кына аш бүлмәсенә савыт-саба юарга чыгып китте.

Рәмзия исә, укый торган китабын ябып куеп, телевизорны кабызды. Анда "Тигез мәхәббәт" сериалы башланып килә иде.

## *Котлыйбыз!*

Каләмдәшебез Кожевникова (Баубәкова) Роза Хәби кызын чираттагы гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез.

*Шып-шыксыз, кап-кара төннәрдә*
*Сырхаулап ятканда өйдә мин,*
*Әнием тибрәтте бишекне:*
*"Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим"*

Рус телендә иҗат итүче шагыйрәнең "Дога" дигән җырыннан бу (Л. Лерон тәрҗемәсе, Я. Гарипов көе). Шушы җырны ССР Союзының Колонналы залында башкарып, "Болгар" ансамбле эстрада җырларының Бөтенсоюз конкурсында лауреат булды. Э. Розали исә "Азия тавышы" халыкара конкурсында уңыш казанды.



Р. Кожевникова 1950 елның 19 декабрендә Әстерхан өлкәсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, комсомол путевкасы белән Түбән Камага килә, йөрәк җылысын кушып кирпеч йортлар сала. Аннан Казан университетына укырга керә. Өч курс укыгач, Мәскәүдә Әдәбият институтында укый башлый. Аны тәмамлагач (1977), Казанда күп тиражлы газеталарда һәм Татарстан телевидениесендә эшли.

Р. Кожевникова "Идел" журналын иң беренче саннарыннан алып чыгарышкан кеше, 1991 елдан баш мөхәррирнең русча басма буенча урынбасары. Аның дүрт шигъри җыентыгы дөнья күрде: "Миләш тәлгәше" ("Гроздь рябины", 1985), "Ике тавыш" ("Два голоса", 1990), Кышкы яңгыр" ("Зимний дождик", 1994), "Таң сызыгы" ("Меж светом и тьмой", 2000). Х. Туфан, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин һ. б. шагыйрьләрнең күп кенә поэтик әсәрләре рус телендә аның тәрҗемәсендә дөнья күрде.

Р. Кожевникова — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М. Горький исемендәге әдәби премия лауреаты.

Шагыйрәгә яңа иҗат уңышлары телибез!

---

## "Казан утлары" 2006 елда

**Мәгълүм ки, киләсе ел—олы әдәби юбилейлар елы. Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек корифейларыбыз тууга—120, "Моабит дәфтәрләре" циклы һәм каһарманлыгы белән дөньякүләм танылган М. Җәлилнең тууына 100 ел тула. Бу уңайдан журналда төрле-төрле материаллар мул итеп биреләчәк.**

**Редакция папкасында әдәби әсәрләр дә күп тупланды.**

**Чәчмә әсәрләрдән, мисал өчен, Ф. Садриевның ("Бәхетсезләр бәхете", III кисәк), Ф. Әмәкнең "Шәүлә" романнары, М. Әмирханов ("И, кылган догам минем"), М. Кәбиров ("Чиксез табут"), Зәки Зәйнуллин ("Мәүлет гусар") повестьлары.**

**Шагыйрьләребездән Ш. Галиев, Р. Харис, З. Мансуров, Р. Миңнуллин, Зөлфәт, М. Әгъләм, М. Мирза, Л. Шагыйрҗан, Роб. Әхмәтҗанов һ. б. шагыйрьләрнең тезмә шигырь-поэмалары дөнья күрер.**

**Фәнни һәм публицистик әсәрләрдән М. Госмановның Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев һәм Рәшат Гайнанов турындагы истәлекләре, Адлер Тимергалинның "Әлифба, имля, фәнни истилях" дигән эше, Разил Вәлиевнең Равил Фәхретдинов белән әңгәмәсе, Ф. Хуҗинның "Алабугага нигә яшь?" дигән мәкаләсе һ. б. укучыларыбыз күңеленә хуш килер дип ышанабыз.**

**2006 елның 2нче саны, әлбәттә, журналыбызның 1000нче саны — бәйрәм саны буларак чыгар.**

*Безнең календарь*

## Газиз Иделленең тууына 100 ел

Газиз Иделле (Габделгазиз Сәлах улы Усманов) 1905 елның 26 декабрендә Әстерхан шәһәренең Тияк бистәсендә эшче гаиләсендә туа. Башлангыч белемне "Дарелтәхсил" мәдрәсәсендә ала. Аннары ике еллык рус-татар мәктәбендә укый. Үзенең хезмәт юлын яшүсмер вакытында ук башлый.

1921—1923 елларда ул Әстерхан өязендә авыл Советы секретаре булып эшли. 1923 елда Свердловск индустриаль техникумына укырга керә. Аны тәмамлап бетермичә, "Сабан һәм чүкеч" газетасы редакциясенә эшкә урнаша. Шушы газета битләрендә, шулай ук сатирик "Шәпи агай" журналында аның мәкаләләре, очерк һәм фельетоннары даими басыла. 1926—1929 елларда Г. Иделле Казанда Тат. ЦИК аппаратында эшли, 1930 елга кадәр "Безнең юл" журналының секретаре була.

1930 елда аның "Пумала башлар" исемле беренче хикәяләр җыентыгы, ә бер елдан Мәскәүдә "Икмәк һәм хатын" исемле икенче китабы басылып чыга.

1930—1940 елларда Г. Иделле Совет Армиясендә хезмәт итә, армия матбугатында эшли, дивизия газетасы редакторы була. 1936 елда ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш белән барган "Дәүләт Бәдриев" драмасын яза. Армиядән соң Г. Иделле "Кызыл Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасы редакциясенең бүлек мөдире, аннары "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналы редакторы, соңрак Татарстан радиокомитетының баш редакторы вазыйфаларын башкара.

Сугыш елларында язучы 1 нче Украина фронты газетасында эшли, күпсанлы мәкаләләр, хикәя һәм очерклар яза. Фронтта ул киң танылган "Очрашу", "Күпер" хикәяләрен, Советлар Союзы Герое Г. Нигъмәтуллин һәм генерал Нагайбеков турындагы зур күләмле очеркларын иҗат итә, 1 нче Украина Фронты татар сугышчылары турындагы "Җиңү юлы" җыентыгын төзүдә катнаша.

1949—1957 елларда Г. Иделле Татарстан Язучылар берлегенең консультанты булып эшли.

1959 елда аның "Тормышка мәхәббәт", 1965 елда—"Язучы һәм аның китабы", 1967дә—"Ул көннәр", 1975тә—"Күргәннәрем, белгәннәрем" китаплары дөнья күрә. Г. Иделленең зур бер төркем татар язучыларының Идел, Кавказ, Кырым буйлап ясаган сәяхәте турындагы "Беренче зур сәяхәт" дигән күләмле очеркы "Казан утлары" журналында басылып, укучылар тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителә, 1980 елда аерым китап булып та басылып чыга. Язучы публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли. Ул яңа чыккан китаплар, театр сәхнәләрендә куелган спектакльләр турында көндәлек матбугатта тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре белән даими катнашып килә.

Г. Иделле әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. А. Фадеевның "Тар-мар", П. Павленконың "Бәхет" романнарын, В. Лаврентьевның "Ата хакы—тәңре хакы" драмаларын һ. б. татар теленә тәрҗемә итә.

Газиз Иделле 1985 елның 27 июлендә Казан шәһәрендә вафат булды.

*

# 2005 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында. №3

2005 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №6

"Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән мактаулы исем бирү турында №7

"Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән мактаулы исем бирү турында №12

## МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Латыйфи Ф. Юбилей уңае илә уйланулар. №1

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әхмәтова Д. Тәтә. Повесть. №11

Бәдри Р. Ярыктагы кояш. Шук повесть. №10

Бәйрәмова Ф. Караболак. Роман. №№11, 12

Габделхакова Р. Зинһар, югалма. Повесть. №10

Галиуллин Т. Мәкер. Повесть. №7

Гаффар Ә. Хикәяләр.№5

Имамов В. Казан дастаны. Тарихи роман. №№8-10

Имамов М. Сугышның мәрхәмәтсез йөзе. Фронт язмалары. №5

Кәримов К. Мин әнигә бик кирәк!.. Хикәя. №6

Маликова М. Чәчкә балы. Повесть. №№1,2

Маннапов Ш. Янгыннан калган баганалар. Хикәятләр. №5

Мирхәйдәров Р. Иманыңнан бер язсаң. Роман. №№6,7

Нәбиуллина И. Миләш тәме. Повесть. №8

Рахман Р. Чикерткә. Хикәя. №7

Сәлах Ә. Көт син мине... Повесть. №1

Фәизов Р. Мәскәүле. Хикәя. №2

Хуҗин М. Айның уты сүнгән. Хикәя. №5

Яхин Ф. Бакыр бозау артыннан. Хикәя. №12

## ШИГЪРИЯТ

Әгъләм М. Шигырь дигән утлы күмердән. Шигырьләр. №2

Әхмәдиев Н. Безнең дөнья. Шигырьләр. №10

Әхмәтҗан Р. Садә авазлар. Шигырьләр. №4

Әхтәмова Г. Галәм, дөнья, тормыш мәгънәләре. Шигырьләр. №7

Бабич Ш. Халкым өчен. Шигырь. №1

Бәдигый Х. Яран гөл. Шигырьләр. №6

Бәйрәмова Г. Безгә язган һаман сагынырга... Шигырьләр. №9

Вәли Н. Җил чәчәге. Шигырьләр. №11

Вәли Р. Татар географиясе. Шигырьләр. №8

Вәлиева Р. Җиңү килгән көн. Шигырьләр. №5

Габдерәхим Ф. Учак хакындагы кыйсса. Шигырьләр. №5

Гаделша Ш. Туган якта – ук атканда. Шигырьләр. №6

Гадел Ә. Саба җилләренә йөрәк ачам. Шигырьләр. №5

Газизова Л. Шигырьләр. №11

Галиев М. Дөньямның көйле гаме. Шигырьләр. №11

Гарифуллина Р. Ак сарайда серләр бар. Поэма. №10

Гариф Р. Сөйләде җилләр. Шигырьләр. №6

Гаташ Р. Шигырь. №3

Гыйззәтуллина Ф. Озата барам гомер кояшымны... Шигырьләр. №12

Гыйләҗев И. Кыйбла якка тәрәз уям. Шигырьләр. №2

Җиһангирова Ш. Кояш белән серләшү. Шигырьләр. №11

Зөлфәт. Яшәп түгел, очып үткәндә. Шигырьләр. №1

Зыятдинова Ф. Иң зур сөю. Шигырьләр. №9

Иделбикә. Дөнья авазлары. Шигырьләр. №12

Идиятуллин Р. Хәтәр хәбәр китерә җилләр. Шигырьләр. №9

Исхаков Ә. И гомер агышлары. №8

Казан турында шагыйрьләребез. Шигырьләр. №8

Маликов Ә. Сугыш кичкән иргә таян. Шигырьләр. №5

Мансуров З. Чыраг тоткан хәтер йөри. Шигырьләр. №1

Мингалим Р. Безне ватып ага вакыт. Шигырьләр. №4

Мирза М. Яктыртмакчы булсаң халык күңелен. Шигырьләр. №1

Миңнуллин Р. Яңа шигырьләр.№7

Мөдәррисова Х. Күзнең нурлы нәкыше. Шигырьләр. №10

Низами Р. Бер могҗиза миңа елмая. Шигырьләр. №1

Рәхимова Б. Күңел игүчеләр. Шигырьләр. №6

Рәшит Ә. Казан. Поэма. №8

Сабиров И. Уй ярында, уел буенда... Шигырьләр. №7

Сафина Н. Күкләр тора – елап, көлеп, күкрәп. Шигырьләр. №3

Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №3

Хәлим А. Алтмышынчы еллар – яңа сулыш. Шигырьләр. №12.

Шагыйрьҗан Л. Галәмнәрне урап кайткан кеше сыман. Шигырьләр. №6

Шәрифуллина Э. Ай йөзендә алтын алка. Шигырьләр. №11

Янсуар Л. Офыкларга таба йөгерәмен. Шигырьләр. №7

Яруллин Ф. Җан хөрлеге. Шигырьләр. №2

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Гали М. Пожарныйлар. Хикәя. №7

Сәйфи-Казанлы Ф. Крушниклар. №2

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Миңнуллин Т. Тәнзиләкәй. Драматик хикәя. №9

Хәким З. Телсез күке. Ике пәрдәле драма. №4

## ПУБЛИЦИСТИКА

Безне санадылар (Рәфикъ Юнысның БТК башкарма комитеты рәисе урынбасары Дамир Исхаков белән әңгәмәсе). №7

Борһанов Ә. Россияне танып белү. №3

Борһанов Ә. Ясалма дәүләт, ялган кыйммәтләр, тамырсыз халык һ. б. турында. №12

Зарипов М. "Татнефть"нең бензин чишмәсе. №9

Мириханов Н. Хезмәт тәме яки шәҗәрә җебе. №6

Мушинский Ә. "Авызың кыек булса..." №5

Татарның иле кайда? (Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров белән язучы Марсель Галиев әңгәмәсе). №8

Таһиров И. Татар дәүләти халык ул. №8

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Галиева Г. Шагыйрь, публицист. №1

Галиуллин Т. Бизмәндә—шигъри роман. №11

Заһидуллина Д. Татар прозасында яңа романтизм. №6

Мансуров З. Чичәннәр кайтавазын кемнәр көчәйтә. №9

Урманче Ф. Шигъри осталык серләре. №12

Фәйзуллин Р. "Чикле чиксезлек". №2

## ДИСКУССИЯ "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"

Акмал Н. Әллә каян әзләп йөрисе юк... №8

Бәшир Ф. Сүз кадере. №10

Гайсин Х. Гамәлен күрә әмәле. №3

Дәүләтшина Л. Киләчәккә күз төбәп. №9

Зарипов Р. Төрле-төрле уйласак та... №7

Мирзануров З. Тозсызны күзсез дә күрә. №12

Мостафин Р. Төгәл булыйк! №5

Хафизов С. Кайда безнең рыцарьлар? №4

Хәбипова З. Фәлсәфә җитми безгә. №11

Хәлим А. Сез беләмсез кая барганны? №1,2

Шәмсутова А. "Тарих таный—иҗатына җаннарын салганнарны..." №6

Шәрифуллин Н. Үзебезне саклыйк! №11

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XV КОРЫЛТАЕН КАРШЫЛАП

Галимуллин Ф. Илһамлы хезмәт нәтиҗәләре. №5

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XV КОРЫЛТАЕ

Вәли М. Тәкъдимнәр. №9

Газизова Л. Рус язучылары иҗаты. №9

Галиуллин Т. Шигърият моңнары. №9

Гыйморанова Д. Сәхнәбездәниләр бар? №9

Дәүләтов З. Адымнарыбыз нык әле. №9

Закирҗанов Ә. Җанлану сизелә. №9

Заһидуллина Д. Ике корылтай арасында татар прозасы. №9

Имамов В. Без кем өчен язабыз? №9

Корбан Р. Заманга йөз белән. №9

Миңлебаев К. Тәрҗемә—сәнгать ул. №9

Рәхим Г. Язучы да ярдәмгә мохтаҗ. №9

Фәйзуллин Р. Киләчәк өчен эшләргә тиешбез. №9

Хәлим А. Көрәштән читтә калып. №9

Шакиров Д. Китап гаме—олы гамь. №9

## ФӘН

Әмирхан Р. Татар матбугаты үткән юл. №11

Зәйнуллин Җ. Телләре төрки, диннәре яһүди. №8

Мәрданов Р. "Бу китап хан догасы берлә тәмам". №7

Михайлова С., Циунчук Р. Башкалабыз Казан.№12

Мусин Ф. Әдәбият тарихын яңача өйрәнү. №7

Нәгыймов Н. Тәрҗемәдә беренче тәҗрибәләр. №12

Өзҗан Ө. Исмәгыйль Гаспралы турында Казанда чыккан яңа басма. №12

Тимергалин А. Милли казаныш. №3

Тимергалин А. Миллият сүзлеге. №№1-12

## ТАРИХ

Гариф Н. Борынгы Чаллы шәһәрлеге бәклек үзәге булганмы? №1

Зәйнуллин З. Бар шундый бер авыл. №2

Мөхәммәтшин Р. Ишми ишан капкасы. №6

Насыйров Т. Октябрь һәм эзәрлекләнгән татар матбугаты. №10

Таиров Н. Фабрикант Акчуриннар һәм татар әдәбияты. №5

Усманов В. Эстәрлебаш "фантал"лары. №2

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ—ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ар-Серги В. Бу—борынгы һәм мәңгелек дөнья. Шигырьләр. №7

Шестинский О. Татар изүе татлы. Хикәя. №4

Шукшин В. Бүреләр. Хикәя. №7

## СӘНГАТЬ

Абдуллин М. Уйна, дустым, гармуныңны! №2

Гобәйдуллина Г. Җыр-моң белән үрелгән гомер. №11

Монасыйпов Ш. Яңарыш чишмәләре (музыкант Ильяс Әүхадиевнең тууына һәм Казан музыка училищесы оешуга 100 ел). №1

## ХӘТЕР

Әхмәтҗан М. Михаил Львов: кем ул? №2
Гыйләҗева Н. Газизебез бар иде. №4
Гыйззәтуллин Н. Әмирхан ага ядкаре. №1
Дәүләтов З. Соңгы көннәр хатирәсе. №7
Ихсанова Л. Бу хатлар – заман көзгесе. №6
Ийбар Т. "Себердән Сәрәндипкә" әсәреннән өзек. №11
Тогач Х. "Бер буынның драмасы" әсәреннән өзек. №12
Шаһин Л. Төрек әсирләренең истәлекләре. №11

## ЮБИЛЕЙЛАР

МУСА АКЪЕГЕТЗАДӘНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Миңнегулов Х. Егетлек күрсәткән Акъегет. №1

ШАКИР МӨХӘММӘДЕВНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Закирҗанов Ә. "Заманыбыз тәрәккыят заманыдыр..." №5

СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Вәлиулла И. Шагыйрьнең җан эзләнүе. №2
Зарипова-Четин Ч. Тормыш газаплары. №2

ӘБРАР СӘГЫЙДИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Закир М. Давыллы дәвер шагыйре. №4

ИСМӘГЫЙЛЬ РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гамбәр Н. Әдәбият хадиме. № 2

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гыйззәтов К. Халык тормышын язды. №9

ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВАНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гаташ Р. Искә алыйк Гыйффәт туташларны. №10

САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Батмаска туган Баттал. №8

АБДУЛЛА ӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Латыйпов Ф. Балачак хатирәсе. № 3

ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Закир М. Туган як һәм әдип кадере. №1

НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Баян Н. Өч бөркет. Шигырь. №5

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

№12

ӘХМӘТ ИСХАКНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Исхак Ә. Хакыйкать төсе. Шигырь. №5

САФА САБИРОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Кәримов К. Иске йорт аксакалы. №7

ГАЛИ ХАЛИТНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Тугрылык. №6

ӘБРАР КӘРИМУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Һадиев И., Асылкаева Н. Татар фәне тарихында эзе тирән. №6
Кәримуллин Ә. Татар басма китабы тарихы сәхифәләреннән. №6

ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Нәҗипова Ә. Хәзинә тапкан әдип. №9

ИЛБАРИС НАДИРОВКА 80 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Шигъри җанлы галим. №4
Надиров И. Игелекле эшнең иртә-киче юк. №4

МӘГЪСУМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Детектив остасы. №10

МӘҖИТ РАФИКОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Вәли-Барҗылы М. Якты һәм җылы бөркелә... №4

ГУРИЙ ТАВЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Хуҗин М. Сары яфраклар коелганда. №12
Тавлин Г. Үги ана. Хикәя. №12

ӘДХӘТ СИНУГЫЛНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Гатауллин Р. Сәйях шагыйрьнең сәяр гомере. №3

ХӘНИФ ХӨСНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Үзгә бер тыйнаклык хас иде. №3

ЭДУАРД МОСТАФИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

№2

ФӘЙЗИ ГАЛИЕВКА 80 ЯШЬ

Җир улы. №7

ВАХИТ ЮНЫСКА 75 ЯШЬ

Хәбибуллин М. Татар җанлы мәскәүле. №11

МАНСУР ХӘСӘНОВКА 75 ЯШЬ

Фидакарьлек. №6

МӘГЪСУМ ХУҖИНГА 75 ЯШЬ

Латыйфи Ф. Хикәя остасы. №5

МӘРЗИЯ ФӘЙЗУЛЛИНАГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №6

ФӘРИТ ХАТИПОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

ӘНӘС ХӘСӘНОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №6

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Сверигин Р. Кеше үзе җавап бирә... №5

ҖӘМИТ РӘХИМОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әхмәдиев Н. Нефть бишегендә туган әдип. №2

ИЛЬАМ ШАКИРОВКА 70 ЯШЬ

Халкыбызның милли хәзинәсе. №2

МӘГЪСУМ ГӘРӘЕВКӘ 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №3

МӘДИНӘ МАЛИКОВАГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

НАИП ЛАИСОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНГА 70 ЯШЬ

Галиев М. Гомер учагы. №4

ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

"Таяныч ул – халык..." (шагыйрь Равил Фәйзуллинның драматург Туфан Миңнуллин белән әңгәмәсе). №9

Миңнуллин Т. Робагыйлар. №9

МАНСУР ШИҺАПОВКА 65 ЯШЬ

Хәмидуллин Л. Купкырлы иҗат иясе. №5

ӘНӘС ИСХАКОВКА 60 ЯШЬ

Хәбибуллин М. Җыр ул – җан азыгы. №8

ҖӘУДӘТ ДӘРЗАМАНГА 60 ЯШЬ

Гыйльманов Г. Самими шагыйрь. №10

Дәрзаман Җ. Шигырьләр. №10

ҖӘУДӘТ СӨЛӘЙМАНГА 50 ЯШЬ

Латыйфи Ф. Шагыйрь күңеле дәрьядыр. №3

Сөләйман. Өзелгәнем, җирдә эзләгәнем. Шигырьләр. №3

РАФИС ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. №3

КИТАП КҮЗӘТҮ

Бәшир Ф. Галиҗәнап шигырь – хәзрәти шагыйрь. №5

Вәли Р. Башкала серләрен ача. №10

Вәли-Барҗылы М. Чын хикәяләр. №6

Гарипова Х. Күңел күзе ни күрә? №7

ҖИҢҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Бикташев Ә. Соңарган сәфәр. №1

Саттаров М. Окопташ дусларымның берсе. Документаль повесть. №3

Шамова Ә. Газета битләрендә фронт сәхифәләре. №5

ЯҢА ИСЕМНӘР

Миннеханова Н. Бәйрәм иртәсе. Шигырьләр. №3

Садыйков М. Яңгырлы җәй. Парчалар. №11

Суфиянов А. Өмет калыр. Шигырьләр. №4

Тангалычев К. Тел белгән сихри биләүдә. Шигырьләр. №4

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Закир М. Хикәяләр. №12

Мәннан Р. Үртәмешләр. №2

Нәҗмиев Т. Саба мәзәкләре. №4

Нәҗмиев Т. Мәзәк хәлләр. №11

Хәмзин А. Үтте гомерләр. Хикәяләр. Парчалар. №1

БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Ренат Гаффар. №1

Розалина Шаһиева. №2

Әлфәт Закирҗанов. №4

Рәис Гыймадиев. №5

Әнвәр Хәйри. №6

Дания Заһидуллина. №7

Дания Гыймранова. №8

Хөсәен Вәлиәхмәтов. №9

Рөстәм Зарипов. №11

МӘСЬӘЛӘГӘ БЕР КАРАШ

Вәлиев Ф. Энциклопедик "Эт борчагы". №6

"Татар энциклопедиясе" битләреннән. №№4-12

Сабирҗанов Г. Асылларның асылы. №4

Мең санның бер чаткысы. №№11, 12

Латин имлясында уку күнекмәләре. №№2,3,4,7,8

Укучы сүзе. №№7, 11

Хатлардан юллар. №№2, 3, 4, 5

Бер сорауга – бер җавап. №9

"Казан утлары" архивыннан. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12



Ictimaği-mədəni
tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни
тормышыбыздан

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### И.Р. Метшинны Татарстан Республикасы Казан шәһәре администрациясе башлыгы итеп билгеләү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 9, 94 статьялары, "Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" 2002 елның 19 апрелендәге Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында" Татарстан Республикасы Законының 57 статьясы нигезендә Метшин Илсур Рәис улын Татарстан Республикасы Казан шәһәре администрациясе башлыгы итеп билгеләргә.

Татарстан
Республикасы
Президенты М. Ш. ШӘЙМИЕВ

Казан, Кремль
2005 ел, 17 ноябрь N УП-445

**Метшин Илсур Рәис** улы 1969 елның 24 апрелендә Татарстан АССРның Түбән Кама шәһәрендә туган. Казан дәүләт университетын тәмамлап хокук белгече һөнәрен алган, юридик фәннәр кандидаты.

Университетны тәмамлаганнан соң 1992 елда юридик факультетның көндезге аспирантурасында укуын дәвам итә. 1993 елдан 1997 елга кадәр Казан шәһәре Совет районы администрациясендә—торакны хосусыйлаштыру агентлыгы мөдире, администрация аппараты житәкчесе булып эшли. 1997—1998 елларда Казан шәһәре Вахитов районы администрациясе башлыгының беренче урынбасары—"Казан посады" территориясе префекты. 1998 елдан—Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре администрациясе башлыгы. 2005 елның ноябрендә "Түбән Кама муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башлыгы итеп сайлана.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

РФ Федераль Жыенының Федерация Советы тарафыннан оештырылган бу чара Татарстанның һәрьяктан да күпләргә үрнәк булуын тагын бер тапкыр күрсәтте. Ул башкалабыз Казанның 1000 еллыгына багышлап уздырылды. Тантаналарда Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин житәкчелегендәге рәсми делегация катнашты.

Татарстан көннәре узган 25-26 октябрьдә Федерация Советында "Россия төбәкләренең үсеш стратегиясе: тәжрибә һәм перспективалар" дигән "түгәрәк өстәл" эшләде, Казанның 1000 еллыгына багышланган күргәзмә оештырылды. "Түгәрәк өстәл"дә Федерация Советы Рәисе С. Миронов чыгыш ясады. Ул: "Россия үзенең төбәкләре белән көчле",—диде һәм моңа Татарстанны үрнәк итеп китерде.

Мәскәүдәге чаралар уңаеннан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин РФ Федерация Советы Рәисе С. Миронов, Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызлов, аның урынбасарлары О. Морозов һәм А. Чилингаров белән очрашты. "Түгәрәк өстәл"дә ТР Премьер- министрының беренче урынбасары—икътисад һәм сәнәгать министры Б. Павлов, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хужалыгы министры М. Хөснуллин да чыгыш ясады.

## КАЛӘМ ИЯЛӘРЕНӘ—ИСТӘЛЕКЛЕ МЕДАЛЬЛӘР

Казанның "Тимерхан" мәдәни-күңел ачу комплексында республикабызның газета-журналлары, телерадиокомпанияләре, мәгълүмат агентлыклары вәкилләрен, Россия үзәк басмаларының хәбәрчеләрен, "Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгы хезмәткәрләрен "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медале белән бүләкләү тантанасы булды. Бүләкләрне Татарстан Президенты аппараты житәкчесе Ю. Камалтынов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, Министрлар Кабинеты Рәисе урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, "Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры М. Моратов, Президент аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге житәкчесе А. Терентьев тапшырды.

"Пирамида" мәдәни-күңел ачу комп-

лексында да шуна охшаш тантана үткәрелде. Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева бертөркем язучыларга "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" һәм "М. А. Шолоховның 100 еллыгына" медальләрен тапшырды.

## ПРЕЗИДЕНТТА ОЧРАШУЛАР

***

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимовны кабул итте. Очрашу барышында киләсе елда Муса Җәлилнең тууына 100 ел һәм Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган чараларны үткәрү мәсьәләләре буенча фикер алышу булды.

Бүген ТР Язучылар берлегендә 306 каләм әһеле бар. Республика Язучылар берлеге—Россиядә ин зур иҗат оешмаларының берсе. Язучылар берлеге татар халкының рухи мирасын һәм әдәбиятын пропагандалау, яшь талантларның һөнәри осталыгын камилләштерү, язучыларның иҗат һәм көнкүреш шартларын яхшырту белән шөгыльләнә, төрле иҗат оешмалары белән үзара элемтәләрне үстерә. Берлектә проза, поэзия, әдәби тәнкыйть, балалар әдәбияты, иҗади тәрҗемә һәм рус әдәбияты остаханәләре эшләп килә.

Очрашу барышында Язучылар берлеге җитәкчесе Президентка бүген Татарстан язучыларының нинди шартларда эшләве, китапларының нинди тиражлар белән басылып чыгуы, аларга күпме гонорар түләнүе турында да мәгълүмат ирештерде.

***

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Россия Фәннәр академиясе академигы, шушы академиянең физика-технология институты фәнни җитәкчесе, физика-математика фәннәре докторы Камил Вәлиев белән очрашты. Президент резиденциясендә узган әлеге очрашуда академикның хатыны—татар һәм немец телләреннән тәрҗемәләр авторы Венера Вәлиева да катнашты. Алар "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медале белән бүләкләнделәр.

Президент белән әңгәмә ТР Фәннәр академиясе язмышы турында барды. "Минтимер Шәрипович Татарстан Фәннәр академиясенең ролен югары бәяли һәм аның үсеше өчен ярдәм итәргә әзер",—дип билгеләп үтте академик.

Президент белән очрашуда бөек Тукай шигърияте төп темаларның берсе булган. Аерым алганда, 2006 елда шагыйрьнең тууына 120 ел тулуны зурлап бәйрәм итү мәсьәләсе буенча фикер алышынган. Венера Вәлиеваның Габдулла Тукай әсәрләрен рус теленә тәрҗемәләрен югары бәяләп, Илбашы шагыйрьнең барлык әсәрләрен дә тәрҗемә итүне бурыч итеп куйган.

## КОНСУЛЛЫК БИНАСЫ АЧЫЛДЫ

Президент Минтимер Шәймиев һәм Төркия Республикасының Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Куртулуш Ташкент Төркия Республикасының Казандагы Генераль консуллыгы бинасын ачу тантанасында катнаштылар.

Тантанада катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, Татарстан җитәкчесе бу вакыйганың ике тугандаш халыкның якынаюы юлында мөһим этап икәнен һәм моның җәмгыятебездәге үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә мөмкин булуын билгеләп үтте. "Төркия җитәкчелеге, бер тамырдан булуыбызны искә алып, тарихи элемтәләребезнең яңаруына мөмкинлек ачты, бу безнең генә түгел, ә бәлки бар төрки дөньяга кагылышлы проблемаларны чишәргә мөмкинлек бирә",—диде Президент М. Шәймиев.

## "КҮКТАУ" ПРИЗ АЛДЫ

5-11 сентябрьдә Казанда мөселман фильмнарының "Алтын мөнбәр" фестивале булып узды.

Ниһаять, аның нәтиҗәләре дә билгеле булды. Шунысы аеруча куанычлы: зур призларның берсе Татарстанда калды. Ул— ин яхшы ир-ат роле өчен" номинациясе бүләге—режиссер Илдар Ягъфәровның "Күктау" фильмындагы роле өчен Фәрит Бикчәнтәевкә бирелде. "Алтын мөнбәр"нең берсенә "Изге Мәрьям" исемле Иран фильмында төп рольне уйнаган актриса Мәрьям Раззавия лаек булды. Таҗикстан киночылары төшергән "Сукбай" фильмының режиссерлары Гөләндәм Мөхәббәтова белән Дамир Рәхмәтов исә Татарстан Президентының махсус призына лаек булдылар. Анимация фильмнары (мультфильмның бер төре) арасында Башкортстан режиссеры Елена Юшкова җинде ("Арыслан һәм Куян" фильмы өчен). Ә иң яхшы нәфис фильм дип Әзәрбәйҗаннан "Сихерче" фильмы (Актай Миркасыйм) табылды. Фестиваль барган көннәрдә Казанга атаклы режиссерлар Вадим Әбдрәшитов һәм Владимир Хотиненко, актерлар Анатолий Кузнецов, Сергей Шәкуров, Наталья Варлей, Елена Цыплакова, Владимир Ильин килеп киттеләр. Жюри әгъзасы Кирилл Разлогов фестивальнең дәвамлы булачагына ышана. Әгәр шулай була калса, фестиваль Татарстан киносы үсешенә нык этәргеч бирәчәк, дип саный ул.

## БӨЕКЛӘРНЕ ЯДЬ ИТҮ

Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының конференцияләр залында Казанның 1000 еллыгына багышлап "Төрек-татар мәдәни бәйләнешләре" дигән халыкара симпозиум үткәрелде.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Төрек теле җәмгыяте идарәсе, Истанбул университетының Төркия институты оештырган бу очрашу бөтен төрки халыклар мәдәниятендә хезмәт иткән күренекле татар эшлеклеләрен искә алу, ягъни аларның эшчәнлеген тәкъдир итү булды. Төркиядә яшәп, Истанбул һәм Анкара университетларында эшләгән, татар милләте өчен җан атып гомер иткән, аның мәдәниятен үстерүгә үзләреннән зур өлеш керткән мәшһүр милләттәшләребез Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Рәшид Рәхмәти Арат, Йосыф Акчура, Зәки Вәлиди Туган, Актәс Нимәт Курат, Адилә Максуди Айда, Абдулкадыйр Инан, Сәгадәт Шакир Чагатай, Әхмәт Тимер, Таһир Чагатай, Хәмит Зөбәер Кушай, Әхмәт Вәли Мәнгәр турында докладлар тыңлаганда аларның эшчәнлекләре тагын бер кабат барланды.

Әлеге халыкара симпозиумны үткәрү идеясе белән төрек галиме, филолог-лингвист, Истанбул университеты каршындагы Төркия институты директоры Осман Фикри Серткая чыккан булган. Ул үзе әлеге институтка нигез салучыларның берсе, төрек галиме Мехмед Фуад Көнрүлүзадә һәм танылган татар галиме, борынгы рун язма истәлекләрен бөртекләп җыеп өйрәнүче Рәшид Рәхмәти Арат традицияләрен дәвам итүче.

Симпозиум эшендә катнашу, алда санап үткән әлеге данлы милләттәшләребез хезмәтен барлап докладлар уку өчен Төркиядән 11 галим килгән иде. Алар арасында профессор-докторлар Осман Фикри Серткая үзе, Төрек теле җәмгыяте президенты Шүкрү Халүк Акалын, Хәмзә Зөлфикар, Абдулкадыйр Донук, ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Надыйр Дәүләт, Садри Максудиның оныгы, Анкарадагы Татар җәмгыяте президенты Гөнүл Пултар, Ришат Гәнч, Нәфәкъ Урал, Сади Бәйрәм, Кәмаль Эраслан, Түнҗәр Байкара, доцент Хакан Кырымлы бар иде.

Симпозиумда татар галимнәреннән Мирфатыйх Зәкиев, Фәһимә Хисамова, Хатыйп Миңнегулов, Флүн Мусин, Фәнүзә Нуриева, Дамир Исхаков, Фәридә Гаффарова, Зөфәр Рәмиев, Илбарис Надыйров чыгыш ясады.

Төрек галимнәре, гомумән, аны оештыручылар тырышлыгы белән уздырылган әлеге симпозиум чит илләрдә яшәгән күренекле татар галимнәре эшенә олы бәя булып яңгырады. Алар үзләре бирегә кайткандай булды. Алай гына да түгел, ике ил галимнәре иркенләп аралашты, төрекчә-татарча яңгыраган чыгышларны тәрҗемә итү өчен тылмач кирәк булмады. Киләчәктә симпозиумда яңгыраган чыгышлар белән танышу мөмкинлеге дә тудырылачак: докладлар татар һәм төрек телләрендә китап булып басылып чыгачак.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

***

Татарстан Язучылар берлеге моннан ун ел элек А. Алиш исемендәге премия булдырган иде. Ул премия балалар әдәбиятын үстерүгә, аны пропагандалауга зур өлеш керткән әдипләргә һәм коллективларга бирелә. Октябрь аенда быелгы лауреатлар ачыкланды. Алар—шагыйрьләр Энже Мөэминова, Әнәс Хәсәнов, коллективлардан—Татарстан китап нәшрияты һәм "Салават күпере" журналы. Октябрь уртасында республикада, шулай ук "Балалар китабы" атналыгы да үткәрелде. Атналыкны үткәрүдә Балалар әдәбияты остаханәсе (җитәкчесе—Рафис Корбан) зур эшчәнлек күрсәтте.

***

Язучылар берлегендә шигърият һәм тәнкыйть остаханәләренең берләштерелгән утырышы булды. Анда танылган шагыйрь Рәниф Шәриповның соңгы вакытларда иҗат ителгән ике әсәре—"Меңнән бер өлеш" һәм "Азатлык көне" поэмалары укып тикшерелде.

Рәниф Шәриповны шигърият сөючеләр "Тәрәзәдә ут", "Ян, учагым", "Күк һәм күңел йолдызлары", "Йорт иясе", "Мәңгелек сер" исемле шигырь китаплары аша белә. Монарчы да ул "Фатыйма мәхәббәте", "Алмагачлар сагышы", "Чокырча тавы" кебек поэмалар авторы буларак билгеле иде.

Танылган тәнкыйтьчеләр, шагыйрьләр, әдәбият галимнәре, Казан дәүләт университетының бер төркем студентлары катнашкан утырышта Рәниф Шәриповның әлеге поэмалары турында җитди сөйләшү булды. Фикер алышуларда Әхмәт Рәшит, Рабит Батулла, Флера Гыйззәтуллина, Факил Сафин, Әлфәт Закирҗанов, Илфак Ибраһимов, Мөдәррис Әгъләм, Рифә Рахман, Шәүкәт Гаделша, Газинур Морат, Дания Заһидуллина, Фәрит Бәшир, Нияз Акмал һ. б. катнашты.

Шигърият һәм тәнкыйть остаханәләре җитәкчеләре Зиннур Мансуров белән Мансур Вәлиев билгеләп үткәнчә, бу утырыш Рәниф Шәрипов поэмалары хакында гына түгел, ә бәлки поэма жанры, аның бүгенге көндәге торышы, әһәмияте, үзенчәлекләре турында эшлекле бер сөйләшү дә булды.

***

Казанда Татарстанның төрле төбәкләрендә эшләп килүче иҗат берләшмәләре һәм әдәби түгәрәкләр җитәкчеләренең республика семинары булып узды. Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган әлеге семинар урыннарда иҗади активлыкны арттыру, иҗат берләшмәләрнең эшчәнлеген тагын да җанландыру максатыннан үткәрелде.

Ижат берләшмәләре һәм әдәби түгәрәк житәкчеләре өч көн дәвамында әдәбият галимнәре, сәнгать белгечләре, язучылар белән аралашты, үзара тәҗрибә уртаклашты. Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов белдергәнчә, ижат берләшмәләренә ярдәм итү, аларны хокукый оешма буларак үстерүне Язучылар берлеге идарәсе күз унында тотачак.

### БАШКОРТСТАНДА ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Башкортстанда татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы Мәжит Гафуриның 125 еллыгы мөһим мәдәни-ижтимагый вакыйга рәвешендә билгеләп үтелде. Халык бәйрәменә әйләнгән тантаналар республика фәнни-гамәли конференциясе, үзешчән сәнгать көчләре бәйгесе, әдәби очрашулар рәвешендә уздырылды. Уфада һәм әдипнең туган авылы Жилем-Каранда М. Гафуриның музей-йортлары янадан ачылды. Казан дәүләт университеты профессоры Хатип Миннегуловның әлеге чараларда әйтелгән фикерләре зур кызыксыну белән кабул ителде.

М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры бинасында танылган әдипләр һәм сәнгать осталары катнашында үткәрелгән тантаналы кичәдә Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов, шулай ук Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы—"Мәгариф" Милли нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев чыгыш ясады. М. Вәлиев Башкортстан Президентына Казанда башкорт һәм татар телләрендә басылып чыккан "Мәхәббәтнамә" китабын бүләк итте. Илбашыбыз Минтимер Шәймиевнең кереш сүзе-сәламләве белән ачылган бу китапта ике тугандаш халык шагыйрьләренең ижатыннан иң күркәм үрнәкләр тупланган.

### ДУСЛАРЧА, ТУГАННАРЧА

Татарстан Дәүләт жыр һәм бию ансамбле 28 октябрьдә "УНИКС" тамаша залында үзенең 68 нче сезонын ачып җибәрде. Бу көнне кунакта Карелия Республикасы Дәүләт жыр һәм бию ансамбле "Кантеле" артистлары да бар иде. "Дуслык күпере" дип аталган әлеге концерт-тамаша танылган ике коллективның уртак бәйрәменә әверелде. Һәр ике коллектив үз программаларын Казанның 1000 еллыгына багышлаган иде.

Карелия ансамбленең исеме "Кантеле" карел һәм фин халыкларының борынгы музыка уен коралы исеменнән алынган, ә инде "Карелия халыкларының музыкасы, жырлары һәм биюләре" дип аталган концерт программасы ансамбльнең иң яхшы номерларыннан төзелгән.

Татарстан Дәүләт жыр һәм бию ансамбле сәхнәгә икенче бүлектә чыкты. "Казан турында риваять" дип аталган театраль тамаша, "Хужалар тавы", "Идел", "Сәхтиян читек" "Чүлмәкче" кебек жырлы һәм биюле композицияләр татар халкының тарихын IX—XI гасырлардан ук башлап чагылдыра, болгар бабаларыбыз рухын тормышын сурәтли.

Ансамбльнең сәнгать житәкчесе, Татарстанның халык артисты Айрат Хәмитов әйтүенчә, бер-берсен күптәннән яхшы белгән, икесе дә элеккеге Советлар Союзы һәм Россия күләмендә танылган, халыкара конкурсларда күп тапкырлар лауреат исемен алган бу коллективларның Татарстан жирендә очрашып, яңа концерт сезонын башлаулары ижади дуслыкның матур бер үрнәге булды.

### МӘШҺҮР ЖЫРЧЫ, ОЛПАТ ИР ЗАТ

13 ноябрьдә М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында опера сәнгате күгендә якты йолдыз булып балкыган, милли операның нигез ташларын салышкан, СССРның халык артисты Азат Аббасовны 80 яшьлеге уңаеннан тәбрикләү тантанасы үтте. Иң элек Премьер-министр урынбасары-мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярга Президент Минтимер Шәймиев юллаган котлау сүзләрен житкерде: "Сез республикабызның музыка сәнгате тарихында якты сәхифә буларак урын алдыгыз. Матур тавышыгыз, артистизм, югары башкару культурасы һәм эш сөючәнлек Сезгә М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында күп еллар буе нәтижәле хезмәт итәргә мөмкинлек бирде. Сезне Татарстаныбыздан гына түгел, аннан читтә дә таныйлар. Ижатыгыз өчен зур рәхмәт Сезгә. Сәламәт булып, тагын озак еллар шатланып яшәргә насыйп итсен..."

Казан мэры урынбасары Әлфия Тутаева Азат Аббасовка "Шәһәрнең шәрәфле гражданы" исемен раслаучы диплом тапшырды.

Юбилярны туган төбәге Алабугадан, ул укыган авиация техникумыннан, жырчы булып киткәнче эшләгән "Казан компрессормаш" акционерлык жәмгыятеннән, "Вертолет заводы" ачык акционерлар жәмгыятеннән килгән вәкилләр дә, танылган жырчыларыбыз да тәбрикләде.

### ТАНЫЛГАН АКТЕРГА ҺӘЙКӘЛ

Танылган рус драма актеры, Чехов исемендәге Мәскәү сәнгать театры актерлык мәктәбенә нигез салучыларның берсе Василий Качаловка аның исемен йөртүче Казан Зур рус драма театры атриумында һәйкәл ачылды. Василий Качаловка һәйкәл ачу тантанасына Чехов исемендәге Мәскәү сәнгать театрыннан делегация, актерның туган-тумачалары килде.

Тантанада ТР Премьер-министры

урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева чыгыш ясады, ул СССР халык артисты, Мәскәү сәнгать театры житәкчесе Олег Табаковның котлау телеграммасын халыкка житкерде.

### ШАГЫЙРӘНЕ ХӨРМӘТЛӘП

15 ноябрьдә Әтнә районы Күлле Киме урта мәктәбендә бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашында әдәби-музыкаль кичә үтте. Әлеге чара Лена Шагыйрьжанның 60 яшьлек юбилее уңаеннан оештырылды.

Тумышы белән Актаныш ягыннан булса да, шагыйрәнең балачак еллары Сибгат Хәким авылы—Күлле Киме белән бәйле. Аның беренче шигырьләре нәкъ менә мәктәптә укыган чорда район газетасында һәм "Пионер" (хәзерге "Ялкын") журналында басыла. Шигърияткә булган мәхәббәте аны соңрак Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә.

Туган мәктәбендә узган кичәдә шагыйрә хатирәләрен яңартты, якташларына шигырьләрен укыды. Соңыннан очрашу истәлеге итеп, ул туган мәктәбенә шәхси китапханәсеннән 300гә якын китап һәм "Казан утлары", "Мирас" журналларын бүләк итте.

Әтнә районында узган бу очрашуда Татарстан Язучылар берлегеннән Факил Сафин, Жәүдәт Дәрзаман, Рафис Корбан катнашты.

### БЕЗНЕҢ ДАНИЯ ШУНДЫЙ УЛ!

"Татмедия" агентлыгы бинасында күренекле радиожурналист, язучы Дания Гайнетдинованың рәсемнәр күргәзмәсе ачылды.

Аның туган як күренешләрен, меңьеллык Казаныбыз манзараларын чагылдырган пейзажларына, натюрмортларына якты төсләр, фон тирәнлеге, ритм үзенчәлеге хас. Даниянең ижат эшләре күргәзмәсе моңа кадәр Казанда, туган ягы Теләче төбәгендә, Түбән Новгородта, Мәскәүдә күрсәтелгән иде инде. Аның рәсемнәре Төмән, Новосибирск, шулай ук чит илләрдәге хосусый коллекцияләрдә саклана. Яна күргәзмәдә исә авторның 40 тан артык эше урын алган.

Күргәзмәне ачу тантанасында "Татмедия" генераль директоры Марат Моратов, "Чор портреты" төбәк фотография бәйгесен оештыру комитеты рәисе Рәйсә Сафиуллина, ТР Журналистлар берлеге рәисе урынбасары Юрий Ханжин, Дания ханымның остазы—Татарстанның халык рәссамы Рәшит Имашев, журналистлар, мәдәният һәм сәнгать әһелләре, рәссамның дуслары һәм якыннары катнашты.

### ХИКМӘТЛЕ ДИСКЛАР

Казан шәһәре китапханәләр берләшмәсе башкалабызның меңьеллыгына әзерлек уңаеннан зур эш башлап жибәреп, "И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!" дигән компакт-дисклар чыгарырга карешге. Шәһәр тарихына багышланган ул дисклар, ниһаять, дөнья күрде. Әлеге дискларда татар халкының йолалары, гореф-гадәтләре, сынлы һәм гамәли сәнгате турында шактый тулы мәгълүмат, шулай ук Казан тарихы турында байтак фактлар тупланган.

Күренекле язучыларыбыз ижатына да зур урын бирелгән аларда. Илдар Юзеев, Туфан Миннуллин, Равил Фәйзуллин, Роберт Миннуллин, Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм башка әдипләребезнең үзләре укуында яңа әсәрләр белән танышырга мөмкин. Әлеге дискта 700 мәкалә, 1100 иллюстрация урын алган. Музыкаль фон буларак күренекле композитор Рөстәм Яхин әсәрләре кулланылган.

Диск мәктәпләр, югары уку йортлары, шәһәребез халкы, башкалабыз кунаклары өчен кызыклы кулланма әсбаб булачак.

Дискларны үзләрендә булдырырга теләүчеләр түбәндәге адрес буенча мөрәжәгать итә алалар: Казан шәһәре, академик Кирпичников урамы, 14 йорт. Белешмәләр өчен телефон: 75-10-39.

* * *

2005 елның октябрь аенда Башкортстанда яшәп ижат иткән күренекле татар шагыйре **Шамил Гомәр улы Мәхмүдов** (Шамил Анак) вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы Казан. ***У. Абдуллов** эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Фәйрүзә Җамалетдинова**.

# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## "Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән мактаулы исем бирү турында



Татар милли әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш керткән югары художестволы әсәрләр иҗат иткән өчен язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе урынбасары **Миңнуллин Туфан Габдулла улы**на "Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән мактаулы исем бирергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

**М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

Казан, Кремль, 2005 ел, 21 ноябрь.
№ УП—453

Индекс 73210



Фәйрүзә Җамалетдинова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)